ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

6. 1998



# JAZUCЬLARЬBЬZ CIT ILLƏRDƏ



Rinat Mөxəmmədief, Aleksej Gagua, Jevgenij Jevtuşenko. Amerikada ədəbiat duslьƣь kөnnəre. Kalifornia. Peperdajn universitetь *(maj, 1992 jьl).*



Şaƣirlər Rawil Fəjzullin (Qazan) həm Rawil Boxarajef (London). Xalьqara PEN–klub kongressь kөnnəre. Şotlandiə. Val'ter Skott jəşəgən zamok baqcasьnda *(avgust, 1997 jьl).*

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1998

# 6

**(908)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Нажар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Клара БУЛАТОВА. Айлы кырда калган ялгыз ат... *Шигырьләр.* 5
Суфиян ПОВАРИСОВ. Күкнең җиденче катында. *Роман* 9
Газинур МОРАТ. Без кичәргә тиеш Иделне. *Шигырьләр* 66
Фәнзаман БАТТАЛ. Сатирик хикәяләр 71
Фәрит ЯХИН. Сагыну көне. *Шигырьләр* 85
Рифат ҖАМАЛ. Аңым белән җаным. *Шигырьләр* 88

РИФКАТЬ ЗАКИРОВКА 60 ЯШЬ

Рәдиф ГАТАШ. Авыл улы, шахтер, шагыйрь... 36
Рифкать ЗАКИРОВ. Кичке моң. *Шигырьләр* 37

ДРАМАТУРГИЯ

Туфан МИҢНУЛЛИН. Сөяркә. *Ике пәрдәле драматик хикәя* 45

ПУБЛИЦИСТИКА

Әгъдәс БОРҺАНОВ. Кем гаепле? Нәрсә эшләргә? 93

СӘНГАТЬ

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Театрыбызның әһәмияте хакында 112
Фәния ХУҖАХМӘТ. Гөлсем бәхетенең серләре 116

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Шакир МӨХӘММӘДЕВ. Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай 123

ФӘН

Равил ФӘХРЕТДИНОВ. Татар тарихы битләреннән 144
Профессор булу җиңелме? *(профессор Ф. Сафиуллина белән әңгәмә)* 164

ХӘТЕР

Зөфәр РӘМИЕВ. Тукайлар замандашы *(күренекле әдип Зариф Бәширинең тууына 110 ел тулу уңаеннан)* 153
Зариф БӘШИРИ. Ардаклым. *Шигырьләр* 157

Риф ХӘЙРЕТДИНОВ. Бормалы юллар (*Академик Рәфикъ Нәфигуллина 70 яшь*) 159
Шаһинур МОСТАФИН. Гомерлек дуслык(*Нур Гыйззәтуллинга 70 яшь*) 170

Наис ГАМБӘР. Авырту булып калды(*Фәннур Сафинның тууына 50 ел*) 172

КИТАП КҮЗӘТҮ

Руфия ХӘМИДУЛЛИНА. Кыргыйлыкка каршы 179
Латин имласында уку күнекмәләре 183
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": продолжение романа С. ПОВАРИСОВА "На седьмом небе"; сатирические рассказы Р. БАТТАЛА; стихи К. БУЛАТОВОЙ, Г. МУРАТА, Ф. ЯХИНА, Р. ДЖАМАЛА.
"К — 60 летию Р. Закирова": статья Р. ГАТАША "Сын деревни, шахтер, поэт..."; стихи юбиляра.
"Драматургия": драматический рассказ Т. МИННУЛЛИНА "Любовница".
"Публицистика": статья А. БУРГАНОВА "Кто виноват? Что делать?"
"Искусство": М. УСМАНОВ — "О проблемах современного татарского театра"; статья Ф. ХУЗАХМЕТОВА о творчестве артистки Гульсум Исангуловой.
"Из сокровищницы татарских рассказов": рассказ Ш. МУХАММЕДОВА "Японская война или доброволец Батыргали агай".
"Наука": Р. ФАХРУТДИНОВ — "Из страниц татарской истории"; беседа Ш. МУСТАФИНА с профессором КГУ Ф. Сафиуллиной.
"К 70 — летию академика Р. Нафикова": статья Р. ХАЙРУТДИНОВА "Нелегкий путь".
В номере отмечаются так же юбилеи ученого Н. ГИЗЗАТУЛЛИНА, поэта Ф. САФИНА.
"Книжное обозрение": Р. ХАМИДУЛЛИНА рецензирует книгу Н. Гиматдиновой.
"Навыки чтения на основе латинской графики".
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Ода древности" работа художника Зуфара Низаметдинова; писатель Фарит Яхин.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": the continuation of S. POVARISOV novel "In the 7 th sky". R. BATTAL'S satirical stories; the verses of K. BULATOVA, G. MURAT, F. YAKHIN, R. JAMAL.
"Commemorating the 60 th Anniversary of R. Zakirov": R. Gatash's article "The village-son, the miner, the poet..." ZAKIROV'S verses.
"Dramatics": T. MINNULLIN'S play "The mistress".
"Publicism": A. BURGANOV'S article "Who is guilty? What can do?"
"Art": M. Usmanov - "About modern problem of Tatar theatre", F. KHUZAKHMETOV'S article about artist Gulsum Isangulova's creative work.
"Science": R. FAKHRUTDINOV - "From the pages of Tatar history; the conversation of SH. MUSTAPHIN with professor of university F. Safiullina."
"Commemorating the 70 th Anniversary of academician R. Naphikov" R. KHAIRUTDINOV'S article "The winding way".
Jubilees: scientist N. Gizzatullin, poet F. Saphin.
Skill of reading on the base of Latin script.
The diary of social and cultural life.
In our covers: the work of artist NIZAMETDINOV, the writer F. Yakhin.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.05.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 14095. Заказ Я-244.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Клара Булатова

### АЙЛЫ КЫРДА КАЛГАН ЯЛГЫЗ АТ...

***

**Яшиселәр инде яшәлгән дә...**
**Яшәлеп тә әле бетмәгән.**
**Бу дөньяда инде безнең башка**
**Ниләр килеп ниләр китмәгән,**
**Безнең буын ниләр кичмәгән...**

**Илдә булды күпме кайнашулар,**
**Җиргә килде күпме афәтләр,**
**Ничә тапкыр тузды, тапталынды,**
**Кайтарылды гореф-гадәтләр.**

**Искеләре калкып яңардылар,**
**Яңалары тумый искерде —**
**Уңнан сулга, сулдан уңга бәрелү**
**Тинтерәтте байтак кешене.**

**Сәбәпләрне эзли, ача китсәң**
**Чәч агара, миләр кабара.**
**Бәя бирер өчен галим аңы,**
**Шагыйрь җаны җитми аңарга.**

**Кеше булып җирдә яшәгәндә**
**Безнең буын азмы кичерде?**
**Яшиселәр инде яшәлгән дә —**
**Яшисе дә бардыр шикелле...**

**Анысында инде адәмнәрең**
**Дога белсен, тәүбә китерсен,**
**Фани дөньяларда — калган гомер**
**Иман белән берүк үтелсен.**

***

Кайчакларда ял итәсем килә
Читкә китеп, качып, ялгызак.
Әллә нишләп төшләремә керә
Айлы кырда калган ялгыз ат.

Ул көтүдән аерылып киткән,
Әллә арып калган, бүленеп,
Әллә мин дә ара төштем микән
Үлчәү белми чабып, йөгереп?

Әллә мин дә мохтаҗ инде ялга?
Бер тукталыш әллә кирәкме?
"Кирәк," — ди дә акыл, әмма аңа
Буйсындырып булмый йөрәкне:

Анысы һаман яшь чактагы кебек
Тыелгысыз яши — ял ерак!
... Ник соң әле төшләремә кереп
Пошаманга сала ялгыз ат?

***

Ләкеләрдә чакта утлар яктым —
Казан аслап түгел, учаклап,
Урамнарга чыгар хәлләрем юк —
Керәшеннәр ала кочаклап.

Кочаклаплар күрешкәннәр саен
Искә төшә сабый чакларым.
Сабый чактан откан керәшен көен
Гомер буйларына сакладым.

Эчкерсезлек белән туган җырлар
Онытылмый икән ул бер дә,
Олы көнен, Торыйсын, Петрауларны
Покрауларны керттем шигырьгә,
Керәшеннәр үзен хөрмәт иткән
Кешеләрне зурлый беләләр,
Урамнарга чыгар хәлләрем юк,
Кочакларын җәеп киләләр.

Кунак ашы — кара каршы бит ул,
Шагыйрәсе бүген татарның
Керәшенне җырларында зурлый,
Үрнәге дип яхшы затларның.

Эчкерсезлек, хезмәт сөючәнлек
Керәшеннең асыл үрнәге —
Моңлы җанда мәкер, явызлык юк,
Җыр тулы бит аның йөрәге.

***

Тәрәзәгә киләм кабат-кабат,
Таянам да салкын тупсага,
Озак-озак торам юлга карап —
Әмма күпме карап торсам да
Теләгәнне анда күрә алмыйм,
Күрәселәр килгән — еракта.
Араларда еллар чакрымнарын
Үтеп чыга алмас юл ята.

***

Бер күрәсе килеп куйды сине:
Кем син хәзер? Кайда? Ничек син?
Өйләнгәнсең, балаларың үскән,
Оныкларың бар дип ишеттем.

Әле һаман укытасың диләр
Минзәләдә, әллә Казанда,
Минем өчен син Кәләйдә йөргән
Практикант егет һаман да.

Күтәрелеп карый алмый идең
Очрашканда кырда бергә-бер,
Тыйнак кына түгел, куркак идең,
Бәлки, тугрылыклы кемгәдер.

Андыйларны кызлар бик өнәми,
Кызлар сөя чутыр-чаяны,
Бер мин генә якын итә идем
Телсез-сүзсез юаш малайны.

Тик ул мине кабул итә алмады,
Курыктымы? Әллә йөрәге
Ятлар өчен ябык бик астында
Йөреттеме башка берәүне —
Без белмәдек.
    Әнә, олыгайгансың,
Оныкларың бар дип ишеттем,
Бер күрәсе килеп куйды сине,
Кем булдың син? Кайда? Ничек син?

***

Дәгъвалэмим ходай язмаганын,
Эзләп йөрмим чит-ят яклардан.
Ни бирелгән — бары шуны алдым,
Ни тиешле — шуны кайтарам.

Ходай язмаганын дәгъвалэмим,
Бирелгәне, шөкер, җитәрлек.
Тик ходаем гомер бирсен иде —
Бәхиллекләр җыеп китәрлек.

***

И, Ходаем!
Башта ярдәм күрсәт
Өен ташлап юлга чыкканга.
Ә аннан соң күрсәт ярдәмеңне
Гарип-гораәбәгә, мохтаҗга.
Аннан килеп, ярлы-ябагайга
Ярдәмеңне күрсәт дөньяда.
Шулардан соң инде... миһербанлык,
Ярдәмеңне күрсәт миңа да?!

***

Учлап түккән энҗеләр кебек
Уйлар, фикерләр кала түгелеп.
Түгелмәс иде — мунчала түгел,
Кулыңа каләм алсаң иң элек.

Алар кәгазьгә теркәлер иде,
Орлык җирлеккә бер төшәр иде.
Әйтер фикерең югалмас иде,
Җанныкы җанга ирешер иде.

Үтә гомерең тибенне күреп,
Үз сәндерәңнән бик түбән йөреп.
Уйлар-фикерләр кала түгелеп,
Учлаплар сипкән энҗеләр кебек.

Чәчелеп кала, — җыясы иде,
Кәгазьгә теркәп куясы иде...

***

Иксез-чиксез михнәт диңгезенең
Упкынына бүген юлыккан,
Ул диңгезнең Чатыр Кыясы мин;
Миңа сыен, миңа ышыклан.

Иксез-чиксез михнәт заманында
(Аермалы булып бүтәннән),
Ярдәм эзләп килсәң минем янга,
Юатырмын, читкә этәрмәм.

Бу тормышның Чатыр Кыясына
Инәлдеңме чыгып диңгездән,
Таянырдай терәк булыр сиңа —
Тик түләмә явыз сүз белән.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Суфиян
Поварисов

# КҮКНЕҢ ҖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

РОМАН

* * *

Барысы да тамакларына балык кылчыгы утыргандай сүзсез калганнар иде. Галимҗан чыгып киткәч тә әле ул дәвам итте. Аның нindидер кайгыга дучар булганлыгын төсе китүдән аңлап алдылар. Нурислам эшнең нидәлеген сөйләп биргәч, сүзсез катып тору һаман дәвам итте. Тынлыкны Сәрвәретдин-Зобани бозды:

— Байгошның оясын ходай кора, егетләр, борын салындырмыйк әле без.

Аның сүзләрен аңлап бетермәделәр:

— Галимҗанга монда яңа оя кирәкме?

— Аны Ходайдан өмет итикме?

— Ходай безгә аракыдан башканы бирми бит.

— Лутчы ул безгә җеп бишмәт бирсен.

— Башка — бүрек...

— Аякка — күнитек...

— Чем-ясау киенгәч, эшләтерсең сезне.

— Майлы ит ашап кына ятмакчы.

— Кикереп...

Тавышны Нурислам туктатты:

— Җәмәгать! Шауламагыз әле. Галимҗан янә бер ел эшләмәкче. Казанга китәргә акчасы юк. Тынлыкны янә Сәрвәретдин бозды:

— Эшләтмибез. И всю...

Сүзгә чуваш Степан кушылды:

— Син, зупани, шылай тисең тә пит, кесәсендә пер тиен тә акчасы калмаган киши кая пара ала сун?

— Ил төкерсә күл була, ди торганыйы атай мәрхүм, төкерик без, и всю, — диде Сәрвәретдин.

Аның томанлы сөйләвенә чувашның ачуы килде:

— Син, Сәрпәреттин, һаман шылай зупанилыгыңа парасын, парин, перәү авыр көлдә калган, ә син шыңа түкерергә кушасын.

Сәрвәретдин көлеп җибәрде:

— Их, син, мәет козгыны, акча җыйыйк, дим мин Галимҗанга, китсен, укысын...

Зобани Сәрвәрнең сүзләренә берәүнең дә ышанасы килмәде. Шаяртмыймы, янәсе. Чуваш аны чынга алды:

---

Дәвамы. Башы 5 санда.

— Ярай, пиртек тә, ти, кәпикә ни жалкы, ул акчаны кире кайтаруп пирерме суң пескә Галимҗан?

Сәрвәретдин кызып китте:

— Син, мәет козгыны, кәпикәң белән чукынып кит, ә мин... менә... — диде дә Сәрвәретдин, чалбар кесәсеннән алып, өстәлгә акча салды.

Башкаларның күзләре тоздай булды. Гелән генә тел катылыгы, яманлыгы белән даны чыккан, шуңа күрә "Зобани" кушаматы алган Сәрвәретдин мукләк кәҗәгә мөгез куярга маташмыйммы? Кеше акчасын җыйгач, әллә кая олагып, чучка урынына эчеп ятмасмы? Берәү дә акча бирмәгәч, аның ачуы бугазына тыгылды. Ул яңадан сөйләргә тотынды:

— Галимҗан бер учитель яллады. Урысча өйрәнергә. Да бит. Шуңа, мескен, ай саен акча биреп барды. Фактмы? Факт. Ул безне укырга-язарга өйрәттеме? Өйрәтте. Соң, туганкайлар, безнең ише аңгыра сарыктан образованный кеше ясады бит бер җылда. Инәкәй бахыркаема әле кичәгенәк кенә менә шушы үз кулкаем белән хат яздым бит. Их, ул укый, яза белү... Шуның өчен Галимҗанга без ни бирдек, ә? Тәтедеме аңа бездән кәпикә? Шиш. Тәтемәде.

Әйе, баракта бервакыт үзенчә мәктәп ачылды. Галимҗаннан берсе — әтисенә, икенчесе — әнисенә, өченчесе — туганына, дүртенчесе сөйгән ярына хат яздыра. Мәгәр коеп куя инде сүзләрне. Каләм очыннан гөл түгә. Аның кеше фикерен үз сүзләре белән кәгазьгә шулай оста нәкышлый белүенә исең-акылың китәрлек. Шунда Галимҗанның башына галәмәт гали бер уй килде. Укырга-язарга өйрәтергә боларны. Ә нигә? Бер тәҗрибәсез көенә нугай балаларын, казакъ балаларын укытты. Китап юк. Методика юк. Бернәрсә дә юк. Ә бит өйрәтте укырга-язарга. Алар арасында шактый зур яшьтәге абзыйлар да бар иде. Хәреф таныргa, сан санарга булса да өйрәт, дип киләләр. Тиз төшендерә белә Галимҗан. Нигә шуны монда да сынап карамаска? Дөрес, башта берсе — җилкәсен, икенчесе — арт чүмечен, өченчесе корсагын кашып карышты. Ташны сыгып су чыкмас, надан баштан юнь чыкмас, дип тә кул селтәделәр. Сәрвәретдин бөтенләй киреләнде:

— Зәррә кадәр дә акыл юк бит минем башта ул хәреф-мәреф галәмәтләрен белерлек, — дип көлдерде.

Шуннан Галимҗан Сәрвәретдингә иң әүвәл "а" хәрефен язарга өйрәтте. Моңа берәм-берәм башкалар да кушылды. Аннан "ана", "ата" дигән сүзләрне яздырды. Әллә ничә кат. Кәҗә маен чыгарды Галимҗан Сәрвәретдиннең. Җисмәни хезмәтне җиңел генә башкара Сәрвәр. Хәрефләрне кушып, йә укый, йә яза башласа, маңгаеннан тирләр тама. Уку — энә белән кое казу, дигәнне шунда аңлады ул. Теге вакытта Галимҗаннан көлеп йөргәненә хәзер үкенеп тә куя. Һәр эшнең үз гамәле, һәркемнең үз әмәле, дигәне шушыдыр. Бер үк нәрсәне йөзәр мәртәбә кабатлата Галимҗан. Сәрвәретдингә аеруча хаслашты ул. Ачуланышып та китәләр. Мондый чакта Галимҗан чын укытучы була белә. Аның төрле нечкә кылларын тарткалый, тыңламаса —ачулана.

— Ялкаулык — фәкыйрьлекнең башы ул, Сәрвәретдин туган, карышма; наданлык белән ярлылык та бер тирәдә йөри, — дип аңлата.

Ярты ел эчендә Сәрвәретдин ару гына укырга-язарга өйрәнде. Әнисенә хат язды хәтта. Дөрес, хәрефләр әле кәкре-бөкре төшә. Нәкъ үзенең исерек чагындагы кебек. Әллә ничә мәртәбә күчереп тә яздыра Галимҗан. Шуннан әйтте беркөн Сәрвәретдин:

— И-и-х! Нигә әллә кайчан синең кебек кеше очрамады икән, белер идем яшәүнең кадерен. Үз кулың белән хат язуы... Бәхет бит бу, бәхет!.. Валлаһи! Акылсыз башка алтын бүрек файда бирмәс, диер иде әти мәрхүм. Надан башка да шулай.

Һәркем акчаны өстәлгә йөрәге кушканча салды. Нурислам аны иртәгә иртүк Галимҗанның кулына тоттырырга сүз бирде. Ул азрак сөйләп тә алды:

— Рәхмәт, туганнар! Тау белән тау гына очрашмый, кеше белән

кеше һәрвакыт очраша. Акыллы артыннан ак юл сузылып кала, ди. Галимҗан кебек акыллы башның монда булуы безнең файдага. Ә инде сезнең бүген шундый олы йөрәклелек күрсәтүегез мине нык шатландырды.

* * *

Иртән Галимҗан эш киемендә килгән иде.

— Син инде, хөрмәтле укытучыбыз, Казаныңа юл тот, оныт завод юлын, — диде Сәрвәретдин.

Башкалар да төрле-төрле сүзләр әйтте:

— Хуш, Галимҗан!

— Ходай Тәгалә юлыңа ак җаймә җәйсен!

— Ак җаймәне йөгереп үткәндә, абына күрмә!

— Бәхетле бул!

— Бәхет — ике яклы: шуны онытма! — Рәхмәт яусын үзеңә!

— Рәхмәттән тун тектермә, китап яз, давай!..

Галимҗан ни дип әйтергә дә белмичә, аптырап тик торды. Берсе кулын кыса, икенчесе кочаклап үбә, өченчесе аркасыннан сөя. Күз ачып күз йомган арада эшчеләр китеп тә барды. Алар икесе генә калгач, Нурислам кичәге хәлне бәйнә-бәйнә, шулай да шактый ашыгып сөйләп бирде дә аның кулына бәләкәч кенә төенчек тоттырды:

— Нәрсә соң бу, Нурислам?

— Акча.

— Нинди акча?

— Сиңа юллык. Эшчеләр җыйды.

— Болай килешми бит.

— Алар сине ярата, Галимҗан! Хөрмәт йөзеннән...

— Болай әллә ничек бит әле...

— Борчылма!

— Мин... Әлбәттә... Җибәрермен...

— Син аларга күп хезмәт иттең.

— Мин бит акча өчен түгел.

— Хәерле юл, туганкай!

## VIII

Нугайлар һәм казакълар арасында мөгаллимлек эше белән шөгыльләнгәндә Галимҗан Ибраһимов күп җырлар, риваять, әкиятләр өйрәнде, төрле халыкларның тормыш-көнкүрешенә, яшәү рәвешенә, йөрәк тибешенә, күңел дөньясына игътибар итте. Ә күңел дөньялары искиткеч бай иде. Аларда чал тарих төпкеленнән килгән ата-бабаларның мәңге күгәрмәс уй гәүһәрләре, аң-акыл энҗеләре, хис-тойгылар кайнарлыгы... — тагын да әллә нинди шөһрәтлелек ялкыннары бар. Әлбәттә, ул күңелләрдә шәфкатьлелекне капларга тырышучы кара пәрдәләр өчен ачыну, ул пәрдәләрне ертып ташларга ашкыну, дөньяны фаҗигадән коткарып калу юлларын белми гаҗиз булулар да җитәрлек. Галимҗан әле үзен төрле кыяфәткә куеп карый. Бер караганда ул — ак белән кара арасына килеп эләккән шәүлә. Яки диңгездәге йомычка. Язмыш давылы аның белән шаяра да шаяра. Ярга алып чыгу турында уйламый. Ул үзен тау итәгендә йөргән дәрвишкә дә тиңли. Кайчан күтәрелер тау башына? Алда торган кара томаннарны ерып чыккачмы? Теге вакытта, үзен җиде юл чатында торган мосафир дип хис иткәндә, бу санның зурлыгы хакында уйлаган иде ул. Әле менә шул җиде саны аны тагын да мәмрәтте. Миас эшчеләре эчү, тарту, сугышу белән генә шөгыльләнми, җае чыкса, күңел ачкан вакытларда, сине әкият дөньясына да алып кереп китәләр. Абдулла исемле бер бабай "Җидегән йолдыз" әкиятен сөйләде.

“Бик борын заманда җир калактай гына, күк табактай гына булган. Адәм заты ишәя барган, киек-җәнлек заты күбәя барган, җир әкренләп киңәя барган; җир киңәйгәч, күк тә зурайган.

Ул чакта бөтен халык бер казаннан ашый икән. Бер Алып килеп чыккан да казанны күтәреп эчкән. Нишләмәк кирәк? Тотынганнар олы Казан ясарга. Казаны булгач, чүмече дә кирәк. Казанны койганнар көмештән, чүмечне ясаганнар алтыннан.

Теге Алып килгән дә казанны күтәреп караган. “Яраган”, —дип, урынына утырткан да чүмечне кулына алган. “Монысы бик җиңел икән”, — дип, һавага очырып тотып алыйм дисә, чүмеч юк: әйләнеп-әйләнеп очкан да йолдызлар арасына кереп поскан.

Алып чүмече әле дә бар. Җиде йолдыз булып ялтырый ул: чүмечнең төбе — дүрт йолдызы, тоткасы — өч йолдыз, җәмгысы — җидәү. Үзе һәрвакыт әйләнеп тора ул Алып чүмече: кичтән авызы өстә була, иртәнгә сырт ягы өскә чыга...”

Монысы инде — Галимҗанга Урал тавы буендагы Миас заводы эшчеләре бүләге. Абдулла бабай шактый авыр язмышлы кеше иде. Башта авылда көтүче булган. Хатыны, ике улы тифтән үлгәч, читкә чыгып китә ул. Алтын приискаларында, заводларда, шахталарда эшли. Акча табып, яңа тормыш корып җибәрү була нияте. Ләкин бервакыт эчүгә сабыша. Аннан бик каты авырып китә. Әле тифтән, әле бизгәктән иза чигә. Шулай йөри торгач, кара сакалына кырау төшә. Биле бөкрәя, күзләре чекрәя, яңаклары эчкә бата. Шулай да күңел рухын югалтмый ул. Әкиятләр, мәзәкләр сөйләп, кешеләрнең күңелен ачарга ярата. Үзе дә шуннан юаныч таба.

Әлеге казанга бәйләнешле әкиятне ни өчен сөйләгәнен аңлады Галимҗан. Син, улым, Казан каласына — татарларның Мәккәсенә барасың. Әнә шул көмештән коелган казан, алтыннан ясалган чүмеч турында уйла әле, дигәндер.

Бу әкиятне Галимҗан башта үз тормышына яраклаштырды. Иң әүвәл аңа фатир табарга кирәк. Бу җәһәттән аның фикер мәсләге яхшы эшли. Кем беләндер мәслихәтләшүенең аслан кирәге юк. Уфадагы, Миастагы тәҗрибәсе бар. Ул шаһ та түгел, шаһзадә дә түгел. Тыштан ялтыраган чибәр йортларга ул игътибар итмәскә тырыша. Аларны юри күрмәмешкә салышып үтә. Әмма мәркәздә, Уфа һәм Миастагы кебек, шәһәр читендә иснәнеп йөрүнең хаҗәте һич тә юк икән. Подваллар “шәп” монда. Шулай да тиз генә “оя” таба алмады. Күп йөри торгач, үзен-үзе сүгеп ташлады хәтта: комак мәкәе урынына мәлҗерәп йөри, янәсе. Килгәненә атна чамасы үтеп киткәч кенә, кереп ояланы ул бер подвалга. Песи күзе зурлыгында гына бер тәрәзәсе бар. Ул да тимгел-томгыл булып саргаеп каткан. Тәмәке тартудан нык саргайган кеше тешләрен хәтерләтеп тора. Бүлмәгә кояш та, яктылык та төшми. Тар гына агач караватт. Уч төбе зурлыгындагы кәкшәнләп торган бер өстәл. Әлеге Абдулла бабай сөйләгән калактай җир, табактай күк аның өчен шушыдыр инде. Бервакыт җире дә киңәер, күге дә зураер әле. Казанны көмештән коеп, чүмечен алтыннан ясарлар.

Хәер, анысы да булган. Уналтынчы гасыр башларында көмештән коелган Казан. Чүмечләр алтыннан ясалган. Ачкүз Иван җимергән барысын да: көмеш казанын да, алтын кашыгын да.

Алып чүмече әле дә бар. Җиде йолдыз булып ялтырый. Чүмечнең төбе — дүрт йолдыз. Тоткасы — өч йолдыз. Җәмгысы —җиде. Җиде! Җиде!! Җиде!!! Галимҗанның үз йолдызы ничәү? Менә хәзер ул “Йолдыз” редакциясенә бара. Казанга ул йолдызсыз гына килмәде. Башта ул язганнарын “Әльислах” газетасына җибәреп торды. Фатих әфәнде Әмирханов җәнаблары фатихасы белән дөнья күрә килде алар. “Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы” хикәясе басылды. “Үрнәк” матбагасында “Гыйшык корбаннары” аерым китап булып чыкты. “Яшьләр хәятыннан бер ләүхә” тиздән тәмамланачак. “Әльислах”та “Шәкертләр аһ-зары”, “Шәкертләр

һәм уку", Оренбургта "Борынгы ислам мәдәнияте" басылып чыга. Димәк, йолдызлар шактый. Ә инде баш мие күзәнәкләрендәге йолдызлар дулкыны санап бетергесез. Басылган мәкаләләрендә шәкертләр тормышының авыр, караңгы, күңелсез яклары гына сурәтләнми. Бөтен иске мәгариф кәүсәсен төбеннән үк үткер пычак белән кисеп ташлап, заман таләпләре зәукына туры килердәй яңа шытымнар җибәрергә тиешлек таләпнамәләр куела. Ул шытымнар турындагы житди фикерләр патша йөрәгенә утлы уктай барып кадала. Мондый уклар Петербургтагы матбугат идарәсенә башка мәкаләләр рухыннан да оча. Бу уклар "Әлъ ислах" мөхәрриятенә кире очырыла. "Әлъ ислах" туктатыла. Татар дөньясын хәзергә "Йолдыз" яктыртмак була.

Казанда Галимҗан Ибраһимов ике мәртәбә булган иде инде: беренчесе — Оренбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсендә укыганда (бүлмәдәше Йосыф мәхдүм аны үз туганнарына кунак сыйфатында алып барды); икенчесе — әлеге "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" исемле хикәясе басылгач. Ике килгәнендә дә, сөйгән кызын күрергә ярсыган егеттәй, күңеле университетка ашкынды. Бу юлы да шулай итте. "Императорский университет" дигән сүзләргә мөкиббәнә хисләнеп карап торды. Әйтерсең, аның да маңгаена шушы ук сүзләр уеп язылган. Бөтен киләчәк хәяте, гүя, ошбу мәһабәт бина эчендә; аны тәмамласа, зур бәхетне кулына әлеге алтын саплы чүмечкә салып китереп тоттыралар диярсең. Житмәсә, тыз да быз йөргән фырт студентлар, кылтым гимназисткалар ярага тоз сибә. "Яшьләр хәятыннан бер ләүхә" хикәясендә Сәлим елый-елый: "Сакалым агарыр, билем бөкрәер, ләкин мин сау булсам, шул бинага бервакыт әгъза булырмын", — дигән иде. Кешене максат зурлаганны белә Галимҗан. Максатсыз кеше — яфраксыз агач. Яфрагы юк икән — тамыры черегән дигән сүз. Димәк ки, ул озакламый авачак. Иллә мәгәр яшәү мәсләгеңне сакалың агаруга, билең бөкрәюгә калдырырга ярамый. Яшьлектә яшьнәү яхшырак.

Маңгаена "Императорский университет" дип алтын хәрефләр белән язылган мәһабәт бина алдында шулай очсыз-кырыйсыз уйлар давылына күмелеп басып торуына үзе дә гаҗәпсенде Галимҗан. Уйлар җебенә әтисе дә, әнисе дә, Солтанморат та, Миас та, тагы да әллә ниләр, әллә нәрсәләр килеп тезелде...

Ул биредән тизрәк китәргә ашыкты. Шулай да анты каты иде: тимерне кызуында сугарга — укырга, бөкрәеп катканны көтмәскә. Җебегән арыш боламыгы булып яшәргә ярамый.

## IX

Казан каласын Галимҗан Ибраһимов чын казан дип хис итте. Әйтик, астына ут төрткәннәр. Ут яна да яна. Шуңа күрә казанның төбе корымлы. Ә эчендә нәрсә кайный? Калҗамы? Бәрәңгеме? Кишерме? Шалканмы? Барысы да бардыр. Корымга ул кара якларны кертә. Печән базарында мең төрле вак-төяк саталар икән: итек, читек, комган, чиләк, көянтә — тагы да әллә ниләр. Бер читеккә күзе төште Галимҗанның. Алтын куллы әнисе дә тегә бит аны. Чигүләп. Каеп. Матур итеп. "Болгар читеге" дип атый аны. Шуңа охшаган бу читек. Хәер, бу һөнәр әһелләре шушы татар мәркәзе казанында кайнаган кешеләр ич. Галимҗанның әнисе Хәсәнә абыстай — Троицк каласы кызы. Дәү әнисе өйрәтә Хәсәнәне "Болгар читеге" тегәргә. Менә ни өчен әле Галимҗан күз явыңны алырдай чибәр читеккә карап онытылды.

— Купи, братук, падари ысвай девушка, она учин будит лубит тибә, — дип такылдады читекнең хуҗасы — карсак кына абзый.

Галимҗан матур гына итеп татарча җавап бирде:

— Бүләк итәрдәй кызым юк шул, абзыкаем!

Татар икәнлеген белгәч, кәмит күрергә җыелган бала-чагадай, аны уратып алдылар. Һәрберсе нидер әйтеп калырга ашыкты:

— Чәчен карагыз әле, җәмәгать...

— Ат койрыгымыни...

— Суган сатучы урыстан да яман...

— Галимҗан берни дә әйтмичә, китеп барды. Бер сүз очкынын алар ялкынга әйләндерергә мөмкин. Аларга татарның чәч үстерүе дә, Европача киенүе дә, тәрәккыйпәрвәр булуы да ошамый күрәсең. Менә болар инде, — шуларга охшаш мең төрле наданлык, җаһиллек, казан төбенә кат-кат сылашкан корымнар. Аларны кырып ташлау өчен, ай-һай ла, яналык пычагын бик нык үткерләргә кирәк әле.

Бөтен Казан белән танышып йөрде Галимҗан. Университет. Сөембикә манарасы. Музей. Тарихи урыннар. Боларның барысы да, ул уйлаганча, казан калҗалары. Корым кырылмый калмас. Бервакыт калҗасы да туйганчы ашалыр.

Дуңгыз кебек аска карап йөрүне Галимҗан үзе дә яратмый. Күңелнең күктә булуы хәерле. Казан күге бүген аеруча матур. Көз урталары булуга карамастан, көннәр һаман әле җылы тора. Хәтта күлмәкчән йөрүчеләр дә бар. Дөрес, җәйге җылылык түгел бу. Салкынлык та берникадәр сизелә. Җәй җылылыгы вә көз салкынлыгының яратышкан егет белән кыз кавышкандагыдай бер мизгеледер. Егет-көз Кыз-җәйнең кулын кыса. Янә аерылышыр вакыт җиткән. Кыз-җәй артта кала. Көз-егет алга ашкына. Кыз-җәйнең җибәрәсе килми. Сабыр итәргә куша. Тиздән кыш килер, ул сине туздырыр, шуңа чаклы җылы кочагымда иркәләнеп кал, ди. Шуннан әйтә Егет-көз: "И чибәрем, шәфкатьлем, акыллым, тыңладым сине, ашыкмыйм, икебезнең кушылган тыныбызны халыклар да күкрәк киереп сулый бит", — ди.

Казан көзен күңелендә шулай җанландырды Галимҗан. Һава суларга чыннан да бик җиңел, ләззәтле, тәмле иде. Яфраклар да әле ныклап коелырга бик ашыкмый сыман. Күрәсең, әйткәндер аларга Егет-көз: Кыз-җәй белән без гашыйк булыштык, ул миңа бик күп мәхәббәт җылысы бирде, кышка ерак әле, бик кабаланмагыз, алтын төсенә кердегез ләбаса, кешеләр сезгә карап, мөкиббәнә сокланып йөрсен, дигәндер.

Җәй белән Көз кул кысышып аерылышкан мәлдә мондый мизгелләр Солтанморатта да була. Әтисе Гыйрфан мулла, хәтта көзгә табигать серләрен йә күңел дәфтәренә, йә гамәл дәфтәренә яза. Әллә никадәр сынамышлар белә ул. Шулар буенча кышның, язның ничек килерен әйтә. Аның да йөрәге табигать йөрәге белән бәйле. Табигатькә маңгай күзе белән түгел, күңел күзе белән карарга бәләкәй чактан ук өйрәтте.

Шундый уйлар кичерә-кичерә барып керде ул "Йолдыз" редакциясенә. Булмә шактый киң. Иркен. Биек. Ике тәрәзәле. Уртада — озын гына өстәл. Аның өстендә газета-журналлар таралып ята. Китаплар. Түрдә ике бәләкәй өстәл. Берсе — унда. Икенчесе — сулда. Икесенең дә артында бигүк затлы булмаган утыргыч. Шуларның уң яктагысында калын гына, әмма мәһабәт гәүдәле берәү утыра. Ул нидер яза. Мәгәр бик нык бирелеп яза. Мөкиббән. Галимҗанның килеп кергәнен әллә ишетте, әллә юк. Ишетсә дә — борылып карамаска мөмкин. Газета эшендә бик авыр чаклар була. Галимҗан моны белә. "Галия" мәдрәсәсендә, җилем басмада булса да, алар да чыгарды бит газетаны. Башта "Шәкерт тавышы" дип исемләргә тәкъдим ителде. Аннан соң — "Безнең юл". Исеме җисеменә туры килә, дигәндәй, икесендә дә зур мәгънә бар. Алар заман рухына бәйле. Чөнки инкыйлаб җилләре шәкертләр тормышына да давылланып килеп керде. Килеп тә керде, таштай селкенми яткан шәкертләрне дәррәү кузгатып та җибәрде. Йомык күзләр дә ачыла башлады. Ачык күз белән кай тарафка карарга? Фикер мәкколәре капкы акта? Нинди юл сайларга? Нинди томаннарны җиңеп чыгарга яктылыкка? Димәк, аң кирәк. Шуңа күрә Галимҗан "Аң" атамасын тәкъдим итте. Аң кирәк надан башлар

карайткан дөньяны агартуга. Аң! Акыл!! Фикер йөртү офыклары киңлеге!!!

Үзе булды Галимҗан Ибраһимов "Аң"ның мөхәррире. Эчендә алтын булган сүзләрне сайлау авырлыгын белә ул. Бу эшкә бер чумсаң, табаныңа ут төрткәнне дә сизми утырасың. Мәһабәт гәүдәле бу каләмкяр дә алтын сүз эзләү белән мәшгульдер. Газета эше кар яудыруны яратмый. Аның өчен минуты-секунды янә бер алтын.

Көтү шактый озакка киткәч, Галимҗан тамак кырырга мәҗбүр булды. Мәһабәт гәүдә аз гына селкенеп куйды. Ишетте шикелле. Шулай да борылып карамады. Кемнәр генә керми редакциягә? Үз хезмәткәрләре дә чыж да выж йөреп тора. Шуларның берседер дип уйлагандыр, бәлки. Ул, ниһаять, язуыннан туктап, кулындагы каләмен шап итеп өстәлгә куйды. Мәһабәт гәүдә, урыныннан торып, Галимҗанга карап катты. Куе кара мыек. Тулы йөз. Арганлыгы сизелсә дә, шактый мөлаем караш. Өстендә яңа кара костюм. Киң маңгай. Зур гына баш өстендәге түбәтәе чәчләрен җыеп тора. Башына караганда — түбәтәе бәләкәйрәк. Менә-менә йә төшеп, йә очып китәр кебек ул түбәтәй. Шунысы да бар: әгәр ул түбәтәй зуррак булса, киң битне ямьсез күрсәтер кебек. Өстендәге костюмы да аны кысыбрак тора. Калын гәүдәнең җәелеп китүеннән куркып шундыйны киядер, бәлки. Ничек кенә булмасын, аның хәлле, түлле, затлы нәселдән чыккан зыялы аксөяк икәнлеге аерым-аерым сизелеп тора. "Галиәсгар Камал абзыкай шушы булырга тиеш", дип уйлады Галимҗан. Үзенчә аны "аксөяк" дип атарга да өлгерде.

Бераз карашып торып, гадәт буенча, исәнлек-саулык сорашкач, "аксөяк"кә сорау бирде Галимҗан:

— Сез Галиәсгар әфәнде буласызмы?

— Шул үзе. Ә сез?..

— Мин — бәхет эзләүче.

Галиәсгар әфәнде елмаеп куйды:

— Бәхетне "Йолдыз"дан тапмакчысызмы?

— Йолдыз караңгы төндә яктырак яна.

— Безнең "Йолдыз" караңгылыкны яктыртыр өчен кирәк тә инде.

— "Әльислах"ны яптырдыгыз. "Йолдыз"ны да сүндермәссезме?

— Кемнәрдән?

— Тәхеттәге кара козгыннардан.

Бу юлы Галиәсгар әфәнденең елмаюында салкынлык чаткылары да сирпелеп алды. Киеменә караганда, керүченең әллә кем булырга тиеш түгеллеге сизелә иде. Башындагы иске картуз астыннан бүлтәеп чыгып торган тәртипсез чәче, кызыл күлмәк өстеннән буган киң каешы, аягындагы тузанлы итеге, янып торган кара күзләре, каты карашы, кыюлыгы, үзен нык тотуы. Аны чегән арбасыннан төшеп калган затка охшата. Шаярып сөйләшүе буенча фикер йөрткәндә, алар күптән танышлардыр, бәлки. Аның кем икәнлеген оныткандыр гына ул. Барысын да хәтердә тотып буламыни? Әйтмәсен кем икәнлеген. Аның барасы җире бар. Ашыга.

— Менә нәрсә, егетем, миңа китәргә кирәк, йомышыгыз булса, әйтегез дә...

— Йомышым юк, Галиәсгар әфәнде, танышып чыгу уе белән генә кергән идем.

— Мин сезне кайдадыр күргән кебек булам, ә менә хәтерли алмыйм.

— Мине Галимҗан Ибраһимов, диләр.

— Галимҗан? Әһә, менә син нинди икән!

Галиәсгар Камалның йөзе ачылып китте. Егетне кочаклап алганлыгын сизми дә калды. Аркасыннан сөеп куйды хәтта.

— Бәхет эзлисең инде, ә?! Зур, иҗади бәхетең "Йолдыз"дан башланыр, бәлки, ә ?! Мин — монда сәркәтип. Ху-у-уш! Буш кул белән килмәгәнсеңдер шәт?

— Хәзергә әллә ни юк, Галиәсгар әфәнде! Өч хикәям бар. "Казакъ кызы" романын төгәлләп киләм...

— Роман?! Ә үзең, "әллә ни юк", дисең. Синең усал, чая, шаян икәнлегеңне беләбез. Мәкаләләреңне укып та, "Зәки шәкерт..." аша да. Әле дә меңә кусәк күтәреп сөйләшкәнеңне аңлап алдым. Әмма тыйнаклык та бар икән әле үзеңдә. Һм... яшь кенә көенә роман язган. "Хәзергә әллә ни юк", имеш...

— Роман тәмамланмаган бит әле, Галиәсгар әфәнде!

— "Башланган эш — беткән эш", дип сөйләшә безнең татар халкы.

— Анысы шулай инде.

— Ярый, Галимҗан туган, күп сүз китапка гына яхшы, ди...

Галимҗан аның сүзен бүлдерде:

— Күп сүзне китап та яратмый, Галиәсгар әфәнде!

Галиәсгар көлеп җибәрде:

— Менә монысы бигрәк тә дөрес.

— Ярый. Казанга бөтенләйгә килгәнсеңдер инде?

— Шулайрак, Галиәсгар әфәнде!

— Безнең "Йолдыз"ны укып барасыңдыр бит?

— Монда килгәч караштырдым. Казанда атна чамасы торам инде.

— "Йолдыз"ны дөнья яктыртa торган чын йолдыз итәсе бар әле, туганкай!

— Әйе. Кирәк. Әле ул тоныграк шикелле.

— "Тонык" дигән сүз Галиәсгар әфәндеңең күңеленә шом салды. Ул — сәркәтип. Сыйфат өчен җавап бирә. Димәк, укучылар таләбе югарылыгында тормый. Шуңа борчылып, сорау бирергә мәҗбүр булды:

— "Тонык" дигәнне ничек аңларга, Галимҗан әфәнде?

— Фикерләр тоныклыгын әйтәм.

— Ә шулай да?

— Күп мәсьәләләр куела. Ләкин ачыкланмый кала. Мәкаләнең мәслләгеn аңлау да кыен. Фикер ачыклыгы җитми.

Галиәсгар әфәнде сәгатенә карап алды.

— Сез ашыгасыз шикелле? — дип сорарга мәҗбүр булды Галимҗан.

— Әйе. Фатих Әмирхан әфәнде белән күрәсе бар иде. Бәлки, бергә барырбыз, ә?! Сез бит инде күптән танышлар. Иҗатың "Әльислах"тан башланды. Ул әле шушы "Болгар" кунакханәсенең өченче катында.

— Минем аны үземнең дә күрәсем килә иде. Тик сезнең әңгәмәгә су кушмаммы икән соң анда?

— Кушалмассың. Без өчәү әле анда — Тукай да шунда булачак.

— Тукай?!

— Әйе, Тукай. Нигә шаккаттың?

— Димәк, мин Тукай белән бүген үк очрашам.

— Озакламый. "Бәхет эзлим", диден бит. Бу — бер бәхетең. Тукай хәзер — бөек шагыйрь. Аның белән күрешүне һәркем зур бәхет дип исәпли.

* * *

Алар барып кергәндә, Галиәсгар Камал әйткәнчә, Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай икәүсе генә иделәр. Галимҗанга Фатих Әмирхан таныш иде инде. Аның янындагы унөч яшьләр чамалы бер "малай"ның кем икәнлеге Галимҗанга хәзергә билгеле түгел. Исәнлек-саулык сорашкан арада Галимҗан күз карашлары белән бүлмәне капшап алды. Нибары — урам якка чыккан бер тәрәзә. Бер өстәл. Дүрт урындык. Тимер карават. Галиәсгар Камалны алар сагынып көткән кунактай ачык йөз белән каршы алмады. Алар күптән түгел генә очрашкан булганнардыр, бәлки. Әле менә салкын исәнләшүнең сәбәбе шулдыр, мөгаен. Аннан соң Фатих Әмирхан теге "малай" белән нык, ихлас, бирелеп, мөкиббән сөйләшә иде. Әмма йөзләре шактый ачулы, күләгәле күренә. Ни өчен? Бу, бәлки, Галиәсгар әфәндегә билгеледер. Ә инде Галимҗан өчен ул караңгы әле.

Болар килеп кергәч, бәхәсләре тукталса да, алар һаман әле баш күтәреп карамадылар. Ата кеше, бер гаебе чыкса, малаен каршысына утыртып йә тирги, йә үгетли, йә башкача тәртип бозмаска сүзен ала. Фатих Әмирхан каршысында утырган "малай"ның да йөзендә әтисе тарафыннан кыерсытылганнан соң була торган үпкә күләгәсе сизелә.

Галиәсгар Камал аларның нык кына ачуланышканлыкларын сизде. Ни генә булмасын, ике арага сузылган ачу җебен өзә торган сүз кылычы кирәк хәзер.

— Без фикерегезне өздек шикелле? — диде ул.

Сорауга җавапны Фатих Әмирхан бирде:

— Өзелгән булса, бергәләп ялгарбыз, Галиәсгар әфәнде... Гафу итегез. Сез кунак белән икән ләбаса...

— Кунакның нинди генә әле, Фатих әфәнде! Әллә танымыйсызмы?

Фатих Әмирхан Галимҗанга шунда гына ныклап игътибар итте:

— Соң, Ходайның рәхмәте, Галимҗан Ибраһимов лабаса бу!

Бу сүзләрдән соң, Габдулла Тукай да Галимҗанга ныклабрак карарга мәҗбүр булды. Галиәсгар Камалга аларны күрештерү кирәк иде.

— Менә монысы халкыбызның яраткан зур шагыйре Габдулла Тукаев була, — диде ул.

Галимҗан Ибраһимов белән Габдулла Тукай бер-берсенә озак кына карашып торды. Тукайның ябык, чандыр гәүдәле булуы хакында ишеткәне бар иде аның. Ләкин болай уктыр дип уйламый иде. Күрешүнең шактый җылы булачагын өмет иткән иде Галимҗан. Әмма көткәннең киресе килеп чыкты. Тукай Галимҗанга "Ни йомыш?", "Ни кирәк?", "Нигә вакытлы-вакытсыз йөрисең?" дигән тойгы беләнрәк карады. Галимҗан сизде моны. Шулай да сер бирмәскә тырышып, башта Фатих Әмирханның, аннан Габулла Тукайның кулын кысты. Боларның барысы да гореф-гадәт буенча, шулай эшләргә кирәк булган өчен, ихлассызлык белән башкарылды.

Ошамады Галимҗанга мондый каршылау. Галиәсгар Камал исә аның сәбәбен яхшы белә. Тукай вакытлы-вакытсыз йөрүчене, сүзен бүлүчене яратмый. Укыды ул Галимҗанның "Әльислах"та басылган хикәясен. Әллә ни түгел. Татар әдәбияты мәйданына киләчәктә ни түгәр: алтынмы, көмешме, бакырмы, чүпме — монысы хәзергә бер Ходайның үзенә генә мәгълүм. Һәрхәлдә, тормыш тора-бара һәркемне, көч-кодрәт чамасына карап, үз чанасына китереп сала.

Галиәсгар Камал Тукайның кеше талантына шундыйрак күзлектән караганлыгын яхшы белә. Дөрес, ул вакыт-вакыт балага әверелә. Урамда хәтта малайлар белән уйный торган гадәте дә бар. Унике-унөч яшьлекләрдән ул әллә ни аерылып тормый. Мәгәр зурлар белән көрәштә үзен Алып батыр итеп күрсәтә белә. Әдәбиятта каләм очыннан гәүһәр түгүчеләрне күккә күтәреп мактый. Каләм очыннан чүп түксәләр — ул чүпне шундук үз каләм уты белән көйдерә. Галимҗанның басылган хикәясе әле Тукай өчен чүп дәрәҗәсендәрәк.

Мондый сөйләшүләр Тукай, Фатих, Галиәсгар әфәнделәр тарафыннан булгалады. Тукайның Галимҗанга мөнәсәбәтен белә Галиәсгар әфәнде. Шуңа күрә әле шактый авыр хәлдә калса да, моның өчен ул кадәр борчылмады да. Шулай да мөһим мәсьәлә турында сөйләшергә җыенганда "чит" кеше алып килүне, әмма аның чит түгел икәнлеген аңлатуны кирәк дип исәпләде дә:

— Галимҗан әфәнде Казанга бөтенләйгә күчеп килгән, аерым фатирда тора, хәзер инде ул безнең үз кеше, шуңа күрә монда алып кердем, теге мәсьәләне бергә карасак, һич зыян итмәс, аның да фикерләре булырга мөмкин бит әле, — диде.

Фатих Әмирханның йөзе ачылып китте. Калын иреннәрендә аз гына елмаю чаткысы сизелгәндәй булды.

— Бик дөрес, Галиәсгар әфәнде, бик дөрес, без бит монда ниндидер яшерен эш тикшермибез, бәс, шулай булгач, Галимҗан әфәндене дә тыңлап карау мотлак, — диде ул.

Тукай исә ни “ә”, ни “җә” димәде. Йөзендә үзгәреш тә күрсәтмәде. Безнең гәпкә бу чакырылмаган кунак катнашса ярый, катнашмаса ярый, дигән кебегрәк утырды. Галимҗан өчен авыр мизгел иде бу. Галиәсгар Камалның: “Аның да фикерләре булырга мөмкин бит әле”, дигән сүзләре аны нык уйланырга мәҗбүр итте. Димәк, алар арасында ул хәзергә ни күтәрелми, ни төшми торган томан кебегрәк. Фатих Әмирхан да фикерен шул томанга китереп чәпәде. “Галимҗан әфәнденең дә тыңлап торуы мотлак”, — дип әйтүе рәнҗетте аны. Ни өчен тыңлап торырга? Күзле бүкән түгел лә ул. Фикер әйтергә хокукы юкмы әллә? Тукайның битарафлыгы да шулар тегерменәнә су коюдан башка нәрсә түгел. Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый, энекәем, утыр шунда бохар песие шикелле шым гына, дигән кебек карый аңа.

Шулай да Галимҗан үпкәсен үрчетмәскә тырышты. Алар белән чагыштырып караганда, каеннар арасындагы усак кына ич әле ул.

Сүз әдәби тел турында барды. Төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең, озын тарихы бар. Ләкин унынчы гасырда ислам дине кабул ителеп, гарәп имласына күчкәч, гарәп-фарсы сүзләре төрки телләргә дулкын-дулкын агыла башлый. Дулкын үттеме, аның астында ләм хасил була. Шуның шикелле, төрки телләрне “ләм” каплый. Шул чорда ук инде төрки телләрнең “ярлы, “артта калган булуы, аның белән әдәби әсәр язу, фәнни хезмәт иҗат итү “мөмкин түгеллеге” турында ялгыш фикер тарала. Бакчадагы чүп үләнен һаман-һаман утап торган шикелле, ялган карашларга каршы даими көрәш бара. Төрки телләрнең байлыгын, гарәп теленнән бер дә ким булмавын унберенче гасыр галиме Мәхмүд Кашгарый төрле юллар белән исбат итә. Унтугызынчы йөздә исә бу мәсьәләне ачыклау өчен Каюм Насыйри бабабыз җиң сызганып көрәшә. Фигыльләр буенча гына фикер йөрткәндә дә татар теленең җир йөзендәге алга киткән телләрдән ким булмавы гына түгел, хәтта өстен икәнлеге турында әйтә ул. Борынгы ата-бабаларыбыз, әле язма әдәби тел барлыкка килгәнче үк, тел турында гаҗәп тирән мәгънәле, эчтәлекле, сәнгатьчә нәфис эшләнгән мәкаль-әйтемнәр иҗат иткән. Менә шуларның берсе:

Тел дигән дәрья бар,  
Төбендә энҗе-мәрҗән бар;  
Теләгәннәр чумып алыр,  
Теләмәгән коры калыр.

Нинди тел диңгезенә чумарга тиеш хәзер татар халкы? Әгәр чумса, тел диңгезе төбеннән нинди энҗе-мәрҗән эзләргә тиеш була ул? Теге яки бу милләткә бәяне башка милләт аның әдәби теле үсешенә карап та бирә бит. Егерменче йөз башында татар милләт буларак оешып алды. Ә инде милли әдәби тел диңгездәге бер утрау кебек кенә, ул утрауны да төрле яклап дулкын юа. Менә-менә ишелеп төшәчәк ул утрау.

Фатих Әмирхан сөйләде бу хакта. Башкалар тыңлап кына утырды. Галимҗан Ибраһимов монда килгәненә нык шатланды. Ул да шулай уйлый иде бит. Гарәп-фарсы сүзләре төрек әдәби телен дә яртылаш каплап алган иде ләбаса. Шөкер, төрекләр вакытында әрсез “кунак”тан котыла белде. Ә татарлар чакырылмаган “кунак”ны һаман сыйлый бирә. Моңа халыкның да ачуы кабарды. “Сөйләсәнә адәмчә, без белмибез гарәпчә” дигән әйтем дә уйлап чыгарды ул. Бәгъзе бер мөхәррирләр, аптыраган үрдәкнең суга арты белән чумганы сымак, гарәпчелектән качам дип, урыс сүзләренә табына башлады. Халык усал. Халык сизгер. Халык акыллы. Ул инде хәзер: “Урысча да яман, татарчага да таман”, — дип көлә башлады. Мескен татар теленең сул як кабыргасын әллә ничә гасырлар буе гарәп йодрыгы төйгечләп килде. Хәзер инде урыс Иван йодрыгы уң як кабыргасын дөмбәсли. Уртада калды бахыр татар теле. Ике яклап туныйлар. Тукмалган шүрәле урынына сикерә татар теле. Ә бит аның тамыры бай. Ул тамырлар кәүсәләр җибәргән иде. Кәүсәләр киселде. Шулай да тамырлар калды. Алар черемәгән. Аны халык саклаган.

Йомшак кына үлән дә ташны тишеп чыгып үсә. Тел тамыры йомшак түгел ул. Нык. Бар ул тамырлар. Күп. Үрчетергә генә кирәк. Шул хакта бара сүз. Яхшы. Шатлыклы. Күрәш эзсез калмый.

Фатих Әмирхан сөйләп бетергәч, Габдулла Тукай сорау бирде:

— Фатих, "Әльислах"та басылган мәкаләңдә дә әле менә шушында сөйләгәнчәрәк сүз бара; бу гел бер балык башын чәйнәү түгелме?

Фатих Әмирхан, зур кара күзләренең карашын Тукайга күчерде:

— Чәйнибез лә ул, Апуш, өзеп чыгара алмыйбыз.

Сүзгә Галиәсгар Камал кушылды:

— Өзәргә кирәкми, егетләр, ялгау хәерле булыр. Сез гарәпчәгә каршы. Ә үзегез һаман әле әсәрләрегезне гарәп сүзләре белән чуарлыйсыз. Бармы минем "Беренче театр"ымда халыкка аңлашылмаган гарәп сүзе? Юк. Әдәби телнең ничек булуын без әсәрләребездә күрсәтергә тиешбез бит.

Янә бераз бәхәстән соң, өчесе дә Галимҗанга карады. "Син, яна кеше, ничек уйлыйсың бу хакта?" — дигәнне аңлата иде аларның карашы. Сөйләргә ашыкмагач, аны Фатих Әмирхан кузгатты:

— Галимҗан әфәнде! Сездән дә фикер көтәбез.

— Фатих әфәнде! — диде Галимҗан, — мин Сезнең "Әльислах"тагы "Тел мәсьәләсенә бер караш" дигән бик кирәкле, бөтен халыкны, милләтебезне уйландыра торган мәкаләгезне зур дикъкать белән укып чыктым. Сез анда татар сарыфын, татар нәхүен ничек язарга кирәклек турында сүз кузгатасыз. Әмма ләкин үзегез аның ысулын күрсәтмисез... Шулай да булсын, ди. Тик аларны кем язарга тиеш соң? Бармы шундый кешеләр татар дөньясында? Булса — кемнәр алар?

Галимҗан күз карашлары белән тишәрдәй итеп Фатих Әмирханга озак кына карап торды. Авыр тынлык урнашты. Галиәсгар Камал мыек очларын бөтереп алды. Тукай җилкәсен кашып куйды. Җавапны Фатих Әмирхан үзе бирде:

— Бөтен бәла дә шунда шул: яңа тәртиптә имла, сарыф, нәху язардай тел галимнәребез һаман юк әле.

— Тагы да бер сорау бирергә мөмкинме?

— Рәхим итегез!

— Сез анда, Фатих әфәнде, "Әдәби телебез ничек булырга тиеш?" дигән сорау куясыз. Кемнән сорыйсыз аны? Урынлымы бу? Хәзер безгә сорап маташмаска, турыдан-туры эшкә күчәргә вакыт түгелме?

Авыр сорау булды бу. Бүлмәне янә тынлык басты. Шулай да ул бик озакка бармады. Фатих Әмирхан җавап бирде:

— Соравың урынлы, Галимҗан әфәнде, ләкин бит бу көне-сәгате белән хәл ителә торган мәсьәлә түгел.

Аның җавабына Галиәсгар Камал куәт бирде:

— Әйе, менә без шуның өчен фикер алышабыз да. "Әльислах"та башлаган бу эшне "Йолдыз" да дәвам итәчәкбез.

Тукай күбрәк сүзсез утырды. Берара ул, сүздән бутка пешерәбез дигәнне аңлатып, үзе сорау бирде:

— Сез монда, юкә чыбыркыны каеш итәргә теләгәндәй, яңа әдәби тел уйлап чыгарырга маташмыйсыздыр бит?

Галиәсгар Камал, бәхәс уты кабына башласа, аны һәрвакыт дөрләтмәү, сүндерү хәстәрен күрә. Бу юлы да шулай итте:

— Син, Апуш, ялкынга май сипмә әле, аннан аны басу бик кыен; монда, минемчә, берәү дә яңа әдәби тел уйлап чыгару турында баш ватмый; фәкать фикер алышабыз; әгәр син куйган сорау буенча китсәк, без тагы әллә кая барып чыгабыз. Болай да озак утырдык, чәйләп алырга кирәктер, бәлки...

Аның сүзен Галимҗан бүлде.

— Галиәсгар әфәнде! Мин әле сорау гына бирдем. Мөмкин булса, бер кәлимә сүз дә әйтер идем.

— Бу безнең нинди дә рәсми җыелыш түгел, Галимҗан әфәнде,

шуңа күрә "мөмкин булса"лар кирәкми; ни генә димә, сез әле безнең өчен кунак; самовар янында фикер тагы да куәтлерәк була, — диде Галиәсгар Камал.

— Сез, Галиәсгар әфәнде, әдәби телнең ничек булуын әсәрләребездә күрсәтергә тиешлек турында әйттегез. Бик дөрес. Аның шулай икәнлегенә иманым камил. Ләкин без бодай урынына һаман әле кырлык чәчәбез түгелме? Яки дөрес уйлап ялгыш эшлибез. Нәкъ намазны тәһарәт алып укырга кирәклекне белгән сурәттә дә, аны тәһарәт алмый гына укыган шәкерт кебек.

Бу сүзләрнең тупасрак килеп чыкканлыгын сизде Галимҗан. Шулай да хәзер артка чигенергә ярамый. Ә инде алга бару — куркынычрак. Шуңа күрә дә ул аз гына туктап торырга, уйланырга мәҗбүр булды. Галиәсгар ага аңа ярдәмгә килде:

— Сез, Галимҗан әфәнде, уратмый гына сөйләсәгез иде.

Галимҗан, үз дәрәҗәсен саклаган хәлдә, җавап бирде:

— Тырышырмын, Галиәсгар әфәнде, борчылмагыз!

"Борчылмагыз" дигән сүз югарыдан түбәнгә карап сөйләшүне аңлатты. Тегеләр елмаеп куйды. Әнә, кемне тынычландыра, янәсе. Ни хакы бар аның?

Галимҗан исә сүзен дәвам итте:

— Гафу итегез, әфәнделәр, мин сезгә бер шигырьнең ике генә юлын әйтәм:

Мәрамем-матлабем анчак сәнең мәнзүм вә мәнсүрең;
Бәнем шаәнемне тәфтиш мәзһәбезне, дине мәнсубең?

Кайсы шагыйрь үз телен шулкадәр бозган? Гомәр Хайяммы? Байронмы? Пушкинмы? Лермонтовмы? Ә бит шигырь "Пушкинга" дип атала. Аңа дан җырлый. Мәдхия укый. Әгәр фаразан Пушкин исән булып, татар телен белсә, шушы шигырьне укып караса, "и мескен татар теле", дип әйтмәс идемени? Шигырь, минемчә, халыкның йөрәгенә сары май булып сеңәргә, рухына илаһият бирергә, күңеленә зәвык индерергә тиеш. Нинди зәвык бар бу юлларда? Аның сүзләрен халык кына түгел, зыялы галиҗәнабларыбыз да аңламый бит...

Бу юллар Габдулла Тукайның "Пушкинга" дигән шигыреннән иде. Моны барысы да белә. Әмма "үз кеше"дән моны берәү дә көтмәгән иде әле. Бүлмәдә авыр тынлык урнашты. Тынлык, әйтерсең, дүрт әдәбият әһеленең телен тәбегә элэктерде. Галимҗан әле берсенә, әле икенчесенә карап алды. Галиәсгар ага түбәтәен яхшылап кия. Фатих Әмирхан күзлеген рәтләп маташа. Мәгәр Тукай йөзен үзгәртми. Тик тора. Минем өчен синең сүзләрең, энекәем, диварга борчак белән бәргән кебек кенә дигәндәй тота үзен. Нык борчылу Галиәсгар Камалда сизелә. Тукайның усаллыгын белә ул. Әллә ни әйтеп ташлавы бар. Галимҗан да сүз өчен кеше кесәсенә керә торган зат түгел ахрысы. Бу ике "тәкә" сөзешә башласа, ай-һай-һай, түзеп тә тора алмассың. Мәгәр Фатих Әмирханда борчылу сизелми. Әллә кайчангы борынгы төрки телдән үк калган тел чаралары белән мавыкмаска, гарәп-фарсы сүзләренә табынмаска дусларча да киңәш итте, язып та чыкты бит ул. "Әльислах"та басылган "Габдулла Тукаев шигырьләре" дигән мәкаләсендә болай дигән иде Фатих Әмирхан:

"Сәнең хөснең табигыйдер сәмави,
Вә һәр гозве ләтыйфендер сәнәви, —

кеби, гарәп сүзләреннән татарча төзелеп ясалган бәетләрнең татар шигырь мәҗмугасында торулары — бөтенләй урынсыздыр", — дигән иде.

Әлбәттә, Фатих Әмирхан йомшак итеп, күңелен китүдән берникадәр шикләнеп, дусларча әйтә. Ә бу маңгайга чүкеч белән китереп бәрер дәрәҗәдә кылана. Катылыкны йомшарту вазифасын үз өстенә алды Галиәсгар Камал:

— Галимҗан әфәнде! Бу хакта Фатих "Әльислах"та язып та чыккан

иде бит. Беләсездер. Күп укыгыз, күпне белүегез сизелеп тора. Бу турыда, бәлки, шушының белән туктатырбыз, ә?

Галимҗан ризалашты:

— Мин каршы түгел, Галиәсгар әфәнде!

Әмма тынычлыкка Тукай үзе ут салды:

— Галимҗан әфәнде! Мин сезгә ул сүзләрне ни өчен кулланганлыгым турында тирәнрәк уйланырга киңәш итәм.

Галимҗан уйлап тормады.

— Поэзия, Тукай әфәнде, гөл бакчасы ул. Мужикның бәрәңге бакчасы түгел. Аны чүпләргә ярамый. Сезнең кебек зур шагыйрьгә килешми. Менә минем уйлануым...

Галимҗан Ибраһимовның чын йөрәктән, ихлас, риясыз сөйләгәнен аңлады Галиәсгар Камал. Шушы ук фикерне Тукайга Фатих Әмирхан да кат-кат әйткән иде ләбаса. Моңарчы гәрчә читтә йөрсә дә, Галимҗанның Казан сулышы, татар дөньясы, аның теле турында даими кайгырып яшәгәнлеге хәзер көн кебек ачык. Шулай да аның сүзләренә төзәтмә дә ясамый калмады Галиәсгар Камал:

— Сез, Галимҗан туган, Габдулла Тукаевның "Пар ат", "Шүрәле" кебек саф татар телендә язылган шигырьләрен дә беләсездер, шәт?

— Белү генә түгел, мин аларны ятладым, Галиәсгар әфәнде! Алар да татар теленең моңы, аһәңе, байлыгы, сәнгатьлелек дәрәҗәсе — тагы да әллә күпме асыл сыйфатлары бар бит. Аларны укыгач: "Менә нинди зәвыклы, соклангыч, зиннәтле икән безнең татар теле!" дип уйланасың. Мин бит аның зур шагыйрь икәнлегенә дә, татар телебезне һәркайсыбыздан шәбрәк белүенә дә шикләнмим.

Хәзер инде аңлашылды Галимҗанның Тукай файдасына сөйләве. Бу барыбер ошамады Тукайга. Галимҗанның мөгаллим сыйфатындарак кылануы аның саруын кайнатты.

— Сез, Галимҗан әфәнде, чын энҗене кырлыктан аера белмисез шикелле, — диде ул.

— Мин барлык гарәп-фарсы сүзләренең тамырына балта белән чабу ягында түгел, — диде Галимҗан. — Гарәп сүзләренең бик нык тирән мәгънә аңлатканнары күп. Калсын алар. Телебезне матурлап, бизәп, нәкышләп торсын. Без әле барыбыз да "иске әдәби телгә юеш йонга ябышкан тигәнәк урынына сыланганбыз. Безне аннан суырып алу мәҗүсине поттан аеру дәрәҗәсендә авыр. Минемчә, якын арада әдәби тел турында болай тар даирәдә түгел, киң җәмәгатьчелек белән ныклап фикер алышу оештырырга кирәк. Аны ничек дип атарга әле менә тәгаен генә әйтә алмыйм: "Җыен", "Корылтай", "Съезд"... Анда-санда мәкалә язып кына эш чыкмаячак. Әгәр болай хушкүңеллелек күрсәтсәк, Әбү Ләһәб хатынының хөрмә агачларын янган утка ташлаганы хәлендә калачакбыз.

Шуның белән Галимҗан сүзен тәмамлады. Тегеләрнең йөзләрендә арыганлык, борчылу, дулкынлану чаткылары, тагы да әллә нинди аңлаешсыз төсмерләр сизде ул. Алар "чәй эчик", "ашыкма", "ял да кирәк бит", кебек сүзләрне әйтсәләр дә:

— Гафу итегез берүк, минем китүемне илтифатсызлыкка санамасагыз иде, сезнең белән бергәләп чәй эчүне үзем өчен ифрәт дәрәҗәдә муафыйк күрер идем, әмма ләкин, мөмкинлегем юк, миңа китәргә кирәк, — дип, чыгып китте.

## XI

Галиәсгар әфәнде аны озата чыкты. Коридорда бер-берсенә карашып, ни әйтергә белмичә, бер мизгел сүзсез тордылар. Ике арага тынлык җебе сузылды. Җепне Галиәсгар Камал өзде:

— Галимҗан әфәнде! Мин бая да сорармын дигән идем, ашыгычлык белән форсат табылмады, әле менә шул хатамны төзәтмәкчемен: Казан

Сезнең өчен хәзергә "чит" шәһәр, биредә кардәш-ыруыгыз юк шикелле, ярдәм-фәлән кирәк булса, авырсынмагыз, кулдан килгәнчә тырышырбыз, фатир мәсьәләсе ничек, кайда урнаштыгыз, канәгатьләндерәме ул сезне?

Фатир мәсьәләсен Галимҗан ничек аңлатырга да белмәде. Мескенләнергә аслан яратмый ул. Бу очракта да шаяртуга күчте:

— Борчылуыгыз өчен рәхмәт, Галиәсгар әфәнде! Фатирым менә дигән. Төрек солтаныныкыннан һич тә ким түгел. Өченче катта. Ике бүлмәле. Балконы бар. Шуннан матур эшләпәле ир-затлар, ак калфаклы ханымнар үтеп киткәнен карап торырга яратам. Тик аяклары гына күренми.

Галиәсгар Камал елмаеп куйды. Күрешкәндә үк "бәхет эзләүчемен" дип, шаярткан иде бит. Әле дә аның нечкә киная белән сөйләгәнлеге сизелде. Шуны искә алып, ул тагы да сорау бирде:

— "Бәхетеңне" таптың инде, алайса?

— Бәхет бит ул зимагур акчасы белән бер, Галиәсгар әфәнде: бүген — бар, иртәгә — юк.

— "Акча" дигәннән, бу мәсьәлә ничегрәк соң?

— Акчаң була торып та "юк" дисәң, үпкәләп, бар акча үз янына башкаларны чакырмый икән; аз гына акчаны да "бар" дисәң, акча үз янына ишләр килүен тели, ди. Моны Миасның Җиз эретү заводында бер эшче бабай әйткән иде.

— Дөньяны күп күрдең инде, Галимҗан туган, нугайлар, казакълар арасында мөгаллимлек итү, эшчеләр арасында эшләү... Мин синнән көнләшеп тә куям хәтта. Без инде шушы Казанда гына кайныйбыз. Бу яктан караганда, син, чыннан да, бездән бәхетлерәктер әле. Дөнья күрү — үзе бер бәхет. Ләкин син инде аны эзләп йөрмә хәзер. Артык эзләсәң, әлеге үзең әйткән зимагур акчасына әйләнергә мөмкин ул. Хәзер инде син иҗатка чум. Шулай да, балконга бик еш чыгарга киңәш бирмим. Матур эшләпәләр, гүзәл ак калфаклар фикереңне чуалтмасын. "Йолдыз"га эшкә дисәң — рәхим ит. Миастан алып килгән бер букча акчаң почмакта торсын. Хәзер инде яңа акчалар өчен икенче букча әзерлә.

Алар икесе дә елмаеп куйды. Галиәсгар Камалның үзенең дә шаярып сөйләгәнен аңлады Галимҗан. Бер ачылып киткәч, барын да сайрап салды. Татар халкы тарихын, аның сарыфын, нәхүен язу, гомумән, күп фәннәр белән шөгыльләнергә теләвен әйтте.

Алар кул кысышып аерылышты.

* * *

Көн һаман матур, кояшлы, күркәм иде әле. Һава саф. Күк йөзе зәңгәр батист белән тарттырып куйган төсле. Авылда — әбиләр чуагы. Кырга чыксаң, пәрәвез җепләренә ураласың. Ул җепләр зөбәрҗәт төсле елык-елык килеп тора. Бу чорда эшчән әбиләр ашыга-ашыга балан, миләш, шомырт җыя. Алар үзләрен шушы хозур табигатьнең илаһи бер бәхетле кемсәсе итеп тоя. Бу чорда әбиләр яшәреп, күңелләнеп китә хәтта. Табигать аларны сөя, иркәли, назлый. Әби йөрәге белән табигать йөрәгенең зөбәрҗәттәй пәрәвез җепләре илә бәйләнгән мәл бу. Шуңа күрә "Әбиләр чуагы" дип атала да ул. Шәһәр әбиләре моны аңламый. Алар карт күңелләрне дә дәртләндереп, хис-тойгыга күмеп, илаһиландырып җибәрүче шушы мизгел ләззәте белән рәхәтләнү бәхет-сәгадәтеннән мәхрүм булып яши. Алар таш исни. Кирпеч һавасы сулый. Тын кысылудан иза чигә.

Шул хакта уйлап атлады Галимҗан. Әле генә булып үткән вакыйгаларга анализ ясарга тырышты ул. Ләкин алары да нәзакәтле хис-тойгыларына пәрәвез җебе булып урала. Чәй эчәргә калмады ул. Моның берничә сәбәбе бар. Нинди генә кыю, чая булмасын, табындаш булып китүне ул авыр кичерә. Бу — бер. Икенчедән, кузгалган көчле бәхәснең һаман дәвам ителүе мөмкин. Ялгыш сөйләп, табын ямен бозуың бар. Беренче очрашу бит. Алар милләт әдәбиятының таҗы булу дәрәҗәсенә

күтәрелгән шәхес-әһелләр ләбаса. Фикер югарылыгын тотуда сынатмады шикелле. Әмма тупас сөйләште. Ни-нәрсәләр әйтте соң әле? "Таһарәт алырга кирәклекне белгән тәкъдирдә дә, таһарәт алмый намаз укыган шәкерт". "Поэзиянең мужик бәрәңге бакчасы түгеллеге..." "Бәхетнең зимагур акчасы кебек булуы..." Хәер, сөяксез тел ни сөйләмәс? Фикер алышырга ул махсус хәзерләнеп бармаган ич. Алдан уйлап куелган чагыштырулар да юк. Ничек кенә булмасын, борынгыларның "Кешенең акылы теле очында", — дигәнен онытмаска кирәктер. "Олы булма, акыллы бул", — дип тә әйтәләр. Олылык күрсәтеп тә сөйләште түгелме соң әле? Тукайны да, Фатихны да тәнкыйть итте. Ләкин ул һич тә үзен әллә кемгә куярга тырышудан түгел. Әгәр бу сөйләшү алар тарафыннан аның акылын бизмәнгә салу өчен кирәк икән — бу дөреслеккә туры килми. Ул, җиң сызганып, роман яза. Әмма поэзиягә дә гашыйк. Эче тулы моң. Шигърият уты дөрли йөрәгендә. Әмма шигърият мужикның бәрәңге бакчасы түгел — гөл бакчасы. Аның әле Сәгыйть Рәмиев, Дәрдмәнд, Тукай поэзиясе җимешләрен күрсәтә белергә кирәк. Халык рухи азык алсын. Алар чәчкән поэтик орлыкны киләчәк буын шагыйрьләре үстерә белсен. Тәмле җимешләр арасындагы тәмсез җимешләрне дә өзеп алып күрсәтәчәк. Болары инде җәһәннәмдәге бәндәләрне агулый торган зәкъкум агачы җимеше кебек. Кирәкми шигърияткә андый җимеш. Ул фани дөнья кешеләренең рухын агулый...

Шундый уйлар белән кайтып керде Галимҗан.

## XII

"Йомран оясы"нда аны "Казакъ кызы" көтә иде. Роман өстәлдә ята. Галимҗанны көтеп. Язарга утыргач, озак кына уйланып алды ул. Әсәрнең башланышы, үстерелеше, югары ноктасы бар. Күз алдына шундый чагыштырулы сурәт тә килеп басты. Менә ул биек тау итәгендә басып тора. Монысы — әсәр язарга керешү турында уйлану. Менә ул менеп китте. Бусы —яза башлау. Бервакыт уртага җитте. Хәзер — инде тау төшәргә кирәк. Монда инде әсәрдәге вакыйгалар чишелә, төрле табигатьле каһарманнар язмышы хәл ителә. Шул тау башыннан ул бөтен дөньяга күз ташлый да күңел күзен казакъ далаларында йөртеп кайтара. Әсәренең башланышына казакъча язып куйган сүзләрне укып рухлана:

Киң дала, күрәсен гуй, ана жаткан,
Жебәктәй жәсел чүптә битен жапкан.
Аскар тау, балдай татлы сулары бар.
Ана шул анам иде мине тапкан...

Янә шундый сүзләрне укып уйга чумды ул:

"Казакъның уртача байлыклы, күп адәмле ике ыругы бар иде. Берсен — Кара-айгыр дип, икенчесен Сарман дип атыйлар иде. Болар, меңләгән җылкылары, яхшы нәсел төяләре, исәпсез куйлары белән Сары-Арканың киң далаларында, ак тирмәләр корып, бер җәйләүдән икенче җәйләүгә үзләренең маллары артыннан рәхәт-рәхәт күчеп йөриләр иде. Бәхетләре ким түгел иде. Мәгәр "канымыз Чингиздән килә", дип мактанучы кайбер кабиләләр соңгы заманнарда, җир-суга тарлык кылып, үзләренең җәберләрен арттыра башладылар. Тик менә шул аларның күңелләрен борчый иде. Болай барса, ике арада яман гауга чыгу куркынычын алга китерә иде..."

Бу юлларны Галимҗан аз сүз белән күп мәгънә аңлату, җанлы картина тудыру, сурәтлеккә ирешү максатында язды. Шулар аша казакъның зур тормышы, яшәү рәвеше, уй-хыяллары укучының күз алдына килеп бассын. Шулай да бу башламны бик яратып бетермәде ул. Нигәдер ул газета теленә тартым сымак. Әдәби әсәрнең теле, өслүбе бизәкле, җанлы, нәзакәтле булырга тиеш. Чөнки анда әле иң әүвәл укучының аңына

түгел, ә бәлки йөрәгенә, күңеленә, хис-тойгысына тәэсир итү максаты куела. Карлыгач-Сылудан башларга кирәктер, бәлки? Аның язмышы бит әсәрдә. Шулай да калдырды ул әсәр башламын шул килеш. Баллы сүз баш әйләндерә, дигәне дә бар бит әле халыкның. Әсәр тукымасын гел баллы сүзләр белән генә нәкышләү килешеп бетмәс.

Романның эчендә бигүк урынлы булмаган сүзләр, җөмләләр бар иде шикелле. Әллә баштан алып янә бер кат укып чыгаргамы? Уйлана торгач, бу фикереннән дә кире кайтты. Юк, тәмамларга кирәк. Тау башыннан итәгенә тизрәк төшү хәерле булыр. Аны Карлыгач-Сылу язмышы борчый. Карлыгач-Сылу яшь ярымлык чакта күрше ыруның Калтай исемле ай ярымлык ир баласына ярәштерелә. Бу Кара-Айгыр белән Сарман ырулары арасындагы мөнәсәбәтне ныгыту өчен кирәк. Моның өчен 400 алтын, 100 баш терлек, ике сандык зиннәтле әйберләрдән калым алынган. Ике йорт уналты ел буе кода булышып яши. Карлыгач казакъ даласын бизәрдәй бер сылу кыз булып үсә. Калтай исә егетләргә хас барлык сыйфатлардан мәхрүм. Аларны яшерен кавыштырырга йөргән җиңгәсе Айбалага Карлыгач-Сылу болай ди: "Үзегез беләсез гуй: үткәндә берничә мәртәбә килде. Йортның җоласы, тәкъдирнең язганы шул икән дип, куеныма алдым... Мәгәр ни күрдем: буе тәбәнәк, йөзе яман шадра, борыны томшык, күзе кыйшык, тәненнән яман ис килеп тора! Ул бәндә белән, карагым җиңгәм, ничек гомер итәрмен?! Кайбер адәм бар: йөзе булмаса, сүзе, акылы белән күңелеңне ала, гайрәте, ирлеге белән йөрәгеңне тарта! Ул Калтай дигәннең яман куллары белән күкрәгемә маймыл кебек сузылудан башка эше дә юк, сүзе дә юк! Инде миңа ни кыл дисең?!"

Шушы урыннарны янә бер мәртәбә укып чыкты Галимҗан. Барысы да дөрес язылган. Казакъ халкының дала кебек киң күңеле яшәешкә киң даирә тәрәзәсеннән карарга өйрәткән иде Галимҗанны. Ул киң күңеллелектә — Карлыгач-Сылу кебек меңләгән гүзәл кызларның ачы, кызганыч язмышы. Бөтен мөселман дөньясында диярлек шулай. Татарларда һаман әле кызларны булачак ирен күрсәтми генә кияүгә бирү гадәте бар. Гарәпләр тугыз яшьлек кызны хатынлыкка ала. Күпме мыскыллауга, түбәнсетүгә, олтырак булуга түзә мескен мөселман хатын-кызлары. Ә менә нишләтергә Карлыгач-Сылуны? Ул инде зур кара күзләре белән Галимҗанга сөеп карый. Әдип аны төрлечә күз алдына китерә: "Аның башында каракүлле, озынча нечкә бүрек, өстендә нечкә билле, күкрәге, якасы укалы бишмәт иде. Аяк тавышына борылды, кара-туткыл йөзендә, матур кара күзләрендә җиңелчә елмаю уйнады". Шуннан Карлыгач-Сылу Галимҗанның алдына ук килеп баса. Гүзәл гәүдәсен уйнаклатып ала. Биеп тә күрсәтә. Җырлый. "Йомран оясы"нда дала моңы агыла. Ул Галимҗанның муенына да килеп сарыла. Нәфис йомшак куллары белән аның чәчләреннән сыйпый да:

— И хөрмәтле әкәм, мине ул яман исле Калтай белән калдырма, сөйгәнем Арысланбай белән кавыштыр", — дип пышылдый колагына.

— Юк, юк, Карлыгач-Сылу, хафа булма, бөтен казакъ халкы алдында ант итәм, мин сине җан сөйгәнең Арысланбай белән кавыштырачакмын! — ди Галимҗан.

Әйе, "Казакъ кызы"н ана тизрәк тәмамларга кирәк. Ашыгуның әллә күпме сәбәбе бар. Өйрәнчек хикәяләре аны әле оста язучылар сафына бастырмый. Шул җәһәттән фикер йөрткәндә, үзе уйлаганча, бу әсәре каләм очыннан ниндидер гәүһәр коелганлыкны күрсәтәчәк. Шул максат белән килде дә бит инде Казанга. Аны язып бетерү кесә мәсьәләсен дә хәл итәчәк әле. Университетка кереп уку теләге һаман тынгы бирми. Моны ул төшләрендә күрә. Хәзерләнү өчен берәр учитель ялламый булмас. Шуннан синең гонорардан килгән акча белән калынайган бай кесәң ярлылана башлый. "Йомран оясы" өчен дә түләргә кирәк. Миас җиз эретү заводындагы эшче дуслар акча җибәрмәскә куштылар ла ул. Ләкин алай килешми. Әгәр намусы кушканча эшләмәсә, гомер буе үкенеп яшәячәк Галимҗан. Димәк ки, аның хәзерге вакыттагы зур бәхете, яшәү

чыганагы "Казакъ кызы"на бәйләнгән. Шуңа күрә аны чыгып киткәндә дә, ятканда да өстәл өстеннән алып куярга ярамый. Һәрвакыт күз алдында булсын.

— И Галимҗан әкә, язмышымны тизрәк уңай якка хәл итче инде, — дип, кәгазь өстендә Карлыгач-Сылу биеп торсын.

## XIII

Ничек бәхетле итим соң сине, казакъ кызы — Карлыгач-Сылу? Бәхетне бит акчага сатып алып булмый.

Мин әле "Йомран оясы"нда, казакъ кызы! Димәк, минем хәятым — хәзергә салкын кыш. Ә тышта — яз. Авылда йомраннар ояларыннан күптән чыкты инде. Әрләннәр дә. Сыерчыклар бала чыгара. Сандугачлар сайрый. Ә минем өчен кыш. Мин — йомран. Киң дөньяга чыгу юлларын эзләп баш ватам. Язып бетердем мин, Карлыгач-Сылу, синең ачы язмышың турындагы "Казакъ кызы" исемле романны. Җибәрдем аны Оренбурдагы "Вакыт" нәшриятына. Фатих Кәрими әфәнде әсәрне алуы һәм яратуы турында хәбәр итте. Шатлыктан түбәм күккә тия язды. Әллә ничә тапкыр ыргып-сикереп куйдым хәтта. Менә чаклы, 1910 елда, Эстәрлетамак шәһәренең "Каләм" көтепханәсе "Татар хатыны ниләр күрми" дигән әсәремне бастырып чыгарган иде. Язмышларыгыз — уртак. Татар кызы Гөлбану да, син — казакъ кызы Карлыгач-Сылу да яратмаган ирдә торудан баш тартасыз. Икегез дә чая, чибәр, башбирмәс тай кебексез. Тик мин, Карлыгач-Сылу, бер ахмаклык эшләдем. "Казакъ кызы" романы миңа байлык китерә, янәсе. Шуннан килгән акчага хәятымны рәтлим: "Йомран оясы"ннан котылып, бурычларымны түлим, Нурислам абзыйга бирәчәгемне җибәрәм, кием-салым алам, ашказанымны затлырак ризык белән сөендерәм...

"Алла боерса" димәгәнмендер инде. Сарапул өязендәге Иж-Буби авылында тирә-якта дан тоткан мәдрәсә бар. Яктылык баш күтәрсә, меңләп шайтан аңа кара япма белән ябырыла. Бу мәдрәсәдә, имеш, пантюркизм канат җәйгән. Шул канатны сындырып ташлау лазем дипме, жандармнар, салам арасыннан энә эзләгәндәй, котырына-котырына, тотынмасыннармы тентү үткәрергә. Бу шомлы хәбәр, кырыс җилләрнең кара канатларына төялеп, "ә" дигәнче Казан, Уфа, Оренбург калаларына һәм башка урыннарга килеп төшә. Жандармнар, айга сикергән ахмактай, үрле-кырлы килә. Тентү, тентү, тентү. 1911 елның гыйнвар — февраль айларында була бу. "Казакъ кызы" романы да әләгә жандармнарның чәнечкеле кулына. Әсәрне кире кайтармыйлар. Шул хакта хәбәр итте Фатих Кәрими әфәнде. Күпме борчылу, йокысыз төннәр, газаплы хезмәт, каләм очыннан кәгазьгә төшкән гәүһәр уйлар юкка чыкты. Гәүһәрне диңгез төбеннән бөртекләп чүплиләр. Сүз гәүһәрен дә тел диңгезе төбеннән эзләп тирлисең. Бер романда әллә күпме миллион гәүһәр бар. Барлык гәүһәр харап булды!

Синең алда тау кадәре гаебем бар, Карлыгач-Сылу! Синең исәпкә яшәргә тырыштым бит. Нәфес бар кешедә. Нәфес. "Нәфесенә ияргән — шайтанга ияргән", — ди иде әткәй. Шуны да уйламаганмын.

Юк, мин сине ташламам, Карлыгач-Сылу! Романны яңадан язармын. Моны эшләмәсәм, гомер буе үкенеп яшәячәкмен. Син бу ачы хәлне әле белмисеңдер. Кара чая күзләрең йөрәгемне өтә. Бит очларыңдагы кызыллык пешкән алманы хәтерләтә. Чия төсле иреннәрең, энҗе тешләрең һушымны ала. Барыннан да бигрәк, миңа мәхәббәт кебек изге хис-тойгыны югары тота белүең ошый. Әдәпсез, илтифатсыз, бәндәчелекнең ни икәнлеген белмәгән, матур уйлардан мәхрүм булган Калтайны синең саф, садә, горур күңелең кабул итә алмады. Мәхәббәт — мәңгелек. Мәхәббәт — матурлык. Матурлык та мәңгелек. Мәхәббәт бизи тормышны. Мәхәббәтле яшәү кешеләрне зур, бөек, хөр итә. Мәхәббәтсезлек адәм баласын

түбәнәйтә, кечерәйтә, мескенләндерә, бәхетсез итә. Мин әле үзем, Карлыгач-Сылу, бәхет белән бәхетсезлек арасында. Кайсы якка авармын? Монысын бер Ходай үзе генә белә.

... Фатих Кәрими әфәндедән "Казакъ кызы" романының югалу хәбәрен алгач, Галимҗанның йөрәге өзгәләнде, чәч бөртекләренә хәтле дерелдәп, уртлары чәйнәлде. Жандармерия кире кайтарып та бирмәсен, ди. Ул романны барыбер яңадан язачак. Бусы ул тиклем куркыныч хәл дә булмасын, ди. Иң аламасы шул: кешеләр кешегә ышанмый, адәм балалары арасында яхшы мөнәсәбәт юк. Акны карадан аермыйлар. Наданлык. Җаһиллек. "Бөек" Русия кара томан эчендә иңри. Егерменче йөз башы. Татар халкы милләт булып оешты. Французларның илледән артык роман биргән Бальзагы бар. Урысларның бөтендөнья әдәбиятын баетырлык Толстой, Пушкин, Лермонтов, Тургенев, Достоевский, Чехов кебек йолдызлары бар. Егерменче йөз башы. Татарның ние бар? "Казакъ кызы" романы өчен шатланырга, горурланырга кирәк иде. Юк. Шуны да яшерәләр. И мескен татар! Ике яктан кабырганны чукмардай зур йодрык белән дөмбәсләп торуга түзәсең. Лачкылдатып йөзенә төкерәләр. Күпме тез чүгеп яшәргә мөмкин инде сиңа? Ә?!

Шундый давыллы уйлар белән акылдан шашыр дәрәҗәгә җитеп, өстәл артына барып утырды ул. Ни өчен икәнлеген үзе дә абайламастан, бер бит кәгазьнең уртасына "Казакъ кызы" дип язып куйды. Әйтерсең, романны яңадан яза башлый. Ул язмады, әлбәттә. Аның күз алдына Карлыгач-Сылу килеп басты. Елмая. Көлә. Шаярта. Аннан ул кәгазь өстенә үк менеп басты. Бераздан Галимҗанның муенына килеп сарылды. Аны иркәләп-назлап торды-торды да, өстәл өстеннән сикереп төшеп, Галимҗанның каршысына килеп басты. Шуннан Галимҗан, пышылдап кына, аңа эч серләрен сөйли башлады. Төнлә рәтләп йокламаган иде ул. Әнисе өйрәткәнчә, ничек кенә сабыр, түземле булырга тырышмасын, роман кайгысы аны газап казанына китереп салды. Төне буе кайнады кайгы казанында. Иртән чәй эчкәндәй итеп алгач, бөтенләй йомшарып китте. Карлыгач-Сылу югалгач күз алдыннан, өстәлгә бөгелеп төште. Йөзе әлеге "Казакъ кызы" дигән язуга туры килде. Шунда ул йокыга талды. Әллә йокы, әллә чир, әллә саташу булды бу.

* * *

Шәһит Әхмәдиев килеп кергәнне сизмәде Галимҗан. Моңа чаклы ул, Галиәсгар Камалга әйткән кебек, Шәһит белән дә гел шаярып сөйләште. Имештер, аның фатиры өченче катта. Ике бүлмәле. Балконнан матур эшләпәле ирләр, ак калфаклы купшы кызлар үткәнен карап ләззәтләнә. Аның шаяртуын белә Шәһит. Андый фатирда тору төшенә дә кермидер әле. Шулай да бу кадәр дә алама җирдә — подвалда яшидер дип уйламый иде. Кешеләрнең башлары түгел, аяклары күренә икән шул монда. Өстә бәләкәй генә тәрәзә. Аңа карасаң, аяклар күренеп-күренеп кала.

Шәһит белән Галимҗанның күңел якынлыгын бер-берсенә үрелеп үскән каеннар итеп күз алдына китерергә мөмкин. Оренбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсендә алар бер бүлмәдә торды. Шәһит — Галимҗаннан бер яшькә кече. Шәһитне Галимҗан "Хак Тәгалә" дип атады. Күңеле хак, саф, дөрес булган өчен бирелде аңа бу атама. Шәһит — ятим бала. Аңа ярдәм итүче юк. Ул бай шәкертләргә хезмәт итә: аш пешерә, табак-савытларын юа, пычрак киемнәрен тазарта... Моның өчен Галимҗан аны өнәп тә бетерми иде.

— Бу бит кешенең табан астын ялау, түбәнсенү була, Шәһит, — ди торган иде ул вакытта Галимҗан.

— Мин бит урлашмыйм, тамагымны кешегә хезмәт итеп туйдырам, — дип җавап бирә иде Шәһит.

Галимҗан — мулла малае. Акмаса да тама, дигәндәй, аңа ата-ана тарафыннан акча да, ашамлык та килеп тора. Галимҗан өлеш чыгара

башласа, Шәһит чыраен сыта: ул хәергә мохтаж түгел, янәсе. Эшләп ашарга кирәк.

Шәкерт халкы әрсез, була. Бәгъзе берсе кулындагы соңгы ризыгыны тартып алырга тора. Кеше үлсә —аларга шатлык. Җеназада аз булса да акча эләгә. Барысы да алай түгел, әлбәттә. Бу "гаскәр"гә Галимҗан үзе дә керми. Андыйлар тагы да бар. Шулай да Шәһитне башта аңлап бетермәделәр. "Хезмәтче малай" дигән атаманы да чәпәп куйдылар үзенә. Ләкин гарьләнмәде. Дөрес кеше икәнлеген күрсәткәч, аның хезмәтенә хөрмәт дигән зур мәртәбә өстәлде. Шуңа күрә атады аны Галимҗан "Хак Тәгалә" дип. Шәһит хезмәте белән генә түгел, матур күңелле, ягымлы, кешеләрне ярата белүе белән дә абруй казанды. Чибәрлеге, сабыйларча елмаюы, үзен бер дә юкка өстен куярга тырышмавы да бизи иде аның кешелеклелек сыйфатын.

Галимҗан белеме белән тиз арада шәкертләрнең тажы булу дәрәҗәсенә күтәрелде. Күп белүенә карап, "пәйгамбәрләр башы бар монда", дип, сөйли башладылар. Шәһит исә, бу сүзләрне кыскартып, Галимҗан өчен "Пәйгамбәр" дигәнен генә сайлады.

Галимҗан Вәли мулла мәдрәсәсеннән киткәч, Шәһит яши башлады аның мәсләге белән. Икенче төрле әйтсәк, Галимҗан урынына басты. Галимҗанга охшап, мәдрәсәдә тарих, әдәбият, җәгърәфия, хисап кебек фәннәр укытуны таләп итеп йөрде. Нәтиҗәсе бер генә — Шәһитне дә кудылар мәдрәсәдән. Шуннан алар "Галия"дә очраштты. Анда да шул ук хәл. Башта Галимҗан китте. Аннан Шәһит куылды.

Язмыш җилләре Шәһит белән дә аз шаярмады. Бәгъзе бервакыт аны уч төбенә утыртып иркәли. Шуннан җил, өермәгә әверелеп, аны тукмарга керешә, сугып ега, янә кулыннан тартып торгызып, әллә кайларга илтеп олактыра. Берчак Себер якларына очырып алып китеп, Иртыш буендагы бер авылга китереп ташлап китте. Табигатең күркәм, холкың һәйбәт, белемең бар, балалар күңеленә мәгърифәт нуры өстә, диде усал язмыш җиле.

1910 елның җәендә килде Казанга Шәһит Әхмәдиев. Хәзер инде аңа егерме ике яшь. Өстә матур костюм. Уйчан йөз. Иплелек. Кара мыек. Дугаланып киткән кара кашлар. Моңсу караш. Галимҗан рухы тарттымы Казанга? Тәгаен генә әйтү кыен. Килде дә ул типографиядә хәреф җыючы булып эшләргә тотынды. Әдәби әсәрләр иҗат итә. Публицистик мәкаләләр язып бастыра. Спектакльләргә, яңа чыккан китапларга рецензияләр яза.

— Без икебез бер чишмә суын эчәбез, Хак Тәгалә, — ди аңа Галимҗан.

— Алай ук түгел, Пәйгамбәр, синең чишмәң зур, ә минеке бәләкәй, — дип җаваплый Шәһит. Шуннан, бераз уйланып торгач, болай дип тә өсти: — Синең чишмә, шөбһәсез, диңгезгә барып кушылачак, моңа иманым камил, ә минекенең кибеп-корып та калуы ихтимал...

Галимҗан Шәһитнең Казанга килүенә мөкиббәнә нык шатланды. Яңа дуслар хәзер Казан тулы: Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин, Габдулла Тукай... Әмма халыкның: "Бер иске дусны биш яңа дус та алыштыра алмый", — дигәне рас икән. "Дуслык — ирнең ирлеге", — дип тә әйтәләр. Дуслыкта күрсәтә белә чын ирлекне Шәһит. Аңа йөрәгендә булганның — кайгы, сагыш, шатлык — барын да бәйнә-бәйнә сөйли аласың. Шуннан күңелең биниһая илаһиланып кала. Ә бәгъзе берәүгә йөрәк капкачын ачу бик куркыныч. Ачтыңмы — ул аны әллә ниләр белән тутыра, уйлыйсың — баллы сүз сала. Бераздан шул ачыклана — бал эчендә кылчык бар икән. Ул кылчык бервакыт тамагыңа килеп кадала. Кешеләр — катлы-катлы. Кәбестә шикелле. Шәһит алай түгел. Ихлас. Рыясыз. Ялганлый белми. Кеше ярата.

Фатирының кайда икәнлеген әйтмәде аңа Галимҗан. Ике бүлмәле, балконлы дип шаяртса да, Шәһит ышанмады моңа. Галимҗанның күзгә туры карап, маңгайга бәреп, алдашмый сөйләшкәнен унике яшьлек чагыннан ук белә ул. Шаяру катыш алдашканы бар. Ләкин анда да тотыла. Алдашты мы — күзенә туры карый алмый. Башын читкә бора. Әлеге ике бүлмә белән "мактанганда" да шулай итә.

— Сон, Пәйгамбәр, нигә күрсәтмисең инде ул төрек солтаныныкыдай зиннәтле фатирыңны? — дип сораса:

— Зиннәтле түгел шул әле, Хак Тәгалә, менә матур-матур җиһазлар, чибәр-чибәр келәмнәр, утырырга куркып торырлык йомшак кәнәфиләр алгач, чакырам барыгызны да: сине, Фатих Әмирханны, Тукайны, Галиәсгар әфәндене, Кәрим Тинчуринны, тагы да бик күпләрне, — дип елмая да күзләрен чет-чет йомып-ачып, башын читкә бора. Кайда яшәгәнлеген сорасаң — әйтми.

... Беркөн Шәһит икмәк кибете янында ике карчыкның сөйләшеп торуына шаһит булды. Алар бик кычкырып гәпләшә. Колакка катыраклар шикелле. Икесенең дә кулында өстәмә көч бирүче өченче аяк — таяк. Өс киемнәре буенча фараз итсәң, аларның ярлы нәселдән яралуларын аңлау һич тә кыен түгел. Бишмәтләрендәге ямаулар, әйтерсең, кием ертыгын гына түгел, йөрәктәге авыр яраларны каплау өчен дә салынган. Аякларындагы иске кәлүшләр дә дөнья кайгысын бу карчыклар белән әллә ничә еллар инде бергә кичерү турында ыңгырашып сөйләп торалар. Берсе — ак, икенчесе кара яулык бәйләгән. Менә аларның әңгәмәсе:

Ак яулык:

— Кызым белән киявем куып чыгарды бүген. Күп сөйләшәсең, диләр.

Кара яулык:

— Инде кая бармак буласың?

Ак яулык:

— Белмим. Ходай Тәгалә бер урынга куяр әле.

Кара яулык:

— И... бу дөньяның авырлыгы.

Ак яулык:

— Бик рәхәт яшәгән кешеләр бар да бит...

Кара яулык:

— Кемнәр?

Ак яулык:

— Байлар.

Кара яулык:

— Аларның да төрлесе бар, җаныкаем. Минем подвалда бер мөхәррир тора әнә. Тамагы ач, өстендәге киеме таралып төшеп бара. И... мескен!.. Фатир хакын түләр рәте дә юк. Үзе көн-төн яза, яза, яза... Юньләп йокламый да бугай.

Шул сүзләрне ишеткәч, Шәһит сорарга мәҗбүр булды:

— Әби, шул мөхәррирнең исемен әйтә алмассызмы?

— Нигә әйтмим ди.

— Кем соң ул?

— Улмы? Ул... ни... Галим... Галимҗан була.

— Әбекәем! Хәзер адресыңны әйт инде, алла хакы өчен...

— Нигә кирәк ул?

— Без аның белән Ырынбурда да, Уфадагы "Галия" мәдрәсәсендә дә бергә укыган шәриктәшем булырга мөмкин. Аңа ярдәм итәсем килә.

— Бик мәгъкуль, бик муафыйк, бик изге бу эшең, балакаем! Бик асыл зат күренәсең. Киемең дә бик матур, йөзеңдә дә — иман нуры. Тик, балакаем, син аңа шуны әйт: иң әүвәл миңа фатир хакын түләсен. Әйтерсеңме?

— Әйтермен, әбекәем!

— Мин үзем дә шул акчага гына карап торам бит, балакаем! Элек кул эше белә идем. Хәзер уң кулым бөтенләй катты. Менә бит...

Әбинең уң кулындагы биш бармагы да бергә укмашкан икән шул. Алар инде җансыз, хәрәкәтсез — үлем якынлашуны хәбәр итеп торалар шикелле. Бер Себер татары Шәһиткә дөньяда өч ямьсез нәрсә булу турында әйткән иде: картлык, фәкыйрьлек, чир. Бу әбидә өчесе дә бар хәзер. Ходай аңа үзе ярдәм итсен инде!

Шәһит, кесәсеннән алып, аның әле бөрешеп катарга өлгермәгән сул

кулына бер көмеш акча тоттырды:

— Хәердән булыр, әбекәем!

Нәкъ шул ук вакытта ак яулык та кулын сузды. Аңа бер көмеш акча бирергә туры килде Шәһиткә.

Әбиләр рәхмәтләр укып, дога кылдылар.

Адресны алгач, Шәһит китеп барды. "Алла юк" дигән кешенең теле корысын. Кем уйлаган икмәк алырга килгән җирдә табылыр дип анын адресы. "Бирим дисә колына, чыгарып куяр юлына", — дигәннәре мең кәррә дөрес икән. Ул кулындагы букчасына икмәк кенә түгел, башка кирәк-яракларны да салды. Төрле кибетләрдә булып, аннан дусты янына китте.

Галимҗанны нишләтергә дә белмәде Шәһит. Уятыргамы? Әллә азрак ял итсенме? Аның бит Оренбурда да, "Галия" мәдрәсәсендә дә, укып-укып арган яки авырып киткән чакта, баш терәп черем итеп ала торган гадәте бар иде.

Шәһит өстәлнең бер як читендәрәк торган кәгазьне алды кулына. Анда — Казанга килгәч басылган әсәрләре, мәкаләләре, рецензияләре, фәнни хезмәтләре. Ни арада күпме хикәя бастырып алган: "Яз башы", "Диңгездә", "Йөз ел элек", "Сөю —сәгадәт", "Уты сүнгән җәһәннәм", "Карак мулла", "Карт ялчы", "Татар хатыны ниләр күрми" Рецензияләр... уку-укыту мәсьәләләре...

"Моның чишмәсе диңгезгә барып кушылган инде", дип уйлады Шәһит. Күпме хезмәт! Шулар өстенә роман язу. "Казакъ кызы"н Оренбурга җибәргәч, "Яшь йөрәкләр" романын яза башлаган бит әле ул. Ничек житешә барысына да? Ярый, хикәяләр, романнар язсын да, ди. Ул инде — чын язучы. Эче тулы моң. Ут. Давыл. Ул моңны кәгазьгә төшермәсә, хыялга сабышырга мөмкин. Ул утны каләм очыннан кәгазь битенә түкмәсә, аның янып үлүе бар. Ул давылны әсәргә әйләндермәсә, аңа яшәүнең бер кызыгы да калмаячак. Ә менә бер ел эчендә "Татар сарыфы", "Татар нәхүе" яза алуына ышанасы килми хәтта. Ул бит һаман әле университетта уку хыялы белән яши. Нигә кирәк ул аңа хәзер? Бу ике хезмәтне оста тел галимнәре генә яза ала. Аларны бит университетта уку-укыту әсбабы сыйфатында кулланалар. Димәк, ул — хәзер үк инде профессор, академик дәрәҗәсендәге кеше. Менә кемдә пәйгамбәрләр башы!

Шулай уйланып торганда, аның күзе янә өстәге тәрәзәгә төште. Ял көне кеше күп йөрүчән була. Тыз да быз. Аның шулай икәнлеген Шәһит күренеп-күренеп калган аяклардан чамалап белә. Тукта! Ни бу! Ул абайламый да калды хәтта. Галимҗан, уянып, торыйм дисә, башы әйләнеп, идәнгә гөрселдәп килеп төште. Шәһит, күтәреп алып, аны караватына салды. Елмаеп куйды Галимҗан. Ул кадәр куркыныч түгел, янәсе. Бераз яткач, ул торып ук утырды. Дустына озак кына гаҗәпсенеп карап торды ул:

— Мине ничек... таптың, Хак Тәгалә?

— Хак Тәгаләнең үз пәйгамбәрен таба алуы гаҗәпмени?!

## XIV

Шәһит өстәлдә тулып, таралып яткан китапларны бер як кырыйгарак өеп куйды да табын әзерләде. Хәзер инде казылык, ак икмәк, тозлы балык кебек нәрсәләр уртасында бер шешә шәраб та кукраеп утыра.

Шәһит йомшак, моңлы, шул ук вакытта җитди тавышлар катыш шаярып сөйләште:

— Рәхим итегез табынга, Галимҗан галәйһиссәләм!

— Мин әле төш күрдем, Хак Тәгалә! Күкнең җиденче катында булдым. Һәр катның уң ягында — оҗмах, сул ягында — тәмуг. бер катның тәмугында фани дөньяда яшел елан белән дус булганнарны җәзалыйлар.

— Ничек?

— Утта кыздырылган кайчылар белән иреннәрен, телләрен кисәләр.

— Әле син шуннан шүрләп аудыңмы идәнгә?

Галимҗан көлеп җибәрде:

— Башым әйләнеп китте, Шәһит галиҗәнаплары!

— Ярый, әйдә, утыр әле, хәзер без җайлыйбыз башларны.

— Кунакны хуҗа үзе сыйларга тиеш.

— Андый чагыңны да өмет итәбез.

— Булырмы?

— Иншаллаһ!

Табында Галимҗан әлеге җиде кат күк капусын чыннан да күрүе турында сөйләде. Беренче катта — Исмәгыйль, икенчесендә — Гайса, өченчесендә — Йосыф, дүртенчесендә — Идрис, бишенчесендә — Һарун, алтынчысында — Муса, җиденчесендә — Ибраһим пәйгамбәр белән очрашкан, имеш. Нәсел кәүсәләренең җиде буын башында Ибраһим хәзрәт булган бит. Шуннан арысын белми әтисе. Әмма ун, егерме, утыз буыннарга китә бит ул. Барысын да кем белсен инде аның. Шуны уйлап, әтисе белән үзләре кавеме таҗындагы Ибраһим хәзрәтне Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәләм тәхетенә китереп бәйләргә ярата иде. Шуңа күрә җиде буын һаман ташламый “Ибраһим” дигән фамилияне. Бу мәсьәләгә Галимҗан моңа кадәр артык игътибар итми иде әле. Ә менә бүген күкнең җиденче катындагы Ибраһим пәйгамбәрнең үзен күргәч, нәсел-нәсәбенә булган мәхәббәте мең кәррә артып китте. Ибраһим пәйгамбәр ифрат мәһабәт гәүдәле. Ап-ак сакаллы. Мөлаем йөзле. Чәчләрендә энҗе бөртекләре җемелди. Өстендәге җиләне көмештәй ялтырап тора. Ул Галимҗанның аркасыннан сөеп куйды:

— Сөбханаллаһ, хур егетләре кебексең, күкнең җиденче катына син Аллаһу Тәгалә кодрәте берлә күтәрелдең, инде Җир улларына Иман нуры алып кайт та шуларны аларның күңеленә индер, — диде.

Шулай сөйләшеп торганда алар янына беренче пәйгамбәр, Адәм галәйһиссәләм белән ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәләм очып килеп җитте. Рәсүлебез Мөхәммәд галәйһиссәләм Аллаһы сөбханә вә Тәгаләнең кодрәте белән Галимҗанны газиз җиребезгә кайтарып куя имеш...

Ашап-эчеп утырганда шул хакта сөйләде Галимҗан. Чынмы бу төш? Түгелме? Дустының шаярта торган гадәте барлыгын белә Шәһит. Белемеңне сынар өчен кайчак. Авыр, кайгылы вакытларда да шулай итүчән. Шаярта. Җор сүзе белән күңелләрне күтәрергә тели. Кайгыны кайгы куерта гына, аңа бирешеп, йомшак көпшә урынына бөгелеп төшәргә ярамый, киресенчә, башыңны ил белән ипле идарә итә белгән горур патшадай, югары күтәреп йөрергә кирәк, янәсе.

Шәһит, Галимҗанның үзе кебек, уратып-чуратып, шаяртып сөйләште:

— Мин дә бүген бер төш күргән идем, Галимҗан галиҗәнаплары, нәкъ синеке ише; бу инде безнең йөрәкләрнең чыннан да алтын пута белән бәйләнгәнлегенә бер дәлилдер. Тыңла! Күкнең җиденче катында мин дә булдым бит. Иң әүвәл Ибраһим пәйгамбәр, аннары беренче пәйгамбәр Адәм галәйһиссәләм, ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһиссәләм белән күрешүеңне карап тордым. Мөхәммәд пәйгамбәр сине Җиргә алып киткәч, мин Ибраһим пәйгамбәр белән калдым. “Җиде буынга сузылган Ибраһимның нәсел-нәсәбе мин. Ибраһим пәйгамбәр тамырыннан үсеп чыккан кәүсә ул, тик менә җиденче буын капкасын ябып, сигезенче буын капкасын ачкан Галимҗан Ибраһимга бер бүләк тә бирә алмаганмын. Бу — минем хата. Хатаны төзәтмәү — зур гөнаһ, инде төзәтәм. Менә бу бәләкәй генә төенчекне тапшыр аңа”, — диде Ибраһим галәйһиссәләм.

Шәһит, кесәсеннән алып, Галимҗанның кулына кечкенә бер төенчек тоттырды:

— Син фани дөньяда хәмер белән шөгыльләнүче әрвахларның ахирәттә телләрен, иреннәрен утлы кайчы белән кисү турында әйттең. Ә инде әманаткә хыянәт итүчеләрне ахирәттә аннан да катырак җәза көтә икән.

— Нинди?

— Утлы казанда кайнаталар. Әманәт — иман кебек ул. Тапшырдым. Төште өстән бурыч. Вәссәлам!

Галимҗан аңа башын кыйгайтып карап торды:

— Син, Хак Тәгалә, элек болай түгел идең бит. Сүзгә нык остарып киткәнсең.

— Исле гөл янында иссез гөл дә хуш исләнә.

— Кем соң ул "исле гөл"?

— "Кем соң ул?" дип сораган кеше.

— Димәк — мин?

— Хәзер инде әманәтнең ни икәнлеген белик. Актар төргәгеңне.

Кәгазь акчаларны күргәч, Галимҗанның күзе дүрт булды:

— Кайдан алдың бу кадәр күп акчаны?

— Соң, Алла колы, әйттем ләбаса инде: Ибраһим пәйгамбәр җибәрде, дидем. Менә шул. Иң әүвәл фатир хакын түлисең...

— Ә ул түләнмәгәнлекне каян белдең?

— Ибраһим пәйгамбәр әйтте.

— Ай-һай, син Шәһит!..

— Ай-һайлама! Бурычын түләмәгәннәргә дә закон каты теге дөньяда.

— Нишләтәләр?

— Утта кыздырылган таш ашаталар.

Галимҗан кычкырып көлеп җибәрде. "Дуслыкның теле каты булса да, күңеле йомшак", — диләр. Алар гадәттә бер-берсе белән кәнфитләнмиләр. Чәнчеп-чәнчеп алырга да күп сорамыйлар. Шәһит артык йомшак күңелле, тәмле телле, ихлас бала иде. Акылы, иплелеге, ягымлы күз карашлары белән үзен яраттыра иде. Бу үзенчәлеге дә үзгәрмәгән диярлек. Шулай да ул хәзер башка Шәһиткә әверелеп бара. Тавышы түлле. Йөзендә берникадәр кырыслык чаткысы. Карашы житди. Элекке кебек сүз әйтергә куркып тормый. Шул инде, Тормыш-бабай кешеләрне игәүли, чарлый, яшәү гәүһәрен табарга өйрәтә. Кырыс табигатьле Себер якларында яшәүнең гәүһәрен генә түгел, акылның алтыннарын да тапкандыр. Йөргән таш — шомара, яткан таш — мүкләнә, диләр бит.

Озак утырды бүген ике дус. Дуслыкның күңелен йомшартканчы.

## XV

Күк йөзен кара болыт каплый. Давыллар куба. Күк күкри. Күк дөньясын утлы еланнар — яшеннәр телгәли. Коеп яңгыр ява. Гарасат агач ботакларын сындырып ыргыта. Мондый манзарә-күренеш кешеләр күңеленә курку сала. Ләкин ул мәңгелек түгел. Кайчак бик тиз, бәгъзе бервакыт озаграк булып, аннары ялтырап кояш чыга. Аның йомшак нурлар белән иркәләве, елмаеп-сөеп каравы бәндәләргә илаһилык, ләззәт, яңа сихри көч бирә.

Бу — табигый хәл. Яшәештә: аклык-каралык, яхшылык-яманлык, шәфкатьлелек-шәфкатьсезлек көрәше. Бу әллә кайчан да шулай булган. Хәзер дә шулай. Мәңге шулай булачак. Дөнья шуна корылган. Капма-каршылыкка.

Галимҗанның күңел күге дә шулай. Кара болытлар булды. Ми күзәнәкләрен утлы уй яшеннәре телгәләде. Давыл-өермәләр котырынды. Болар инде — үткән күңелсез хәтирә. Хәзер аның күңел күге — аяз, кояшлы, якты. Тормыш әле аны әнисенекедәй ләтыйф куллары белән иркәли. Ул Киевка китә. Аннан чакыру кәгазе килде. Татар студентларына, гимназистларына дәрес бирәчәк. Киевта мөселман студентларының яшерен оешмасы бар икән. Шулар белән элемтәгә керәчәк. Монда — Казанда аның университетка керү хыялларына йодрык күрсәттеләр. Шулай булуының әллә күпме сәбәбе бар. Ирешә алмады ул өлгергәнлек аттестаты алуга. Анда — университетта — иләктән нык илиләр икән. Урыс балалары үтә әлеге жиз иләктән. Мөселманнар өстә кала. Көрпә булып. Оренбурдагы "Хөсәения" мәдрәсәсенә сәламәтлеге яхшы булмаган өчен алмадылар. Ә Казан университетында тырнак араңнан керне ныклап эзлиләр икән әле.

Ул — ике мәдрәсәдән куылган мәхдүм. Оренбурда патшага каршы оештырылган демонстрациядә катнашты. Уфа вокзалында думага китәчәк депутатларны тозлы сораулар белән тетрәндерде. Шәкертләр, ирек сөюче яшьләр дулкыны катнашты анда. Башлык булды Галимҗан. Мондый "ышанычсыз" кешене университет кара чыраен сытып каршылый. Киевта аны бирәү дә белми. Кара сакалы артыннан ияреп бармаячак. Уфа һәм Казан калаларында калачак.

Оренбургдагы Фатих Кәрими янә бер хат язды. "Казакъ кызы"н жандармнар югалткан. Шулай да Галимҗан өметен өзмәде: табылыр, бәлки. Ләкин аның өчен әрнеп гомер үткәреп булмый. "Яшь йөрәкләр" романын язарга тотынды ул. Шашып-шашып язды. Тиз. Ярсып. Мөкиббәнә кайнар хис-тойгы белән. 1912 елның май аенда соңгы сүзенә зур нокта куйды.

Басылып чыккач, күккә күтәреп мактадылар романны. Тәнкыйтьчеләр жылы сүз әйтергә ашыкты. "Аң", "Хокук вә хәят" журналларында, "Йолдыз", "Вакыт", "Идел" газеталәрендә рецензияләр язылды. Җамал Вәлиди болай дип язды: "Яшь йөрәкләр", үзенең зурлыгына карамыйча, Галимҗан әфәнденең башка әсәрләреннән ким түгел. Бер диккать вә мөлахәзә илә язылган, вә шуның сәясәтендә әсәр күркәм вә тәмле дә чыккан. Бигрәк тә сүзгә осталык вә фикергә байлык җәһәтеннән әсәр татар әдәбиятында беренче урынны тотарлык".

Галимҗанның йөрәк моңы, кайнар хис-тойгысы, күңел зәвыгы салкын кан белән язылган романнарны сөйми. Ул бөтен татар прозасының сәнгатьлелеге өчен көрәш ачты. Бер үк вакытта тәнкыйтьче булып китүе дә шуңа бәйләнгән. "Әдәбият мәсьәләләре" дигән хезмәтендә болай дип язды ул: "Безнең бик күп мөхәррирләребез авыр вә үтереп язалар. Күбесе бер бәхетсез каһарманны колагыннан тотып ала да, шуның ялгызын хикәяненң буена өстерәп йөртеп, татар тормышында булуы мөмкин күренгән һәрбер пычракка илтеп чумдыра, батыра, шуның илә хикәя бетә торган була. Аларда буяу аз, аларда действие булмый. Алар чын мәгънәсе илә үлек кыйсса ясап чыгаралар..." И бу наданлык! И бу томаналык! И бу җаһиллек!

Шундый уйлар кичерде Галимҗан. Ялгызы. Берүзе. Уйлар кайчак тәмле, татлы, ләззәтле була. Бәгъзе бер вакыт уйларның тәмсезе, ачысы, кылчыклысы болгата баш миендәге күзәнәкләрне. Матур, төпле, мәгънәле уйлар күкнең җиденче катына күтәрә адәм баласын. Тозсыз уйлар аны кечерәйтә. Моңсу, кайгылы, сагышлы уйлар хыялга сабыштыра. Галимҗан күңелендә әле ул уйларның һәммәсе уптым-илаһи берләшкән. Тәмлесе дә, тәмсезе дә, кылчыклысы да, тозсызы да, сагышлысы да... — барысы да бар. Тәмлесе — Киевка китү. Тәмсезе —"урлашуда" гарьләнү. Моңсуы — туган якларын сагыну. Ничек кенә булмасын, мәгънәле уй кешене мәнсезлектән коткара, үз-үзенне танып-белергә ярдәм итә. "Кешегә иң авыры үзен аңлау", — диләр бит. "Үзен танымаган кешене танымас", — дип тә әйтәләр. "Үз турында кешеләрдән сора", — дигәне дә бар. Боларның өчесе дә карый Галимҗанга. Фикерләвенчә, ул әле үзен белеп-аңлап бетерми. Димәк, кешеләрне тану сәләте дә җитми. "Яшь йөрәкләр"дәге Зыя турында көчле бәхәс купты. Тәнкыйтьче Г. Газиз болай диде:"... бик тормышта муафыйк, бик татар галәмендә, бигрәк тә фанатизм золымы астында тәрбия кыйлынган бер типтыр". Сәйфи-Казанлы исә башкачарак әйтте. Зыяның типик образ булмавын расларга тырышты: "... мондый кешене каян эзләп тапкандыр инде. Аның башы-аягы белән музыкага бирелүе аны рухани авыру дип уйларга мөмкинлек бирә", — диде.

Нык уйланды Галимҗан бу хакта. Ике тәнкыйтьченең уты арасында калды. Бу утны ерып чыга алды ул. Янмады. Көймәде. Ахыр чиктә килеште Сәйфи-Казанлы белән. Чыннан да, Зыя башы-аягы белән моң дәрьясына чумган. Әйтерсең, яшәеш шуннан гына тора.

Шулай да бу роман Галимҗанга үзен-үзе танып-белергә ярдәм итте. Бусы — бер. Икенчесе шул: башкалар аның рухи дөньясында нинди асылташ ятканлыкны аңлады. Маңгайга бәреп сөйләшүенә, кырыслыгына, тәкәббирлегенә карап, Галимҗанны артык "коры" кеше дип исәпләүчеләр дә

шактый күп иде. "Яшь йөрәкләр" дөнья күргәч: "Эче тулы моң икән бу Галимҗан Ибраһимовның", "Салкын йөрәкле мөхәррир мондый роман яза алмый", "Кеше язмышы өчен нык борчыла икән", кебек аяклы хәбәрләр йөри башлады. Шулай да Галимҗан, киләчәктә бер форсаттан файдаланып, үз йөрәге кушканча гына түгел, ә бәлки кин җәмәгатьчелек фикеренә сәҗдә кылган хәлдә, "Яшь йөрәкләр" романының тукымасын янә бер мәртәбә нәкышләячәге турында уй беркетте.

Мондый уй "Татар хатыны ниләр күрми" повесте басылып чыккач та булган иде. "Татар хатынының ир олтырагы булуы, каенана, каената зәкъкумында яшәве мәгълүм инде анысы. Бу кадәресе әсәрдә дөрес бирелгән. Хәтта артыгы белән. Әмма Гөлбануның ирләр киеме киенеп йөрүе — татар хатыны өчен типик яки табигый хәл түгел. Монысын ташлап, Гөлбануның фаҗигый хәятен тирәнәйтү мотлак. "Калган эшкә кар ява", — дип әйтүе бар анысы. Әйдә, хәзергә яусын кар. Капласын. Өй биеклеге булса да, язын кар эри ич. Килер яз — "Татар хатыны ниләр күрми" өстенә яуган кар да эрер. Шуннан әсәрне яңадан язар ул.

Каты телле Галимҗанның нечкә күңеллелеге, садә йөрәге, моңсулыгы, мәхәббәт тойгылары, табигать дөньясы илаһилыгы белән яшәве "Яз башы", "Дингездә", "Сөю — сәгадәт" кебек әсәрләрендә дә чагылды. "Йөз ел элек" хикәясендә күңелен шактый ерак тарихка сәяхәт иттерә. Баксаң, анда да дөнья гөнаһ ияләре белән тулы икән. Изге гамәл ияләре шифалы канатларын җәя алмый иза чигә икән. Яшәеш җепселләре ныклы булмаган. Җаһиллек. Караклык. Шәфкатьсезлек. Шулар үзәгендәге җепселләр, агулы елан булып, изге күңелле адәмнәргә зәһәрен чәчә-чәчә, һаман алга үрмәли. Ничек көрәшергә явыз көчләргә каршы? Агулы еланнарның башын ничек өзәргә? Шул уйлар аны "Карак мулла" хикәясен язарга мәҗбүр итте.

Уйлар! Уйлар!! Уйлар!!! Ничек арынырга алардан? Алар, кара сакал булып, Киевка ияреп бармасын иде инде. Яңа урынга Казанның корымын алып бару килешмәс.

## XVI

Күктә йолдызлар ничаклы — безнең дуслар шулчаклы, дигәндәй, дуслары күп хәзер Галимҗанның. Сакла, Ходай дуслардан, дошманнан үзем сакланырмын, дип тә әйтәләр. Ни гаҗәп, дошман дустан килеп чыга. Дусның дошманга әйләнүе — иң ачы кайгы. Казанда өч ел яшәү дәверендә андыйлар да булмады түгел. Андыйлар "Яшь йөрәкләр" романы басылгач калкып чыкты. Ялган яла ягулар каралыгын суд хөкеме генә агартты. Бусы инде — көнчелек галәмәте. Озак яңгыр яумый торса, үләннәр көя, саргая, күктән шифалы яңгыр өмет итә. Милләт күңеле дә шулай бит. Ул көйгән, сулган, касмакланган. Ул нидер көтә. Аңа нидер җитми. Аңа ниндидер зәвык кирәк. Әдәби әсәр бирә зәвыкны. Аның күңеленә нур, матурлык тойгысы, мәгънә орлыгы сала.

Тукай белән Галимҗан берничә мәртәбә махсус фикерләште. Әлеге беренче очрашуда ук купкан бәхәс давылы файдага тынды шикелле. Фатих Әмирхан — сабыр, салкын канлы. Эзле, уйлап, тиешенчә сөйләшә. Юкка-барга уттай кабынып китми. Туры әйтергә ярата. Туры әйткәнгә үзе дә үпкәләми. Ә бит сүз гел әдәбият турында бара. Фикерләр шәхси караш кысасында гына калмый. Фикерләр — гомуммилләт әдәбиятын үстерү турында. Моны Галиәсгар әфәнде дә нык аңлый. Ул кешелеклелек дәрәҗәсен дә югары тота. Берничә мәртәбә чакырды Галимҗанны үз өенә. Ләкин Галимҗан ризалашмады. Күп-күп рәхмәтләр әйтү белән котылырга туры килде аңа. Ә инде Кәрим Тинчурин, Шәһит Әхмәдиев белән булган дуслык чылбыры аларның күңелләрен бик нык бәйләде. Алар үзләрен "өчпочмак" дип атады хәтта. Моны башкалар да әйтә. "Дустыңа — дуслык бурыч", "Дуслык акчадан кыйммәт", "Дус хакы өчен — җан фида" кебегрәк мәкальәйтемнәрне искә алып яшиләр. Чын дуслык утының сүнмәс дәрәҗәдә

кабынып китүендә сәбәпләр дә бар. Шәһит белән Галимҗан Оренбурда да, Уфада да бер үк мәдрәсәдә укыдылар. Алардан икесе дә куылганнан соң, берсе — Себердә, икенчесе Кавказда, казакълар арасында мөгаллимлек кылды. Хәзер икесенең дә дөньяга, кем әйткәндәй, педагогик күзлектән карау мөмкинлекләре бар. Кәрим Тинчурин белән дә язмышлар уртак. Икесе дә 1887 елда туганнар. Кәрим Тинчурин да, Галимҗан һәм Шәһит кебек, 1905 елгы революция дулкыннары эчендә кайнаша, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә үзгәртүләр, яңалыклар даулый, тәрәккыят өчен көрәшә. Аңа да мәдрәсәдән китәргә туры килә. Шуннан соң, Галимҗанга охшап, төрле "кара" эшләр башкара, урман каравылчысы булып тора, мөгаллимлек итә. Хәзер елына йә бер, йә ике драма әсәре яза. Үз әсәрләрен сәхнәгә үзе куя. Үзе үк уйный да. Шул арада мәкаләләр, рецензияләр дә яза. Кыскасы, кем әйтмешли, башы-аягы белән әдәбият-сәнгать дингезенә чумды. Кеше иң әүвәл әле ашка бәһане өресенә карап бирүчән. Кәрим Тинчуринны уптым-илаһи белән алган шөгыльләр өресе — Кешелеклелек. Ул ихлас, чын күңелдән, мөкиббәнә дус була белә. Риясыз. Алдашмый. Үз фикерендә нык тора. Шул сыйфатлары өчен ярата аны Галимҗан. Шулай итеп, өч дус өчпочмак тәшкил итте. Һәр почмакта — бер шәхес. Һәр шәхеснең йөрәгендә — зур дөнья. Язмыш. Бәхет төрлелеге. Сәләхиятлелек.

Янә шунысы бар. Якын гына кешеләр дә бер-берсенә "әфәндем", "галиҗәнап", "хәзрәтләре" кебек сүзләр белән эндәшә. Андый нәзакәт, аһәң нәфислеге җәмәгатьчелектә кирәк, әлбәттә. Әмма "өчпочмак" калыбындагы шәхесләребез үзара тапкан атамалары белән сөйләшергә ярата. Галимҗан "Шан-Галим" булып китте. Шан — гарәп телендә бөек, зур, югары, кадерле, мәртәбәле дигән мәгънәдә. Димәк ки, "ж" авазын "ш"га алыштыру Галимҗанның күп фәннәр чылбырын бер төен тирәсенә җыю кодрәтен чамалата. Галимҗанның әтисе Гыйрфан мулла, бик якын кеше белән сөйләшкәндә, "әй" ымлыгын кыстыручан. Ул рәсми аһәңлектән качып, гадилеккә, ихласлылыкка күчәргә дә ярдәм итә. Ата-ана күп вакыт бер-берсенә "әй", "әйкәем" дип эндәшә. Аларның бу сыйфаты Галимҗанга да йокты. Галимҗанның "туган", "туганкай" дип әйтә торган гадәте дә бар. Шәһит тә — гарәп сүзе. Гарәптә хак өчен сугышта үлүчеләргә карата әйтелә ул. Шәһит хаклык, дөреслек, гаделлек ярата. Тугрылыклы дус була белә. Шуңа күрә Галимҗан аны Оренбурдагы Вәли мәдрәсәсендә үк "Хак Тәгалә" дип атаган иде. Тап төшермәде ул бу атамасына. Хәзер дә дуслары аны "Хак Тәгалә" дип йөртә. Кәрим дә — гарәп сүзе. Әллә күпме мәгънәсе бар: юмарт, рәхимле, киң күңелле, хөрмәтле, кадерле, бөек, газиз. Шул төшенчәләргә бай Кәрим Тинчурин күңеле. Шуңа күрә аның намус гәүһәренә "Кәримбай" дигән мөһер сугылды.

Бу сыйфатын Тинчурин бүген янә бер мәртәбә күрсәтте. Кулындагы шактый зур төргәкне чишеп җибәрде дә иске киемнәрен салырга кушты:

— Син ни кыланасың әле, Кәримбай, әллә акылыңнан шаштыңмы? — дип аптырады Галимҗан.

— Соңыннан аңлатырбыз, Галимҗан галиҗәнаплары Шангали. Синең бүгенге шөһрәтеңә карап тап төшерүче бу кылкаларыңны салып ыргыт та, менә боларны киеп җибәр әле. Кунакны киеменә карап каршы алалар. Акылы — соңыннан. Анысы аның синдә җитәрлек. Күрсәтә белерсең. Хак Тәгалә дә шулай уйлый. Әллә ямьле Киев каласында чибәр туташлар алдына шушы сәләмә киемең белән барып басар идеңме? Әллә Киев татарлары белмиме синең мәшһүр язучы, галим дәрәҗәсенә күтәрелгәнеңне?

— Кем киемнәре соң болар?

— Анда синең эшең юк. Мөбарәк урынга мәһабәт кыяфәт кирәк.

Галимҗан башта карышып маташты. Кәрим Тинчурин белән Шәһит Әхмәдиев, көлешә-көлешә, Галимҗанны чишендереп ташладылар да өстенә ак күлмәк кидереп, муенына чәчкәле галстук бәйләделәр. Аннан — карасу костюм. Плащ. Башка — бик килешле киез эшләпә. Шуннан Кәрим Тинчурин, Шәһит Әхмәдиевкә карап, сорап куйды:

— Кемгә ошады бу мыеклы матур йөз, мәһабәт гәүдә, Хак Тәгалә ә?!

Шәһит хис-тойгы белән бирде җавапны:

— Бумы? Бумы? Нәкъ үзе. Бер тамчы су кебек охшаш. Суеп каплаган. Нәкъ Максим Горький!

Өчесе дә кычкырып көлеп җибәрде. Калын тавыш белән. Ирләрчә. Бу көчле тавыш урамга да яңгырап чыкты шикелле. Әлеге өстәге бәләкәй тәрәзәдән күренеп-күренеп калган аяклар да бу каты көлештән калтыранып калгандай тоелды. Галимҗан исә бу изге дуслыкның бөеклеген, бу дуслык эченә яшерелгән кешелеклелек гәүһәренең кыйммәтен, бу мөкатдәс тойгылар югарылыгын ничек бәһаләргә да белмәде. Ул бер мизгелгә югалып калды хәтта. Каушады да шикелле. Карашында аңлашылмастай әллә нинди мәюслек чаткылары чагылды. Аның күңелендә — илаһилык халәте. Йөрәгендә — дуслык сәгадәте. Кырыс табигатенә дуслары мөгамәләсеннән килеп өстәлгән иҗтиһадлы мөкиббәнлек. Мондый мәлдә Галимҗан баллы-майлы, нәзакәтле сүзләр әйтүне дә яратып бетерми. Эчендәге кайнар тойгысын тышка ут итеп чыгарырга да ашыкмый. Тыштан ялтырау гадәтен аның табигате кабул итми. Моны ул үзе фигылендәге бер нәкыс як, кимчелек дип исәпли. Ә инде рәхмәт сүзен барыбер әйтми, белдерми калмый. Әмма аз сүз белән. Моның өчен кайчак яратып әйтә торган әлеге "әй" ымлыгы да җитә. Бу юлы да коткарды аны күпсүзлелектән "әй" ымлыгы.

— Ну, әй!.. — диде дә телен шартлатып куйды. Тагын нидер әйтмәкче булган иде, Шәһит Әхмәдиев "әй"гә "су" өстәргә ирек бирмәде. Хәзер инде ул дусларча бирелгән кушамат белән түгел, башкача мөрәҗәгать итте:

— Хөрмәтле вә мәрхәмәтле Алексей Максимович Горький галиҗәнаплары! Китап өемнәрегезне бер як кырыйга алып куярга тиешлек әмернамәсез генә әйтәм... — диде дә үзе үк җыештырырга тотынды, аннан, төенчеген актарып, өстәл өстенә ашамлык-эчемлекләрен тезеп куйды.

Утырышып алгач, сүзне Кәрим Тинчурин башлады:

— Боларның бөтенесе дә әпен-төпен эшләнде. Бу әпе-чепе үзара гына, иртәгә сине озату хөрмәтенә зур мәҗлес оештырачакбыз. Галиәсгар Камал галиҗәнаплары оештыра. Ул моны сез хәзрәти Шан-Галимҗанга тапшырырга боерык бирде.

Галимҗан шаян сүзләрдән хакыйкый тойгыга күчте:

— Соң, Кәримбай туган, андый урынсыз шау-шуларны сөймәгәнлегемне беләсең ич инде. Болай да әле үземне энә очында утырган кешедәй хис итәм.

Берегез — акча бирә, берегез — киендерә...

Кәрим Тинчурин янә шаяртуга күчте:

— Син бит, Алексей Максимович, Киевтан баеп кайтачаксың. Моның куркыныч ягы да бар, әлбәттә. Бай кешенең борыны югары була. Артык кәпәренмәссеңме дип куркам.

Алар җиңелчә генә көлешеп алды. "Казакъ кызы" романы югалгач, Галимҗанның хәле нык мөшкелләнгән иде. Хикәядән, вак-төяк мәкаләдән килгән акча фатирга түләргә, ашарга, киенергә җитми. Ул эшкә урнашмак булды. Ә үзе көн-төн "Яшь йөрәкләр" өстендә утыра. Эшкә керсә, билгеле, "Яшь йөрәкләр" романы шулай тиз язылмас иде. Шәһит Әхмәдиев тә, Кәрим Тинчурин да аңа әсәрен тәмамларга киңәш итте. "Эш бүре түгел, урманга качмас, кыенсынма, кулдан килгәнчә ярдәм итәрбез", — диделәр. Галиәсгар Камал да шул ук фикерләрне әйтте. Акчалата да ярдәм итте. Ә инде теге вакытта Шәһит биргән акчасын ул Нурислам абыйсына җибәрде. Эшчеләргә таратып бирергә. Алган әҗәтне түләмәү адәм баласының иң начар бер сыйфаты, ди торган иде аның әтисе. Шуларны уйлап:

— Мин, җан дусларым, сезгә бурычлы булып калмам... — диде Галимҗан.

*Ахыры киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ

*Рифкать Закировка 60 яшь*

## АВЫЛ УЛЫ, ШАХТЕР, ШАГЫЙРЬ...



Каләмдәшебез Рифкать Хәйдәр улы Закиров 1938 елның 16 июнендә Актаныш районының Усы авылында туган. Әйе, безнең кебек үк авыл баласы. Ямьле Агыйдел буйларында узган балачак ятимлеккә, фәкыйрьлеккә юлыкса да, барыбер үзенчә матур, шигъри... Әтисе сугышта үлгән малайны — әнисе, авыл, табигать үстерә, күңеленә шигърият, иман орлыклары сала. Ә шигырьгә юл — урау, бик урау була. Ерак Көнчыгышта (Советская Гавань шәһәрендә) төзүчеләр мәктәбен тәмамлап, шунда эшләү; илгә кайтып, Минзәлә авыл хуҗалыгы училищесында уку, авылда механизатор булу... Аннан — Урал яклары, Гремячинск шәһәре. Шахтер егет булып, Казанга шигырьләр юллау, аларның газета-журналларда басылып килү шатлыгы... Сөенеп, янә туган якка кайтып, Актаныште "Игенче даны" газетасында (1969 — 1971 еллар) эшләү; янә Гремячинск шахталары... Шахтер тормышында очрый торган михнәт-зәхмәтләр, авырулар, аларны җиңү һәм тагын шигырь...

Ниһаять, шагыйребез тәвәккәлләп Казанга килә (сиксәненче еллар ахыры, янарыш җилләре искән чор!). Бу вакытта ул укучыга "Беренче карлыгачлар" исемле күмәк китап (1968), "Юл башы" исемле — Фәннур Сафин, Флера Гыйззәтуллиналар белән бергә чыгарган җыентык (1972) һәм "Шахтер моңы" исемле мөстәкыйль китабы белән инде таныла башлаган, күңелләргә юл тапкан шагыйрь иде. Казанга килгәч, ул авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтында, "Сабантуй" ("Яшь Ленинчы") газетасында эшләп ала, аннан — бары иҗат белән генә янып яши. Шигырьләр, поэмалар... Китапларның яналары дөньяга килде: "Ай сөярмен, ел сөярмен" (1988), шактый саллы, күркәм басма — "Йөрәк уты" (1993)... Шагыйрь һаман актив яза, аның журналыбызда дөнья күргән (1993 ел, 2 сан) "Гамьле моң" исемле күләмле поэмасы тәнкыйтьтә югары бәя алды (җөмләдән, А. Хәлим аны безнең көннәрнең иң яхшы поэмаларыннан берсе, дип атады). Язганнарыннан туплап, шагыйрь "Кичке моңнар" исемле 20 табаклык шигырьләр һәм поэмалар сайланмасын әзерләде — ул хәзер нәшриятта басылуын көтеп ята...

Рифкать Закиров — 1988 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. ..."Кәккүк моңнарын тынларга" дигән бик матур җыр язды композитор Ренат Еникеев шагыйрь сүзләренә. Моң һәм көч. Табигать һәм Күңел. Шагыйрь һәм кырыс чынбарлык. Болар бәрелеше — Рифкать Закиров шигырьләренең канына сеңгән. Алар — гаҗәеп тыгыз фикерле, халыкчан, җырга тартым ритм-агышлы, сагышлы шатлык белән өртелгән шигырьләр.

Кәккүк моңнарын тыңларга киләчәк дуслары күп булачак аның, димәк, чын шигъриятне аңлап ятучылар да һич кимемәячәк, — моңа да иманым камил минем.

— Озак яшә, яз, шигырьдәш, замандаш, моңдаш дустыбыз Рифкать Закиров! — дип тәмамлыйм мин шагыйрьнең юбилее мөнәсәбәте белән бирелгән бер бәйләм шигырьләренә кереш сүземне...

Рәдиф ГАТАШ

# Рифкать Закиров

## КИЧКЕ МОҢ

### Шахтер идем...

Шахтер идем... Кайнар чишмә булып,
Тау аркылы тирем саркыды.
Җаным янды, халкым җылынсын дип,
Кулым бозлы ташны талкыды!

Яшьлегемдә, әйе, шахтер идем
Һәм бүген дә гүя шахтер мин:
Ташлар эретерлек сүзләр эзлим, —
Кайный каным, чыга җан тирем.

...Ташлар ярып, таулар күчереп мин
Таптым моңның тирәнрәген...
Халкым бәгърендә янса җаным,
Җырларымда — тибә йөрәгем!..

### Таштугай

Таштугайда ташның, әй, саны юк,
Берсенең дә әмма җаны юк.
Җилләр булып иңгә моң сарылып,
Егылдым мин шунда абынып.

Түзгән, сабыр иткән ирләргә, һай,
Таштай авыр икән җилләр дә;
Үз Илендә орса-какса ходай,
Чит тоела туган җирләр дә.

Бәхет кенә көткән бер көнемдә
Нишләттең син, әйтче, Таштугай?! —

Таң нурлары дисәм керфегемдә,
Күз төбемдә ачы яшь бугай...

## Уйлар, уйлар...

Мин уйланып ятам төннәр буе —
Моннан хәтәр авыр чир юктыр;
Тирә-ягым тулы җеннәр туе,
Башкаемны куяр җир юктыр.

Төннәр буе йокы алмый мине...
Бүтәннәрнең хәле ничектер?
Шөкер, әле дә җуймыйм акылымны:
Кичәгедән бүген уй күптер.

Иртән торсам янә уйга чумам:
Җир-Су үксегәндә җан тынмый;
Һаман да кан-яшькә туймас сыман,
Уеннан бер уймак чыкмас сыман,
Ил язмышы белән кем уйный?!

Кемнәр генә кемгә теш кайрамый, —
Каргыш-каһәр төшәр дип тормый;
Җан кыелган җирдә эш кайнамый,
Кан коелган җирдә гөл корый?!

Юкка гына, ахры йөз саргаймый,
Күкрәгемә ургып моң тулмый!..
...Телләремә кунып кош сайрамый,
Күзләремә карап эт елый...

## Инкыйраз

### I

Торган саен һаман
Җир игътибар сорый:
Җитте ахырзаман,
Инеш-сулар корый.

Булмаган да сыман
Чишмә юкка чыга.
Фенол тәмен тоям
Эчкән "чиста" суда.

Урман дөрләп яна,
Көлләр генә кала.
Гөлләр кебек дала
Кибеп яргалана.

Таулар иңә төпкә,
Ташлар җиргә сеңә:
Бар авырлык төшә
Җирнең җилкәсенә!

Күкләр күкри дә,
Җирләр тетри дә:
Өйләр торган җирдә
Җилләр бөтерелә...

2

Бер авылда тынлык,
Бер авылда давыл...
Синдә тудык, тордык,
Хуш, авылым, сау бул!..

Бурыч-салымнарга
Дучар иттеләр дә:
Сине саудылар да,
Сине җиктеләр дә?!.

"Эт кояшы" — күктә,
Эт тормышы — җирдә;
Оланнарың — читтә,
Өлкәннәрең — гүрдә.

Чут-чут сайрап былбыл
Килер микән быел?
Борчак үскән кырга
Төшәр микән торна?..

Бушка эшли халык,
Төнгә көнне ялгап;
Түрә туплый байлык,
Ач халыкны алдап.

3

Бай ярлыны талый,
"Пан" "брат"ны таный...
Ахры, илгә, җаный,
Банкротлык яный?!

Ханнар балтасыдай
Базар балтасы да! —
Килми базарга, һай,
Аяк басасы да!.

Күп кыз тәнен сата,
Комсыз җанын сата;
Байлар малын сата,
Донор канын сата...

Кануннарга карап,
Тормый сине аяп:
Закондагы карак
Йөри кеше талап.

Дөнья-җиһан диләр,
Вәгъдә — иман диләр...
Дингә ышанмыйлар
Әле дә имансызлар!

4

Туктар-тынар чакта
Туплар һаман ата;
Артык тумасак та,
Үлем-китем арта.

Бала аяк суза
Азмы-күпме яшәп.
Картлар газап чигә
Ачлы-туклы яшәп.

Атышалар көн-төн
"Өер" белән "Төркем",
Хет егылып үл син —
Ярдәм итмәс беркем!

Ә кем яшьле күзен
Йөртеп як-ягына:
Хөкем итә үзен
Үлем җәзасына.

Тумый калып була,
Үлми калып булмый;
Кайсы чиктә дөнья —
Белеп-танып булмый...

5

Эш шулпасы сыек,
Сүз боткасы куе...
Җен шайтанны суеп
Ясый пәри туе!

Этлек күреп үскән
Яшьләр эшсезлектән:
Беткән инде күптән
Чыгып кешелектән!

Уңга-сулга бакмый
Эчә яше-карты:
Башы чатный-чатный,
Эче ярылганчы...

Бу заман кемнеке? —
Ак сөякләрнеке!
Вак-төякләрнеке,
Как сөякләрнеке...

Ак төсләргә карый
Күбрәк каралары;
Янган саен әрни
Йөрәк яралары.

6

Илне төрле яктан
Ялган төреп алган:

Хакыйкатьтән-хактан
Тик “х” генә калган...

Дөньялар тар — начар,
Хәлләр хөрти-хәтәр:
Тагын күпме ашар
Татар башын татар?!

“Милләт” ике телле,
Бер җан ике төрле:
Тере дисәң — үле,
Үле дисәң — тере...

Күпләр лаф органда,
Ил — хөр, мөстәкыйль дип,
Ник соң мин һаман да
Үксим: без ятим дип?!.
Илнең кесәсе буш,
Акчасы юк, имеш...
Өч аршын җир ич
Безгә дигән өлеш...

7

Алтын-көмеш тү-тү
Дәүләт казнасыннан:
Көзен көтү-көтү
Киткән казлар сыман.

Сәмән теләнәләр:
Галим-голәмалар,
Гарип-горабалар,
Шәһәр-хәрабәләр...

Урамнарга тулып
Ага тимер ташкын:
Куба тузан-болыт,
Ява коеп таш-ком.

Таш диварлар суык,
Көзгеләре чалыш...
Бик күпләрне сугып
Ега монда язмыш?!.

Күк түбәсе тишек,
Җир күчәре авыш...
...Без Җир-Судан бизеп,
Хаталандык.. ялгыш...

## Гөлсәнә

*Бөек Ватан сугышыннан соңгы ачлык елларда мине үлем тырнагыннан йолып калган Гөлсәнә апа Ардашировага.*

*"Булат белән Фәйрузә, дисәнә,
Бигрәк инде пар килгән, дисәнә".*

М. Җәлил
("Хат ташучы" поэмасыннан)

I

**Адай юллары комлы, дисәнә,
Адай урманы моңлы, дисәнә;
Язгы таңда урманга, дисәнә,
Киттек юа җыярга, дисәнә.**

**Шунда бер мин саташтым, дисәнә, —
Сазга кереп адаштым, дисәнә.
Чак акылдан язмадым, дисәнә,
Кочагында саз-базның, дисәнә.**

**Барча күрше-күләннәр, дисәнә,
Шактый эзләп йөргәннәр, дисәнә,
Хәлдән таеп беткәннәр, дисәнә,
Тапмый кайтып киткәннәр, дисәнә.**

**Ничек ходай саклаган, дисәнә,
Бер Гөлсәнә кайтмаган, дисәнә.
Сазны ярып атлаган, дисәнә,
Үзе ярый батмаган, дисәнә.**

**Баткак сазда йөзсә дә Гөлсәнә,
Байтак җәфа күрсә дә Гөлсәнә,
Карар кыла кайтмаска Гөлсәнә,
Риза була тапкач та... үлсә дә.**

**Фәрештә күк кыз бала, дисәнә,
Тәмугта күк шомлана, дисәнә:
Ир баланы кызгана, дисәнә,
Изге җаны сызлана, дисәнә.**

**Бар өметне җуйганда, дисәнә,
Арып, күзне йомганда, дисәнә,
Табып мине, чыннан да, дисәнә,
Саздан тартып чыгара Гөлсәнә!**

**Озак йөргәч көенеп Гөлсәнә,
Кош тоткандай сөенеп Гөлсәнә,
Нечкә талдай бөгелеп, дисәнә,
Ала үбеп иң элек, дисәнә.**

**Шунда гаҗәп хәл булды, дисәнә,
Шундый рәхәт тоелды, дисәнә,
Җаным-тәнем җылынды, дисәнә,
Татлы яшем коелды, дисәнә...**

Итте микән ул якын, дисәнә, —
Күчте миңа ут-ялкын, дисәнә...
Шуннан бирле мин хаклыйм, дисәнә,
Саф сөюнең чын хакын, дисәнә.

2

Зур булсаң да өч яшькә, Гөлсәнә,
Түгел иде эш яшьтә, белсәнә!..
Гыйшкың төшеп бирәүгә, дисәнә,
Киттең чыгып кияүгә, Гөлсәнә.
Бер авылда торсак та, Гөлсәнә,
Әверелдек Сак-Сокка, Гөлсәнә;
Аерылдык як-якка, Гөлсәнә,
Авыр булды шул чакта, белсәнә...

Сөюемне белмәдең, Гөлсәнә,
Гомер буе сизмәдең, дисәнә;
Мин гел сине күзләдем, Гөлсәнә,
Ә син мине күрмәдең, дисәнә.

Җанга дөрләп капкан ут, дисәнә,
Кайный канда сакланып, дисәнә;
Моңа чара тапкан юк, дисәнә,
Еласаң да капланып, Гөлсәнә...

Булмый, димәк, булмагач, дисәнә,
Уйный йөрәк уйнагач, дисәнә...
Түбәнгәрәк түнә баш, дисәнә,
Төптәнрәк уйлагач, дисәнә.

Булып өрәк — Мәҗнүн мин, дисәнә,
Калыр идем мәңге мин, дисәнә,
Әмма сузмый озакка, дисәнә,
Киттем чыгып чит-якка, дисәнә.

Айнуын мин айныдым, дисәнә,
Җырда — уем, бар моңым, дисәнә.
Тик оныта алмыймын, дисәнә,
Дөньяда син барлыгын, Гөлсәнә!

Күп йөрсәм дә читтә мин, Гөлсәнә,
Әнкәемнең сөт тәмен, дисәнә,
Саф сөюнең чын тәмен, дисәнә,
Җан түремдә йөртәмен, дисәнә.

Бар бурычны бирергә, дисәнә,
Зар булып бер күрергә, дисәнә,
Калганчы мин күмергә, дисәнә,
Яначакмын гомергә, Гөлсәнә!

Үксеп җилләр иссә дә, Гөлсәнә,
Исле гөлләр шиңсә дә, Гөлсәнә,
Үсмер кызлар көлсә дә, Гөлсәнә,
Исемдә — син! Белсәнә, Гөлсәнә! —
Гөл-сә-нә-ә-ә!..

## Кичке моң

Батамын мин уйга зәңгәр таңда,
Ятам моңга чумып, кич җитсә.
Гәрчә кеше булып яралсам да,
Төштә генә яшәү кешечә.

Уйга түгел, суга чумар идем,
Булсам җофар яки сусар мин.
Моң-дәрьядан йөзеп чыгар идем,
Төнбоектай шиңеп — суલармын...

Ут белән су арасында яшим,
Йотып яшем, назга сусап мин.
Күзем карасында уйный яшен:
Куе-кара төндә — учак мин!

Керер идем кеше арасына,
Тарсыналар кермәс борын ук.
Утырмагач һичкем арбасына,
Беркайда да миңа урын юк.

Тай типмәгән юкса башыма да,
Әмма уйлап куям юк-юкта:
Әллә кулны селтәп барсына да,
Кайтып китим микән "төп йортка"?

Гомергә дә уйдан чыгасым юк,
Тыным бетеп, сулыш буылып:
Тар бүлмәдә ятам уйга чумып,
Ком-таш түгел, тоташ моң булып...



# ДРАМАТУРГИЯ



## Туфан Миңнуллин

# СӨЯРКӘ

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМАТИК ХИКӘЯ

Катнашалар:

Әнисә — 36 яшьтә
Хәбир — 45 яшьтә
Рәмзия — 19 яшьтә
Хәзрәт — 30 яшьтә
Хәбирә — 80 яшьтә
Хәлил — 38 яшьтә

## Беренче пәрдә

**Әнисәнең бер бүлмәле фатиры. Фатирның хуҗабикәсе урындыкка баскан да ишек өстенә гарәп хәрефләре белән бизәлеп катыргыга язылган "Аятел-Көрси" догасын кадаклап маташа. Тышкы ишек ачылган тавыш.**

Әнисә: Хәбир, синме? *(Алгы бүлмәдә Хәбир тавышы: "Үзе!" Әнисә урындыктан төшмичә генә алгы бүлмәгә карый. Хәбир керә).*

Хәбир: Исәнмесез-саумысыз, нигә кәҗә саумыйсыз? *(Әнисәгә күтәрелеп карап)* Бу ни-нәрсә? Үзе пьедесталда, кулында — чүкеч.

Әнисә: Ялгыз хатын өенә кем бәреп кермәс.

Хәбир: Кундыр инде алайса берне, беткән баш бетсен.

Әнисә: Мәле, кадаклап куй әле шуны. *(Чүкеч белән догалыкны бирә).*

Хәбир: Нәрсә соң бу?

Әнисә: Белмисеңме? Бигрәк тә наданнар инде без! Шушы яшькә җитеп... Дога ул. Шундый дога бар. Аны ишек өстенә кадаклап куйсаң, ишектән җен-пәриләр, шайтаннар керә алмый. Аңладыңмы?

Хәбир: Чепуха...

Әнисә: Кагып куй.

Хәбир: Нәрсә язылган соң анда?

Әнисә: Белмим.

Хәбир: Менә китте заман. Беркем бернәрсә белми. Барысы да белгән булып кылана. Каян алдың син аны?

Әнисә: Мәчеттән.

Хәбир: Мәчеткә йөри башладыңмы әллә?

Әнисә: Аның ни начарлыгы бар?

Хәбир: Хәзер сине кочакларга да ярамыйдыр инде?

Әнисә: Ярамый.

Хәбир: Ә нишлибез?

Әнисә: Белмим.

Хәбир: Өйрәтимме соң?

Әнисә: Өйрәт.

Хәбир: *(Әнисәне кочагына алып)* Сагындым мин сине.

Әнисә: Мин дә...

Хәбир: Бик сагындым.

Әнисә: Мин дә...

Хәбир: Өзелеп-өзелеп сагындым.

Әнисә: Мин дә...

Хәбир: Туктале, бырат... *(Кесәсеннән кассета чыгара)* Кабызып жиффәрик әле магнитофонны. Тыңлап жиффәр әле шушыны. Тик аны болай гына тыңларга ярамый. Кил әле яныма, кер әле кочагыма, әкрен генә танцы-манси жиффәрик әле.

**(Магнитофоннан яңгыраган жырга бииләр).**

Сагындым мин сине, аппагым,
Өзелеп сагындым, гүзәлем.
Кавышу сәгатен көткәндә
Минутка минутлар тезәмен.

Карале тутырып күземә —
Сагындым күзләрең карасын.
Сагындым кыйгач ай кашыңны,
Сагындым кашларың арасын.

Йөрисең күңелем түрендә —
Бәхетле һәр көнем, һәр төнем.
Кил әле, санаймча берәмләп —
Сагындым керфегең бөртеген.

Хәбир: *(Магнитофонны туктатып)* Йә, ничек, бырат?

Әнисә: Ишеткәнем юк.

Хәбир: Ишетергә... Яна гына табадан төшкән жыр ич ул. Спициялне синең өчен. "Сагындым Әнисәне" дип атала. Ошадымы сиңа?

Әнисә: Ошады.

Хәбир: Ошамаска... Кемнәр язды диген син аны! Ләкин әйтмим. Иң атаклы шагыйрь белән, атаклы композитор. Алар минем офиска йөриләр — саунага. Әйттем: "Әгәр дә дөньяда иң матур жыр язып бирмәсәгез, юлларыбыз аерыла", — дидем. "Кемгә багышлап?" — диләр. "Сөйгән кызыма", — дидем.

Әнисә: "Сөяркәмә", — диясе иде.

Хәбир: Әйтмә инде шул сүзеңне. Яратмыйм мин ул сүзне. Начар сүз ул, ямьсез сүз. Ахмак, ангыра татар уйлап чыгарган ул сүзне... Шәп язганнар бит, әйеме? "Кил әле санаймча берәмләп — сагындым керфегең бөртеген". Гениально! Чыннан да, киләле, санап карыйк әле. *(Әнисенең керфекләрен саный)* Берәү, икәү, өчәү. Йомма күзеңне, саташтырасың... Берәү, икәү... өчәү, дүртәү... Тагын саташтырдың (көлешәләр).

Әнисә: Ярый, син саный тор, мин чәйне яңартыйм. *(Кухняга чыгып китә).*

Хәбир: *(Кухня ишегенең яңагына сөялгән килеш)* Беләсеңме, Әнисә, "кашларыңның арасы" дигәнен үзем яздырдым. Синең кашларыңның арасын яратам бит мин. Жүләр бит мин, әйеме? *(Магнитофон янына килә. Яңадан теге жырны жырлата. Жырга кушылып сызгырына, сызгырына бии. "Аятел Көрси"гә карап туктап кала.)* Әнисә! Бу доганң минем ачуны китерә.

Әнисә: *(Кухнядан чыгып)* Ни дисең?

Хәбир: Әллә нишләтә синең бу доган. Әллә мин шайтан микән?

Әнисә: Бәлки...

Хәбир: Ничек инде ул бәлки?..

Әнисә: Бәлки без икебез дә шайтандыр.

Хәбир: Менә монысын ялгыштың, бырат. Мин шайтан булсам да син... кем әле син?.. Ангелның татарчасы ничек әле?

Әнисә: Фәрештә.

Хәбир: Син — фәрештә. Юк, фәрештә генә түгел, син — алла. Хатын-кызларның алласы син, Әнисә.

Әнисә: Алай димә, ярамый.

Хәбир: Кем әйтә ярамый дип?

Әнисә: Алла исеме белән шаярма.

Хәбир: Ә мин шаярмыйм *(Әнисәне кочагына алып)*. Яратам мин сине, Әнисә.

Әнисә: Йә, гел кочаклашып кына тормыйлар инде.

Хәбир: Мин сине бер секундка да кочагымнан чыгармас идем.

Әнисә: Чәйне кем ясар иде... *(Хәбирнең кочагыннан чыгып өстәлгә табын әзерли. Хәбир аңа булышкандай итә. Шунда бер китапны күреп ала).*

Хәбир: Ә монысы нәрсә?

Әнисә: Догалык.

Хәбир: Да-а-а, бырат. Мулла булып беткәнең ич син. Кай арада?

Әнисә: Мәчеттә саталар.

Хәбир: Нишлисең инде моның белән?

**Әнисә:** Торсын әле. Бәлки берәрсен ятлармын да. Безнең әби догаларны күп белә иде.

**Хәбир:** Син тагын догалар ятлап әби булып китмә. Мин нишләрмен аннары?

**Әнисә:** Бабай булырсың.

**Хәбир:** Ю-у-ук... Бабай буласым килми минем. Ташла син боларны, бырат. Боларның бөтенесе дә чепуха. Барысы да еврейлар уйлап тапкан нәрсә. Беләсең килсә, аның Мөхәммәте дә еврей.

**Әнисә:** Ул — гарәп...

**Хәбир:** Барысы да бер аларның. Бөтен этлек шул яктан чыга.

**Әнисә:** Хәбир... Син мине яратасыңмы?

**Хәбир:** Аңладым. Ни әйтергә теләгәнеңне аңладым, Әнисәкәй. Бер сүзем юк. Беләсеңме, мин сиңа гел догалардан гына торган обой ясатам. Бөтен стеналарны шуның белән ябыштырырсың. Тик менә шунысын гына аңламыйм, нишләп әле син болай?.. Андый түгел идең ич.

**Әнисә:** Әйдә, чәй эчик.

**Хәбир:** *(Дипломатыннан "Шампанское" шешәсе чыгарып)* Башта монысын.

**Әнисә:** Юк, кирәкми, Хәбир.

**Хәбир:** Нәрсә булды соң сиңа? Ярата идең. Мин аны синең өчен генә алам. Син яратканга гына эчәм. Юкса женем сөйми. Кемдер тәрбияли башлаган сине. Әллә берәр мулла белән таныштыңмы?

**Әнисә:** Йом әле авызыңны.

**Хәбир:** Булды, булды, йомдым.

**Әнисә:** Ач әле авызыңны.

**Хәбир:** Ачтым.

**Әнисә:** *(Хәбирнең авызына бал кашыгы белән бал каптыра)* Тәмлеме?

**Хәбир:** Бик.

**Әнисә:** Тагын ач *(Бал кашыгы белән чәй каптыра. Бала-чагага эчерткән шикелле чәйне өреп эчертә. Ара-тирә ирен очы белән генә үбеп тә ала).*

**Хәбир:** *(Урындыктан авып төшә)* Үләм, бетте, эредем. *(Аякларын-кулларын ян-якка ташлап ята).*

**Әнисә:** *(Аның баш очына татарчалап аяк бөкләп утыра. Хәбирнең башын алдына сала, чәчләрен бармаклары белән тарый)* Рәхәтме, Хәбир?

**Хәбир:** Рәхәт. Дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк, Әнисә.

**Әнисә:** Шулайдыр... Бүген бит безнең юбилей көне, Хәбир. Моннан нәкъ ун ел элек без синең белән танышкан идек. Мин мәхәббәткә, назга сусаган карт кыз идем. Син ике бала атасы ир идең.

**Хәбир:** Мин дә назга сусаган идем, Әнисә.

**Әнисә:** Шулайдыр. Ун ел үтте дә китте. Миңа инде хәзер утыз алты яшь. Күп бит инде ул, әйеме, Хәбир?

**Хәбир:** Мин сине унжиде яшьлек кызларга алыштырмыйм. Беләсеңме алар минем тирәдә күпме бөтерелә? Бал савыты тирәсендәге чебеннәр кебек. Унбиш яшьтән алып егерме яшькә хәтле, теләсәң кайсын сайлап ал. Ак чәчле дисеңме, кара чәчлесе дисеңме. Аларның унысы синең кашларың арасындагы шул сызыкка тормый.

**Әнисә:** Сызык түгел ул — сыр. Картлык галәмәте.

**Хәбир:** Дөрес түгел. Ун ел элек тә бар иде ул. Минем күзем ни өчендер иң беренче шул сызыкка төште. Шул сызык мине бәхетле итте, бырат.

**Әнисә:** Сине бәхетле иткәндер дә бит...

**Хәбир:** Ә син бәхетле түгелмени?

**Әнисә:** Бәхетле идем.

**Хәбир:** Хәзер?

**Әнисә:** Хәзерме? Белмим, бәлки бәхетледер. Яратам бит һаман да. Ун ел элек ничек яратсам, хәзер дә шулай. Яраткан кеше бәхетсез булмыйдыр. Аннан соң, мин ун ел инде тормыш мәшәкатенең ни икәнен белмим. Бу фатир, бу җиһазлар, өстемә кигәннәрем, колакка, муенга такканнарым. Бары да синеке. Син мине оҗмахта яшәтәсең. Анысы да бәхеттер инде аның бу мәрхәмәтсез заманда. Ләкин барыбер кеше бәхете белән бәхетле булып булмыйдыр шикелле...

**Хәбир:** Кем инде ул кеше бәхете?

**Әнисә:** Беләсең инде. Кеше өлешенә кереп...

**Хәбир:** Ни сөйлисең син, аңламыйм. Кем өлеше?

**Әнисә:** Гөнаһ нәрсә ул, Хәбир?

**Хәбир:** Нинди гөнаһ?

**Әнисә:** Гөнаһ турында ишеткәнең юк мәллә?

**Хәбир:** Бар. Беләм.

**Әнисә:** Алайса, әйтеп кара — нәрсә ул гөнаһ?

**Хәбир:** Гөнаһ... Гөнаһ... Ничек инде нәрсә? Син аны нигә сорыйсың?

**Әнисә:** Беләсем килә.

**Хәбир:** Соң, мәчеткә баргансың ич, мулладан сорарга иде. Гөнаһны алар учетка алып утыра. Минем эшем — бизнес. Туктале, нигә дип әле син? *(Яткан җиреннән торып тезләнә дә Әнисәнең күзләренә карый).* Туктале, сиңа ни булды?

Җылыйсың ич син. Ни булды?

Әнисә: Юк ла инде.

Хәбир: Җылыйсың, күзләрең тулы яшь.

Әнисә: Без аерылышабыздыр бүген, Хәбир. Шунадыр ул күз яшьләре.

Хәбир: Ничек инде аерылышабыз? Кем әйтте? Ни өчен?

Әнисә: Беләсең ич инде.

Хәбир: Мин берни дә белмим.

Әнисә: Белмәсәң, сизәсеңдер. Кайчан да булса шулай буласы билгеле иде инде.

Хәбир: Бер нәрсә дә билгеле түгел иде. Мин сине мәңгелеккә яраттым.

Әнисә: Яратуың, бәлки, мәңгелеккәдер. Минем дә хисләрем үзгәрмәде.

Хәбир: Шулай булгач?

Әнисә: Әтием турында сөйләгәнем бар идеме сиңа?

Хәбир: Бар иде, бөтен балаларыннан да күбрәк ярата, дия идең.

Әнисә: Әйе, шулай иде. Минем кызым дөньяда бер генә, мине бәхетле итәр өчен туган кыз ул дия, иде. Үлгәндә дә, ходайга шөкер, сине үстереп җиткердем. Шунысы гына үкенеч, балаларыңны тезем утыртып сөя алмыйча китәм, дип күзен йомды. Бер көн мин аны төшемдә күрдем. "Нишләдең син, кызым? Нишләдең?" — ди. — Кемгәдер сөяркә булыр өчен генә үстердеммени сине?" — ди. Куркып уяндым. Сөяркә... Сөяркә...

Хәбир: Әйтмә шул сүзеңне. Зинһар өчен әйтмә.

Әнисә: Кем соң мин сиңа? Законлы хатының бар, балаларың бар. Мин кем?

Хәбир: Әнисә...

Әнисә: Юк, кирәкми, дәшмә. Мин үземнең кем икәнлегемне беләм. Элек аңлап бетерми идем, хәзер инде беләм. Мин инде үземнең кем икәнлегемне белер яшьтә. Утыз алты яшь. Дүрт елдан кырык. Аннан илле, аннан... Син мине бүлдермә, Хәбир, әйтә башлагач әйтеп бетерим. Минем яшьтәшләрнең инде бала-чагалары үсеп җитеп килә. Мин әле һаман да... Болай ярамыйдыр ул, Хәбир. Гөнаһ кылуның да бер чиге булырга тиештер. Әнә әйтәләр, кылган гөнаһлар өчен бер Ходай каршында җавап тотасы бар, диләр... Бүлдермә, зинһар. Тулган күңелем ташып түгелсен. Хөкемеңне аннан чыгарырсың. Мин нәрсәнең гөнаһ, нәрсәнең гөнаһ түгеллеген белештермичә сине яраттым. Син минем өчен алла да, пәйгамбәр дә идең. Мин беркемне күрмәдем, күрергә дә теләмәдем. Хатының да, балаларың да минем өчен юклар иде. Мәхәббәтем сукыр иде минем. Ләкин сукыр кеше ничаклы сакланып йөрсә дә, бер килеп терәлә. Менә мин дә бәрелдем, Хәбир. Җаным белән килеп бәрелдем. Авырта, сызлый минем җаным. Мин аны сиңа сиздермәскә тырышам, ләкин күпме мөмкин... Мин инде элеккечә яши алмыйм, Хәбир. Гафу итә күр, зинһар.

Хәбир: *(Аптыраганнан елмаеп)* Менә сиңа мә!

Әнисә: Шулай, Хәбир, шулай, бәгырькәем.

Хәбир: Нәрсә булды инде бу? Нәрсә була инде?

Әнисә: Миңа бүтәнчә яши башларга кирәк, Хәбир.

Хәбир: Ә миңа?..

Әнисә: Сиңа да.

Хәбир: Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме?

Әнисә: Беләм, Хәбир, беләм.

Хәбир: Һәм чынлап әйтәсеңме?

Әнисә: Бу шаярта торган нәрсәме...

Хәбир: Хатын-кызны кем белә. Бәлки ялындырыр өчен генә...

Әнисә: Кимсетмә мине, Хәбир.

Хәбир: Да-а-а, бырат. Шулай итеп аерылышабызмыни? Аерылгач нишлибез инде? Син нишлисең дә, мин нишлим?

Әнисә: Белмим, әлегә белмим.

Хәбир: Ә кем белергә тиеш?

Әнисә: Син акыллы кеше.

Хәбир: Акыллы? Минме акыллы? Ниемә кирәк ул акыл, син булмагач! Син дә булмагач, миңа бернәрсә дә кирәкми. Хатыным белән дә мин син булганга гына яшим. Ун ел мин аның янына ятканым юк, син әйткәнчә яшим. Нинди гөнаһ турында сөйлисең син? Минем дә алла каршында җавап тотасым бармы? Сине яратканым өчен берәүнең дә мине җавапка тартырга хакы юк. Хәтта синең алланың да...

Әнисә: Тел тидермә аңа.

Хәбир: Тидерәм. Әгәр дә ул безнең арага кереп, мине бәхетсез итәргә җыена икән, *("Аятел-Көрси"гә карап)* Димәк, син бу нәрсәләрне миннән котылыр өчен элеп куйдың? Шайтаннан котылыр өчен. Хәзер күрсәтәм мин аларга шайтанның кем икәнен. *(Үрелеп "Аятел-Көрси"не куптарып алмакчы була).*

Әнисә: *(Кычкырып)* Кагыласы булма!

Хәбир: *(Кинәт борылып)* Син миңа кычкырдың? Син миңа кычкырдыңмы,

Әнисә?.. Син ун елга беренче тапкыр миңа кычкырдың.

**Әнисә:** Гафу ит.

**Хәбир:** Юк, юк, гафу үтенмә. Мин сине гаепләмим, гаҗәпләнәм генә.

**Әнисә:** *(Хәбирнең кочагына сыенып)* Куркам мин. Гөнаһтан куркам. Зина кылабыз бит.

**Хәбир:** Анысы ни тагын?

**Әнисә:** Беләсең ич инде, нигә сорыйсың?

**Хәбир:** Мин бер генә нәрсәне беләм, Әнисә. Мин сине яратам. Синнән башка минем бер кешем юк. Әгәр дә син ЗАГС язып биргән бер кәгазь кисәге гөнаһтан коткара дип уйлыйсың икән, мин ул турыда сиңа әйттем. Риза булмадың. Семьяңны ташласаң, өемә кертмим, дидең. Әйттеңме шулай, дип?

**Әнисә:** Әйе.

**Хәбир:** Соң, шулай булгач, минем ни гаебем бар?

**Әнисә:** Юк, юк... Юк синең гаебең. Мин үзем, Хәбир. Җаным тыныч түгел минем. Бөтенләйгә булмаса да, очрашмый торыйк без. Бәлки син дә... Гөнаһ бит...

**Хәбир:** Таптың бер сүз.

**Әнисә:** Аны мин тапмадым, Хәбир. Аны безгә чаклы тапканнар.

**Хәбир:** Әнисә, ныклап тыңла мине. Безнең бу сөйләшүебез — әкият. Мин эш кешесе, әкият сөйләшергә яратмыйм. Гөнаһ-фәлән диеп баш әйләндермә, әйт дөресен генә — миннән котылырга телисеңме?

**Әнисә:** Алай түгел.

**Хәбир:** Шулай. Ярый, мин түзәрмен. Сине очратканчы яратусыз яшәргә өйрәнеп бара идем. Ярый, яшәрмен, түзәрмен. Төн үткәрерлек кызыйлар да табылыр. Син нишләрсең? Үзең нишләрсең? Минсез сиңа рәхәт булачак икән, мин китәм. Гөнаһсыз булырсың син, җаның да тыныч булыр.

**Әнисә:** Газаплама мине. Миңа бик авыр. *(Хәбирне үбә, коча).*

**Хәбир:** Бүтән барма син ул мәчеткә. Мәчет ул сиксән яшьлек картлар өчен. Алар инде яшәп арыган. Безнең әле яшисебез бар.

**Әнисә:** Хәбир... Син бүген монда калма инде, ярыймы. Өеңә кайт.

**Хәбир:** Өем монда минем.

**Әнисә:** Хәбир, мине яратсаң, тыңла сүземне.

**Хәбир:** *(Әнисәгә карап тора да кычкырып көлә башлый. Көлүеннән кинәт туктап)* Ачкычларны да тапшырыйммы? *(Кесәсеннән ачкычлар алып идәнгә ташлый)* Мә, ал! Алар синең гөнаһлы ишегеннең ачкычлары. Догаларыңны укып ал.

**Әнисә:** Хәбир...

**Хәбир:** Хәбир икәнлегемне оныттыңмыни әле? Әйе, Хәбир мин... Син шаярма минем белән, кызый. Минем белән инде бер тапкыр шаярдылар. Минем белән шаяручының бәхетле булганы юк. Син мине ялындырырга маташма. Мин ярата беләм, ялына белмим. *(Чыгып китә. Ут сүнә)*

**Хәбирнең эш бүлмәсе. Хәбир креслосына чумып уйга калган. Менә ул кабул итү бүлмәсендәге секретарьны чакыра торган төймәгә баса. Рәмзия кереп ишек төбендә туктый. Хәбирнең йомыш кушканын көтә.**

**Хәбир:** Түргә уз, Рәмзия. *(Рәмзия өстәл янына килгәч, аңа текәлеп карап тора)* Ни хәлләрдә соң, Рәмзия?

**Рәмзия:** Без бүген исәнләштек, Хәбир Фәйзерахманович.

**Хәбир:** Шулаймыни?.. Димәк, склероз башланган. Кабул итү бүлмәсендәге өстәл артында утыручы чибәр кыз Рәмзия белән исәнләшкәнемне онытканмын. Ни хәлләрдә соң, Рәмзия? Син исәнләшә белмисеңмени?

**Рәмзия:** Исәнмесез.

**Хәбир:** Менә шулай. Утыр, нигә басып торасың? Утыр. *(Рәмзия кыяр-кыймас кына утыра. Хәбир урыныннан торып, Рәмзия каршысындагы креслога утыра. Тагын Рәмзиягә төбәлеп карап тора.)* Ни хәлләрдә соң, Рәмзия?

**Рәмзия:** *(Тәмам аптырап калган.)* Мин исәнләштем Сезнең белән.

**Хәбир:** Шулаймыни?.. Гафу ит, алайса. Нигә шулай карап торасың?

**Рәмзия:** Сез әллә нинди?

**Хәбир:** Нинди?

**Рәмзия:** *(Урыныннан торып)* Сез минем белән "Сез" дип сөйләшә идегез. "Рәмзия Гариповна" дия идегез.

**Хәбир:** Шулай әйтә идеммени? Хәтердән чыккан бит, әй. Син, Рәмзия, үзеңнең чибәр икәнлегеңне беләсеңме?.. Нигә шулай кызардың? Әйт инде, нигә кызардың?

**Рәмзия:** Сез шаяра белмисез. Әйтәләр: Ахметшин шаяра башласа, начар була, диләр.

**Хәбир:** Беренчедән, Ахметшин түгел, Әхмәтшин.

**Рәмзия:** Гафу итегез.

Хәбир: Зарар юк. Сез инде ярыйсы ук беләсез үз телегезне. Безгә килгәндә ни татарча, ни урысча түгел иде.

Рәмзия: Рәхмәт, Хәбир Фәйзерахманович. Отпускада авылда булдым. Әби белән бабай мине өйрәттеләр.

Хәбир: Әби белән бабай өйрәтсә, була инде ул. Тукай шигырьләрен ятладыңмы?

Рәмзия: Өчне беләм.

Хәбир: Өчне белгәч, ярыйсы. Сиңа хәтле эшләгән кызыбыз берне дә ятлый алмады.

Рәмзия: Беләм. Шуның өчен ул китте эштән.

Хәбир: Бик күп беләсең түгелме соң син? Мин шаяра башласам, хөерлегә булмаганын беләсең, кемнең эштән ни өчен киткәнен беләсең.

Рәмзия: Әйтәләр...

Хәбир: Алайса, шуны да бел, чибәркәй, күп белгән кешене бу дөньяда яратмыйлар. Бигрәк тә син эшләгән эштә. Йә, йә, кызарма... Яхшы... Урысчаны син инде сиптерәсең генә. Инглиз телен өйрәнергә йөрисеңме?

Рәмзия: Әйе.

Хәбир: Ничек соң, булдырып буламы?

Рәмзия: Әйе.

Хәбир: Утыр әле син, басып торма. Утыр. *(Рәмзия шикләнеп кенә урындык читенә утыра)* Сез миңа ошыйсыз, Рәмзия Гариповна. Сезнең яшьтәге Казан кызлары эш яратмыйлар. Тупаслар, наданнар һәм җыйнаксызлар. Җыйнаксыз дигән сүзне аңлыйсызмы?

Рәмзия: *(Урыныннан торып)* Гафу итегез.

Хәбир: Утыр, утыр... Җыйнаксыз ул — несобранный була. Димәк, бездә эшләү сиңа ошый?

Рәмзия: Әйе.

Хәбир: Ни өчен?

Рәмзия: Ошый...

Хәбир: Син һәрвакыт шулай сүз әйткән саен кызарасыңмы? Син эшләгән урын оялчан кызлар эшли торган урын түгел.

Рәмзия: Ә мин оялчан түгел.

Хәбир: Алайса нигә туктаусыз кызарасың?

Рәмзия: Мин Сездән куркам.

Хәбир: Миннән?.. Ни өчен?..

Рәмзия: Сез шундый... *(Сүз эзли дә таба алмый)*

Хәбир: Нинди?

Рәмзия: Ну... Не знаю...

Хәбир: Ярый, ярый. Куркыныч икән, куркыныч.

Рәмзия: Куркыныч түгел, ну...

Хәбир: Син үзеннең бик тә чибәр икәнлегеңне беләсеңме?

Рәмзия: *(Җыларга җитешеп)* Ну чего вы меня мучаете?

Хәбир: Разве?.. Ну тогда можете встать и уйти.

Рәмзия: Гафу итегез. *(Үзен кулга алырга тырыша.)*

Хәбир: Йөргән егетегез бармы?

Рәмзия: Юк.

Хәбир: Ә син, Рәмзия, гөнаһның нәрсә икәнен беләсеңме?

Рәмзия: Гөнах?

Хәбир: Гөнах түгел, гөнаһ. Грех. Беләсеңме, нәрсә ул грех?

Рәмзия: Гөнах?.. Миңа басып торырга мөмкинме? Миңа алай җайлы.

Хәбир: Утыр. Бу бит имтихан түгел. Дусларча әңгәмә. Сиңа ничә яшь? Унтугызмы әле?

Рәмзия: Әйе.

Хәбир: Миңа кырык биш. Унтугыз яшьлек кыз белән кырык биш яшьлек ир сөйләшеп утыра алалармы?

Рәмзия: Нәрсә турында?

Хәбир: Әйтик, мәхәббәт турында. Әйтик, мин сиңа мәхәббәт аңлата башладым, ди. Яратам мин сине дип әйттем, ди.

Рәмзия: *(Елмаеп)* Ә сез аны әйтмисез.

Хәбир: Нигә?

Рәмзия: Сез андый түгелдер.

Хәбир: Әгәр шундый булсам. Сиңа бездә эшләү ошый. Акчаны бик күп аласың. Күпме синең хезмәт хакың?

Рәмзия: Хезмәт хакы? Ә-ә-ә... Миллион... Бер миллион ике йөз мең.

Хәбир: Унтугыз яшьлек кыз. Мин аңа шундый акча түлим. Сиңа яратам дип әйтергә хакым бармы?.. Әйт инде, бармы?

Рәмзия: *(Паузадан соң)* Бар.

Хәбир: Син ни дип җавап бирәсең инде?

Рәмзия: Ә... Откровенно?

Хәбир: Әлбәттә. Без бит откровенно сөйләшәбез.

Рәмзия: Мин белдем.

Хәбир: Нәрсәне белдең?

Рәмзия: Сезнең шулай дип әйтәсен... Көттем.

Хәбир: Көттең? Минем яратам дип әйтүемне көттеңме?

Рәмзия: Әйе.

Хәбир: Ничек инде?

Рәмзия: Ну... Не зря же вы меня приняли на такую работу. Не зря же платите такие деньги.

Хәбир: Менә сиңа мә! Менә сиңа Рәмзия! Син кыз кешеме?

Рәмзия: В смысле...

Хәбир: Да, в смысле.

Рәмзия: Әйе.

Хәбир: Миңа бит кырык биш яшь.

Рәмзия: Ну... сезнең хатыныгыз сездән уникe яшькә зур.

Хәбир: Анысын да беләсең.

Рәмзия: Гафу итегез.

Хәбир: Димәк, син миңа кияүгә чыгарга да риза?

Рәмзия: Мин беләм, сез өйләнмисез.

Хәбир: Ничек өйләнмим?

Рәмзия: Беләм, өйләнмисез.

Хәбир: Димәк, болай гына яратышабыз?

Рәмзия: Ну не мучайте меня. Я же знаю, я все знаю.

Хәбир: Юк, кадерлем, барысын да түгел икән. Унтугыз яшьтә болай гына кырык биш яшьлек ирнең кочагына керү гөнаһ бит. Гөнаһмы? Туктале, тукта, син миңа гөнаһның нәрсә икәнен әйтмәдең бит әле. Нәрсә соң ул гөнаһ? Син һаман кызарасың. Үзең минем кочагыма керергә җыенасың, үзең кызарасың. Әйт син, сиңа минем кочагыма керү гөнаһмы?

Рәмзия: Наверно. Но за это вы отвечаете.

Хәбир: Почему же?

Рәмзия: Вы старше. Старшие отвечают.

Хәбир: Кем алдында?

Рәмзия: Кем алдында... Наверное, перед богом.

Хәбир: Перед каким богом?

Рәмзия: Мусульманским, естественно. Ну и, конечно, перед законом.

Хәбир: Димәк, син үзең сөттән ак, судан пакь булып каласың?

Рәмзия: Ничек сөттән ак?

Хәбир: Син алла каршында да, закон каршында да җавап тотмыйсың булып чыга.

Рәмзия: Почему же... Но старшие должны быть умнее.

Хәбир: Нигәдер урысчага күчтең.

Рәмзия: Ну, на эту тему по-русски легче.

Хәбир: Аллага ышанасыңмы?

Рәмзия: Бабай ышана, әби дә...

Хәбир: Алар сиңа ни диләр?

Рәмзия: Үзеңне сакла, ди әби. Ну, ул белми, аңламый.

Хәбир: Нәрсәне?

Рәмзия: Ну, жизнь... Тормыш...

Хәбир: Син аңлыйсыңмы?

Рәмзия: Мин кечкенә түгел инде.

Хәбир: Әйе, син бик зур инде. Миннән куркам, диден, курыкмыйсың икән ич.

Рәмзия: Куркам.

Хәбир: Ни өчен?.. Әйт инде. Без бит откровенно — ихлас сөйләшәбез.

Рәмзия: *(Җылап)* Я хочу быть порядочной.

Хәбир: Нигә җылыйсың?

Рәмзия: Вы не трогайте меня, пожалуйста. Я вас очень прошу.

Хәбир: Булды. Тынычлан... Тынычланыгыз, Рәмзия Гариповна. Күз яшьләрегезне һәйбәтләп сөртегез.

Рәмзия: Ачуланмагыз мине... Сез миңа ошыйсыз.

Хәбир: Ошыймдыр шул. Бик һәйбәт кеше бит мин. Авылга кайткач бабаң белән әбиеңә сәлам әйт. Әтиең белән әниеңә дә.

Рәмзия: Әти юк минем.

Хәбир: Ничек юк?

Рәмзия: Булмаган.

Хәбир: Ярый, барыгыз.

Рәмзия *(Чыга башлый. Ишек буенда туктапып)* Можно мне отвечать на Ваш вопрос?

Хәбир: Нинди сорау?

Рәмзия: Ну, гөнах нәрсә ул...

Хәбир: Әйтеп кара.

Рәмзия: Ну, когда обманывает тот, кому больше всех доверяешь.

Хәбир: Яхшы. Бар инде хәзер шуны татарча әйтергә өйрән.

**Әнисә фатиры. Әнисә Хәбир калдырган җырны тыңлый. Үзенең күзләре тәрәзәдә. Хәбирнең машинасын күреп тәрәзә янынан китә, магнитофонны сүндерә. Диван читенә утырып Хәбирне көтә. Ишектә звонок. Әнисә барып ишекне ача. Алгы бүлмәдән Әнисәне күтәреп Хәбир керә.**

Әнисә: Хәбир, тилермә.

Хәбир: *(Әнисәне күтәргән килеш бүлмә буйлап бөтерелеп йөри дә Әнисәне диванга утыртып үзе аның каршына тезләнә).* Әнисә... Зинһар, гафу ит мине. Ачуланма мине, Әнисә. Мин. Юк, юк, юк... Син мине ачуланма гына. Юк, ачулан. Кыйна син мине, мин гаепле. Кабахәт мин, подлец. Мин... Зинһар, гафу ит. *(Сикереп торып алгы бүлмәгә ташлана, аннан бер*

*кочак чәчәк күтәреп керә, аларны Әнисә алдына сибә, үзе тагын тезләнә)* Мин килмичә озак тордым. Мин сине күрдем, машина тәрәзәсеннән күрдем. Син тәрәзә янына килдең дә качтың. Берәр сүз дәш, ә... Әйт, "кабахәт" диген, "подлец" диген. *(Тагын сикереп тора. Кесәсеннән кассета чыгарып, магнитофондагы кассетаны алыштыра. Үзе кабалана. Магнитофонны кабыза. Анда җыр яңгырый).*

Таң җиленә сөйлим серләремне,
Серләремне җилләр генә белә.
Син җилләрдән сора хәлләремне,
Сәлам юлла җилләр белән генә.

Мине танырсыңмы, Әнисәм,
Таң җиле булып иссәм?

Ишетәсеңме, Әнисә? Бу сиңа. Сиңа бу җыр. Бүген язылган.

Очкан кошның язып канатына
Хат җибәрсәм, барып җитәр микән?
Агымсуга салсам сагышымны
Сагышларым агып китәр микән?

Тәрәзә ачарсыңмы, Әнисәм,
Кош булып очып килсәм?

Эзләп таптым. Язгыгыз, дидем. Шундый җыр язгыз, дидем. Үкереп җыларлык булсын, дидем.

Гөлбакчага керсәм, сукмаклардан
Эзләп йөрим синең эзләрне.
Гөлләр арасында зәңгәр чәчәк —
Хәтерләтә синең күзләрне.

Сиңа дип белерсең, Әнисәм,
Гөлләргә башым исәм.

Ошадымы, Әнисә? Анда бераз ялгыш бар. Күзләреңне "зәңгәр чәчәк" дигән. Синең күзләрең кара. Син ачуланма инде аларны. Аларның бит сине күргәннәре юк. Мин аларга әйттем: "Әнисә турында йөз җыр язып бирегез" — дидем. Алар көләләр. Алар ахмаклар, алар аңламыйлар. Җыр ошадымы, Әнисә?

Әнисә: Ошады.

Хәбир: Ай, рәхмәт... *(Әнисәнең аякларын кочаклап)* Сагындым мин сине, Әнисәм. Син дәшмә. Син тик кенә утыр, ярыймы. Син бер сүз дә дәшмә. Мин дә дәшмим. Янында гына утырам. (Әнисәнең алдына башын куеп тынып кала. Әнисә аның чәчләреннән сыйпап иркәли).

Әнисә: Нигә шулай икән ул?

Хәбир: Нәрсә, Әнисә?

Әнисә: Тормыш... Язмыш... Нигә берәүләргә андый язмыш бирелгән, икенчеләргә мондый? Барысы да адәм балалары бит югыйсә.

Хәбир: Язмыш бирелмәгән, Әнисә. Ул мескеннәр философиясе. Үз язмышын кеше үзе ясый.

Әнисә: Син дә үзең ясыйсыңмы?

Хәбир: Үзем. Ялгышы да үземнеке, барысы да үземнеке. Тегесе дә үземнеке, монысы да үземнеке. Сиңа үпкәләгән булып, ялындырырга маташтым. Әйеме... Туктале, мин әйтәм, бер-ике көн бармый торыйм әле, дим. Сагынсын әле, өзгәләнсен әле, дим. Шуннан уйлап алдым — ахмак, мин әйтәм, нишлисең? Югалтасың бит Әнисәңне, дим. Бәхетеңне югалтасың, дим. Менә чабып килдем. Килмәсәм, подлец була идем. Язмыш шулай эшләткәнме? Юк, үзем. Да-а-а, сынадың син мине, бырат. Ә мин — ахмак, сынаттым, ә?

Әнисә: Сынарга теләмим мин сине, Хәбир. Мин сиңа үземә ышанган кебек ышанам. Күңелеңдә әшәкелек, явызлык юклыгын беләм. Һәрхәлдә миңа карата шулай.

Хәбир: Һай, рәхмәт, Әнисә. Шулай да мин әүлия түгел. Эштә мине "усал" диләр, "хәйләкәр" диләр. Ә синең янында бер күзәнәкле амеба. Чөнки мин сине яратам. *(Идәндәге ачкычларны күреп алып)* Син аларга кагылып та карамагансың.

Әнисә: Нәрсәгә?

Хәбир: Әнә ич — ачкычлар. Ахмак мин, әйеме, чын подлец. Ачкычларны атып бәргән булам. Янәсе, бүтән килмим. Балачага. Килмичә нишли алам инде мин, йә? Кая бара алам мин? Миңа аларны кире алырга ярыймы, Әнисә?

Әнисә: Алар синекеләр.

Хәбир: Һай, акыллы хатын син, Әнисә!..

Әнисә: Хатының түгел...

Хәбир: *(Ишетмәгәнгә салынып)* Син беләсеңме, Әнисә, минем дус шагыйрем хулиган булып чыкты. Әнисәгә багышлап шундый да моңлы җыр яз, күздән яшьләр китерерлек булсын, дим, әйеме? Ул әйтә, мин сиңа бөтен Казан үкереп җыларлык җыр язып бирәм, көен композитордан сора, ди. Яхшы көй бит, әйеме? Беләсеңме, Әнисә, мин бит чүт кенә ахмаклык эшләдем. Сиңа ачу итеп исермәкче булдым. Ахмак түгел диген инде, әйеме?.. Әйе, диген инде, Әнисә.

Әнисә: Әйе.

Хәбир: Әйдә, танцевать итәбез, Әнисә.

Әнисә: Бу чәчәкләрне суга утыртыйк инде, шиңмәсеннәр.

Хәбир: Шиңсеннәр, тагын алып киләм мин аларны.

Әнисә: Син алып килгән чәчәкләр бит алар.

Хәбир: Шулаймы? Әйтә белеп тә әйтәсең инде, Әнисә. (*Чәчәкләрне җыеп Әнисә кочагына сала)* Мин су ташыйм, син утыртып торырсың. *(Йөгереп йөреп Әнисәгә булыша. Үзе бая гына җырланган җырны көйли):*

Мине танырсыңмы, Әнисәм,
Таң җиле булып иссәм?
Тәрәзә ачарсыңмы, Әнисәм,
Кош булып очып килсәм?

***(Юл уңаенда Әнисәне үбеп алырга да онытмый.)***

Әнисә: Тилермә, Хәбир.

Хәбир: Бер миллион өч йөз кырык ике мең дүрт йөз уналты!..

Әнисә: Нәрсә, бер миллион?..

Хәбир: Син: "Тилермә, Хәбир", — дип ун ел эчендә бер миллион сиксән мең биш йөз уналтынчы тапкыр әйттең. (Чәчәкләрнең урнашып беткәнен күргәч) Ә хәзер киттек.

Әнисә: Кая?

Хәбир: Машина алып барган якка. Барабыз, барабыз, барабыз... Безнең авылга кереп чыгарбыз. Мин сиңа үзебезнең нигезне күрсәтермен. Мин аннан киткәндә миңа ун гына яшь иде, ләкин онытмыйм. Авыл малае бит мин, Әнисә. Үзем машинада барам, артымнан салам коелып йөри. Киттекме?

Әнисә: Китмик.

Хәбир: Шулаймы?.. Китмибез алайса. Монда гына аулакта утырабыз.

Әнисә: *(Елмаеп)* Син үзеңнең бик күп сөйләгәнеңне сизәсеңме?

Хәбир: Сизәм, Әнисә... Син беләсең, мин бит дәшмичә дә озак тора алам. Син әйт, Хәбир, күп сөйләшмә, дәшмичә генә миңа карап тор, диген. Алдыңа башымны куеп ятып торыйм әле, Әнисә. Беләсеңме, сиңа әйткәнем бармы — ни өчен мин синең алдыңда башымны куеп ятарга яратам. Балачакта әнием шулай йоклата иде мине. Бишек җыры җырлый иде. *(Диванга утырган Әнисәнең алдына башын куеп ята).* Миңа әз генә зарланырга ярыймы, Әнисә?

Әнисә: Зарлан...

Хәбир: Арыйм мин, Әнисә. Арымаска тырышам, әмма арыйм. Арыталар. Тынычлап эшләргә бирмиләр. Өстәгеләр налог белән, астагыларның да эшләмичә байыйсылары килә. Синең яныңда мин ял итәм. Җырла әле берәр бишек җыры.

Әнисә: Мин бишек җыры белмим бит, Хәбир. Ни өчен, кем өчен өйрәним мин аларны, балам юк.

Хәбир: Мин гаепле түгел бит инде аңа, Әнисә.

Әнисә: Кем сине гаепли. Балалар янына класска керергә ояла башладым мин. Безне тәрбияләгәнче үзеңне бел, дип әйтерләр төсле.

Хәбир: Тагын башлана инде, Әнисә. Кереп утырган башыңа бер уй, тәки...

Әнисә: Башыма түгел, күңелемә кереп ояләды. Куып чыгара алмыйм. Утыз алты яшь бит миңа. Акылга утырырга вакыт. Бала табып, бала үстерәсем килә минем, Хәбир. Кадерле сөяркә генә түгел, әни дә буласым килә.

Хәбир: Бәгырькәем, Әнисә... Нигә инде син?.. Тап. Берне, өчне, унны тап. Мин сиңа рәхмәт кенә укыячакмын. Барысын да сине яраткан кебек яратачакмын.

Әнисә: Зинадан бала табасым килми.

Хәбир: Тагын зина. Соң, ит рөхсәт, аерылам. Өйләнешәбез. Печать басылган ЗАГС кәгазе булыр. Үзең әйткән законлы хатыным булырсың. Аңла, җан кисәгем, сөяркә түгел син миңа — хатын. Хатыным.

Әнисә: Кешенең бәхетен җимерү — гөнаһ.

Хәбир: Нинди бәхет? Нинди гөнаһ? Синнән башка юк минем хатыным. Балаларым бар, алар алдында гаебем юк. Үстердем. Кечкенәсенә егерме яшь. Гөнаһ та гөнаһ. Белмисең бит син гөнаһның ни икәнен.

Әнисә: Кеше өлешенә керү — гөнаһ.

Хәбир: Ә минә Рәмзия алай дип әйтми.

Әнисә: Кем ул Рәмзия?

Хәбир: Миндә эшли. Унтугыз яшь. Синең кебек чибәр. Синең кебек акыллы кыз. Ул әйтә: сиңа бик нык ышанган кешене алдау — гөнаһ, ди. Гөнаһ кыласың килмәсә, син мине алдама инде, Әнисә.

Әнисә: Кайчан сине алдаганым булды.

Хәбир: Яратам, дия иден, яратмыйсың икән ич.

Әнисә: Уенга борма.

Хәбир: Мин уйный белмим бит, Әнисә. Син минем белән уйнарга җыенасың. Нининдидер хәтәр уен уйнарга җыенасың. Йә, ярый, тагын әллә кая кереп киттек. *(Чишенә башлап)* Мин синең кочагыңны сагындым, Әнисә.

Әнисә: Монда кунмассың инде син, Хәбир.

Хәбир: Тагынмы?

**Хәбирнең эш бүлмәсе. Хәбир тәрәзәдән карап тора. Тиз генә өстәле янына килә дә төймәгә баса. Рәмзия керә.**

Хәбир: *(Кабат тәрәзә янына барып)* Рәмзия Гариповна, килегез әле бирегә. *(Рәмзия килгәч)* Әнә теге карчыкны күрәсезме? Ак яулык бәйләгән. Монда алып керегез шуны. Аңладыгызмы?

Рәмзия: Аңладым да...

Хәбир: Аңласагыз, нигә карап торасыз? Аңлагач, үтәргә өйрәнегез. *(Рәмзия чыгып киткәч, өстәл янына килеп креслосына утыра, телефоннан шалтырата)* Кайттыңмы, Әнисә? Арыдыңмы?.. Тыңла әле, өр-яңа көй. *(Янындагы магнитофонны кабыза, телефон трубкасын магнитофонга якын китерә).* Ишетеләме?

Гәрәбәдән тезгән муенсаңның
Гәрәбәсе кайсы иллләрдән?
Тапмас диеп белмә, мин табармын
Җилләр эзләп тапмас җирләрдән.

Беләзегең, колак алкаң көмештән,
Күңелләрең ник суынды, фәрештәм?
Йөзегеңә ахак кашлар тапмадым,
Нахак сүзләр кем сөйләде, аппагым?

Калганын янында килгәч тыңларбыз. Яратасыңмы син мине, Әнисә? Мин сине бик тә, бик тә яратам. Күрмәгәнемә бер тәүлек була бит инде. Сау бул, көт мине *(Трубканы куя. Тәрәзә янына бара. Өстәле янына килеп каршы алырга әзерләнә).*

Рәмзия: *(Керә)* Мөмкинме?

Хәбир: Керсен. *(Рәмзия чыгып китә. Ишектән курка-курка гына кергән Хәбирәне каршылап)* Әйдә, әйдә, әби, түрдән уз. Син курыкма, әби... Син татармы, әби?..

Хәбирә: Татарин, татарин... Миңа бит анда ярый, диделәр.

Хәбир: Нәрсәне әйттеләр ярый дип?

Хәбирә: Әрбир сатырга ярый, диделәр.

Хәбир: Син сату итәсеңмени? Мин хәер сорашасың дип торам.

Хәбирә: Бирсәләр, анысын да алам. Үзебезнең кеше икәнсең әле. Ачуланма инде, пинсәм җитми бит. Гомер буе эшләдем. Мидаль бирделәр. Элек җитә иде, хәзер житкереп булмый шул. Ирексез баштан чыкканыем инде. Курше Начтыга ияреп чыкканыем.

Хәбир: Нәрсә сатасың инде?

Хәбирә: Нәрсә дип. Шул инде, сагыздыр, чигәриттер...

Хәбир: Ничә яшь инде үзеңә?

Хәбирә: Сиксәнне тутырдым инде. Болай, Аллага шөкер, үземне йөртәм дә, пинсәм җитми шул.

Хәбир: Кил әле, әби, утыр әле шушында.

Хәбирә: Утыр дип... Нинди жир соң бу?

Хәбир: Курыкма, әби, исемең ничек?

Хәбирә: Хәбирә Сөнгатуллина булам. Башта авылда тордык ирем белән. Аннан Казанга күчтек. Картым үлде шул. Ыртыйда эшләп пинсәгә чыкты да үлеп китте шул.

Хәбир: Без адашлар икән бит, Хәбирә әби. Мин үзем Хәбир исемле.

Хәбирә: Охшаган икән шул. Бар инде ул андый исемнәр.

Хәбир: Балаларыгыз бармы?

Хәбирә: Нинди жир соң бу?

Хәбир: Курыкма, дидем бит. Утыр җайлап...

Хәбирә: Куркуын курыкмыйм да... Куркыр яшьтән дә узган инде. Нишләтсеннәр мине. Шул куып кына җибәрәләр инде.

Хәбир: *(Төймәгә баса. Рәмзия кергәч)* Бик тәмле итеп чәй ясა әле безгә, Рәмзия Гариповна.

Хәбирә: Рәмзия исемлемени? Әйдә, ди, кая, мин әйтәм. Сезне бик әйбәт кеше чакыра, ди. Җилтерәтеп кенә алып керде. Бик яшь күренә, мескен.

Хәбир: Мескен?..

Хәбирә: Мескеннәр инде алар. Начтыларга килеп йөри берсе. Начтының кызының кызы. Карап торсаң, монын кебек тә... Үзгә эчерек, ди Начты. Эчерек булмый соң... итәктән төшүгә чигәрит тарта башлыйлар, аракы эчәләр... И Алла...

Хәбир: *(Рәмзия керткән чәйне һәм тәм-томны Хәбирә алдына куеп)* Яле, Хәбирә әби, тәмләп кенә эчик әле.

Хәбирә: Нинди җир соң бу?

Хәбир: Шикләнмә инде... Тәрәзәдән күрдем үзеңне. Утырасың. Татар әбие икәнең күренеп тора.

Хәбирә: Шушыннан да күренәмени?

Хәбир: Әйе, ап-ак яулыктан татар әбиләре генә була бит.

Хәбирә: Сабынга да акча җитми шул. Җитмәсә дә, тамактан өзеп булса да, юасың инде. Көнелләребез каралды инде каралуын да, яулыгыбыз ак булсын, ичмасам... Чәй эч, дисеңмени?

Хәбир: Шуның өчен куелган. Сөйләшеп утырасым килде.

Хәбирә: Нәрсә сөйләшәсең инде безнең белән, чыкмаган җан гына инде. Үлеп булмый бит әҗәл килмичә...

Хәбир: Товарлар үтәме соң?

Хәбирә: Ниткән товар?

Хәбир: Сагызларны әйтәм, чигәритләр...

Хәбирә: Кем алсын инде, дөнья тулы. Начтыга ияреп чыкканыем инде. Начты чиркәуләре янына да барып утыра. Мина да, мәчетегез ягына барып утыр, ди. Ничек инде барып утырасың, гөнаһ җыеп...

Хәбир: Балаларыгыз булмадымы әллә?

Хәбирә: Булмады шул. Бирмәде Ходай. Күчмик, дидем, Казанга. Уена керде бит. Калхузда пазур булып йөрмим, диде. Калхузда пазур булсаң да — үз җирең. Менә хәзер йөр инде пазур булып.

Хәбир: Туганнарыгыз бармы?

Хәбирә: Бар да бит. Һәрберсенең үз тормышы, үз кайгысы... И Алла... Әллә ниткән канфитләр чыгаралар хәзер. Безнең акча барында канфитләр югые. Нигә дип сыйлыйсың соң әле син мине?

Хәбир: Әйтәм бит, күрдем дә...

Хәбирә: Минем кебекләр дөнья тулы. Барын да чакырып чәй эчерсәң...

Хәбир: Барысын да булмый инде. Син күңелемә ошадың.

Хәбирә: Сөбханалла! Әле мондыйлар да бармыни дөньяда? Үзең зур нәчәлнек күренәсең. Үзебезчә дә әйбәт сөйләшәсең.

Хәбир: Мин авыл малае бит, әби. Минем әтиләр дә авылдан күчеп килделәр.

Хәбирә: Куптардылар шул халыкны. Чегән ясап бетерделәр халыктан. И Алла...

Хәбир: Әби, нәрсә ул гөнаһ?

Хәбирә: Ни-нәрсә, диден?

Хәбир: Гөнаһ... Нәрсә ул гөнаһ?

Хәбирә: Гөнаһ... Нишләп сорыйсың әле аны?

Хәбир: Беләсем килә.

Хәбирә: Беләсем килә, дип... Мин бит остабикә түгел. Мәчеттә беләләрдер.

Хәбир: Минем Сездән ишетәсем килә.

Хәбирә: Шуның өчен чакырып керттеңмени? Пинсәм җитмәгәч, нишлим инде.

Хәбир: Юк, әби, зинһар начар уйлама. Сез бит инде дөньяда озак яшәгән. Күрәсен күргән. Төрле чаклар булгандыр.

Хәбирә: Үзең дә бик яшь күренмисең. И Алла... Булгандыр инде, төрлесе булгандыр. Ходай үзе кичерә күрсен инде. Ашыйсың инде, дуңгызын да ашыйбыз... Хәерлегә генә булсын инде. Берәр нәрсә булды мәллә?

Хәбир: Ярату гөнаһмы ул, әби?

Хәбирә: Ничек ярату?

Хәбир: Ярату инде... Мәхәббәт...

Хәбирә: Минем башымны әйләндереп, карчык кешедән көлеп утырма инде.

Хәбир: Мин көлмим, әби. Минем чыннан да беләсем килә. *(Төймәгә баса, Рәмзия кергәч)* Рәмзия Гариповна, әбигә тагын чәй ясап кертегез әле. *(Рәмзия китә)*

Хәбирә: Юк, юк, кирәкми. Булды, җибәр инде син мине. Өйгә кайтыр чак та җитте. Начты инде киткәндер.

Хәбир: Үзегез генә утыра идегез ич.

Хәбирә: Начтының кибете икенче якта бит (кеткелдәп көлеп куя).

Хәбир: Әби, утырыгыз инде чак кына. Өегезгә машина белән илтеп куярбыз.

Хәбирә: Ниткән машина. Монда ерак түгел генә торам мин.

Хәбир: *(Рәмзия чәй керткәч)* Шушыны гына тәмләп эчегез инде. Чәе бик тәмле бит.

Хәбирә: Чәе тәмле инде анысы. Безнең чакта теге фил төшкән тәмле була иде. *(Чәйне эчә-эчә)* Яратуның ни гөнаһы бар икән. Яратмаган кешең белән тормышыңны бәйләү гөнаһтыр... Кит, диде. Китәм, дидем. Китмәдем түгел, киттем. Үле хәбәре килгәч тә киттем, җиде ел киттем. Кайтмады бит. Чыктым инде. Ялгыз калып булмый ич.

Хәбир: Яратмаган кешегә чыктыгызмы?

Хәбирә: Яратмаган, дип... Хәзер инде үлгән кешегә... Яраткан да түгел иде. Анысы калды бит сугышта. Китмәдем

түгел, көттем. Нишлисең инде... И Алла... Гөнаһлы булдым инде. Күңелем ятмаган килеш чыктым. Балабыз да булмады. Ярый, китим инде мин.

**Хәбир**: Туктале, әби. Менә шуны тыңла әле. (Магнитофонны кабыза. Анда баягы җырның дәвамы).

Энҗеләрдән тезгән муенсаңның
Энҗеләре кайсы яклардан?
Мин кагылган кайнар кулларыңа
Кагылдыра күрмә ятлардан.
Беләзегең, колак алкаң көмештән,
Күңелләрең ник суынды, фәрештәм?
Йөзегеңә ахак кашлар тапмадым,
Нахак сүзләр кем сөйләде, аппагым?

*(Хәбир магнитофонны туктата)* Ничек, әби, җыр сиңа ошадымы?

**Хәбирә**: Миңа нәрсә инде, үзеңә ошагач. Рәхмәт сиңа. Ходайга шөкер, мондый кешеләр дә калган икән.

**Хәбир**: *(Акча чыгарып Хәбирәгә суза)* Әби, боларны ал әле син.

**Хәбирә**: Нәрсә соң ул?

**Хәбир**: Ал син аларны. Йөрмә бу чигәритләрне сатып, ярыймы.

**Хәбирә**: Бик күп түгелме соң бу?

**Хәбир**: Күп түгел, ал. Син монда кергәләп йөр, әби. Мин булмасам, Рәмзия чәй куеп эчерер.

**Хәбирә**: Алар кулына калсаң, юк инде ул.

**Хәбир**: Алай димә, Хәбирә әби. Әйбәт кыз ул *(Рәмзияне чакыра. Рәмзия керә).* Рәмзия Гариповна, әбине озатып куй. Наилгә әйт, өенә илтеп куйсын. Сау бул, әби.

**Хәбирә**: Сау бул. Рәхмәтләр яусын үзеңә *(Рәмзия белән чыгып китә).*

**Хәбир**: *(Телефоннан шалтыратып)* Мин әле бу. Сагындыңмы мине? Әйт инде сагындым дип... Килеп җитәм... Көт мине.

*Пәрдә.*

# Икенче пәрдә

**Әнисә фатиры. Әнисә диванда утырып тора. Хәбир бүлмә буйлап йөренеп магнитофонда яңгыраган җырны тыңлый.**

Беләзегең, колак алкаң көмештән,
Күңелләрең ник суынды, фәрештәм?
Йөзегеңә ахак кашлар тапмадым,
Нахак сүзләр кем сөйләде, аппагым?

**Хәбир**: Гениальный җыр!

**Әнисә**: Гениальный түгел инде. Халтурить итә башлаганнар дусларың.

**Хәбир**: Шулай дисеңме, Әнисә? Ярый, искә алырбыз.

**Әнисә**: Кирәкми инде. Кай арада өлгерсеннәр инде алар көн саен бер җыр язарга...

**Хәбир**: Алар бит талантлар!.. Елга бер җырны мин үзем дә язам. *(Җырлап та күрсәтә)* Әнисә-ә, Әнисә!.. Әнисә-ә-ә.. Үләм дә китәм, Әнисә ул дисә-ә... *(Бүлмә буйлап болганып йөргәндә күзе тагын "Аятел-Көрси"гә төшә)* Ичмасам укып күрсәт бирәр сүзен. *(Әнисә янына утырып аны кочагына ала)* Укыма син аларны, Әнисә, укыма. Аларны күбрәк укыган саен яшәве авыррак. Болар бит идеаль кешеләр өчен язылган. Тормыш ул үз юлыннан бара. Рәмзия әйтмешли, жизнь башка нәрсә ул.

**Әнисә**: Синең Рәмзияң бик күпне белә икән. Килгән саен аның сүзен сөйлисең.

**Хәбир**: *(Кул чабып)* Ура-а-а!.. Берәүләр көнләшә. Димәк, ярата. Яратасың бит, әйеме?

**Әнисә**: Әллә нинди кеше син, Хәбир. Бер караганда — сабый, икенче караганда — деспот.

**Хәбир**: Син белмисеңмени, һәрбер бала-чага — деспот.

**Әнисә**: Чөнки ул үзен генә ярата, әйеме?

**Хәбир**: Үзеңне ярату начармыни? Үзен дә ярата белмәгән утын агачы ничек бүтәннәрне ярата алсын... И Алла, дияр иде Хәбирә әби.

**Әнисә**: Анысы кем тагын?

**Хәбир**: Чирле кеше сихерчеләргә ышана башлый бит. Мин дә шундыйга әйләнеп барам бугай. Әмма дә ләкин әйбәт әби ул.

**Әнисә**: Хәбир...

**Хәбир**: Юк, башлама...

**Әнисә**: Хәбир, бәгырькәем. Син аңла, җаным тыныч түгел. Әйдәле, кызмыйча гына уйлашыйк әле. Без икебез дә олы кешеләр ләбаса.

**Хәбир**: Гомер болай да кыска, нигә аны уй уйлап әрәм итәргә.

**Әнисә**: Шаярма инде.

**Хәбир**: Әйдә соң, уйлашыйк алайса. Сез ничек уйлыйсыз, Әнисә Кадый-ровна, мин Сезнең ишек төбенә

килеп асылыныйммы, өйгә кайтып асылыныйммы? Ничек итсәк, гөнаһысы әзрәк булыр икән?

Энисә: Хәбир, шаярма...

Хәбир: Мин чынлап. Синең турыңда уйлап. Мин инде беләм — минем урыным тәмугта. Ничек асылынсам, гөнаһысы әзрәк булыр икән?

Энисә: Мин ун ел синең белән бәхетле булдым, Хәбир. Бер кеше гомере өчен ун ел әз түгел ул. Гөнаһлы бәхет инде бәхетен дә... Анысын ходай кичерер. Инде тәүбәгә килеп тә гөнаһ кылсам, кичермәс.

Хәбир: Анысы аңлашыла. Нишлибез, син миңа әйт.

Энисә: Мин кияүгә чыгам.

Хәбир: Кияүгә? Кемгә?

Энисә: Мине бик күптәннән яратып йөргән кеше бар.

Хәбир: Кеше? Мин беләмме аны?

Энисә: Юк.

Хәбир: Элегрәк әйтмәдең.

Энисә: Нигә кирәк иде...

Хәбир: Хәзер кирәге чыктымы? Өйләнәм, диме?

Энисә: Ул мине көтә.

Хәбир: Ничек көтә?

Энисә: Минем акылга утырганымны.

Хәбир: Димәк, син акылга утырдың? Һәм яратмаган килеш шул кешегә кияүгә чыгасың?

Энисә: Бөтен кешеләр дә гел яратышып тормыйлар. Аның каравы, кеше алдында, үземнең алдымда йөзем чиста.

Хәбир: Әйбәт кешеме?

Энисә: Намуслы ул.

Хәбир: Намуслы? Ни сөйлисең син, Энисә? Бозау ул, ишәк ул!

Энисә: Хәбир, тукта...

Хәбир: Туктамыйм. Ничә еллар буе яраткан кызының ир куенынннан бушаганын көтеп яткан бәндә ишәк булмый кем булсын. Намуслы... Ярата... Яратса, әллә кайчан ул минем бугазымны чәйнәп ташларга тиеш иде. Һәм син, Энисә, минем Энисәм, шул ишәктән бала табып гөнаһсыз булырга җыенасыңмы? Бу гөнаһ кына түгел, җинаять. Бу кабахәтлекне карап торып, моны кичергән алла — идиот ул. Нишләвең бу, Энисә? Мин ун ел буе акылдан шашып шушы Энисәне яратып йөрдемме? Юк, син чирлисең, Энисә. Нормаль кеше болай сөйләшми. Намуслы, имеш.

Энисә: Бөтен кеше дә синең кебек...

Хәбир: Минем кебек булмаса, минем кебек булырга тырышсын. Була алмаса, яратам дип, маңкасын агызып йөрмәсен. Гафу ит, зинһар, ямьсез сүз әйттем. Ләкин башка сүзгә лаек түгел ул. Синең янына килеп кенә карасын, мин аның бугазын чәйнәп өзәм. Аягыннан күккә асып куям. Бөтен намуслы затлар күктә яши. Җирдә — бөтенесе дә гөнаһлылар.

Энисә: Усал син, Хәбир.

Хәбир: Син мине усал булганым өчен яратасың. Нишләтим, юаш түгел... Мин дә бит намуслы, Энисә. Сиңа хыянәт иткәнем юк минем. Рәмзия яшендәгеләр рельс шпаллары кебек тезелеп ятарга ризалар. Мин хыянәт итмим, чөнки сине яратам. Нигә әле кемдер намуслы да, мин намуссыз? Юк, юаш түгел мин. Һе... Ун ел буе көтеп тора, ә... Ун ел буена көтә.

Энисә: Мин дә бит ун ел көтәм, Хәбир.

Хәбир: Көтәсең?..

Энисә: Аны түгел, сине. Нидер булыр сыман иде, берни дә юк. Гомер үтә.

Хәбир: Һаман үз туксанын туксан. Үзең сөйләгәнгә үзең ышанмыйсың. Аңла, син минем өчен генә яратылган, бары тик минем өчен генә. Без йә икебез дә бәхетле, йә икебез дә бәхетсез.

Энисә: Бәлки, дөрес әйтәсеңдер дә... Ләкин мин зинадан бала табарга теләмим. Олыгайган көнендә синең балаларыңның анасын да ялгыз итәсем килми. Ничек син шуны аңлый алмыйсың?

Хәбир: Балагыз булмаячак. Хәбирә әбинең булмаган. Яратмаган кешегә кияүгә чыксаң, Ходай Тәгалә бала бирми икән. Бигрәк тә сине көткән...

Энисә: Хәбир, әгәр дә син аны мыскыллап берәр сүз әйтсәң...

Хәбир: Да-а-а, бырат. *(Магнитофон янына барып шунда кайнаша. Аннан җыр яңгырый)*

Гәрәбәдән тезгән муенсаңның
Гәрәбәсе кайсы иллердән...

*(Магнитофонны туктатып)* Да-а-а, бырат. *(Энисәгә төбәлеп карап тора)* Яратам бит мин сине. Югыйсә, ун ел йоклаган хатын үзе китәм дип торганда сөенер генә идем. Мин куркам бит, Энисәм. Ниндидер фаҗига булыр кебек *(Өстәлдә яткан догалыкны алып)*. Дога да дога. Гөнаһ... Мөхәммәтегезнең ничә хатыны булган?.. Мин аңардан киммени? Ул да яраткан, мин дә яратам... Стоп!..

Килеп життек!.. Беләсеңме нишлибез, Әнисә. Син теләгәнчә була. Мулла алып киләм дә, безгә дога укый да өйләндерә дә куя. Ул вакытта син дә минем законлы хатыным буласың. Тегесе урыс законы белән законлы, син татар законы белән законлы. Ризамы шуңа? Әйт, ризамы?

**Мәчеттә Хәкимулла хәзрәтнең эш бүлмәсе. Хәкимулла хәзрәт өстәл янында язып утыра. Ишектә Хәбир.**

Хәбир: Мөмкинме керергә?

Хәзрәт: Рәхим итегез. *(Аягүрә басып)* Узыгыз, рәхим итегез, утырыгыз.

Хәбир: *(Үзен иркен тотарга тырыша да, каушабрак калганы сизелә. Игътибар белән бүлмәне күзәтә. Элгечтәге чалма белән чапанга карап тора)* Исәнмесез. Сездә ул икенче төрлерәк әйтелә бугай. Әссәламегаләйкем.

Хәзрәт: Вәгаләйкем әссәлам вә рәхмәтулла вә бәрәкәтүһ. *(Елмаеп)* Сәлам бирүегез хак булсын. Сүзләрнең төрле булуы мөмкин.

Хәбир: Мәчеттә здравствуйте, дип әйтергә ярамыйдыр инде. Гөнаһтыр.

Хәзрәт: Әгәр сәлам бирүче урыс кешесе булса, нигә ярамасын.

Хәбир: Мәчеткә урыска да керергә ярыймыни?

Хәзрәт: Ни өчен ярамаска тиеш?

Хәбир: Сез мулламы?

Хәзрәт: Мин бу мәчетнең имам хатибы.

Хәбир: Миңа мулла кирәк иде.

Хәзрәт: Йомышыгызны әйтегез.

Хәбир: Миңа мулла кирәк.

Хәзрәт: Тыңлыйм Сезне.

Хәбир: Сез мулламы соң?

Хәзрәт: *(Елмаеп)* Әйе, дип әйтик.

Хәбир: *(Ышанмыйчарак)* Бик яшь күренәсез.

Хәзрәт: Муллалар карт булырга гына тиешме?

Хәбир: Гарәбстанда укып кайттыгызмы?

Хәзрәт: Юк. Бохарада.

Хәбир: Миңа кем икәнемне әйтер-гәме?

Хәзрәт: Кем икәнегезне әйтү мәҗбүри түгел, ни өчен килгәнегезне белү кирәктер.

Хәбир: Алдан ук әйтеп куям — мин дингә ышанмаучы кеше.

Хәзрәт: Ышанмаучы димәгез, динне тотмыйм, дисәгез дөресрәк булыр.

Хәбир: Мин консультация алырга килдем.

Хәзрәт: Рәхим итегез.

Хәбир: Шулай да... Ничә яшь Сезгә?

Хәзрәт: Утыз.

Хәбир: Утыз... Утыз инде яшь түгел... Әйе... Әйтегез әле, нәрсә ул гөнаһ?

Хәзрәт: Сез укыган кешеме?

Хәбир: Югары белемем бар.

Хәзрәт: Алайса, соравыгызның җавабын беләсез.

Хәбир: Белсәм, сорамас идем.

Хәзрәт: Гөнаһның ни икәнен белмәүчеләр андый сорауны бирмиләр.

Хәбир: Кызык икән.

Хәзрәт: Зарар юк. Сез консультация дип ялгышрак әйттегез. Сез, ялгышмасам, бирегә бәхәсләшер өчен кергәнсез.

Хәбир: Бәхәс? Әйе, бәлки бәхәстер. Ә Сез бәхәстән куркасызмы?

Хәзрәт: Нигә куркырга. Дөнья ул үзе мәңгелек бәхәстән тора.

Хәбир: Нишләргә? Ничек яшәргә икәнен ходай язып куйгач, бәхәсләшеп торасы юктыр.

Хәзрәт: Ходай хакыйкатьне эзләүне тыймаган.

Хәбир: Шулай да, әйтегез инде, нәрсә ул гөнаһ?

Хәзрәт: Рәхим итегез. Кылырга ярамаган гамәлләрне кылу.

Хәбир: Сез мине ачуланасызмы?

Хәзрәт: Нигә?

Хәбир: Мин Сезне кимсетебрәк сөйләшәм бугай.

Хәзрәт: Әгәр шулай икән, Сез мине түгел, үзегезне кимсетәсез. Томана кешеләр генә үзләре кебекләргә кимсетеп карый.

Хәбир: Мәчетегезгә кеше күп йөриме?

Хәзрәт: Шуны белергә килдегезме?

Хәбир: Юк... Төп сүзне ничек башларга белмәгәннән ул. Мәчеттә беренче тапкыр. Чиркәүгә кергәнем бар, Мәскәүдә. Мәчеткә — юк.

Хәзрәт: Андыйлар Сез генә түгел. Күрәм, әле Сез телне онытмагансыз. Теленнән дә, дененнән дә язганнар күбәйде.

Хәбир: Анысына алар гаепле түгел.

Хәзрәт: Кем гаепле соң? Шулай инде — явызлык, имансызлык арткан саен гаеплеләр азая бара. Имансыз җан һәрвакыт үзен үзе аклар өчен җай таба. Иманлылар гына кеше гаебен дә үзләреннән эзлиләр.

Хәбир: Нәрсә соң ул иман?

Хәзрәт: Намус нәрсә соң?.. Вөждан нәрсә?.. Оят нәрсә?..

Хәбир: Сез миңа берәр дога укып күрсәтегез.

Хәзрәт: Мәчет — цирк, мин клоун түгел, абзый кеше.

Хәбир: Мин Сезне мыскыл итәргә теләмәгән идем.

Хәзрәт: Сез бервакытта да мыскыл итәргә теләмисез.

Хәбир: Ачуланмагыз. Мәчеткә төрле кеше киләдер инде. Минем ише томаналары да. Гел әйбәтләр генә килсә, Сезгә кызык та булмас иде, әйе бит? Мин шундый бәйләнчек кеше инде. Тагын бер генә сорау бирәм дә йомышымны әйтәм.

Хәзрәт: Рәхим итегез.

Хәбир: Ярату гөнаһмы?

Хәзрәт: Яратмау — гөнаһ.

Хәбир: Рәхмәт. Инде — йомышым... Мәсьәлә болайрак. Башта Сез мине мулла булып тыңламагыз, ир кеше булып тыңлагыз. Әйтик, без мәчеттә түгел, ди, поезд вагонында барабыз, ди. Икебез дә әз генә төшереп алган, ди. Әз генә... сез бераз тоткалыйсызмы?

Хәзрәт: Минем аңлавымча, Сез ахмак кеше түгел...

Хәбир: Ачуланмагыз инде. Димәк, без поезд вагонында барабыз.

Хәзрәт: Юк инде, без мәчеттә утырабыз.

Хәбир: Нәрсә, мин сүземне муллага гына сөйләргә тиешме?

Хәзрәт: Йомышыгыз хәзрәткәдер бит.

Хәбир: Әйе. Әйе, муллага, хәзрәт. Ярый, сезнеңчә булсын. без вагонда түгел, мәчеттә. Димәк, болай... Кыскасы, мин — өйләнгән кеше. Законлы, ЗАГС тарафыннан теркәлгән. Ике улым бар. Икесе дә житкән егет. Хатынымны ялганларга жыенмыйм. Ничек бар шулай. Ләкин мин икенче берәүне яратам. Ун ел очрашабыз. Мин аны хатыным дип саныйм, ул үзен алай санамый. Өйдә минем очрашканны беләләр, дәшмиләр. Менә шулай. Ун ел буе аны-моны уйламый яшәдек. Көннәрдән бер көнне мин яратып йөргән кыз әйтә: бала табасым килә, ди... Юк, аңа хәтле әле ул гөнаһ дип сөйләнә башлады. Кыскасы, бала табасым килә, ди. Ләкин зинадан табасым килми, ди. Мин әйтәм, өйләнешик, дим, законлы хатын белән аерылышам, дим. Ул риза түгел. Кеше өлешенә керәсем килми, ди.

Хәзрәт: Нигә әле Сез боларны мәзәк сөйләгән кебек сөйлисез?

Хәбир: Әллә шулай килеп чыктымы? Юк, бу мәзәк түгел. Мин аны чын-чынлап яратам. Минем хәлне аңлыйсыздыр инде? Әйтегез, нишләргә миңа?

Хәзрәт: Сез ун елга соңарып килдегез.

Хәбир: Ничек ун елга?

Хәзрәт: Ун ел элек, мин бер кызга гашыйк булдым, ләкин хатыным, балаларым бар, дип килгән булсагыз...

Хәзрәт: Менә мин бүген килдем бит. Дога укып безне өйләндерегез.

Хәзрәт: Сөяркәгез белән никахла-шырга телисезме?

Хәбир: Сөяркә генә түгел ул миңа.

Хәзрәт: Сезгә түгелдер дә, бүтәннәр өчен шулай.

Хәбир: Ярый, мәсьәлә анда түгел, безне законлы ясагыз.

Хәзрәт: Сезнең законлы хатыныгыз бар инде.

Хәбир: Мин Сезгә аңлаттым бит.

Хәзрәт: Димәк, ике хатын белән торырга телисез?

Хәбир: Шулай килеп чыга.

Хәзрәт: Без андый эшкә бара алмыйбыз, абзый кеше.

Хәбир: Нигә?

Хәзрәт: Нигә икәнен үзегез дә беләсез.

Хәбир: Мөхәммәтнең хатыннары ничәү булган?

Хәзрәт: Без Мөхәммәт рәсүлулла илендә яшәмибез.

Хәбир: Беләм. Сез әйтегез, ике хатын белән яшәү мөселманга рөхсәт ителәме?

Хәзрәт: Ләкин сез бит мөселман түгел.

Хәбир: Кем соң?

Хәзрәт: Кем соң?

Хәбир: Ярый, мөселман дип атагыз мине. Аннан соң ул никах миңа кирәкми дә. Аңа кирәк. Гөнаһтан котылырга кирәк. Зина дигән сүздән котылырга кирәк. Укыгыз никах. Беркем дә белмәс. Без өчәү генә белербез.

Хәзрәт: Жуликлар шикелле төнлә белән кача-посамы?

Хәбир: Жуликлар илендә яшәгәч шулай була инде.

Хәзрәт: Юк, абзый кеше, алай жиңел генә эшләнми ул. Хәтта Сезгә никах укыган очракта да беренче хатыныгызның ризалыгы кирәк.

Хәбир: Нигә аны шул чаклы зурга жибәрергә?

Хәзрәт: Зур эш белән килгәнсез,

абзый кеше. Мин жулик түгел. Кача-поса гына никах укып, Сезне законлы ясасам, гөнаһысын кая куярмын. Бөтен нәрсәне кача-поса гына эшләргә өйрәндегез дә, шуның бар гөнаһысын без җыеп алыйкмы?

Хәбир: Һаман гөнаһ...

Хәзрәт: Ә ни дип белдегез?

Хәбир: Ярату гөнаһ түгел, дидегез.

Хәзрәт: Ярату гөнаһ түгел. Ләкин Сез яраткан саен никах укып торсаң... Ярый, мин сезгә кача-поса никах укыдым, ди. Сез тагын берәүне ярата башласагыз, анысына да укыргамы?

Хәбир: Анысы булмый инде.

Хәзрәт: Ә ни белән ышандыра аласыз? Дәлилегез кайда?

Хәбир: Намусым бар ич минем.

Хәзрәт: Законлы хатыныгыз булып та икенчене ятратканда намусыгыз юк идеме?

Хәбир: Бутамагыз әле, хәзрәт.

Хәзрәт: Сез үзегез буталмагыз. Бик җиңел генә яшәргә җыенасыз. Яратам, яратмыйм. Дөньяның уртасына басып алабыз да яратамларга, ярат-мыймларга бүләргә тотынабыз. Безнең барыбызны да яраткан ходай бар. Аны онытабыз. Берәр җиребез авыртканда "алла, алла" дип авырткан җиребезгә тотынабыз. Бер хатыныбызга канәгать булмыйча, икенчеләрен алдыйбыз да "сөяркә" дип атарга теләмибез. Сөяркә ул сөяркә инде, абзый кеше. Нидән куркасыз? Нидән ояласыз? Алар белән зина кылырга оялмыйсыз ич. Бу дөньяда һәр нәрсәнең үз исеме бар. Әйбер урлый икән — карак, урлашып кочаклаша икән — зина. Гөнаһ кыласың икән, гөнаһны күтәрергә дә әзер булырга кирәк. Оҗмахка арткы ишектән генә керергә телисез.

Хәбир: Мин, мулла, вәгазь тыңларга килмәдем.

Хәзрәт: Мәчет ул вәгазь укый һәм вәгазь тыңлый торган урын. Сатулашыр өчен базар бар.

Хәбир: Үзегез бер дә гөнаһсыз-мыни?

Хәзрәт: Без барыбыз да гөнаһлы-лар. Шуның өчен бер алладан ярлыкау сорыйбыз.

Хәбир: Тормыш бар, мулла. Ул Сез теләгәнчә генә бармый. Сезнең вәгазегез генә төзәтә алса икән аны. Сез тормышны белмисез, белергә теләмисез. Шуңа күрә дә мәчетегезгә йөрмиләр.

Хәзрәт: Кем әйтте? Сез бит тикшереп тормыйсыз.

Хәбир: Күренеп тора инде.

Хәзрәт: Йөрерләр. Буталып, буталып йөриләр дә бусагага килеп егылалар. Азып-тузып йөрү рәхәт тә, аның өчен җавап тотасы бар шул. Сез дә килгәнсез битәнә.

Хәбир: Килдем дә — куасыз.

Хәзрәт: Шайтаннарны куалар инде мәчеттән. Мәчет бит ул фәхешханә түгел. Хуш иттек. Минем өйлә намазына керәсем бар.

**Әнисә фатиры. Диванда Хәбир ята. Магнитофон иң көчле тавыш белән "Әнисә" җырын җырлый.**

Очкан кошның язып канатына
Хат җибәрсәм, барып җитәр микән?
Агымсуга салсам сагышымны,
Сагышларым агып китәр микән?

Тәрәз ачарсыңмы, Әнисәм,
Кош булып очып килсәм?

Әнисә: (*Кайтып керә. Хәбир карап тора. Магнитофонның тавышын әкренәйтә)* Исәнме, Хәбир.

Хәбир: *(Урыннан кузгалмыйча гына)* Исәнме. Гафу ит, синең өең, синнән алданрак кердем... *(Әнисә эндәшмәгәч)* Нигә дәшмисең?

Әнисә: Ни дип әйтим соң?

Хәбир: Нигә кердең? Кем рөхсәт итте, диген.

Әнисә: Син инде күптән рөхсәт сорап тормыйсың.

Хәбир: Начармы ул, яхшымы?

Әнисә: Белмим.

Хәбир: *(Әнисәгә сырты белән борылып ята. Әнисә эндәшмәгәч, яңадан борыла)* Сиңа рәхәт, бер нәрсә дә белмисең.

Әнисә: Ни диим инде?

Хәбир: Чәй куйдыңмы минем кайтышыма, диген.

Әнисә: Чәй куйдыңмы минем кайтышыма?

Хәбир: Өстәлдә. (*Әнисә әзерләнгән табын өстенә җәеп куелган тастымалны күтәреп карагач)* Рәхмәт әйт инде.

Әнисә: Рәхмәт, Хәбир.

Хәбир: Мондый хезмәт өчен үбеп алырга да ярый инде. *(Әнисә яңагыннан үбеп алгач)* Болай итеп йә балалары әтиләрен үбәләр, йә әтиләр балаларын үбәләр.

Әнисә: Тор әйдә, куйган чәеңне эчәбез.

Хәбир: Тормыйм, торсам, куып

чыгарырсың. Син кайсы мәчеткә йөрисең?

**Әнисә:** Йөрмим мин. Бер генә тапкыр бардым.

**Хәбир:** *(Торып утырып)* Бюрократлар алар.

**Әнисә:** Кемнәр?

**Хәбир:** Муллалар. Элеккеге бюрократлардан артык бюрократлар. Мин аларга әйтәм, яратам, дим, ә алар? Ничә мәчеткә бардым. Бер сүз сөйлиләр. Шайка. Бюрократлар шайкасы. Ярамый, имеш... Яраса, мин алар янына ялынып барамммы?

**Әнисә:** Йөрмә инде син, Хәбир, кирәкми.

**Хәбир:** Дөрес, Әнисә! Беркая да йөрмибез. Әгәр безгә рәхәтләнеп яшәр өчен бер дога житми икән, үзем өйрәнәм. Бөтен Коръәнне ятлап чыгам, үзебезгә тиешле доганы үзем укыйм һәм — вәссәләм. Бисмилла ирахман ирахим...

**Әнисә:** Хәбир, тукта.

**Хәбир:** Булды, Әнисә. Туктадым. *(Әнисә каршына утырып)* Син беләсеңме, Әнисә, мин бу фатирга беренче тапкыр куркып кердем. Бу бик начар. Ир кеше хатын-кыздан курка башлый икән, ул ир булудан туктый, алашага әверелә. Син алашаның нәрсә икәнен беләсеңме? Мин белми идем, миңа аны авылга кайткач, Миңнур абый күрсәтте. Күр, Хәбир, ди, шундый көнгә калырга язмасын, ди. Үлгәндә дә айгыр булып үләргә кирәк, ди.

**Әнисә:** Кеше бит ул ат кына түгел.

**Хәбир:** Ат кешедән акыллырак, шуңа күрә аны печәләр дә кешеләр.

**Әнисә:** Таптың сөйләшер сүз.

**Хәбир:** Ни турында сөйләшик соң? Син беләсеңме, Әнисә, элек без бик аз сөйләшә идек. Сөйләшергә вакытыбыз калмый иде. Син әнә шул доганы ишек өстенә кадаклап куйганнан соң — сүз дә сүз. Мин сиңа тагын да куркынычрак сүз әйтәм әле. Мин синең өенә киләсе килмичәрәк килдем. Элек атлыгып тора идем, бу юлы килергә кирәк булганга гына килдем сыман.

**Әнисә:** Шулай булырга тиеш инде ул, Хәбир.

**Хәбир:** Ничек, шулай булырга?

**Әнисә:** Кайчан да булса бер шулай буладыр. Яшьлек үтә бит. Тиеш булганга гына яши башлыйсың. Мин дә шуңардан куркам.

**Хәбир:** Яман бит бу, Әнисә.

**Әнисә:** Яман, әлбәттә. Иң яманы, үткәннәрне еш искә ала башлыйсың. Гөнаһларыңны барлыйсың.

**Хәбир:** Житте, сөйләшмик, Әнисә. *(Паузадан соң)* Кешегә җайсыз бу дөньяда яшәве. Ярамый да ярамый. Мин аңлыйм, урлашырга ярамый, сугышырга ярамый, үтерергә ярамый. Ләкин яратышырга ярый бит. Яратсын яраткан кеше яраткан кешесен. Нигә аны тыярга? Хәтта хайваннарга да җиңелрәк: яраткан хайванын ярата, ярамый дип әйтүче юк. Гөнаһ та димиләр.

**Әнисә:** Хайван кешедән акыллырак, дидең бит. Кеше кебек азып-тузып йөрми.

**Хәбир:** Молодец! Без синең белән философлар булып беттек. Әйе... Мин болай уйламый идем. Мин эш турында уйлый идем. Конкрет уй, конкрет план һәм аны тормышка ашыру. Хәзер уйлыйм — чыннан да, нәрсә ул гөнаһ? Нәрсә ул намус? Нәрсә ул?.. Әле бер мәчеттән чыктым да, чиркәү яныннан узып барганда, туктале, поп янына да кереп чыгыйм әле, дим. Аныңча нәрсә икән ул гөнаһ, дим. Югыйсә, нәрсәгә кирәк ул миңа чиркәү, нәрсәгә кирәк поп? Менә син әйт әле, Әнисә, әгәр дә поп әйтсә, рәхәтләнеп яшәгез, яратышыгыз, сез гөнаһ кылмыйсыз дисә, син нәрсә әйтер идең?

**Әнисә:** Мәгънәсез сүзләр сөйләшмик.

**Хәбир:** Шулай инде. Философ булгач төрлесен сөйләшәсең. Менә мин, мәсәлән, әгәр дә син Әнисә булмасаң, Анфиса булсаң, мин Әнисәне яраткан кебек Анфисаны да ратсам, поп әйтсә, догасыз, ЗАГС сыз рәхәтләнеп яшәгез, гөнаһ түгел дисә...

**Әнисә:** Хә-ә-би-ир...

**Хәбир:** Курыкма, мин чукынмадым. Аллам сакласын. Ләкин кердем чиркәүгә. Аларның барысы да бер, Әнисә. Мулласы да, побы да. Берсе дә кешегә яхшы булсын, кеше бәхетле булсын дип тырышмый. Мин монда кунмыйм инде, Әнисә. Сине кочакламыйм да. Гөнаһ бит. Әйтерсең инде теге кияүгә чыгасы кешеңә. Композитор шалтырата, ни булды, җыр сорамыйсың, ди. Язган әзер җырыбыз бар, ди. Тагын Әнисә турында, ди.

**Әнисә:** Нигә алып килмәдең соң?

**Хәбир:** Сиңа кирәкми иң алар.

**Әнисә:** Кайчан әйттем, кирәкми, дип?

**Хәбир:** Халтура, дидең.

**Әнисә:** *(Хәбирнең кулларын учына алып)* Шаяртып әйткән сүзне дә күтәрә

алмыйсың, ә? Ә менә син ишәк дип атаган кеше ничә ел буе миңа багышлап шигырьләр яза. Баштарак көлә идем, ул барыбер туктамады. Тик аларны миңа укымый инде. Күптәннән. Өметен өздe.

Хәбир: Үзе көтәме?

Әнисә: Көтә.

Хәбир: Өметен өзгән килеш көтәме? Димәк, өзмәгән.

Әнисә: Әйе, шулай булып чыга.

Хәбир: Миңа күрсәт әле шуны.

Әнисә: Нигә кирәк?

Хәбир: Хет, ичмасам, кыяфәтен күрим. Бәлки мине дә шигырь язарга өйрәтер. Син аңарга кияүгә чыгып, бала табарсың да мин сиңа шигырь язып ятармын. Синең аерылганыңны көтәрмен. *(Кинәт Әнисәне кочагына ала)* Мин сине, Әнисә, беркайчан да беркемгә дә бирмәячәкмен. Син — минеке. Син бары тик минеке генә. Зинһар бизмә миннән... Зинһар биздермә мине. Миңа дөньяда яшәүнең кызыгы калмаячак. Кызган мине, Әнисә.

**Хәбирнең эш бүлмәсе. Хәбир үз урынында утыра.**

Рәмзия: *(Ишек төбендә)* Сез чакырган кеше килде.

Хәбир: Керсен. *(Рәмзия чыгып китә. Хәлил керә).*

Хәлил: Исәнмесез.

Хәбир: *(Өстәл артыннан чыгып)* Нихәл, бырат? Син әле һаман "сез" дип сөйләшәсең. Мин әйттем бит инде.

Хәлил: Шулай өйрәнелгән, шулай җайлырак.

Хәбир: Йә, утырып җибәр әле, бырат. *(Рәмзияне чакырып кертеп)* Рәмзия, беләсеңме бу абыеңны? Шагыйрь ул, белдеңме? Сыйла әле шагыйрь абыеңны тәмле итеп чәй белән. *(Хәлилгә)* Мәй тотмыйсың инде син.

Хәлил: Юк.

Хәбир: Синең бу бүлмәдә булганың да юк бугай әле.

Хәлил: Юк.

Хәбир: Менә шушында эшләп ятам, инде мин, бырат. Кара, исемеңне дә сораган юк. Бырат та бырат. Исемең ничек синең?

Хәлил: Хәлил.

Хәбир: Безнең исемнәр охшаш икән ич. Эшләр ничек соң? Ну синең җырларны ярата Әнисә. Үлеп китә инде. Мин әйтәм аңарга, аның кебек шагыйрь Татарстанда юк, дим. Чыннан да шәп язасың бит. Мин әле синең кебек язганнарны күргәнем юк.

Хәлил: Бүтәннәрне укымаганга шулай ул.

Хәбир: Шулайдыр, бырат. Укыганым юк. Вакыт та житми. Аннан, мин бит урысча укыдым, татарчага күнегеп булмый. Ну синекен аңлыйм. Китапларың да бардыр инде.

Хәлил: Юк.

Хәбир: Ничек юк? Әллә чыгармыйлармы? Нигә әйтмисең? Беркөн депутат сөйләп тора иде, акча юк китап чыгарырга дип. Табабыз аны.

Хәлил: Мин үзем өчен генә язам.

Хәбир: Минем өчен дә язасың ич.

Хәлил: Сорады да инде Җәүдәт.

Хәбир: Җәүдәт исемлемени композитор? Ну, подлец мин. Бырат та бырат. Сез дуслармыни аның белән?

Хәлил: Танышлар.

Хәбир: Карале, бырат. Ничә күрәм сине, һаман нindидер боек син. Кемдер сине рәнжеткән кебек, чирле кеше кебек.

Хәлил: Шундый инде.

Хәбир: Беркөн колакка ишетелеп калды, синең квартир юкмыни?

Хәлил: Бар. Миңа житә, берүземә.

Хәбир: Ничек берүзеңә? Әллә үзең генә яшисеңме?

Хәлил: Әйе.

Хәбир: Аерылдың мәллә?

Хәлил: Өйләнгән юк әле.

Хәбир: Ничә яшьтә соң үзең?

Хәлил: Утыз сигездә.

Хәбир: Ничек?..

Хәлил: Шулай... Йомышыгыз бар идеме?

Хәбир: Ә-ә, әйе. Карале, бырат. Миңа шигырьләр кирәк. Күп шигырь кирәк. Беләсеңме, менә шундыйлар. Минем Әнисәне яратып йөргән берәү бар икән. Шигырьләр яза икән. Ун ел буе Әнисәгә багышлап шигырь яза икән, ахмак. Менә шуны уздырырлык булсын. Беләсең, мин акчаны кызганмыйм.

Хәлил: Мин шигырьне акчага язмыйм.

Хәбир: Ничек язмыйсың. Җырлар өчен...

Хәлил: Җыр өчен Җәүдәт ала.

Хәбир: Сиңа бирмиме?

Хәлил: Мин үзем алмыйм.

Хәбир: Кызык икән. Шагыйрьләр барысы да бераз ниерәктер инде.

Син ачуланма, бырат. Мыскыл итеп әйтмим. Әнисә әйткән кеше дә шундыйрак, ахрысы. Ун ел буе көтә, ди Әнисә.

Хәлил: Яраткач, көтә инде.

Хәбир: Әнисәнең мине ярат-канын белгән килеш бит. Ничек була инде ул. Мин аның урынында булсам, төкереп кенә китәр идем.

Хәлил: Димәк, төкерә алмый. Яраткан кешесенә төкерә алмый.

Хәбир: Анысы шулай инде. Ничек итеп Әнисәгә... Ну, ун ел буе көтеп ятып та булмый ич. Минем бугазымны чәйнәп ташласын иде.

Хәлил: Ни өчен?

Хәбир: Соң бит мин аның ярат-кан кешесе белән йоклыйм.

Хәлил: Сез дә яратасыздыр ич.

Хәбир: Кемне?

Хәлил: Әнисәне.

Хәбир: Яратам гынамы?

Хәлил: Шулай булгач?.. Сезнең ни гаебегез бар? Нигә Сезнең бугазны чәйнәргә?

Хәбир: Карале, бырат, шулай килеп чыга бит. *(Кинәт Хәлилгә сынап карап торып)* Карале, син шул түгелдер ич?

Хәлил: Кем?

Хәбир: Әнисәне яратып йөрүче... Өйләнмәгән дисең, шигырь язасың.

Хәлил: Өстәвенә, көтәм дә әле.

Хәбир: Әнисәнеме?

Хәлил: Әнисәне.

Хәбир: Кит әле. Алай булмый.

Хәлил: Ничек була?

Хәбир: Ничек инде?..

Хәлил: Тынычланыгыз. Сезнең Әнисә түгел ул.

Хәбир: Шулай дисәң генә. Сырттан тир бәреп чыкты, бырат. Болай булганы юк иде. Мин үземне бик көчле кеше дип йөри идем.

Хәлил: Сез чыннан да көчле. Хатын-кызлар көчле кешеләрне яраталар.

Хәбир: Син көчсезме?

Хәлил: Шулайдыр, күрәсең. Хәер, кем ничек аңлый бит көчне. Берәүләр, уңга-сулга селтәнеп, кешеләр авызын җимереп йөрүне дә көчкә саный-лар.

Хәбир: Супермэннар заманы инде, бырат, нишләтәсең. Паханнар заманы.

Хәлил: Китәм мин...

Хәбир: Бераз утыр әле, бырат. Миңа күңелсез. Әллә ничеккә китте әле тормыш. шундый әйбәт тәгәри иде. Әнисә әллә нишләде. Яратам мин аны, бырат, бырат. Әллә нишләде. Гөнаһ, ди. Син беләсенме, нәрсә ул гөнаһ?

Хәлил: Белмим.

Хәбир: Беләсең. Син белергә тиеш — шигырьләр язсаң. Безнең эше утын агачы гына ул унны султан аера белми. Менә синен гөнаһың бармы?

Хәлил: Мин дә кеше.

Хәбир: Әйе, кешеләр инде без. Син көткән кыз сине яратмыймы?

Хәлил: Күрәсең, яратып бетерми.

Хәбир: Кияүдәме?

Хәлил: Юк.

Хәбир: Карале, син мине шикләндерәсең бит, бырат.

Хәлил: Мин ахмакка охшаган-мыни?

Хәбир: Кем әйтә?

Хәлил: Әнисәгә багышланган шигырь язучыны ахмак дидегез.

Хәбир: Син нәрсә, бырат... Ни-чек инде сиңа ахмак дип әйтим. Әнисәне әйтәм, ун ел дәшмәде аның турында... Тик торганда исенә төште. Шуңа кияүгә чыгам, ди. Мине алачак, ди.

Хәлил: Яраткач, нигә алмасын...

Хәбир: Әйт әле, мужикларча уй-лыйк әле. Ни әйтсәң дә, миннән калган хатын була бит инде ул.

Хәлил: Булса ни. Сез дә бит аңардан калган буласыз.

Хәбир: Карале, чыннан да шулай килеп чыга шул. Кызык кеше икән син. Әйдәле, әз генә коньяк тотыйк.

Хәлил: Юк, мин эчмим. Беләсең.

Хәбир: Эчкән дә булмадымы?

Хәлил: Юк.

Хәбир: Кайда эшлисең?

Хәлил: Мәктәптә.

Хәбир: Укытучымы?

Хәлил: Укытучы.

Хәбир: Слушай, син дурака не валяй, ярыймы? Мине ахмакка санап утырма. Әйт, дөресен генә.

Хәлил: Сез бизнесмен кеше, Хәбир әфәнде. Дөреслекне әйтергә ярамаганны беләсез. Дөреслекне белүгә үк яшәүнең кызыгы бетә. Бер шигырь укыйммы үзегезгә?

Хәбир: Йәле, йәле...

Хәлил:

Яратмыйм, дип син кычкырып әйтмә,
Сары сандугачның ишетүе мөмкин;
Былбыл йөрәгенен шартлавыннан
Өмет ярларының ишелүе мөмкин.

Яратам, дип син кычкырып әйтмә,
Серләр төененең чишелүе мөмкин;
Йолдызларга йолдыз бәрелүдән
Күкләр гөмбәзенең тишелүе мөмкин.

Хәбир: *(Паузадан соң)* Да-а-а, бырат. Ничек башка килә ул синең шундый нәрсәләр. Туктале, тукта, укыганым бар бит бу әйберенне. Син шул...

**Әнисә фатиры. Әнисә диванда утыра. Хәбир ишек төбендә басып тора.**

Хәбир: Син борчылма, Әнисә. Мин саубуллашырга гына килдем. Хушлашырга килмәдем, саубуллашырга гына килдем. Чык киявеңә, котыл сине гөнаһка батырган Хәбирдән. Яшәп кара. Аннары әйтерсең, Хәбир, килеп ал, диярсең. Мин көтәрмен. Бүтәннәр көткәнне әллә мин көтә алмаммы? Билгеле инде ун ел көтсәм, миңа ул чакта илле биш була. Сиңа да кырык алты була. Сау бул, Әнисә. *(Ишек өстенә карый).* Сау бул, "Аятел-Көрси", сакла Әнисәне шайтаннардан. Саубуллашыр алдыннан мин сиңа, Әнисә, бер җыр гына җырлыйм.

Тәрәзә төбем — каты бал,
Ашыйсың килсә, ватып ал.
Сөюләрең чыннан булса,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Тәрәзәдән тартып ал.

"Галиябану" дигән пьесада кем җырлый әле бу җырны, Әнисә.

Әнисә: Син аны каян белдең?

Хәбир: Җырнымы?

Әнисә: Хәлилне?

Хәбир: Үзе килде. Синең квартираңның ачкычларын сорый.

Әнисә: Шаярма, Хәбир.

Хәбир: Әкәмәт дөнья. Мин бит Сезнең арада хат ташучы була башлаганмын.

Әнисә: Ни сөйлисең, Хәбир?

Хәбир: Ул сиңа багышлап җырлар язган, мин аларны сиңа ташыганмын. "Әнисә, Әнисәм, җил булып иссәм, җил булып иссәм".

Әнисә: Берни дә аңламыйм, Хәбир.

Хәбир: Син миңа бер генә сүз әйт, син белә идеңме ул җырларны? Сине ун ел көткән Хәлил язганын? Юк, мин сиңа ачуланмыйм, ачуланырга хакым да юк. Әйт кенә, белә идеңме? Сез очраша идегезме? Әйт инде, очраша идегезме?

Әнисә: Нигә син миннән сорау аласың әле?

Хәбир: Сорау алмыйм, сорыйм гына. Үтенеп сорыйм.

Әнисә: Син миңа ышанмыйсыңмы?

Хәбир: Ышанам. Мин инде хәзер әллә нинди әкиятләргә дә ышанам. Үзең әйт. Үз телең белән әйт. Мин үземнең кем икәнлегемне белеп китәсем килә синең яннан.

Әнисә: Очрашмадык без, Хәбир, очрашмадык.

Хәбир: Алайса, син аның көткәнен кайдан белдең?

Әнисә: Юлымда көтеп торып, әйткәли иде.

Хәбир: Димәк, очрашкансыз.

Әнисә: Очрашмадык. Очрашу андый булмый. Син аны беләсең. Мин синең белән генә очраштым.

Хәбир: Хәер, очрашсагыз да, минем гаепләргә хакым юк. Мин бит нибарысы сөяркә генә.

Әнисә: Хәбир, рәнҗетмә мине. Минем бернинди гөнаһым юк синең алда. Әйт, аңлат миңа. Нинди җырлар?

Хәбир: Әйтмәдемени? Кайда ул кассеталар?

Әнисә: Әнә, өстәлдә.

Хәбир: *(Кассеталардагы җырларны уйнатып-уйнатып күрсәтә)* Таныйсыңмы?

Әнисә: Үзең алып килгәннәр.

Хәбир: Әйе, мин ахмак, мин ишәк алып килгән җырлар. Ә аларны язучы синең Хәлил.

Әнисә: Мин берни дә белмим, Хәбир. Белмим, берни дә белмим. *(Хәбир кассеталарны аяк астына салып таптаганда)* Хәбир!.. Хәбир...

Хәбир: *(Ишеккә таба бара да тукталып)* Барыбер минем кебек яратучы булмаячак сине.

Әнисә: *(Хәбир янына килеп)* Хәбир, туктале, тынычлан әле. Кил әле, утыр әле. *(Җитәкләп алып килеп диванга утырта)* Тынычлан... *(Хәбир сулкылдап еларга ук тотынгач)* Йә инде. бәгырькәем. Нишлисең соң син?

Хәбир: Нигә алдадың син мине? Дөньяда иң зур гөнаһ — сине бик яраткан кешене алдау.

Әнисә: Ышан, бәгырькәем. Валлаһи, билләһи, белмәдем. Элек шигырьләр язып җибәрә иде. Берсен син аны үзең дә укыдың. Көлә-көлә укыдың. Моннан тугыз ел элек иде ул. Шуннан

бирле язганы юк. Тыйдым. Хәтерендәме? Кем ул, диден. Мин әйттем, һәм без икәүләшеп көлдек. Шигырен ертып ташладык. Хәтерлисеңме?

Хәбир: Ничек соң алайса... Димәк, мин аны үзем эзләп таптым? Юк, композитор эзләп тапты. Һәм ул мине, сине белгән килеш. Ах, подлец. Идиотизм... Кара син аны... Һәм син шуның белән?.. Әйткән булса, ул минем яраткан Әнисәм, дисә... Мин аны синнән дә ныграк яратам, дисә... *(Кинәт урыныннан торып)* Ярый, Әнисә, булды бу. Казына торгач, казып чыгардык. Теләгеңә ирештең. Күңелнең кайсыдыр жирс кителде. Мин инде сине ратуымны чыннан да гөнаһ дип уйлый башладым. Гөнаһтыр. Яшьлегем миннән үч ала. Унсигез яшемдә утыз яшьлек кызга өйләнеп... Ярый. Хәерле булсын *(Иелеп кассета ватыкларын ала).* Болар өчен гафу ит. Жүләрлек. Үзең дә бит, тилермә, Хәбир, дия иден. Шул сүзенне әйтә иден дә рәхәт булып китә иде. Мин киттем, Аерылышканда кочаклалмыйм, кулымны да бирмим, китә алмам дип куркам. Нигә син бер сүз дә дәшмисең? Сау бул, диген. Һич югында, хуш, диген.

Әнисә: Хуш, Хәбир. Миңа үпкәләмә.

Хәбир: Нигә үпкәләргә? Һәркемнең үз тормышы. Рәмзия әйтмешли, жизнь... Бәхетле бул. *(Ишеккә юнәлә)*

Әнисә: Ачкычларны калдырдыңмы, Хәбир?

Хәбир: Ә-ә-ә, гафу ит. *(Ачкычларны китереп өстәлгә куя да:*

Озата барма, дустым, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам, —

дип *көйләп чыгып китә).*

Әнисә: *(Хисләрен тышка чыгарырга куркып, үзен көчкә тыеп торараш кебек хәрәкәтсез басып торган жиреннән кинәт ишеккә ташлана)*

Хәби-ир! Китмә! Китмә! Хә-ә-бир!..

*Крутушка.*

*Пәрдә.*

# ШИГЪРИЯТ



## Газинур Морат

### БЕЗ КИЧӘРГӘ ТИЕШ ИДЕЛНЕ

#### Замана

Бәреләдә сугыла ул,
Бәреләдә... сүгенә.
Әллә ширбәт, әллә шәраб
Тәме килә сүзеннән...

Бәреләдә сугыла ул,
Бәреләдә... сүгелә.
Әллә зурлык, әллә хурлык
Исе килә үзеннән...

* * *

Ил корабын күптән упкын йоткан,
Дию йоткан башын Алыпның.
Ярык тагаракта Идел кичеп
Яткан мәле әле халыкның.

Аваз килә Идел төпләреннән:
Сез кичәргә тиеш Иделне!
Шулай гына коткарырга мөмкин
Ирегеңне, Туган илеңне.

#### Сискәнү

Күзге ачы җилләрдә
Фетнә чыккан илләрдә...
Безнең башка ни язгандыр —
Тәрәзәмә җил бәрә.

## Нәтиҗә

*Урман биргән аңа матурлыгын,*
*Күлләр саф суларын сипкәннәр.*

Һ. Такташ. "Урман кызы".

Зиләйлүкләр, Гөлҗамаллар булып
Ул җырларда яши һаман да...
Табигатьтә урман кызы иде,
Урам кызы итте замана.

## Бәет

*Фәиз Зөлкарнәй рухына*

Бәетләргә бәет чыгарырлык
Чорсыз чорлар килгән чагында
Мин дә бәет чыгармакчы булдым,
Сыктамакчы булдым тагын да.

Мин дә бәет чыгармакчы булдым
Күккә ашкан кардәш хакында.
Ай күрде дә Кояш алды аны
Үз янына, Тәңре катына.

Мин дә бәет чыгармакчы булдым
Бер юламан егет турында.
Еллар түгел — юллар илтә икән
Кайтып булмый торган урынга.

Еллар түгел — юллар өзә икән
Юламанның соңгы сәфәрен.
Соңгы сәфәр...
Фәрештәләр мәллә
Буташтырган гамәл дәфтәрен?

Еллар түгел — юллар кисә икән
Соңгы өметне дә...
Шуңарга
Юл газабы — гүр газабы, диеп
Калды хәзер авыр суларга.

Чәкештергән идек чәркәләрне
Шигырь саулыгына икәү без.
Үзебезнең исәнлекне генә
Истән чыгарганбыз икән без.

Чәкештергән идек чәркәләрне
Болай гына... Күңел өчен дә.
Офык аръягында чал Вакыт та
Кирәдер күк шәфәкъ төсенә.

Чәкештергән идек чәркәләрне
Дөнья белән...
Булдык... казалы...

Юламанны соңгы сәфәренә
Озатадыр Киек Каз юлы...

Мин дә бәет чыгармакчы идем,
Сыктамакчы идем тагын да,
Бәетләргә бәет чыгарырлык
Чорсыз чорлар килгән чагында.
Мин дә бәет чыгармакчы идем...

* * *

*Р. Н.*

Сәхнәдә чынлап яшәде,
Ә тормышта — уйнады.
Бу дөньяда яшәүне ул
Уен диеп уйлады.

Бу дөнья аңа тамчы да
Кертмәде бугай акыл.
Сәнгатькә корбан кирәккәч,
Үз башын куйды, бахыр.

Бөек иде... Тиле диеп
Сөйләделәр ахырдан.
Илдә олтан булды...
Читләр
Һәйкәл куйды алтыннан.

## Сәрхуш

Ике кояш бата көн дә
Аның күгендә генә.
Ике ай йөзә төн буе
Аның күлендә генә.

Ике тәхет, ике ханча —
Аның түрендә генә.
... Чәркә аша чәчбие дә
Чибәр күренә менә.

Айныр иде...
Кайтыр иде
Мәгарәи мәленә:
Ул айныса, сәрхуш дөнья
Айнымас күк мәңгегә!

## Әйттеләр...

Йөрәгенә батман-батман
Кан сауды... калды авып.
Әйттеләр: бирде, дип, илгә
Соңгы шигырен савып.

## Хәтердә калган сурәт

Укылган китап күк ханым,
Кырын ятып ятагына,
Китап укый. Мәче белән
Эте ауный як-ягында.

Китапта — яшьлеге аның,
Үз яшьлеге — узмаганы, —
Үз бәхете, үз тәхете,
Үз базары, үз заманы...

Дөнья инде йоклый күптән,
Тик йокысы килми аның.
Таушалган бестселлер кебек,
Ятагында ауный ханым...

## Ялгыз карт

Узды гомер, сызды гомер,
Сызланып үтте еллар.
Тәгәрәпләр елар идең,
Яшь кипкән, булмый елап.

Бәхетле дә булалмадык,
Булмадык тәхетле дә.
Белмим, туган булганбыздыр
Кемнәрнең бәхетенә?..

## Көй чакыру

*Шәукәткә*

Күчем ханның күченнән ул,
Түмән диган тияктән.
Бу Казанга тик адашып
Килеп чыккан киектәй,

Гел сагаеп яшидер күк,
Гел сагынып яшидер.
Шуңа һәр кош ахир аңа,
Һәрбер җәнлек яшьтидер.

Һәр киекнең көен белә,
Көе китсә — көенә.
Ул юксынып яшидер күк
Себернең черкиен дә.

Җанында ау комарлыгы
Алса әгәр уянып,
Чөй язуын укыгандай
Укый эзен куянның.

Кошлар эзен укый күктән,
Укый үлән ымын да.
Бер мәҗүси шаман сыман,
Көй чакыра ырымлап.

Көй чакыра...
Әле кем дә
Көйләмәгән үзгә көй...
Күзе буйлап ялгыз болан
Чабып узды гүяки...

## Ялгызлык исемле кыз

Эзләмәгез мине бүген,
Мин юк бүген дөньягызда.
Күңелнең сыңар ачкычы
Ялгызлык исемле кызда.

Ул кыз мине тоткын итте,
Сарылды да иңнәремә.
Тәмәкемнең күк төтене
Кочып алды билләреннән.

Ул кыз мине тоткын итте,
Таратты да толымнарын,
Пышылдады... Ишеттем мин
Күзләр күзгә орынганын.

Тезләр тезгә орынганын
Ишеттем мин, ишеттем мин.
Сыңар ачкычын күңелнең
Сорарга, аһ, кичектем мин,
Кичектем мин.

Ялгызлык атлы кыз белән
Калырмын күк мин мәңгегә.
Ул кыз миңа шундый якын —
Сеңә барам пакь тәненә.

Ул кыз миңа шундый якын —
Гүя хатын — мин ялгызга.
Эзләмәгез мине бүген —
Мин юк бүген дөньягызда.

## Элегия

Сөмсере коелган күкнең,
Көннең кәефсез чагы.
Козгыннар каркылдый.
Кемгә
Ясин чыгалар тагы?

Кара шәлен бөркәнгән көн,
Кулында — төн гөлләре...
Дулкыннар көлә шаркылдап —
Йоткан диңгез кемнәрне?

Пәрәнҗәле көн сулкылдый —
Сынган кемнең канаты?..

Чү, офыкта Тәңре кызы
Толымнарын таратты.

Һәм чишенде... Оялчан гына
Кереп китте диңгезгә.
Йөзеп китте... Офык-ярда
Чәчелеп калды эзләр.

Чәчелеп калган эзләргә
Көн сипте төн гөлләрен.
Офыкта Тәңре кызының
Ишетелде көлгәне...

## Эпитафия

Фәрештәнең канат җиле
Тыныңа капмы мәллә?..
Үлемсезлек каян килсен,
Фани булмаса бәндә...

# Чәчмә әсәрләр



## Фәнзаман Баттал

# САТИРИК ХИКӘЯЛӘР

### Пони хикмәте

Күршең сыер сауганда кәҗә савып яшәүләре хурлык...

Күршең "Мерседес"та сәйран кылган чакта "Запорожец" асларында шөреп борып ятулары мәсхәрә...

Күршең фәрештәдәй сылу белән гөрләшеп көн иткәндә, шайтан кебек ямьсез, эт кебек талашчы хатынга тап булып, ырлашып гомер үткәрүләре бик авыр...

Күршенең тавыгы да күркә булып күренә, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер инде. Ярый ла ул күренеп кенә калса! Әгәр дә чынлап торып шулай булса?!

Әле менә бакчамда җиләк җыеп йөрим. Валлаһи, дип әйтәм, "виктория" дигәнче "юк, тәре!" дисәң, дөресрәк булыр. Күпме генә казымадым, ничекләр генә йомшартмадым, нинди генә тиресләр белән ашламадым мин бу туфракны! Җиләге — тфү! — чәнчә бармак башы хәтле дә юк ичмасам... Бөрешкән, корыган, кипкән. Ә мин аңа күпме су сипкән!..

Әнә, ызан аша гына Гыйльметдин дә җыеп ята. Ун җиләк салса, чиләге тула, ачуым да бер килмәгәе! Җиләк өзгән саен кешнәп куя, житмәсә: "И, Ходайның кодрәте!" имеш. Минем хатынның колагы ишетми, дип белә микәнни? Ул пошкырган саен Сафурам кура-куак арасыннан күз төшереп ала. Хәзергә аны-моны шыншымый, иллә дә мәгәр төн буе сафура бураннары уйнаячак өйгә кайткач. Үстергәнең дә, кистергәнең дә вак шул инде синең, диячәк.

Хәер, бер без генә түгел Гыйльметдин бакчасына күз атканнар. Уңнан да, сулдан да, арттан да, алдан да күзәтеп торалар. Чөнки аларның да җиләкләре ташкүлчим... Кырык күз карап торганны, кырык колак тырпайганны сизеп тора бугай, чукынчык, чиләккә җиләк төшкән саен Айсылуы иренең аркасыннан сөя.

— Гыйльми, ярый әле теге ашламаны таба белдең! Үзе бер хәзинә икән бит ул! — дип пышылдаган була.

Ә минем хатын, тегеләрнең чиләге тулган саен, кәҗә тоягын арт чүмечемә тери...

Караңгы төшкәч, якын тирәдәге ирләрнең инеш буена төшеп ял итә торган гадәте бар. Бил турайткан булабыз инде, үзебезчә. Бүген дә төштек. Көттеребрәк булса да, Гыйльметдин дә килеп житте. Учактан төшкән ут

яктысында да күренеп тора — карашы чеби көтүен күзәткән күркәнеке сыман.

— Җиләк ташып арыганлыгы күренеп тора егетләрнен! — дип, өстән генә мыскыллы елмая.

Сизеп торам, мондагы һәр "мыеклы бәрәнге"нең уе да, әйтер сүзе дә бер генә бүген: ни өчен безнеке болай да, синеке тегеләй, димәкчеләр. Җиләк турында, билгеле...

Битенә караганда борыны кинрәк Гарифҗан башлады бу "ни өчен?" дигән сүзне. Гыйльметдин исә, авызын ачкан, тел очын өске иренενә терәгән килеш, хәйләкәр генә елмаеп тора. Ә Гарифҗан барыбызның да телен кытыклап торган сорауны янадан кабатлый:

— Нишләп ул синдә зур үскән дә, бездә вак булып калган?

Гарифҗанның Мичурин бәрәнгеседәй танавына туп-туры карап торгач, Гыйльметдин кинрәк елмая:

— Нишлисең бит, егетләр, берәүдә бер нәрсә, икенчедә икенче нәрсә зур булып үсә инде ул. Кешедән кеше ким түгел дә, дөнья көтүләре дә тиң түгел бит... Ходай биргәне белән яшисең инде.

— Ходайның күпме биргәнен күреп торабыз анысы, — дип сүз кыстыра гөбе тавышлы, нечкә муенлы Әхмәдиша. — Нинди дер ашлама тапкансын дип ишетәбез, хак булса. Барыбер нинди дә булса хикмәте бар синең җиләкнең...

— Барын бар ул, егетләр, — дип куя эре җиләкләр хуҗасы, чишелеп китәргә әзерләнгән кебегрәк. — Иллә дә мәгәр бер югынны бар итәм дип йөргәндә, бер барынны да юк итә белергә кирәк. Карап-карап торам да, сез барыгыз да бушка гына табып өйрәнгәнсез. Менә бу юлы да зур сер аласыгыз килә, ә алдыгызда коньяк түгел, ак та юк.

Чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыга, дигәндәй, шәһәрдән ерак шушы су буеннан да барысы да табыла икән —кемдер аракы юнәтте, кемдер — сыра, кемдер коньяк та чыгарып утыртты! Әйтеп кара син дөньяны авыр, дип...

Сүзнең буасын гына җибәрергә кирәк. Аннан соң агуын да ага, юлын да таба. Гыйльметдиннең дә телен чишеп җибәрде теге нәмәстәкәйләр. Бердәнбер түмгәккә менеп кунаклады да, сүз башлап җибәрде. Хәер, аңа кадәр рәхәтләнеп көлде әле...

— Сез бит, күршеләр, җилкә белән эшләргә күнеккән кешеләр. Ә баш ни өчен кирәк? Сез, мәсәлән, тиресне ат белән дә, машина белән дә ташып торасыз. Җә, әйтегез, узган ел ашлама ташыдыммы мин бакчага?

Уйлап-уйлап карыйбыз да, искә төшерә алмыйбыз. Шуңа күрә барыбыз да бертавыштан диярлек:

— Юк! — дидек.

— Ә быел?

— Юк!!

— Менә ялгыштыгыз да... — диде Гыйльметдин, барыбызның да күзенә серле карап. — Ә мин атна саен китереп тордым тиресне. Әмма берегезгә дә күрсәтмәдем.

— Төнлә ташыгансыңдыр, алайса, — дип кыстырды тынкыш Хәмәй.

— Көпә-көндез барыгызның күз алдында ташыдым!

— Күрмәдек...

— Күрергә дә тиеш түгел идегез. — Гыйльметдин кесәсенә суккалап куйды. — Ни өчен дигәндә, менә шушында салып ташыдым мин аны! Менә шушы кесәгә! Хәзер дә бар минем кесәдә ашлама, бик беләсегез килсә!

— Кит инде, әкият сатма, — диде борынын кушучына салган Гарифҗан. — Әле тиресне КамАЗ белән ташып та үсмәде безнең җиләк. Кесәдә нинди юләр ашлама йөртсен ди!

— Мин юләр йөрттем. — Гыйльметдин кесәсенә тыгылды да, зуррак куян күчтәнәчен каезлап чыгаргандай маташкач, чәчкәле полиэтилен янчык тартып алып, өскә күтәрде. — Менә ул минем ашлама. Аның бер гөрәнкәсе...

түгел-түгел!.. бер мыскалы да сезнең бер йөк тиресегезгә тора.

Ул, бик кадерле байлыгын барлагандай, янчыкны сыйпап куйды һәм, тиз генә ачып, борынын тыкты.

— Исе үк бүтән шул, рәхмәт төшкере! Килосына бер бәрәнлек акчамны кызганмасам-кызганмадым, барыбер үземнекенә ирештем. Беләсезме, бер сутыйдан илле чиләк җиләк җыйганымны? Бу ашламаны уны белән аклады минем җиләк!

Барыбыз да янчыкка үрелдек. Беренче булып Елгыр Сафа эләктерде. Кат-кат иснәп карагач, күзен янчык эченә берничә мәртәбә тыгып алгач, бүтәннәргә сузды. Барыбызның да кулыннан үткән янчыкны Гыйльметдингә сузганда, чырае чытылган чуаш Вәчке мыгырданып куйды:

— Пу ни инде пу?..

— Менә! — дип кинәт кенә кистерде Гыйльметдин. — Нәрсә икәнен үзең дә әйтеп бирә яздың. "Пу ни" түгел, пони бу, Вәчке туган. Инде дә әйтеп бетерергә дисәгез, пони дигән бәләкәй атның тизәге. Менә шул үстерә инде бөтен нәрсәне!

— Бөтен әйберне дә үстергәч, нигә соң ул понинын үзен үстерә алмый?

Һәр сүзне кирегә сукаларга яратучы Сафаның сүзенә дә җавабы әзер иде Гыйльметдиннен:

— Бөтен хикмәт тә шунда шул инде, братлар! Бу ат бөтен энергиясен табигатькә бүләк итүче, кем әйтмешли, үз авызыннан өзеп бирүче изге зат икән. Бөтен энергиясе, шифалы матдәләр шушы тизәк белән чыга икән аның! Әнә, япуннар ни өчен баеп беткән дип беләсез? Нәкъ менә понилярны күп үрчеткән өчен! Ә безнең Казанда андый атлар бер дистәдән дә артмый бугай...

— Үзең каян алдың? — диештек.

— Менә монысын сорамагыз инде, егетләр! — дип кырт кисте янчык иясе. — Үз өлешемә кертмим, бигайбә!

Сөенечтән чүт кенә:

— Мин беләм!!! — дип кычкырып җибәрмәдем. Ярый әле ачылган авызымны учым белән ябарга өлгереп калдым. Чыннан да, белә идем мин пони атларының кайдалыгын! Мин тора торган йорт артында гына бер парк бар. Шунда Шәфкать исемле тешсез бер абзый әлеге кәрлә атларга бала-чага атландырып йөри. Менә кайдан алачакмын мин бу хәзинәне!

Шунда ук игътибар иттем: бүтән күршеләр дә, ни өчендер, ачылган авызларын җәһәт кенә томалап, каплап өлгерделәр.

... Икенче көнне үк теге Шәфкать янына йөгердем.

— Карале, абзый кеше, — димен, — сезнең бу бәләкәчләр дә ал яктан капкан ризыкларын арттан чыгарып, дөнья пычраталардыр инде... Ни дисән дә, болар да ат кебек нәрсәләр бит...

- Атлар гына түгел, алтын затлар болар, энем! — диде агай, сыртларына нечкә муенлы, зур күзле, олы авызлы малай-шалайларны, сыбызгыдай череллдек кызчыкларны утыртып теркелдәүче җанияләренә зур соклану белән карап торгач. — Әнә, йөз адымны әйләнеп килделәрме, бер бөтен ипилек акча бар дигән сүз. Монысы әле пүчт-ә-әк. Иң зур акчаны нәкъ менә шул арттан коелган нигъмәтләре китерә дә инде!

Агайның балкып торган йөзе кинәт кенә сүрелеп китте, ә үзе кәефсез генә кул селтәде:

— Тик, энем, безгә тәтеми аларның ул нигъмәтләре... Безнең нәчәлстуа бик комсыз. Грамын-грамга барлап торалар. Күзәтүчеләре дә йөреп тора сыман. Үткән атнада бер дуска җамыягы тулыр-тулмас кына биргән идем, сыразы якадан эләктерделәр. Чүт кенә кумадылар эштән!..

— Төнлә дә саклыйлармы?

— Һу-у!.. Банк саклаган кебек! Бер килосы бер тонна ашламаны алыштыра, диләрме сон... Бөтен дөнья шуңа калган кебек кыланалар, парин.

Ничек кенә булмасын, абзыйны барыбер юмаладым. Кич белән,

эштән кайтышлый, караңгы урамда очрашкач, сумкасыннан бер кило хәлвә хәтлерәк "алтын" чыгарып тоттырды. Үзе як-ягына карый, үзе ялвара:

— Зинһар, бүтәннәргә әйтә күрмә! Үзеңне — байлыктан, мине эштән мәхрүм итәчәксең... Янымда кешеләр булса, алдан ук әйтеп куям, якын килмә! Сирәк-мирәк кенә булса да, синең өчен юнәткәләп торырмын...

Тегенең кесәсенә ике күлмәклек акчамны тыгып, шыпырт кына өемә тайдым. ике-өч көннән соң кабат барсам, понилар йоклый торган ташпулат янында, күзләрен чет-чет йомгалап, бәлеш авызын мыймылдатып, Вәчке чукынмыш утыра! Кулына татарча гәҗит тоткан әле, житмәсә! Әйтерсең лә, укый белә. Ял итеп утыра, имеш...

Ярый әле күрмәде. Куак артыннан карамый чыккан булсам, каршына барып басачак идем. Конспирацияне саклый белдем: тын да тартмый чигендем дә, агачлар арасына кереп сыздым. Ә инде Шәфкать абзый белән төнлә очраштык. Кисәтеп тә куйды:

— Кемнәргәдер әйтеп өлгергәнсең дигән шигем дә бар, энем. Ике кеше килеп, теңкәмә тиделәр... Еландай телләрен чыгарып ялваралар, валлаһи!

— Тын да чыгармадым, абзый җаным!.. Бирдеңме соң?

— Аларгамы?! Юк-бар сөйләп торма инде, энем. Кешеләре кеше төсле булса ярар иде... Берсе тынкыш, берсе пупылдап сөйләшә... Синнән башка кешегә исен дә иснәтәсем юк. Тизәк дигәч тә, теге-ни... Хәзинә бит ул!

Тагын бер атнадан әлеге парк таныш кешеләр белән тулды: Гарифҗан да, Әхмәдиша белән Сафа да шунда бөтерелә, бакча күршеләренең бүтәннәре дә күзгә чалынып үткәли. Бер-беребезне күрмәгәнгә салышып узабыз, алай-болай маңгайга-маңгай килеп бәрелешсәк, исәнләшкән, елмаешкан булабыз:

— Һо-һо-һо!.. Ял итеп йөрешме? Әйе-әйе, саф һава файдалы инде ул, — диешеп үтәбез. Ә инде күзләребез теге ташпулатны күзәтә.

Паркта бердәнбер кеше — Гыйльметдин генә күренми. Ул хәзер, теге җиләкләрен сатып, нарат мунча сала, дача йортына икенче катны күтәрә, артезиан коесы бораулый, бакчасын тимер рәшәткә белән әйләндерә, базын мәрмәр белән эчли, урта бер җиргә бронза һәйкәл утырта. Анысы тирә-якка су бөркеп торачак фонтанның бер төре икән. Үзе генә эшләми инде, билгеле — җиде-сигез ир-ат бер алдына, бер артына төшеп торалар. Киңәшәләр, сораулар яудыралар:

— Фонтанны алтынга маныйкмы, көмешкәме?

— Мунчага бер кран гына кертсәк, су җитәрлек килер микән?

— Ләүкәсен нытып беркетәбезме, кирәк чакта гына күтәрелә торган итәбезме?

— Йорт түбәсен әбәзәтелне ялтыр калай белән ябыйк, Гыйльметдин абый, балкып торсын.

Менә нишләтә бит ул мул уңыш — бөтен дөньяны ямьләргә җитә!

... Көннәр үтә тора, Казан урамнарында тыз-быз йөрүче ирләрнең күбесе гел бер темага керә:

— Пони атлары кайларда бар, белмисезме?

— Пони тизәген ничек чылатасыз, суны күпме кушасыз?

— Түтәлгә нәрсә белән сибәсез?

Бер сүз белән әйткәндә, бөтен башкаланың сөйләгәне һәм эзләгәне дә, тапканы һәм мактанганы да пони тизәге генә. Гыйльметдиннең генә гаме икенче тарафта: хәзер инде, акча өстәп, ике бүлмәле фатирын дүртлегә алыштырып йөргән чагы. Мыегын бетереп, киң елмаеп, зур кинәнү белән сөйләшергә дә вакыт таба:

— Пони тизәге тәки тормышымны матурлады бит, егетләр! Күрдегезме инде теге җиләкләр китергән байлыкны? Акчасы күп чыкты шул, акчасы! Давай, гафил булып яшәмәгез, сез дә кадерен белегез пони гауна... әй, түгел... алтынының!

Тик менә, кара күзгә кергәч, ни күрик, Гыйльметдиннең дачасында

яна кеше йөри: киләп сала-сала, жир үлчи, туфракка яна үсентеләр тәрткәли, тәрәзә читләренә нәкышле такталар кага... Гажәпләнеп торгач, янына килдем. Дачаның яна хужасы икән. Гыйльметдин саткан... Ә үзе Казаннын икенче башыннан жир алган... Саубуллашырга да вакыт тапмаган...

— Сезнең дә җиләк әйбәт уңар инде, — мин әйтәм, — Гыйльметдин серен ачып киткәндер...

Яна хужа кеткелдәп куйды:

— Пони тизәге турындамы? Әкият ул. Салып утырганда сөйләп ташлады ул аны... Шаярткан гына ул. Башта пони караучы бөтен мужиклар белән сөйләшеп-килешеп чыккан, аннан соң инде шул әкиятне тараткан. Ә инде уңыш мәсьәләсенә килсәк, хикмәте бик гади — Минзәлә галимнәре чыгарган өр-яңа сорт алып кайткан булган ул.

Чираттагы кадагына соңгы мәртәбә суккач, үзалдына әйтеп куйды:

— Бер нәрсә дә гаеп түгел хәзерге заманда. Бизнес бит, бизнес...

... Әгәр дә киләсе елда йә ишәк, йә куян кәкәенең гаҗәеп уңышка китерүе турында ишетсәм, бер дә гажәпләнәчәк түгелмен. Әле менә уйлаштырып йөрим: аш серкәсенә черегән кавын кушсаң, пеләш башка чәч үстерә торган дару ясап булмый микән? Буладыр! Ни өчен дигәндә, бер туганым серкә заводының хужасы, ә апамның егерме КамАЗлык кавыны чередә. Бәясе күтәрелгәч сатмакчы иде...

## Бигайбә

*БЕР ЖЫРЧЫ АВЫЗЫННАН*

Китап кибетенә кереп бара идем, күптәнге танышымны очраттым. "Һай, очрашмаганга күпме еллар, күпме гомерләр үтте!" диешкәләп калгач, хәл белешүләр китте.

— Дуслар белән очрашырга да вакыт тими хәзер, әфәндем, эштә кайнарга туры килә, — ди бу, кулындагы күн папкасын әле бер, әле икенче кулына күчерә-күчерә. — Мин бит хәзер илчелектә, урысчарак әйтсәк, посольствода тылмач булып эшлим. Бүтән башкалада яшәгәч, кайтып йөрүләрем дә сирәкләнде...

— Әйе, — мин әйтәм, — заманалар үзгәрде, Рәсәйне чит ил товарлары белән бергә инглиз, япун теле басты... Кайлардан гына килмиләр дә, нинди генә телләрдә сөйләшмиләр хәзер. Тәржемә итеп кенә өлгер!.. Димәк, Мәскәүгә үк барып урнашкансың.

— Юк, Мәскәүдә түгел мин, Уфада. Соңгы елларда яңа тел өйрәндем. Әле менә бу кибеткә кереп баруымның да сәбәбе шул иде... Сүзлек эзләп йөрим. Ни дисәң дә, тәржемә иткәндә бу телнең дә, теге телнең дә аңлаешлы, төгәл булуы кирәк бит. Урыс яки инглиз теле генә түгел ул, брат!

— Әллә кытайчага ук барып җиттеңме?

— Аннан да хәтәррәк! Татарчадан — башкортчага, башкортчадан татарчага тәрҗемә итәм мин. Әйтик, Башкортстанга татар эшмәкәрләре, язучылар, менә синең кебек артистлар еш килә. Алар башкорт милләтендәге коллегалары, кәсептәшләре белән аралашырга, аңлашырга тиешләр. Һәркем дә чит телне белми бит... Менә мин шуларны кавыштырам, берсенең сүзен икенчесенә тәрҗемә итеп торам.

Аптырадым да калдым бит моның сөйләвенә! Шаяртадыр, дияр идең, йөзе бик җитди күренә. Җитдилеген расларга теләгәндәй, каты кәгазьдәй күлмәк якасына тагылган бронзадай галстугын да бик эре генә сыйпаштырып алгалый.

— Туктале, тукта! — дию емне үзем дә сизми калдым. — Башкорт якларында күп йөргәнем бар минем. Бер генә дә тәрҗемәче кирәк булганы юк. Мин үземчә сөйлим, тегеләр үзләренчә җиффәрә. Мин дә аңлыйм,

алар да һәр сүземне әләктереп ала... Кычытмаган җирне кашу була түгелме соң бу яңа һөнәрең?

— Чү-чү! — дип, бармак янады танышым, мәгънәле дә, сагайткыч та карашын йөземә текәп. — Алай сөйләшергә ярамый! Хәзер бит Татарстан да, Башкортстан да суверен дәүләтләр. Димәк, һәр милләтнең үзенчәлекле теле дә бар. Әгәр дә без хәзер: "Татар теле дә, башкорт теле дә шул ук бер тел инде", дисәк, бер-беребезнең суверенлыгын да, телен дә танымыйбыз дигән сүз була. Ике милләтнең үпкәләшүенә китерүе ихтимал мондый сүзеңнең!

Дустымның рәнҗүеннән, үзәккә үтәрлек итеп кисәтүеннән каушап та калдым сыман. Тишәрдәй кырыс карашы да сихерләде бугай, тотлыга башладым.

— Сон... соң... — дип торганнан соң, күнелемдәге ихлас фикеремне әйтеп бирергә көч таптым. — Таныйм, бик таныйм! Суверенлыкларын да, телләрендәге аермалыкны да таныйм. Ләкин... ни бит...

— "Ләкин"е кирәкми! Таныйсың — шул җиткән! — Аннары тылмач танышым, ягъни Сафур әфәнде, тавышын күңелне эретердәй йомшартып, сүзен дәвам итте. — Давай, Уфага килеп чык әле син. Мин бит анда радио, телевидение белән дә хезмәттәшлек итәм... Килсәң, мин сине экранга чыгартам, үзең кебек үк танылган башкорт җырчысы белән әңгәмәгезне оештырам. Син сөйләрсең, син сөйләгәнне башкорт җырчысына тәрҗемә итеп торырмын. Теге сөйләгәнне — сиңа... Ләкин бер шарты, каттый шарты бар: тегенең сүзләрен аңласаң да, аңламаганга салышырга тиеш буласың! Теге дә шулай итәчәк! Менә шундый әңгәмә үткәрсәк, ике милләтнең татулыгын көчәйтәчәкбез, аерым телләребез барлыгын исбат итәчәкбез. Анда җырсыз да булмас, билгеле. Бер-ике җырыңны да әзерләп куй. Юл чыгымнарыңны илчелектән түләрбез.

— Күптән шулай диләр аны! — дип кычкырасым килсә дә, тыелып калдым. Кайсыдыр илдә яки төбәктә телевизор булып телевизордан чыгыш ясау өчен артистлардан кем генә атлыгып тормый бу дөньяда!

— Риза булсаң, үзем белән үк алып китәм сине, — диде тылмач. — Юлга җыен.

* * *

Менә, ниһаять, студиядә утырабыз. Уртада — Сафур, ә без, ягъни башкорт җырчысы белән мин фәкыйрегез, аның ике ягына кунаклаганбыз. Үзебезгә төбәлгән прожекторларга, камераларга текәлмәскә тырышып, тамашачыларны үзебез белән таныштырабыз да әңгәмәне башлап җибәрәбез. Беренче минутта ук сизелде инде — башкорт җырчысына да инструкция каты бирелгән. Шуңа күрә ул мондыйрак сорау бирә:

— Ни тиклем ауыр булһа ла, дөрөһөн белгән якшы, тигән бедден бабайлар, Касыйм туган, Татарстанда ла аксалата түләү яктары йук дәрәҗәдә булһа кәрәк. Әлбиттә, ситендер, ауырдыр ошондай осорда гастрольдәрдә йөрүе. Кайһыбер ауылдарда бесән менән түләйдәр бедден әртистәргә...

Һәр сүзен аңлап утырам бит инде, ходавәндә! Шундук җавап бирмәкче, сүзгә кушылмакчы булам. Әмма Сафурның сизелер-сизелмәс кенә кисәтүле карашын күреп, телемне тешлим. Шуны сизгән тылмач, күзләремә ягымлы карап, саф татарча сорый. Дөресрәге, әңгәмәдәшемнең соравын кабатлый:

— Гайяр әфәнде болай ди: "Никадәр авыр булса да, дөресен белгән яхшы, дигән безнең бабайлар, Касыйм туган, Татарстанда да акчалата түләү яклары юк дәрәҗәдә булса кирәк. Әлбәттә, читендер, авырдыр шундый гастрольләрдә йөрү. Кайбер авылларда печән белән түлиләр безнең артистларга..." Сез аңа нәрсә диярсез?

Мин Гайяр коллегамның сүзләрен менә хәзер генә аңлагандай елмаеп куям:

— Әһә-һә-һә! Тәрҗемә иткәч, аңладым. Гайяр әфәндегә дә минем

сүзләремне житкерегез: ул бик дөрес әйтә. Әле сездә, Гайяр әфәнде, әйбәтрәк, чистарак икән. Бездә еш кына тирес белән дә түлиләр. Дачалы жырчыларга ярый да ул, ә минә минем кебек бакчасызларга бик авыр...

Шулчак Гайяр елмаеп жибәрә, теле кычыткандай, иреннәре мимылдап куя. Ләкин, үзе утырган якка тиз генә борылган тәржемәченен сулышын тоеп, тешләрен кыса. Шулай итеп, Сафур инде минем кәлимәләремне аңа тәржемә итә:

— Касыйм әфәнде һедгә ошондай яуап бирә: "Әле һеддә, Гайяр әфәнде, һәйбәтрәк, систарак икән. Беддә йыш кына тирес менән түләйдәр", ти...

Бая ук рәхәтләнеп көләсе Гайяр минем сүзләрем "тәржемә ителеп беткәч" кенә көлеп жибәрә:

— Һай, кыдык икән. Гажәп, гажәп!.. Персидәтелләр унда ла һарандар икән. Акса йуклыктан сәстәр агара инде бында... Бәһлеүән тиклем гәүдәң менән ер йөдөндә йөрөгән булаһың, бөтәһе лә файдаһыдга кайтып кала. Гаделһедлек хөкем һөргән Рәсәйдә йәшәү ысынлап та кыйын.

Аның сүзе тынып торган арада, мәгълүм инде, Сафур жәһәт кенә мина карый:

— Гайяр туган әйтә, кызык икән, ди, перседателләр анда да саранннар икән, акча юклыктан чәчләр агара инде монда, ди, пәһлеван хәтле гәүдәң белән жир йөзендә йөргән буласың, бөтенесе дә файдасызга кайтып кала, ди...

Бер үк сүзләрнең ике мәртәбә кабатлануы саруны кайнатса да, түзми жаең юк. Ни өчен, дигәндә, һаман да шул бер үк максатны — ике милләтнең дә үзенчәлекле, һәркайсының аерым дәүләт төзеп яшәргә хаклы икәнен, телләренең дә бер-беренә охшамаганлыгын күрсәтергә, жөпләргә кирәк!

Шуннан соң, тәржемәче аркылы, башкорт жырчысына мин сорау бирәм:

— Әйтегез әле, Гайяр туган, соңгы вакытта нинди жыр өйрәнәсез? Репитицияләр ясыйсызмы? — димен.

Сафурның шул сүзләрне тәржемә итүе, дөресрәге, кабатлавы була, Гайяр, хәзер генә аңлап алгандай, жанланып китә:

— Әлбиттә, әлбиттә! Репитицияһыд булмай. Һуңгы көннәрдә минең теләк үдебеддең милләткә халык ижатын йакынайту. Әйтәйек, башкорт халкының "Өй артында муелым" тигән жыры бар. Ул тәрән мәхәббәт менән һугарылган. Йәш сакта йаратып башкара инем уны. Бынау һүддәре бик окшай минә: "Өй артында муелым бар, йаннарында сияләр шул, йаннарында сияләр. Сияләр дә бедгә карап: — һед бәхетле! — тияләр."

— Ә-ә! Без дә жырлыйбыз аны! Әллә парлап жырлыйкмы соң? — дип ычкындыруым булды, Сафур кырт кисте:

— Юк, Касыйм туган, сез жырлый алмыйсыз аны. Чөнки сүзләре чит телдә — башкорт телендә. Әле яңа гына сөйләшкәнебезчә, башкорт теле үтә дә катлаулы тел ул татарлар өчен. Көйләренә дә теш үтми...

Шулчак, кабат акылыма килеп, Сафурның сүзләрен хупларга ашыктым:

— Әйе, ялгышрак әйтеп ташладым ул тәкъдимне...

Ни башкортча, ни татарча уртак жыр "таба алмагач", парлап торып "Подмосковные вечера"ны жырладык...

... Тапшыру беткәч, коридорга чыккач, Сафур икебезнең дә кулларны кысты:

— Молодцы, егетләр, булдырдыгыз! Шулкадәр әйбәт, шулхәтле ышандырырлык булды бу тапшыру, хәтта, минемчә, берәр жирдә юып алсак та гөнаһ булмас.

Мин, студиядәге гадәт буенча, Сафурның кабыргасына тиеп алдым:

— Тәкъдимеңне Гайяргә дә үз телендә әйт инде. Аңламый тормасын...

Шулчак, дөньяны шартлатырдай итеп, икесе дә көлеп жибәрде.

— Гайярме?! Гайяр ул, аңлау мәсьәләсенә килгәндә, теләсә кайсы татарыңны сата! — диде Сафур.

Гайяр исә, бер кулы белән көлә-көлә каткан эчен тотып, икенчесен жилкәмә куеп, Сафурның сүзенә пичәт сукты:

— Татар кыддары менән һөйөшөп, татар йегеттәре менән гөрләшеп гумер иткән әдәм бит мин, Касыйм кустым! Мин татарда үдем аңнамаган бер һүдде лә белмәем... Хәдер инде йән теләгәнсә һөйләшәек.

Ниләр генә сөйләшмәдек ул кичтә Гайяр белән күзне-күзгә карап: кызлар турында да, артистлар, язучылар турында да, хәтта гарип Россинең хәерчелеге турында да... Ә инде Сафурга килсәк, минем белән башкортча, Гайяр белән татарча сиптерә. Беребез дә рәнжеми, өчебез дә бертуганнардай аңлашабыз, рәхәтләнеп гөрләшәбез. Хәер, әйтергә онытып торам икән, ул кичтә бөтен ресторан кул чапты безгә: "Сакмар"ны да, "Җиләгән чишмә" белән "Раушания"не дә күңел булганчы парлап җырладык... Ул — башкортча, мин — үз телемдә! Берберенә ятып кына тора безнең телләр. Әйтерсең лә икебез дә бер ана балалары. Әллә икебез дә татар, әллә икебез дә башкорт — белмәссең.

— Һокланам мин татар теленең матурлыгына! — диде соңыннан Гайяр.

— Ә мин башкорт теленә гашыйк! — дидем ихлас күңелемнән.

... Тик менә...

Ярый, авыр булса да, анысын да сөйләп үтим инде...

Ресторанннан чыгып, Салават һәйкәленә таба барганда бер күңелсез хәл булды. Каршыбызга килүче дүрт-биш егетнең берсе, кинәт кенә туктады да:

— Карагыз әле, егетләр, болар бит печән белән бесәнне дә аера белми торган ахмаклар! Әллә аңлатып үтәбезме?

— Һалып ебәр берне, киләсәктә аңларлык булһын!

Озакка сузмадылар, өчебезнең дә якадан элеп алдылар.

— Йәле, агаем, әйтеп һал, нәмә ул "сия"? — дип күзләремә тутырып карады минем галстуктан эләктергәне. Калтыраудан авызым кипсә дә, җавап бирерлек әмәл таптым:

— "Чия" була энекәш, "чия"!.. Аны гына беләбез инде...

Ә янымда гына Гайярне җилтерәтә бер егет:

— Әйт әле, абзый кеше, нәрсә ул "акча"?

— Һун, кустым, һорап та тораһы түгел... "акса" була бит инде, "акса"! Кем белмәй ти уны... — дип аклана Гайяр.

Бер сүз белән әйткәндә, өчебезнең дә котны алды бу егетләр. Әле ярый рәхимле булып чыктылар кыйнамадылар. Татарлары — татарча, башкортлары башкортча тукыдылар колакка:

— Эс бошорып, тел сарлап йөремәгед моннан һуң, һаташып, тигәндәй!

— Ике милләт арасына таяк тыгуыгызны ташламасагыз, абзыкайлар, ут чыгаруыгыз ихтимал. Сак булыгыз!

— Менә без, яшьләр, бер-беребезнең телен генә түгел, сулышын да аңлыйбыз. Бернинди тылмач та кирәкми!

Ниһаять, арадан берсе юатырдай тавыш белән соңгы сүзне әйтте:

— Йарай, иламагыд, агайдар... Һакалыгыд агаргас булһа ла акыл йыйыгыд... Ә һед, егеттәр, ебәрегед уларды, еткәндер...

... Менә шулай бетте бу әңгәмәнең ахыры. Шуны гына өстисем калды, әгәр дә кайбер башкорт сүзләрен төгәл үк әйтмәгән булсам, ачуланмагыз. Ни генә дисәң дә, башкорт теле татар теле түгел, башкортларның үз теле! Бигайбә!

## "Мәет" белән очрашу

Мин аны инде күптән үлгәндер, исәннәр арасында юктыр, дип уйлаган идем. Хәтта: кабере кайда икән, өстендә нинди агач яки куаклар үсә микән, шушындый җилле-давыллы караңгы төннәрдә алар ничек шаулый икән кебегрәк уйлар да җанны өшетеп куя иде. Хәер, күңелсез, ямьсез төннәрдә яшәү мәгънәсе, гомер кыскалыгы хакында "төпләргә төшеп" уйланучы бер мин генә түгелдер. Бигрәк тә япа-ялгыз чакларда...

Бүтән сабакташлар, аны белгән кордашлар белән очрашкан, моннан утыз елдан артык булган хатирәләрне искә алган чакларда аның турында “мәрхүм”, “мәрхүм Зәет” дигән сүзләр дә еш ычкынгалый иде. Чөнки ул чактагы хәлен, башыннан чыкмаган гамен, иртәдән кичкә кадәр кылган гамәлләрен күнелен белән иләп карасаң, ул, һичшиксез, үлгән булырга тиеш иде.

Аның сүзләрен, тормыш фәлсәфәсен искә төшерсәк, яшь аралаш булса да, дигәндәй, тыннар катканчы көләбез дә. Бигрәк тә Илдар хәтәр көлә. Мондый чакларда үзеннән дә көлгәнебезне белми Илдар. Гомер-гомергә шундый гадәте бар: кызык-мызык әңгәмәләр вакытында, түзеп-түзеп утыра да, башын кинәт кенә артка ташлап шаркылдый. Бу мизгелдә аның пеләшләнеп бетә язган акыл чүлмәге стенага таба ыргыган кувалданы хәтерләтә. Абайламыйча арт чүмечен берәр каты яки очлы әйбергә бәреп ярмаса яки тишмәсә ярар иде, дип тә куркып куясың. Әйткәләп, кисәткәләп торуның да файдасы юк — барыбер үзенчә!

Кайгырырлык та, көләрлек тә иде шул Зәетнең холык-гамәлләре. Күзенә карап мыскыл иткән чаклар да булгалады. Бигрәк тә бүлмәдәшебез Әскәр туры сүзле иде. Түзмәде бервакыт, Зәеткә ябырылды:

— Ташлыйсыңмы син күнелләргә шом салуыңны, әллә юкмы?! Соң, канса да консов, егерме яшебездән чирләшкә ясап бетерәсең бит инде безне. Валлаһи, дип әйтәм, Зәет түгел, тере мәет син!

Зәет һәрвакыттагыча тыныч калды. Өстәлгә тамган чәй тамчысын бармак очы белән сорау билгесенә охшатып сылый-сылый, боек кына әйтеп куйды:

— Соң... егетләр... мин белгәнне сез дә белсен дип сөйләвем инде...

Артык күп белә иде шул Зәет. Бергә-бергә базарга чыккан көннәрдә аның “белемен” ишетмәү өчен, колакларыбызны томалардай булабыз. Без, ягъни аннан башкалар, ризыкларга карап, болай сөйләшәбез:

— Әнә тегендә эчәк-бавыр пирәшкие саталар. Әх, акча булса!.. Берьюлы егермене ашар идем!

— Шикәр бетте... Алырга акча да юк...

— Туйганчы әчтерхан чикләвеге ашарга иде!

— Дүртебезгә икене булса да морожный алабызмы соң әллә? Кесәләрне кырыштырыйк әле.

Зәетнең уйлары бөтенләй икенче юлдан йөри. Сүзләре дә бүтән. Читтән карап, тыңлап торучының: “Бу өчесе — надан тыгынучылар, ә тегесе, миранусныкыдай вак бөдрә чәчлесе, акыл иясе икән”, дип нәтиҗә ясавы бик ихтимал. Без күргән ризыкларга үзе дә күз салганнан, сүзләребезгә игътибар иткәннән соң, Зәетнең салмак тавышы агыла башлый:

— Карап-карап торам да сезгә, егетләр, юри шаяртасыз, дип уйларга мәҗбүр булам. Рәже туйганчы ашарга ярый әчтерхан чикләвеген?! Аны бит врачлар көнгә биш-алтыны гына ашарга киңәш итәләр. Күбрәк ашасаң, бөергә дә, бавырга да сугуы бик мөмкин. Ә бавыр белән бөернең эшчәнлеге туп-туры йөрәктә чагыла. Теге ике орган аксадымы, йөрәкнең дә сикерә башлавын көт. Аны күп ашап ычкынучылар да шактый... Һичьюгы аллергия тудырачак! Дөрес, баш миенә файдалы нәрсә ул. Төшенең нәкъ менә мигә охшаганлыгын үзегез дә күреп торасыз. Кытай галимнәре дә күп язган ул чикләвек турында. Туп-тулы бер китап багышлаганнар аңа, симпозиум нәтиҗәләрендәге фикерләрне берләштереп...

— Эх, тарих факультетында укып, тарихны да медицина хәтле белсәң иде син, — ди-ди үртәлә Илдар. — Төннәрен безгә лекция укыр идең. Төп фәнебезне яхшырак белер идек, ичмасам!

Зәет исә Илдарның дәгъвасын сабыр гына әйләнеп үтә:

— Тарих ул — тарих инде, малай... Ә менә дөрес туклану, ашаганыңны дөрес үзләштерү бөтенләй икенче нәрсә. Ашказаның бозылгач, бавырың таркала башлагач кына үрсәләнә башласаң, соң була инде ул. Менә, мәсәлән, шушы челләдә, тән генә түгел, маңгайлар да тирләгән кызуда сез туңдырма ашамакчы буласыз. Ахырын да уйларга кирәк бит

аның. Әллә сез мондый вакытта салкын тими дип беләсезме? Узган җәй Түбән Камадан бер таныш директор килгән иде былтыр шушы вакыттарак. Кырыктан узды температурасы! Салкын әйбер дә ашамаган үзе. Кунган фатирында ачык тәрәзә янындарак йоклаган. Дифтерия йөргән вакыт иде какрас. Врачлар, дифтериядер дип уйлап, үзе яшәгән шәһәрнең санэпидстанциясенә шалтыратканнар. Үзенең генә түгел, бөтен туганнарының фатирларын дизенфикцияләп чыкканнар. Җәй буе диярлек бүлнистә ятты... Ә сез бозланган сөт йотмакчы!

Түзмәдем, төрттереп куйдым:

— Берәр зәгыйфь бәндәдер инде...

— Рәшит абыйны әйтәсеңме?! Булыр зәгыйфь! Ел саен, авылларына кайтып, сабантуй тота иде. Былтыр гына кайта алмады. Кирәк булса, дүртебезне бер тишеккә дөңгечләп тыга. Әле сакланып яшәсән дә, чамага туры килә ул. Бүлмәдә җиде банка тотуны үзем уйлап тапмадым мин, егетләр...

Чыннан да, Зәетнең караватт астында өчәр литрлы җиде пыяла банка тезелеп тора. Бүген, әйтик, җиде көн элек тутырылган банкадан эчә суны. Суы беткәч, кранны яңа су агызып, аны жиденче итеп куя. Иртәгә ул алтынчы банканы ачачак... Җиде көн торган суның хлоры, төрле зарарлы матдәләре юкка чыга яки төпкә утыра, имеш. Без ахмаклар исә суны краннан агызып эчәбез. Имтиханнан соң бәйрәм итеп тә алсак әле!.. Иртән авызларыбызны кранга тоташтырып куябыз: йотып та торасы юк — су үзе бәреп керә ашказанына!

Әйтеп торуның кирәге дә юктыр, аракыны түгел, квас та эчми Зәетебез. Аның да алкоголе бар икән. Күп эчә алмавыбыз аркасында гына исермибез икән квастан. Ашказаныбыз берьюлы бер мичкә квасны сыйдырса, ләх булганчы исерүебез дә бик ихтимал, янәсе.

Кичләрен Зәет иртәгәге көнгә әзерлек күрә: стакан хәтле берәр банканы сода белән ышкый-ышкый юа, аннары аны кайнар пар өстендә тота, үзенчә әйтсәк, иң хәйләкәр микроб та калмаслык дәрәҗәгә китерә — "дистиллировать итә". Кечке ашны ашамый. Поликлиникага алып барылачак сидекнең составы реальлеккә туры килмәскә мөмкин, дип аңлата без наданнарга. Икенче банкага салыначак "проба" турында да тәфсилләп сөйли. Ашказаны глисталар оясына әверелмәсен өчен, шундый "пробаларны" ике-өч көн саен анализлатырга кирәк икән.

Караватына ятар алдыннан, өстәл лампасына үтә якты лампочка бора да, сәгать буе шәрә тәнен тикшереп утыра: теге яки бу бетчәсе зурайммаганмы, төсен, рәвешен үзгәртмәгәнме, кан тамырларының берәрсендә тараю-киңәю галәмәте сизелмиме, җыерчык-мазар артмаганмы?.. Яткач исә берничә мәртәбә пульсын саный, градусникны әледән-әле селеккәләп, тән температурасын кат-кат үлчи. Иллә дә мәгәр пульсы — 72 дән, температурасы 36,6 дан кайтышрак булса, бетте — үзенә дә, безгә дә йокы юк: авыр сулый, ашыгыч ярдәм чакыртырга туры килмәгәе, дип сөйләнә, мәтрүшкә, сукыр кычыткан, андыз тамыры кебек нәрсәләр кайнатырга керешә, ниндидер таблеткалар йота, микстуралар эчә, кайсыдыр төшләренә массаж ясарга керешә, медицина брошюралары актара, грелкага су тутыра... Грелка дигәннән, Зәет һәр ризыкны, эчемлекне әлеге дә баягы 36,6 градуска житкереп "кабул итә" — суыграк булса, җылыта, кайнаррак булса, суыта. Кавын-карбыз чорында аннан көлеп эчебез ката. Ходай биргән тубалдай җимешләрне ничекләр генә кыландырмый ул! Башта зур кәстрүлдә су җылыта, аңа салынган карбыз яки кавынны тишеп, әледән-әле градусник тыга, аннан соң гына кисеп ашый башлый...

Бергә күпме яшәгәнбездер, аны иртәнге сәгатьтә күргәнебез, аның белән бергә университетка чыгып киткәнебез булмады сыман. Ул инде без торганчы ук, төрле-төрле анализлар ясату өчен, поликлиникага киткән була. Дәрескә дә шуннан килә. Беренче тәнәфестә үк каныннда, сидегендә нинди хикмәтләр барлыгын тәфсилләп сөйли:

— Бәвелдә тоз бер бөтен уннан биш процент кына булырга тиеш. Ә

минекендә бер бөтен уннан алтыга житә язган... Ә менә минераль матдәләр йөздән бер процентка кимеп куйган әле... Сульфат-фосфатлары да бик үк төгәл түгел, магний белән аммоний да норма белән тәңгәл килми... Димәк, бөерләремдә ниндидер гаеп бар...

Зәет кызлар белән йөрми. Без көлә башласак, әзер фәлсәфәсен чыгарып кына сала:

— Көлегез, әйдә, көлегез. Елавын соңрак еларсыз. Эш үткән булыр... Чөнки сезнең медицина буенча грамм да белемегез юк.

— Мәхәббәткә ни пычагыма кирәк ул синең медицинаң!?

_ Медицинаны белмәгән килеш кызлар белән чуалсаң, бик тиз шиңәр мәхәббәтең, — дип, Зәет кайнар бәхәскә кереп китә. — Ә сез беләсезме соң һәр кешедә нинди дә булса чир барлыгын. Үзен сәламәт хис итүче адәмнәр дә бөтенләй үк сәламәт булмый. Менә сез кызларны үбәсезме? Үбәсез! Ә һәр авызда нинди дә булса микроб яки вирус булмый калмый. Хәтта, күп галимнәрнең исбатлавына караганда, авыз ул аэай итә торган жирдән дә пычраграк. Бик чибәр кызлар да бу җәһәттән башкалары кебек... Егетләр дә шулай ук. Димәк, үбешкән саен бер-берегезгә нинди дә булса чир өстисез.

Моның ише чакларда Илдарның көлүенә чама юк. Күзгә күренмәс шүрәле кытыклый диярсең — караватына авып китә дә, калай түбәдән сырлы стакан тәгәрәгәндәге тавышлар чыгарып көлә.

— Үтерәсең, Зәет!.. Тынны тыгылдырып үтерәсең!.. Кайсы төштән дә пычраграк дисең әле? Һай... Һу-у-у...

Зәет, никадәр генә тыныч булырга тырышмасын, үзеннән көлгәндә нык үртәлә:

— Ә синең карт маржаңда кырык төрле микроб бардыр әле. Көчеңне генә түгел, каныңны да, тора-бара җаныңны да суырачак әле ул синең, бик беләсең килсә.

Яшерен-батырын түгел, Илдар чыннан да бер маржа янына йөри иде. Бигрәк тә ашарына акчасы калмаган чакларда еш бара ул аның янына. Ресторанда пешекче булып эшләүче бу хатын сумкасына бифштекслар, антрекот-эскалоплар, пирәшкиләр салмыйча кайтмый һәм таза тамаклы Илдарны һәрвакыт тук тотарга тырыша. “Хутлы машинаның заправкасы да шәп булырга тиеш”, ди-ди сыйлый икән егетне. Илдарның беренче курста укый башлаган Миләүшә белән йөрүен дә белә икән. Алай гына да түгел, парлап кунакка да чакыра, имеш. Ягъни, көнләшми.

— Ревновать не имею права. Ты мне — на сегодня, а ей на будущее, — дип әйтә ди. Бу очракта Зәет ялгышмый. Тик менә “карт маржа” диюе белән генә арттырып җибәрә. Чөнки әле Наташага утыз да юк. Хәер, үзебезгә егерме-егерме ике яшь чакта андый хатынны карт дип санавыбыз әлләни гаҗәп тә булмагандыр...

— Син бит хәтта интим гамәлләрнең дә хикмәтен аңламыйсың, — дип сүзен дәвам итә Зәет. — Сөйләвеңә караганда, ата-баба ысулы белән генә эш итәсең син ул маржаң белән... Көч-куәтеңне сарыф итеп кайтасың...

Илдарның “шүрәлесе” шушы сүзләрне генә көтеп торгандыр сыман — егетнең кытыклана-кытыклана көлүенә караганда, тыны да тыгыла башлады кебек.

— Соң... соң... кимеме кая барсын ул куәт?.. Ул гамәлне вагон бушатуга тиңлиләр бит! Кирпеч тә, калай да бушаттык бит инде — беләбез вагон бушату хикмәтен. Көч түктергән эш кенә ләззәт китерә бит...

Каршысында утырган ахмакны күзәткән философтай, Зәет Илдардан күзен алмый гаҗәпләнеп карап торды-торды да, тегесе суына төшкәч, һәрвакыттагыча тыныч кына сөйләвен белде:

— Тибетлылар бирә торган акылны белергә кирәк, дустым. Алар ләззәтен дә кичерә белә, энергияләрен дә саклый белә. Чөнки син түгә торган куәт белән бергә яралгы күзәнәкләре генә түгел, акыл потенциалының күзәнәкләре дә сарыф ителә.

Бу фәлсәфәдән соң башкаларыбыз да егылып киткәндәй була:

— Көч тә тукмагач, ул кытайлар бер гасыр эчендә нечекләр итеп кенә биш тапкыр арткannар соң?!

— Инде "анысын" да экономияләргә кирәкмени?

— Башы булган эшнең ахыры да булырга тиеш ләбаса...

— Җөмләдән соң ноктасын куймагач, мәгънәсе аңлашылмаячак бит...

... Төрле даруларны йота торгач, һәр әгъзасыннан чир эзли торгач, Зәетебез тартылып, агарып китте. Табиблардан атна саен флюорография үткәрүләрен, кардиограмма алуларын таләп итә башлаган. Тегеләре, аптырашта калган хәлдә, иңнәрен сикертеп, кулларын җәяләр икән. Зәетнең үҗәтлегеннән туйганнармы шунда, әллә чыннан да берәр чир тапканнармы —кайсыдыр профессорга күрсәткәннәр моны. тагын бер нәрсәне аңламый калдык: чынлапмы, шаяртыпмы, профессор Зәеткә:

— Дааа, егет, психикаң нык авышкан синең!.. Сине дәвалау өчен Казандагы медицинаның көче җитәрлек түгел инде. Мәскәүдә яшәүче Америка профессорына барырга туры килмәгәе сиңа. Ләкин ул дәвалау процессы өчен ким дигәндә егерме мең доллар сораячак. Кыргый капитализмда акчасыз бернәрсә дә эшләмиләр, энем, — дигән.

Ул төнне беребез дә көлмәде. Алай гына да түгел, үкенү хисе дә оялады күңелләргә: юкка рәнҗеткәнбез, тиккә бәхәсләшкәнбез, ахрысы... Ә Зәет, үзалдына дигәндәй, юк акчаны бармак бөгеп саный:

— Доллар белән безнең сум бәядә йөри дип уйласак, егерме мең сум кирәк. Бер сыер мең ярым чамасы тора... Ике тана минәр сумнан китсә, менә сиңа өч мең ярым бар дигән сүз. Җиде сарыкны сатсак...

Ул, менә-менә елап җибәрердәй булып, безнең белән киңәшләшә башлый:

— Алты почмаклы яңа нарат йортка күпме бирәләр икән, белмисезме?

Илдар белән Әскәр эрергә өлгергәннәрме, әллә дәшмиләрме — тавыштыннары юк. Шуңа күрә соравына каршы сорау бирәм:

— Әллә запас йортыгыз да бармы?

— Юк та... Әти-әнигә бердәнбер бала бит мин. Минем сәламәтлек хакына совхоз фатирына күчсәләр, йортны да сатып булыр. Бәлки әле кассада да акчалары бардыр. Алай да җитмәсә, авылдашлардан әҗәткә алырлар. Кардәш-ырулар да хәлгә керер, бәлкем...

Икенче көнне Зәет урыныннан хәлсез картлардай авыр кузгалды. Температурасын үлчәп, пульсын санагач, йөзен ике учына алып, авыр сулап утырды. Аның бу халәте күңелләребезгә траур булып урнашты.

— Ярый, егетләр, сау булып торыгыз. Мин юлга чыгармын бүген... Тәки, кырыкмаса-кырык чир белән җәфалана торгач, шушы көнгә төштем бит. Әле күпме сакланып яшәдем, югыйсә... Деканатка кереп әйтергә онытмагыз инде... Исән калсам, укырга туры килер бит әле... Хат язып торырмын...

Өзек-өзек сүзләреннән башларыбыз иелде: "Менә бит ул гомер дигәнең нишли! Бүген яшисең, иртәгә ни булырын белмисең".

Әскәр белән Илдар, хәсрәт баскан кешеләрдәй, университет юлына чыгып киттеләр, ә мин, бер-ике дәрес калдырганга гына укудан кумаслар әле, дип, Зәетне озатырга булдым. Автобусы кузгалып киткәндә күзләремә яшь тулды. Кызганыч, бик кызганыч иде аның кыяфәте. Кем белә, соңгы саубуллашудыр бу бәлки...

Атналар уза торды. Зәеттән хат-хәбәр килмәде. Җәйге каникуллардан соң да әледән-әле искә төшергәләп тордык:

— Чире чыннан да каты булгандыр, бүлнистә ятадыр.

— Язып торырмын, дигән иде бит. Ник язмый икән соң?

— Хәле юктыр...

— Әллә үлде дә микән?..

Күп айлар уза торгач, мондый сөйләшүләр сирәкләнде. Анда да күптән булган хәлне, күптән үлгән кешене искә алуга гына кайтып кала сүзебез: исән булса, йә язар, йә шалтыратыр, йә телеграмма сугар иде бит инде бу кадәр гомердә! Юкка чыкты Зәетебез... тарих дәрьясына чумгандай

булды. Әйткәнемчә, сагынып һәм юксынып та, эчләр катканчы көлеп тә искә алгаладык аны соңгы дистә елларда.

Нишләмәк кирәк, аксакаллы картлар, бөрешкән әбиләр генә китми шул фани дөньядан. Әнә, чәчәктәй кызлар, алмадай матур егетләрнең рәсемнәре күпме зиратларда!.. Төрлечә үлгәннәр: машинага машина бәрелеп тә, мин-минлек белән исергән ил башлыклары чыгарган сугышларда да, үзара сугышып та, чирләп тә, үз-үзләренә кул салып та... Зәетнең үлеменә дә артык гаҗәпләнеп булмый, димәк...

* * *

— Дайте дорогу!
— Юл бирегез!
— Юлда тормагыз!
— Товар килә!..

Һай, яратмыйм базарда йөргәндә әледән-әле яңгырап торган шундый сүзләрне, әмерләрне! Ниндидер товарга күз текәвең була, арбасын сөйрәп килгән хутка кемдер кычкыра:

— Юл бирегез!

Бу юлы арба, аяктан егардай итеп, ышкылып үтте. Ачу килде. Арба хуҗасының каршына чыгып:

— Син нәрсә?! Синең товарың өчен бөтен базар аяктан егылырга тиешмени?! — дип, якасыннан аласы килде.

Һәм шулай иттем дә. Каршына чыктым тегенең, әмма якасыннан алырга батырлык җитмәде: артык сәламәт, артык таза, сабакы. Сал бүрәнәсе кебек. Ләкин әйтер сүземне барыбер әйттем! Нәфрәтемне булса да тойсын, ичмасам,

Китеп бармакчы идем, теге бәндә, сыер түшкәсе салган арбасын бергә килүче әшнәсенә тапшырды да, иңбашыма кулын куйды:

— Туктале, тукта... Хәнәфи түгелме соң син?

Сүзендә янау-мазар сизелмәгәнлектән, мин дә тегенең йөзенә тынычрак карадым. Әйе, Зәетнең үзе иде бу! Миранусныкыдай кара чәчләре киезләнгән ак сарык йонын хәтерләтә хәзер, баш түбәсендә түгәрәк пеләше ачылган. Өстендәге киемен дә аңламассың: әллә халат, әллә плащ... Күз алмасы да элпәләнгән сыман бераз... Ләкин карашында ук ныклык, үз-үзенә ышанганлык сизелеп тора. "Төшереп" тә алган булырга охшый. Күнелдән шом да йөгереп үтте сыман. Ни дисәң дә, үлгәнгә санап йөрелгән кеше бит...

Ләкин Зәет шомланып торырга форсат бирмәде:

— Әйдәле, юл өстендә тормыйк, читкәрәк китик. Менә бит ул гомер дигәнең, кемнәрне генә югалтмыйсың да, кемнәрне генә тапмыйсың, — ди-ди, читкә тарта башлады. Аулаграк почмакка баскач, йөземә тагын текәлеп куйды:

— Берегез дә истән чыкмады, парин. Син дә, Илдар белән Әскәр дә... Әледән-әле уйлап яшәдем.

— Исенә дә төшмәгәнбездер. Хат та язмадың, — дип көллем үземчә. — Адрес бар иде, каләм тота белә идең.

— Башта оялып йөрдем, малай, кыенсындым. Соңрак үземне сездән түбән тою хисе дә керде күңелгә. Сез — гыйлем кешеләре, мин — колхозчы, көтүче... Көләрсез дип уйладым. Ә аннан соң инде еллар үтә торды...

— Туктале, тукта, — дидем тегеңә үзенчәрәк. — Америка профессорында озак дәваландыңмы соң? Баргансыңдыр бит?

Зәет кинәт кенә шартлап киткәндәй булды: мондый ук каһкаһәле, мондый ук ихлас, зәһәр көлүне шушы яшемә җитеп күрмәгән идем, ахры. Мин соңгы соравымны кабатлагач, тагын көләргә керешге. Күз яшьләрен сөртә-сөртә сулышын тигезли төшкәч кенә, өзек-өзек сүзләре чыга башлады:

— Америка... профессор... уфф... авылдан да чыгарга туры килмәде...

шунда таптылар дәвасын... әти тапты... шул өшкерде...

— Берәр тылсымын белгәндер инде?

Сорау биргәнемә тагын үкендем — Зәет янадан "шартлады".

— Һу-у, каты булды тылсымы, каты! Бер генә өшкерде!..

Бераздан тәмам тынычланды Зәет, хәтта күзләренә моңсулык инде. Тирән сулап куйгач, моңсу гына тавыш белән сөйләп бирде:

— Син озатып җибәрдең бит инде мине теге вакыт... Да-а-а, аңа да утыз ел үткән... Аякларымны көчкә сөйрәп, авылга, аннан өйгә кайтып кердем. Әти, ишек тоткасына бәйләп, чыбыркы ишә, әни өстәл әзерли. Исәнләштек, ашарга утырдык. Хәл-әхвәл белешә башладык. Мин шунда... бүгенгедәй хәтердә... елап-сыктап, үз хәлемне сөйләп бирдем. Әни көенә, әти исә, йөземә әледән-әле текәлеп карый-карый, ашын чөмерә. Сүз әйтми. Мин Америка профессорына барырга кирәклек турында сөйлим. Ашый. Эндәшми. Егерме мең доллар турында сүз кузгатам. Шуннан соң гына, кашыгын куйды да: "Тамагың туйдымы?", дип сорады. "Туйды", мәйтәм. "Туйгач, әйбәт. Әйдәле, улым, тышка чыгып, ирләрчә генә кинәш-табыш итеп алыйк әле, әниең өстәл җыештыра торыр", ди бу. Чыктык. Әти абзарга таба китте. Мин артыннан атладым. Шуннан соң, әллә каян гына бишкә үргән камчы тартып чыгарды да, сырт буйлатып тартты: "Мә, яптырмалахай, монысы Америка булыррр!.. Менә монысы профессоррр булыррр! Мә, доллаҗрр ссиңа!.. Китап корты була торгач, үзең дә кортлый башладыңмыни?! Мин монда тин өстенә тин өстәлсен, дип, көн-төн көтү көтәм, ә сиңа егерме мең доллар кирәк. Буржуйга әйләнеп беттеңмени?! Безнең нәселдә кортлылар да, чирлеләр дә юк. Саташып йөрмә моннан соң, йөрмә, йөрмә!.." Ул сыдыра тора, мин үрле-кырлы сикерә торам. Бөтен тәнне ут итте картлач. Шуннан соң, тәмәкесен кабызып, бүрәнәгә утырды, авыр сулый-сулый, тартып бетерде. Йомшарды бу, йомшарды... Шуннан соң, үз янына утыртып, кулын аркама куеп, сүзен әйтеп бетерде: "Көтүне икәүләп көтәрбез, улым. Тагын бер кеше эзли персидәтел... Миңа да таяныч кирәк. Тормышны алып барулары бик кыен... Давай, күз яшьләреңне сөрт, тынычлан. Әниең сизә күрмәсен. Хатын-кызга ирләр сүзен белеп бетерергә димәгән. Сер дә булырга тиеш әзрәк..."

— Әниең тәки сизмәдеме?

— Ничек сизмәсен инде!

— Әтиеңне орышкандыр?

— Бездә әти белән бәхәскә керү гадәте булмады.

Зәет, сүзе беткәндәй, берничә сулыш тын утырды. Аннан соң болай түгәрәкләде:

— Үлделәр инде — мәрхүмнәр, сагынып сөйләргә генә калды...

— Әллә чыннан да бөтенләй дәваланмадың?

— Шушы яшькә житеп, дару да капканым юк. Салкын тигәләгәндә дә йә мәтрүшкә, йә кура җиләге белән хушланасың... Чирләргә вакыт та юк, парин. Малайлар башка чыга, кызлар кияүгә җыена. Унга барсаң да акча кирәк, сулга борылсаң да — акча...

Әңгәмә моңсу булса да, көлеп җибәрдем, түзмәдем:

— Балаларың күп икән, алайса. Көч-кодрәтне экономияләп тормагансың?

Тел төбемне аңлады — онытмаган. Тагын бер мәртәбә рәхәтләнеп көлде:

— Татарга да үрчергә кирәк бит. Кытайга гына димәгән.

Шулчак авылдашы килеп житте Зәетнең. Түшкәне чапкалап, сату өстәленә куярга кирәк икән.

Саубуллаштык. Бер-беребезне ихлас күңелдән кунакка чакырыштык.

*Июль, 1997*

# ШИГЪРИЯТ

Фәрит
Яхин

## САГЫНУ КӨНЕ

### Сөенеч

Күңелдән яз — урамнарга күчте, —
Урманнарга, кырлар-болынга:
Шәфкатеннән сөелде бар тараф, —
Мин уралдым синең толымга...

Бәхет килде, рәхәт тапты җаным,
Кысалардан чыгып, күкләргә
Ашты — кайтты,
Һаман шулай булыйк,
Калдырмасын тәкъдир читләргә.

Без инде пар,
Күгәрченнәр кебек
Килик гөр-гөр, оя — түгәрәк.
Мәңгелек яз белән яшик илдә,
Китәчәкбез төнгә — бергәләп...

### Дөнья авар, диләр...

Хакимнәр дә фараз кылды, беркөн
Дөнья авар, егылыр, диделәр,
Аллаһыдан хәбәр юк идеме?
Ничек болай дөрес белделәр?

Ялгышларны авыр күтәрүе,
Җиңел түгел табу дөресне.
Көн дә сөйләп, онытып хакыйкатьне,
Әкият тә чынга ирешә.

Хакимнәрнең кулда — дәлилләре,
Бәхәс мәйданында йөрмиләр.
Кодрәте аз сүзнең, дигәннәрне
Ышандырып булмый, белмиләр.

Хакимнәрнең сүзен вакыт үзе
Хөкем итә, бәхәс чишелеп.
Дөнья авар, егылыр, дигән сүз бар,
Бездән соңмы калыр ишелеп?!

## Киявең килә

Капкаң — тимер, кияү көтеп
Сулыкма, йозагын ач.
Кем ул анда сине бутый,
Кычкыра: — Күренмә, кач...

Ачык капкадан үтүгә
Кем килеп каршы алыр?
Көттереп киявең килгән,
Аңарга кем дә барыр.

— Тимер капкаң ач-ач,
Киявең килә, кач-кач...

Качкан җирдән ник киләсең,
Кәләш хәлен беләсең,
Ярыкка күзең кысылган,
Анда кемне күрәсең?

Капкаңны яп, йөзеңне ач,
Әйләнсен кияүнең баш,
Мичтән бәлешеңне чыгар,
Казаныңда — кайнар аш.

## Мәхәббәт тәмугында

Сара җанны сәер, олуг тынлык.
Дөнья чиген тапкан шикелле,
Багып калам ерак офыкларга,
Өсләремә хәтер түгелде.

Әгәр саный китсәк, безнең көннәр
Ике айга тулыр, мөгаен.
Әмма сүзе гомерлеккә булды,
Тәкъдир безгә сытты чыраен.

Гайбәт өчен яралмаган идек,
Яманнардан безнең баш — өстен.
Гөнаһысыз
гөнаһларга чумдык,
Мин мәхәббәт
Тәмугына төштем...

## Аңлашу

Мин сөйләрмен
Сүз арканын ишеп,
Йолдызларга элеп һәм чөеп.
Син тыңларсың күңелеңә салып,
Утларымнан янып һәм көеп.

Мин сөйләрмен,
Сүзнең китеге юк,
Артыгы юк, әгәр тыңласаң,
Мең сүземнән берсен аңлаталмам,
Шулай була икән, соңласаң.

Сүз кадерең колагымда шаулый,
Йөрәгемә тама күз яшең.
Шулкадәр дә яратканың өчен
Рәхмәт сиңа, назлы кояшым.

* * *

Учак яктым, шәүләм, озынаеп,
Кара төнгә кереп тоташты,
Салкын йолдызлары белән галәм
Энҗе сипкән булып алдашты.

Фалын ачтым, хәерлегә юрар
Өчен иде һәрбер хәрәкәт.
Кая китте минем насыйбыма
Тиеш булган бәхет-бәрәкәт.

Тәкъдирдәген һичкем урлый алмый,
Бүлешәлми кеше ризыгын.
Учак яна, җаным
Кулын сузган,
Ярлыкауны сорый языгын...

## Сагыну көне

Күкләр елый, елгаларга иңеп,
Киң кырларга, бакча, талларга.
Күкләр елый бәгырьләргә үтеп,
Урам юып, тулып ярларга.

Күкләр елый, кошлар адашалар
Очып барган җирдән егылып.
Тәкъдирдәндер миңа бар да болар,
Үкси йөрәк, үкси сыгылып.

Күкләр һаман шулай булмас әле,
Ачылыплар китәр тарафлар,
Күңел дә гел болай булмас әле, —
Сагышымнан тәкъдир аралар.



# Рифат Җамал

## АҢЫМ БЕЛӘН ҖАНЫМ

* * *

Зурламагыз —
Мин батыр түгел,
Хурламагыз —
Мин бахыр түгел.

Көнләшмәгез —
Мин бөркет түгел,
Өркетмәгез —
Мин көртлек түгел.

Юатмагыз —
Мин юаш түгел,
Елатмагыз —
Күңел таш түгел.

Сөйләмәгез:
"Ул — кеше түгел!"
Яратсагыз —
Мин — кече күңел!

### Аңым белән җаным

Мине җитәкләгән
Җаным белән Аңым,
Әйтерсең лә, алар —
Кичем белән таңым.

Әйдәп бара көчле
Ихтыярлы Аңым.
Иярәмен аңа —
Зур-зур минем адым.

Аңа кирәк зур эш,
Аңа кирәк уңыш.
Мин — бәхетле һәм шат,
Иркен минем сулыш.

Ә нигә соң бик еш
Җаным бәргәләнә?
Исе китми аның
Данга, мәртәбәгә.

Сулкылдый ул, елый,
Өзгәләнә кайчак,
Табалмый тынычлык
Дөньяларны айкап.

Ишетә ул һәрчак
Халыкның моң-зарын,
Күрә ул үксезләр,
Ятимнәр дә барын.

Бер миндә, бер тәндә
Сыешалар алар.
Аңым тоймаганны,
Бәлки Җаным аңлар?

Аңым белән Җаным
Алга алып бара...
Гөлләр белән көлләр
Артта калып бара.

* * *

Язгы җилләр җанны тибрәтәләр,
Мәйданнарда ярсый шагыйрьләр.
Бар да өзгәләнә: "Милләт!" — диеп...
Тик нигәдер дәшми чал ирләр.

Нигә дәшми? Әйтер сүзе юкмы?..
Күзләрендә күпме сагыш бар.
Буразналы куллар. Бу кулларга
Кагылып үткән күпме арышлар?!

Нигә дәшми? Алар хәтерендә
Башка җырлар — шул ук авыздан.
Сүзләр бүтән. Ләкин көе китми
Шушы "хәтер" дигән явыздан.

Нигә дәшми? Чөнки сөйләүчеләр
Сулга каердылар кичәсен,
Бүген каералар уңга. Шуңа
Ышаналмый. Инде нишләсен!

Мин дә дәшмим әле. Бер уй борчый —
Сөйләүчеләр бүген житәрлек.
Көзге җилләр иссә, булыр микән
Көрәшчеләр, Себер китәрлек?!

* * *

*"... иң беренче*
*байракчылар ава!.."*

Рәшит Әхмәтҗан

**"Иң беренче байракчылар ава",**
**Исән кала арттан шуышкан.**
**Шуышканнар белән чыга күрәк**
**Һәрбер халык һәрбер сугыштан.**

**Батырларның кайсын ядрә алган,**
**Кайсын алган кара хыянәт.**
**Шуышканнар күп чак исән калган,**
**Алар өчен юктыр кыямәт...**

**Яшьләй һәлак булган күпме батыр —**
**Чәчәкләрен койган Ил гөле.**
**Шуышканнан шуышучы туа...**
**Бу хаклык та күптән билгеле.**

**Кеше булган маймыл — туры баскач...**
**Бер уй борчый, җанга ишелеп:**
**Сөйрәлүчеләргә әверелеп**
**Калырмыни инде Кешелек?!**

* * *

*"Поездлар китеп тора,*
*Ә сөю китми, сабый күк*
*Могҗиза күтеп тора."*

М. Әгъләмов

**Учаклар сүнә таңда.**
**Сөюләрем сүнми әле —**
**Син генә дәва җанга.**

**Чәчәкләр шиңә көзен.**
**Сөюләрем шиңми әле —**
**Син — минем күңел көзгем!**

**Көньякка китә кошлар.**
**Сөюләрем китми әле —**
**Күңелгә килми кышлар!**

**Гомерләр үтеп бара.**
**Сөюләрем үтми әле —**
**Ябылмый әле яра...**

* * *

**Атлар — тышауда,**
**Ирләр — богауда...**
**Халык — бозаудай.**

Илбашлар — ауда,
Малайлар — яуда...
Мәетләр — таудай.

* * *

Урамнарда, зәһәр бураннарда,
Бер моң йөри бәрелеп, каңгырап.
Мине эзли кебек. Бәлки табар
Киек казлар белән каңгылдап.

* * *

"Гөнаһсыз!" — дип күкрәк суга алмыйм. —
Гөнаһларым хәттин ашканнар.
Гөнаһсызлар атсын миңа ташлар...
Нигә эле бар да... качканнар?!

* * *

Кызган ташка суык суны сипсәң,
Син бел, җаным, таш та ярыла.
Ярылсын ла йөрәк авыр сүздән —
Кирәкмәгәч сөйгән ярына!

* * *

Бу дөньяда безне кунак, диләр...
Дөнья гына җигә ат итеп.
Шуңа янә алдалыйлар, бәлки:
Оҗмахта, дип, тора ял көтеп.

* * *

Тәрәзәмне кочып буран елый...
Нигә, буран, болай елыйсың?
Киткән дусларымның сагышы син.
Илтче, зинһар, йөрәк җылысын!

* * *

Чишмә ага челтер-челтер,
Җилләр исә җилфер-җилфер.
Челтер-челтер узсын гомер —
Ул бит бары искән җилдер!..

* * *

Яшен яшьни, күкләр күкри,
Яңгыр булып җир үкси...

Күз яшьләрем кипте инде,
Яшен булып бер үпче!

* * *

Шигырьләрең моңсу, дисең,
Гел аерылу турында.
Бергә чакта ничек языйм? —
Кулым синең кулыңда.

* * *

Бәхәсләш син, бәхәсләшмә —
Ап-ачык ачы хаклык —
Китапханәләрдән хәзер
Базарга күчте халык.

* * *

Боргаланып ага сулар,
Боргалана кешеләр...
Боргаланган су болгана.
Болганамы кешеләр?!

* * *

Бер үк бакчада үсәләр
Миләш белән алмагач...
Әллә миләш ачылана —
Аны һичкем алмагач?!

* * *

"Иелгән башны кылыч кисми..."
Юктыр монда хата.
Иелгән башны кылыч кисми —
Бары чаба балта.

* * *

Мин — дөньяның күз күрке, дип
Мактана Адәм.
Сүзләреннән тып-тын гына
Көләдер Галәм.

# ПУБЛИЦИСТИКА



**Әгъдәс Борһанов**

*тарих фәннәре докторы, Россия дәүләт гуманитар университеты профессоры*

## КЕМ ГАЕПЛЕ? НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ?

### Нәрсәдән башларга?

СОҢГЫ вакытларда байтак кына сәясәтчеләр, тарихчылар, публицистлар, совет үрнәгендәге тоталитар коммунизмны гаепләп чыксалар да, кайбер мәсьәләләрдә аның яхшы якларын да табалар. Әйтик, индустриаль һәм мәдәни революцияләр үткәрүдә коммунизмның казанышлары зур булды, диючеләр бар. Әлбәттә, җиде дистәдән артык ел эчендә илдә нәрсәләргә булса да ирешелгәндер. Хакимият башында азмы-күпме утырган теләсә кайсы режим ниндидер уңай эш-гамәлләр башкара, юкса, халыкка карата нинди генә явызлык-рәхимсезлекләр кылып та, хакимлекне барыбер саклап калып булмас иде. Әмма ирешелгәннәрне коммунистик режим тырнагыннан котылып калган ил-халыкларның казанышлары белән чагыштырып карарга кирәк. Россиянең тәрәккыяттә алга киткән илләрдән калышуы гомер-гомердән килә, аның кара язмышы шул, дип карыйлар, күрәсең. Әгәр дә Россия Октябрь инкыйлабына кадәр Европа һәм Американың алдынгы илләреннән чама белән бер гасырга артка калып килгән булса, хәзер инде ул, усал телләр әйтмешли, Азия илләренең байтагыннан да мәңгелеккә калыша. Совет хакимияте бөек ил-дәүләт — Советлар Союзын төзеде, диючеләр бар. Ул "бөеклеккә" халыкның канын эчеп, миллионнарны ГУЛАГларда черетеп ирешелгәнен онытмаска иде, ичмасам. С. Кортунов дигән галим: "Россиягә һәм, гомумән, кешелек дөньясына чын-асыл коммунистик идея кирәк булыр әле, Россияне бер тапкыр бөек дәүләт иткән "әйбәт ягулык" сыйфатында түгел, ә иң мөһиме — милли һәм дөньяви үсеш мөмкинлекләрен алдан күрүчән тәгълимат сыйфатындадыр, бәлки", — дип яза. Аз да түгел, күп тә түгел — "дөньяви үсеш мөмкинлекләре" өчен! Әле коммунистик идея кешелекнең бары тик өчтән бер өлешен генә, анда да вакытлыча гына, "бәхетле" итеп торган иде бит.

Публицист Л. Оников Сталинны ни өчен хурлык баганасына кадаклый, дисәгез, әлеге "юлбашчыбыз" бөтен кешелекнең котылгысыз якты киләчәге — коммунизмның иң явыз дошманы булган икән, аны

күп дистә елларга артка алып ташлаган икән... Менә шулай, телибезме-теләмибезме — анысы мөһим түгел, барыбыз да "котылгысыз якты киләчәк — коммунизмда" булачакбыз! Һичшиксез!

Күренекле галим, Россия Фәннәр Академиясе академигы Н. Моисеев исә: "Советлар Союзында һәм коммунистик блокның башка дәүләтләрендә яшәгән формадагы коммунистик дәүләт принциплары тормышчан түгел", — дип яза. Ягъни автор коммунистик дәүләтнең башка формалары тормышчан булу мөмкинлеген инкяр итми. Хәзерге хакимиятнең рәсми сәясәт белгече саналучы А. Мигранян, Ленинның НЭПына (яңа икътисади сәясәтенә) үзенчә бәя биреп: "Уңай үсеш шартлары булганда, мөгаен, вәзгыятьтә милекнең һәм хуҗалык эшчәнлегенең социалистик һәм капиталистик формалары бер-берсенә якынаер, аннары органик рәвештә кушылыр иде", — дип раслый. Шулай итеп, капитализм белән социализмның асылда кушылу-берләшү мөмкинлекләре турында сүз алып барыла.

Болай фикер йөртүләр, фараз кылулар беренче карашка гына зарарсыз шикелле. Беренчедән, Ельцин командасы үткәрә торган реформаны кабул итмәгән халыкның үзаңы үзенчәлеген, икенчедән, үткән "бәхетле" тормышны сагынучы, хәзерге вакытта реформаторларга каршы торырлык көч — социаль җирлеге булган коммунистик оппозиция барлыгын онытмаска кирәк. А. Ципко: "Илдә марксистик-ленинчыл партия сакланып калу сәбәпле, бездә көчле сәяси үзәк булу мөмкинлеге юк. Шул ук сәбәп аркасында, бездә чын мәгънәсендә оппозиция дә юк, демократия дә юк — сәяси үсеш-тәрәккыяткә дә мөмкинлекләр юк", — дип зарлана. Мәсьәлә шунда ки, президент чирүенең нәфрәтенә карамастан, коммунистлар партиясе тыелмый, янәсе, — демократия! Тагын да яманрагы — хакимият, коммунистларга вак-төяк ташламалар ясап, үзара нииндидер килешүгә барырга да әзер шикелле. Иҗтимагый кануннарга буйсынып, бетеп-юкка чыгып бара торган булса да, коммунистларның әлегә социаль җирлеге бар: бу социаль катлам хөкүмәткә каршы плакатлар, Сталин портретларын күтәреп, кычкырып-янап йөрергә сәләтле әле. Чыгырыннан чыгарсаң, күбрәккә дә сәләтледер. Демократия дигәнебез дә алай гади генә түгел: аның уң канатында шулай ук үз социаль җирлеге булган олигархия — банкирлар, эре алыпсатарлар сатлык түрәләр белән бергә укмашкан булса, сул канатында социаль җирлеген йорт-җирсезләр, хәерчелекбөлгенлеккә төшкән люмпеннар һ. б. төшкил иткән жириновскийчылар, баркашовчылар, коммунистларның анпиловчылар кебек аерым төркемнәре тора. Ә гамәлдә чын демократик үзәк юк, демократиянең нигезе булырга тиешле күпсанлы хосусый милекче урта сыйныф юк чөнки. Димәк, шулай икән, уң яки сул канатның җиңүе котылгысыз. Әлегә уң канат җиңеп килә, әмма тиздән җиңү сул канатта булмас дип кем әйтә ала? Сәгать теле шикелле уңга-сулга тайпылуларны тоткарларга сәләтле үзәк юк бит.

С. Кортуновның "милли һәм кешелек дөньясы үсешенең перспективасы" булырга тиешле коммунизм тәгълиматы турындагы фикерләрен сүтеп карыйк. Кешелек тарихының төп чорлары турында Маркснең яшьрәк чагында әйткән фикерләренә — тарихның алшарты ("табигый зарурлык патшалыгы"), коммунизм ("аңланган зарурлык патшалыгы") һәм уңай гуманизм "("азатлык патшалыгы") чорлары дигәненә таянып, С. Кортунов ул чорларның тормышка ашмавына үкенеч белдерә, "марксистик теориянең мөмкинлекләре бетмәгән әле", "Россиядә чын коммунизм беркайчан да булмаган", ди. Кыскасы, чын-асыл коммунизмны яңабаштан төзү кирәк, имеш. Гомумән, "мәсьәлә коммунизмның үзендә түгел" икән. Бәла шунда, ул дәүләт идеологиясенә әверелергә сәләтле булып, шул идеология тарафыннан үзенең асылын нык бозуга китергән икән, имеш.

Хакимият башына коммунистлар килгәннән соң, коммунистик хыялның котылгысыз рәвештә дәүләт идеологиясенә әверелергә тиешлеген, шулай булмаса, аның тормышка ашмаячагын, ә тормышка ашыру өчен дәүләтнең хакимият көче — диктатура кирәклеген С. Кортунов аңламый, күрәсең. Коммунизм — кешелекнең якты киләчәге, һәркем өчен тигез, бәхетле-рәхәт тормыш — бу шигарь-хыял шулай көгазьдә генә кала; аны тормышка ашыру максатыннан диктатура, — юк, пролетариат диктатурасы түгел, анысы да сүздә-кәгазьдә генә, ә комбюрократия диктатурасы! — урнаштырыла; гражданнарның хосусый милке һәм милли байлык дәүләт кулына күчеп, дәүләтнең үзенә һәм бар милеккә түрәләр — номенклатура хуҗа була. Кешеләр — табигатьләре белән индивидиумнар, ягъни һәркем үзенә аерым, кабатланмас бер шәхес. Хосусый милкеннән мәхрүм итү кешене шәхси бәйсезлегеннән, үзе теләгәнчә яшәү мөмкинлегеннән, яшәү җирлегеннән мәхрүм итү, дигән сүз. Кешеләрне тигезләргә омтылган коммунизм — әхлаксызлык. Шунлыктан аның бу максатка ирешү чаралары да кешелексез: болар — сыйнфый көрәшнең, кискенләшеп, "корыч адымлы, кызыл командирлы" гражданнар сугышына кадәр китереп җиткерелүе; кешенең шәхси тормышына тыкшынуны, көчләү-ирексезләүне җәмгыять белән идарә итү ысулына әверелдерү; каршы торучыларны юк итү, сөбереп түгү; тормыш шартларын җәмгыятьнең иң түбән тәгәрәгән, череп таркалган, "тормыш төбендәге" катламы һәм пролетариатның яшәү рәвешенә тигезләү; бөтендөнья сугышы аша булса да, Җир шарында коммунистик революциянең җиңүенә ирешү максатындагы мессианчылык идеясе һ. б. һ. б. Нәкъ менә әле санап кителгән шул ысул-чаралар "коммунизм — кешелекнең якты киләчәге" дигән мәрхәмәтчел максатны юкка чыгара да куя. Шуңа күрә коммунизм чагыштырмача кыска вакытка гына җиңүгә ирешә ала, матур хыялга алданган халыкның иртәме-соңмы күзе ачыла. Илне-дәүләтне яулап алмаса, коммунизм — җәмгыять үсешенең тарихи закончалыкларына каршы килә торган, фәнни нигезләнмәгән буш хыял, "җирдәге оҗмах" хыялы гына. Ә инде, диктатура урнаштырып, ил-дәүләтне үзенә буйсындырган коммунистик режим — ул "җирдәге тәмуг"! Аның юлы гына игелекле ниятләр белән түшәлгән була. Иң зур куркыныч та әнә шунда. Кешеләр арасында һәрвакыт бу хыялны тормышка ашырырга тырышучы шәхесләр табылып торачак. Алар халыкны коммунизмга бару юлында мөмкин булган хаталар өчен борчылмаска үгетләячәкләр, "бер эшгамәл кылмаганнар гына ялгышмый", диячәкләр. Ә ул "хаталар" кан кою, төрмә-лагерьлар була икән, Бухарин әйтмешли, "яңа кеше" бары тик шулай гына тәрбияләнә ала да! Коммунизм төзү идеясе шулкадәр көчле аздыргыч, кызыктырырлык-мавыктырырлык вәсвәсә ки, Мао Цзедун "моның өчен миллионнарча корбаннар да, хәтта кешелекнең өчтән бере дә кызганыч түгел", дип кистереп әйткән. Имеш, соңыннан бөтен кешелек дөньясы бәхетле-имин яшәячәк. Кайсыдыр бер чын гуманист, игелекле зат "кешелек бәхете бер баланың күз яшенә дә тормый" дип әйткән икән, "коммунистик гуманистларга" бер гаепсез миллиардлаган кешеләрнең гомерләре дә берни тормый. Сталин, Мао Цзедун, Ким Ир Сен, Пол Пот ишеләр нәкъ шундый вәхшилекләр аша коммунистик идеяләрне тормышка ашырып маташмадылармы?! Коммунизм, сыйнфый көрәшкә йөз тотып, бер сыйныфны икенчесенә каршы котыртып һәм бер-берсен юк итүгә этәреп, социаль фашизм буларак туган иде. Совет коммунизмы (өлешчә Болгария һәм Кытайныкы да), үз ил-дәүләтендәге "вак-төяк" милләтләргә каршы геноцид — тулаем юк итү сәясәте үткәрә-үткәрә, расизмга кадәр барып җиткән иде. Димәк, коммунистик идеологияне "коммунофашизм" дип атау дөресрәк булыр.

Кешелекнең бәхетле-иркен тормышы коммунистик тәгълиматка, ул кулланган чараларга капма-каршы демократик чаралар белән генә тормышка ашырыла ала. Иң мөһиме — чын демократик дәүләт булдыру һәм хосусый милекчелекне үстерү, аңа гражданнарны мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итү. Югары тәрәккыяткә ирешкән демократик дәүләтләр тәҗрибәсе шуны күрсәтә: хосусый милекчелеккә ил халкының ким дигәндә өчтән ике өлеше тартылырга тиеш. Әлбәттә, иң яхшысы, ялланып эшләүчеләрне бөтенләй бетереп, барлык халыкны хосусый милекче урта сыйныф итү булыр иде. Әмма монысы мөмкин түгелдер.

Коммунизм, хосусый милекчелекне инкяр итеп, үзәктән планлаштырылган, үзәкләштерелгән дәүләт кулында булган икътисадка таяна. Бу исә бары тик дәүләт диктатурасы булганда, демократия, плюрализм, ягъни карашлар-фикерләр төрлелеге һ. б. сыйфатларга ия гражданнар җәмгыятен таркатканда гына тормышка ашырыла ала. Мондый ил бер-берсенә капма-каршы ике төркемгә бүленә: беренчесе — дәүләт диктатурасы, икенчесе — тулысы белән ялланып эшләүчеләр (коллар). Дәүләт икътисады һәркем өчен мәҗбүри булган дәүләт планы буенча үстерелсен өчен дәүләт диктатурасы кирәк тә. Диктатура аз гына йомшаклык күрсәтсә дә, коммунистик система җимерелеп төшәргә мөмкин. СССРда һәм калган барлык социалистик илләрдә бу шулай булды да. Ә диктатураның көчсезләнүе һәм вакытлар үтү белән юкка чыгуы котылгысыз. Чөнки һаман да штыкларга таянып утырырга мөмкин түгел, халык даими репрессияләргә әкренләп "күнегә-ияләшә", курку хисеннән арына һәм, ниһаять, диктатурага каршы күтәрелә. Сталинның үлеменнән соң илдә диктатураның йомшаруы КПССның җитәкче даирәләре арасында күпмедер әхлакый сыйфатлары сакланып калган, намуслы эшлеклеләр булуда гына түгел, ә диктатура аркасында халыкның аңы-психикасы коточкыч үзгәрүдә: гомуми эчкечелек һәм караклык, җинаятьчелекнең күрелмәгәнчә артуы, кешеләрнең бар нәрсәгә, шул исәптән үз язмышларына да битараф булуы, бик түбән хезмәт җитештерүчәнлеге һәм аз хезмәт хакы — ачы хакыйкать әнә шуннан гыйбарәт иде. Моны ачык аңларга кирәк. Юкса, коммунизм өрәге кешеләр башын озак катырачак әле. Ачык аңлап, коммунистик идеологияне махсус закон белән тыярга кирәк, аңа табынган кешеләрне җинаятьчеләр итеп караганда да начар булмас иде. Әйе, тыюдан башка чара юк. Коммунизм тәгълиматын көчләп тагып, башка халыкларга да күп зыян салган һәм үзе дә күп газаплар кичергән Россия бу тыюны беренче булып гамәлгә ашырырга тиештер. Аннары Россия, БМО әгъзалары булган башка илләрнең дә шундый Закон кабул итүләрен үтенеп, аны БМО әгъзасы булуның бер шарты итеп, Берләшкән Милләтләр Оешмасы Уставына кертүне күтәреп чыгар иде.

Коммунизм авыруыннан котылу өчен бездән дә күп көч һәм вакыт сарыф иткән бер генә ил-халык та юк. Җиңелгәннән соң яки диктаторлары үлгәннән (бәреп төшерелгәннән) соң, барлык фашистик һәм милитаристик дәүләтләр дә озакламый тәрәккыяткә ирештеләр. Ә Германия, Япония кебекләре барлык кешелек дөньясын әйдәп баручы илләр булып танылды. Без исә һаман бер урында таптанып кына калмыйбыз, киресенчә, артка тәгәрибез...

Бу уңышсызлыкның сәбәпләре нәрсәдә соң?

Без башта, бюрократ-сорыкортлар идарә иткән тоталитар дәүләтнең авыру-зәгыйфь икътисадына таянып, Көнбатыштагы демократик дәүләтләрнең сау-таза, чәчәк аткан икътисадын "куып җитеп, узып китәргә" азапландык; анысы барып чыкмагач, "салкын сугыш"ка ташландык. Коммунизм куыгы, әнә шул көрәштә көчәнә-көчәнә, бар Җир шарына яман ис

таратып шартлады. Җиңелүнең төп сәбәбе эчке оешмаганлыкта, социаль тотрыксызлыкта иде. Ил-дәүләт бүген тарган бәла-казаларга да гаҗәпләнмәскә кирәк, гаҗәбе — Россиянең гасырлар буе хәерчелек һәм хокуксызлыкта яшәгән халкы белән дә вакыт-вакыт бөек дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелә алуы һәм әлегә бербөтен дәүләт булып калуыдыр. Хикмәт шунда ки, коммунизм "үсеш субьектларын" — һәртөрле милекчеләрне революциягә кадәрге Россия дәүләтеннән дә болайрак итеп юкка чыгара килде. Нәтиҗәдә җәмгыятьтәге вәзгыять сәяси, гомумдәүләт һәм милли мәсьәләләргә карата халыкның тотрыклы битарафлыгы белән аерылып тора.

Шунлыктан, КПССның 1961 елда халыкка нәрсәләрдер вәгъдә иткән Программасы коммунистлар хакимиятен ничек тә булса саклап калу ниятеннән чыгып эшләнгән иде. Чөнки "тимер пәрдә" никадәр генә калын булмасын, "аргы яктагы" тормыш дәрәҗәсе турындагы хәбәрләр саркып керә, халыкның көннән-көн күзе ачыла бара иде. "Коммунизм өчен көрәшкә!" шигаре искереп, кешеләрдә шәхси матди мәнфәгать уяна; партсовноменклатура симергәннән-симерә барган заманда, иң гади ихтыяҗларыңны да үти алмыйча күпме яшәргә була, дигән сорау туа; "хезмәтнең асыл нигезле рухы" дигән аңлаешсыз ялганнар белән халыкны һаман да алдап тору мөмкин булмый башлый.

Бездә бит җәмгыятьнең акылы һәм ихтыяры патшаның (генсекның, президентның) акылы һәм ихтыярына буйсындырылган. Ике башлы даһи булса да, аның уй-ниятләре төшләрендә дә тәрәккыят көпчәгенә таяк тыгып ятучы бюрократ түрәләр кулы белән тормышка ашырыла. Түрәләрнең исә максатлары бер: ничек тә булса күбрәк үзләренә "көрәп" калырга кирәк. Көнбатышның капиталистик илләрендә бюрократлар андый көчкә ия була алмый, чөнки милли байлык алар кулында түгел, халык аларга хезмәт итми, түрәләр халыкка хезмәт итә. Шуңа күрә, тормыш дәрәҗәсенең югарылыгы миллионлаган шәхесләрнең көче, акылы һәм ихтыяры белән барлыкка китерелә. Капитализмның уңышлары социалистик ысуллар белән түгел, капиталистик ысуллар белән тормышка ашырыла.

Кайберәүләр халык аңына сиздермичә генә "хәзерге коммунистлар "совок"-соскыч заманнардагыдан аерылып тора" дигән фикер сеңдерергә тырышалар. Монысы да — чираттагы әкият. Моңа төп дәлил — хәзерге коммунистларның җиргә хосусый милекчелекне кабул итә алмаулары. Җир — төп җитештерү чарасы, аны хосусый милекчелек мөнәсәбәтләренә җәлеп итмичә, беренди базар икътисады була алмый. Бүгенге түрәләр яңа җәмгыятьтә дә дилбегәне үз кулларында тотып, җиргә хуҗа булу хокукын үзләренә алмакчылар. Җирне сүздә-кәгазьдә "түләүсез уртак байлык" дип игълан итеп, бюрократия аны ришвәт бәрабәренә сатып ятмакчы була түгелме икән? Хосусый милекнең дә аерымлыклары бар: җиргә хосусый милекчелек белән башка төрле хосусый милекчелек бер үк нәрсә түгел. Җир мәсьәләсенә килгәндә, җәмгыять төрле чикләүләр куя ала, алары хакында бирәдә аерым сөйләп тору кирәкмидер.

Бүгенге коммунистларның: "Әгәр без хакимияткә килсәк, икътисадның күптөрлелегенә каршылык күрсәтмәячәкбез. Дәүләт милкенә ия булган без төзиячәк социализм хосусый милекчелеккә дә, икътисадның башка төрләренә дә юл куячак һ.б. һ. б.", — дигән вәгъдәләренә һич ышанырга ярамый. Бу — безнең өчен былтыргы "А" инде! Дәүләт милкенә нигезләнгән икътисад белән хосусый милекчелек икътисадын әле Н. Бухарин да, янәшә хәрәкәт итеп, киләчәктә бербөтен социалистик икътисадка әверелачәк "ике әрҗә"гә тиңләгән булган. Моның мөмкин түгеллеген аңлаган Сталин хосусый милекчелек икътисадын тулысы белән дәүләт икътисадына әйләндергән дә куй-

ган. Дәүләт икътисадының гомерен шул рәвешле байтак елларга озайтуы белән "бөек юлбашчы" үзенчә хаклы да булгандыр, мөгаен. Бүгенге коммунистларның буш вәгъдәләре яңа икътисади сәясәт (НЭП) тарихын бозып аңлауларына нигезләнгән. Бу мәсьәләгә ачыклык кертү өчен: "Сталинның яңа икътисади сәясәт һәм кооперация хәрәкәтен иң чәчәк аткан вакытында тыюы, юкка чыгаруы нинди сәбәпләр белән эшләнгән соң?" — дигән сорау кую кирәктер.

Минемчә, Россиянең барлык реформалары һәм алар уңышсыз тәмамланганнан соң булган революцияләр тарихи бер максатка — җәмгыятьне капи-талистик юнәлештә үзгәртеп коруга, җитештерүче көчләргә тулы ирек биреп, халыкның тормыш-көнкүрешен яхшыртуга юнәлдерелгән булган. Әмма бу максат сер итеп, яшереп тотылган. Чөнки өстен сыйныф моны бервакытта да аңлап бетермәс, риза булмас дип уйланылган. Моның сәбәбе бер генә — хаким сыйныф "Россиянең үсеш юлы Гарепкә дә, Шәрекъкә дә охшамаган, ул үзенчә генә була ала, әмма бөтен кешелек өчен үрнәк (өченче Рим — өченче Интернационал) юл" дип ианып яшәгән һәм яши. Петр Беренче, Александр Икенче, Столыпин реформалары һәм баштагы ике революция (1905 һәм 1917 елгы февраль) максатлары белән буржуаз характерда булалар. Октябрь инкыйлабын да шул ук максатлар китереп чыгара. Аның шигаре: сугышны туктату, феодалларның җиргә хуҗа булу хокукын бетереп, җирне крестьяннарга бирү, халыкларга үзбилгеләнү хокукы бирү. Бу уңай белән Ленин "большевизм хакимияткә буржуаз-демократик революция агенты буларак килде" дип билгеләп үтә. "Агент"лык бурычын үтәгәннән соң, бу хакимият шунда ук икътисадка дәүләт хуҗа булу хокукын (национализация, продразверстка) яулап ала, коммунистик номенклатура хакимиятен урнаштыра. Бәланең башы нәкъ менә шунда була да инде. Коммунистик тәгълиматны большевиклар партиясе шул рәвешле тормышка ашыра башлады һәм... ялгышты!

Моны Ленин 1918 ел башында ук аңлагандыр дип раслый алмыйм, әмма ул хакимиятнең халыктан аерыла барганын, хезмәт җитештерүчәнлегенең кискен кимегәнен күргән һәм сәяси нәтиҗәләр ясаган. 1918 елның март-апрель айларында ук Ленин, "буржуазия белән көрәшнең яңа фазасы" дигән сылтау табып, капитализм белән килешеп яшәү юлларын эзли башлый һәм 1921 елда НЭП — яңа икътисади сәясәт игълан итә. Бу инде турыдан-туры капитализмны тергезү юнәлешендәге буржуаз эш-гамәл була. Аннары, вафатына күп тә калмаганда, Ленин большевиклар партиясе тормышка ашыра барган гамәлләрнең һич тә үзе уйлаганча социалистик булмаганлыгын төшенә һәм "социализмга булган карашларыбызны тамырыннан үзгәртергә кирәк" дигән нәтиҗә ясый. Әмма аны тыңлаучы калмый шул инде, дилбегә Сталин кулында була.

Ленин исән вакытта, социалистик киемнәргә төренгән булсалар да, буржуаз-капиталистик үзгәрешләр үзләренә юл яра торалар. Инде Ленин үлгәч, алар коммунистик диктатура тарафыннан читкә тибәрелә. Читкә тибәрелә вә ләкин көн тәртибеннән төшереп калдырыла алмый. Шуңа күрә дә бу үзгәртеп коруларга омтылыш яңадан баш калкыта. Шулай итеп Тарих галиҗәнаплөре яңадан үз эзенә кайтып төшә: моннан өч гасыр элек Петр Беренче башлап җибәргән, аннары 19-20 гасырларда Александр Икенче, Столыпин һәм Ленин дәвам иткән буржуаз реформаларны җиренә җиткерергә тагын бер мәртәбә (бәлки, соңгысыдыр?) талпыныш ясала. Моның төп максаты, хакимият башында утыручылар аңласа-аңламаса да, хосусый милекчеләрнең урта сыйныфын булдырудыр. Без хәзер шул талпынуларның кәсафәтен күрәбез...

Ни өчен Сталин һәм аның иярченнәре Ленин аңлаган социализмны кабул итмәгән, яңа икътисади сәясәт (НЭП) белән кооперацияне кире каккан? Югыйсә, яңа икътисади сәясәтнең нәтиҗәләре менә дигән булган бит: ил аякка басып, бөтәеп, тернәкләнеп килгән. Моны кабул итмәүнең асылында ни-нәрсә ята? Ленин үлгәннән соң, большевик җитәкчеләрнең, үзебезчә эшлибез дип, мөгез чыгарырга тырышуларымы бу, әллә аларга да буйсынмаган башка сәбәпләр булганмы? Булгандыр. Чөнки, халык хуҗалыгындагы төп мал-мөлкәт крестьяннар һәм сәүдәгәрләр кулында икәнлеген күргәч, большевистик сәяси система хосусый милекчелеккә мөнәсәбәтен тамырдан үзгәртеп, яңа икътисади сәясәтнең язмышын хәл иткән.

Яңа икътисади сәясәт (НЭП) икътисадка хуҗа булган дәүләт белән яраша алмый иде. Ул крестьяннарның аерым хуҗалык итүенә, һөнәрчеләр-сәүдәгәрләрнең хосусый эш-гамәлләренә нигезләнгән иде. Россия тарихында беренче мәртәбә күпсанлы урта сыйныф аякка баса башлаган иде. Бу вәзгыятьне крестьяннарның дүрттән өч өлеше белән миллионнарча шәһәр халкы — һәртөрле һөнәрчеләр, кәсебчеләр барлыкка китергән. Нэпманнар-кооператорчылардан каерып алынган зур-зур салымнарны "йотып" торуына карамастан, дәүләт икътисады урта сыйныф белән ярыша алмаган. Шуңа күрә, Сталин, НЭПны һәм кооперацияне юк итеп, крестьяннарны көчләп коллективлаштыру эшенә керешкән. Аңа ашыгырга кирәк була. Чөнки сыйфат һәм сан ягыннан туктаусыз үсә барган урта сыйныф партия һәм дәүләт номенклатурасын бөреп төшерергә дә күп сорамаячагын ул аңлаган. Сталинның шәхес культы белән, аның иярченнәре тудырган бюрократия белән дәүләткә буйсынмыйча, бәйсез-мөстәкыйль яши алырлык урта сыйныф һич тә яраша-килешә алмас иделәр. Яңа икътисади сәясәт һәм кооперацияләштерү бөтен сәяси системаны үзгәртеп коруны таләп итәр иде. Большевиклар моңа бара алмаганнар, әлбәттә.

Коммунистлар партиясе хакимияткә килүгә үк яңа өстен сыйныф булып, дәүләт белән хуҗалык итүне үзенә буйсындырып, җәмгыятьне читкә тибәреп яши башлый. Ул бары тик бюрократ түрәләрнең хосусый милкенә әверелгән дәүләт мәнфәгатьләренә генә хезмәт итә ала. Башкача үзгәрә дә алмый, үзгәрергә теләми дә.

Барлык милли байлыкны үз милкенә әверелдергән дәүләт башында Сталин торган коммунистик бюрократия дәүләте үзе оештырган җитештерү мөнәсәбәтләренә үзе үк әсир төшә, тоткын хәлендә кала. Хакимият белән икътисадның урыннарын алыштыргач, кушылучыларның суммасы бөтенләй башка булыр: икътисад хакимият күрсәткән юлдан китәр, дип фикер йөрткән большевиклар ялгышалар. Җитештерү мөнәсәбәтләре алардан "ялган хуҗалар" — яңа изүче сыйныф әвәләп чыгара.

Сәяси өскорма (хакимият) тарих кануннарын әйләндереп каплый алмый, ул бары тик икътисадны гына әйләндереп каплый ала. Андый икътисад исә, милекчелеккә мөнәсәбәтләр ничек кушса шулай, бер очракта чәчәк атып, икенче очракта үлә барып, үз кануннары белән яши башлый. Икътисад белән хакимиятнең урыннарын алыштыру — арбаны ат алдына җигү белән бер ул. Яңа өскорма (хакимият), иске җәмгыять эченнән өкренләп, эволюцион юл белән үсеп чыккан яңа икътисади нигез (базис) ихтыяҗларына буйсынып, сәяси революцияләр тарафыннан төрле сикерешләр аша ясала. Икътисади нигез (базис) исә алай туа алмый. Ул яңа большевистик хакимият (өскорма) ихтыяры белән ясалма рәвештә барлыкка китерелә, милекчелеккә мөнәсәбәтләр җимерелгән булганлыктан, дәүләт ышыгында көчкә-көчкә генә сулыш ала, халыкның мул-имин тормышын тәэмин итә алмый, рухи-әхлакый төшенчәләрне дә җимерә һәм, ахыр чиктә, үзе дә

җимерелеп төшә. Дәүләт икътисады — һәрвакыт зыян, ул — бөлгенлек, ул үзенә тоткан чыгымнарны кайтарырлык хәлдә түгел.

Әгәр дә икътисади нигез (базис) тарихи-табигый хосусый милекчелеккә корылган булса, хакимият (өскорма) аның белән бер мичәүдә була. Инде ясалма икътисади нигез (базис) икән, аның халыкны җәберләп торган хакимияте (өскормасы) дә һавада эленеп кала. Социалистик революцияләр төзегән дәүләтләрнең җимерелүе шуңа күрә дә котылгысыз һәм, киресенчә, буржуаз дәүләтләр һәрвакыт тотрыклы уңышка ирешә.

* * *

ТАРИХНЫ шәхесләр ясый, шәхесләр иҗат итә. Әмма шәхесләрнең эш-гамәлләре алар ихтыярына буйсынмаган иҗтимагый-сәяси һәм икътисади күренешләргә бәйле, шуларга яраша. Фән телендә ул субъектив һәм объектив факторларның бәйлелеге дип атала. Безнең ил очрагында нәкъ менә шунысы булмады да: Лениннан соң килгән житәкчелек белемсез-надан, теоретик әзерлексез, җитлекмәгән иде. Шуның өстенә Сталинның холкы-табигате шулкадәр әшәке-җирәнгеч була ки, әйтерсең лә, аңа дөньяның бөтен явызлыгы тупланган. Сталин турында сүз йөртеп, Л. Оников аның чын коммунист булмаганлыгын әйтә. Мин әле: "Ул хәтта фашист та булмаган", — дияр идем. Чөнки фашистлар булып фашистлар да тиктомалдан үз халкын кырмаган. Әмма Л. Оников бер мәсьәләдә хаклы түгел: Сталин коммунизмның абруй-дәрәҗәсен төшермәгән. Ленин сүзләрен бераз үзгәртеп әйтсәк, "җирдәге оҗмах" турындагы татлы хыялларга нигезләнгән коммунизмны кимсетеп, дәрәҗәсен төшереп булмый. Ул үз дәрәҗәсен үзе төшерә — менә шуны онытмаска кирәк иде.

Сәяси оешма буларак ничек кенә булса да исән калырга тырышкан КПССның көчәнүләре инде җегәре беткән социалистик дәүләтнең Бөек Ватан сугышыннан соң череп таркала баруын көчәйтеп кенә җибәрә. Аны камилләштерергә омтылышлар Сталин заманында хөр фикерләрне коммунистик идеология һәм төрмә-лагерьлар белән буып тору рәвешендә булса, Хрущев заманында партия оешмасын сәнәгать һәм авыл хуҗалыгыныкы итеп икегә аеру кебек буталчыклыклар гына китереп чыгарды. 1978 елда мин шәхсән үзем Л. И. Брежневка, яңа кадрларны үстерү һәм сайлап алу максатыннан, башлангыч партия оешмаларын икегә бүләргә кирәк дигән тәкъдим белән мөрәҗәгать иткән идем. Эт итеп тиргәп кенә ташлады. КПССның яңарышына бөтенләй өмет калмады. Хрущев белән Косыгин түрәләрнең җаваплылыгын арттыруга юнәлтелгән чаралар үткәрергә тырышып карасалар да, уңышсызлыкка очрадылар. Монысы партиянең инде күптәннән "мөмкин кадәр бернәрсәне дә үзгәртмәскә" шигаре белән яшәгәнлегенә бер дәлил иде. "Искегә тисәң — исең китәр", — ди халык. Тутыгып, эштән чыгып беткән партия машинасын бер сүтсәң, яңадан җыеп булмаслыгы көн кебек ачык булгач, нигә аңа тияргә? Тора бит әле, торсын, безнең гомергә җитәр — брежневчылык әнә шул "әйдә, ярар" белән яшәде дә.

Октябрь революциясенең бәласе шунда иде: ул хакимияткә элекке иҗтимагый-икътисади нигезләрдә туып, милекчелекнең яңа мөнәсәбәтләренә таянып үсәрдәй яңа сыйныф алып килә алмады, ә бәлки, яңа бюрократия — түрәләр белән генә килде. Бюрократ түрәләр исә гомер-гомергә Россиядә өстен сыйныф саналдылар. Горбачевның "үзгәртеп коруыннан" соң ясалган Ельцин түнтәрелеше дә шуны ук эшләде. Иске һәм яңа түрәләрнең аермасы бары тик

шәхесләр, кланнарда гына иде. Башта "пролетариат диктатурасы" дигән пәрдәгә төренеп, феодал-буржуаз бюрократияне коммунистик номенклатура алыштырган булса, инде хәзер сәлперәеп беткән коммунист картларны заман җилләрен тиз тойган яшь коммунистлар типкәләп чыгарды да, үзләрен "демократлар" дип атады. Алар арасында охшашлык та бар: һәммәсе дә түрәләр, һәммәсе дә элекке коммунистлар — димәк, дөньяга карашлары, сәяси тәҗрибәләре, холык-гадәтләре, большевистик ысуллы эш-гамәлләре дә уртак. Хакимияткә яңадан кайтырга омтылучы коммунистлар да (оппозиция), барысы да бер юрган — коммунистик юрган астыннан чыккан затлар. Дөрес, игътибарга лаек булырлык бер аермалы сыйфатлары бар. Беренче коммунистлар арасында акыл һәм явызлык даһилары, күренекле шәхесләр дә бар иде — революция һәрвакыт шундый шәхесләрне тудыра. Икенче буын коммунистлар исә тарихта "юлбашчыларның" тышкы кыяфәт-сыйфатлары белән генә истә калачак: "калын каш", "тамгалы", "елак болшевик". Өченче — хәзерге буын (соңгысы булыр дип ышаныйк) "коммунист" исеменнән бөтенләй ваз кичеп, "демократлар" исемен үзләштереп хакимияткә килде. Кайберәүләр әйтмешли, "кибетче идарә итүче" булды, элгәрләре кебек дәүләтчелек мәктәбен үтмәгән килеш, шәхес буларак иң начар сыйфатлары белән "чабатасын салып, түргә менеп" утырды.

Гаҗәеп бер закончалык: искесен алыштырган яңа дәүләт элитасы, элгәрләренең тәҗрибәсенә таянып, тагын да акыллы-эшлеклерәк булырга тиеш иде кебек. Юк шул, гел киресе килеп чыкты — боларның эш-гамәлләре сыйфаты начарайганнан-начарая бара. Россиядә патшалар заманында да шулай булган, Октябрьдән соңгы һәм "үзгәртеп кору" дәвере җитәкчеләре дә шундый иде, инде хәзер дә шуны күзәтәбез: депутатлар чакырылыштан чакырылышка сыегая гына бара...

Россиядә ике бәла бар, диләр. Аның беренчесе — ахмаклар. Алары — түрәләр. Алар халык тормышыннан көнсәләр эше белән аерылганнар. Ә бит бары тик халык арасында кайнап яшәү генә зиһенне үстерә, акылны арттыра. Түрәлеккә үрмәләгән табигый акыллы яңа шәхес тә аң-зиһен ягыннан үсеш ала алмый, ул бары тик бер дәрәҗә-баскычта гына кала. Язучы А. Битов андыйларны "үсештә туктап калган кешеләр" дип атый.

Бюрократ түрә — хуҗа сыйфатындагы ялган шәхес, үзенеке булмаган милли байлыкка дәгъвасеннән аның хуҗа булу хокукы туа да. Милли байлыкны халыктан тартып алып, дәүләтнеке иткән очракта гына түрә өстен сыйныф санала ала. Даими рәвештә үз милкең белән идарә итү — бер хәл, хәләл көчең бәрабәренә үзең эшләп тапкан милек урынына кеше милкенә вакытлыча хуҗа булу — бөтенләй башка нәрсә. Беренче очракта хосусый милекченең мәнфәгате сакланып, ишәеп-үрчеп торырга тиешле милек "мәнфәгате" белән тәңгәл килә, яраша-кушыла, икенче очракта, хәтта идарә итүче түрә намуслы-эшчән булганда да, андый тәңгәллек юк. Бу уңайдан академик Н. Моисеев фикерләре кызыклы. Илнең егерменче еллар тарихында яңа икътисади сәясәтнең уңай күренеш икәнлеген искәртеп, ул шул замандагы синдикатларның — капиталлары дәүләтнеке булса да, үзләре дәүләттән бәйсез-мөстәкыйль сәнәгать-сәүдә берләшмәләренең уңышлы эшчәнлеге турында яза. "Вакыйгаларның мондый үсеш алуы хәрби коммунизм чорында барлыкка килгән бюрократия өчен үлем куркынычы белән бер иде, — дип дәвам итә Н. Моисеев. — Бюрократлар сәүдә итә белмиләр, НЭП чорына хас көндәшлек-ярыш шартларында исән калу өчен кирәкле базар мөнәсәбәтләрен, аларның нечкәлекләрен аңламыйлар. Алар өчен "иптәш маузер сүзе" иң ышандыргыч дәлил иде... Шуңа да НЭП таркалды... Аннары җитештерелгән

мал-мөлкәткә хуҗа булган, аны бүлгәләштереп өләшеп утыра торган төрле халык комиссариатлары барлыкка килде. Нәкъ менә шул комиссар түрәләр халык байлыгына хуҗа булып алдылар да инде. Аларның мәнфәгате партия сәясәтен билгели башлады". Н. Моисеев белән килешкән хәлдә, бер мәсьәләгә ачыклык кертү кирәктер: бюрократ түрәләр "сәүдә итә белмиләр", "аңламыйлар", "теләмиләр" түгел, ихтыяҗың төшсә, аюны да нәрсәгә булса да өйрәтергә мөмкин. Бюрократ түрәгә исә өйрәнүнең хаҗәте юк, аңа болай да начар түгел. Чын хуҗа көндәшлек-ярышта борыны белән җир сөрәчәк, ә бюрократ түрә "иптәш маузер сүзе" белән генә эшне башкарачак.

Россиядәге элекке һәм хәзерге вәзгыятьнең мәгънәсезлеге шунда: дәүләт үзенә хас булмаган, көче җитмәгән эшкә алына —халык тормышының иҗатчысы булырга тели. Ә асылда ул бары тик халыкның ил эчендә тыныч яшәвен, илдән тыш сугыш куркынычсызлыгын гына тәэмин итәргә тиеш; ул халык тормышындагы көнкүреш ихтыяҗларына булышырга, тиеш булмаганнарына чик куярга бурычлы. Шуннан артыгы кирәкми дә. Товар җитештереп чыгаруны оештыру — аның эше түгел. Дәүләт базарны үз күзәтүе астында тотса, шул җитә. Әмма бер шарты бар: дәүләт үзе җәмгыять күзәтүе астында булырга тиеш. Бу исә дәүләт милли байлыкка хуҗа булмаган очракта гына мөмкин эш. Дөньяның барлык демократик нигездә оешкан илләре шулай яши.

Хакимиятнең икътисадтан бары тик кыска вакытка гына өстен була алуы турында әйтеп үткән идек инде. Андый хәл революция җиңгәннән соң беренче чорда килеп туа. Ельцин-Гайдар-Чубайс командасы хакимияткә килгәч тә шулай булды — кискен һәм бик тиз генә "шок терапиясе" үткәрелде: бәяләрне "ычкындырдылар", дәүләт милкен ваучерлаштырдылар (әмма ул халык кулына эләкмәде), торакларны хосусыйлаштыру башланды, акционерлык ширкәтләре барлыкка килде. Халык зур югалтуларга дучар булып, бәяләрнең котырынып үсүе, акчаның арзанаюы, икътисадның җимерелүе, халык байлыгын урлау-талау киң күренеш алуга карамастан, башта бу реформа шактый тиз адымнар белән алга атлады. Нәтиҗәдә, вәгъдә ителгән хосусый милекче урта сыйныф урынына, дәүләт белән ышанычлы үрелеп, ярымҗинаятьчел финанс олигархиясе барлыкка килде, "демократ" Борис Ельцин җитәкчелегендәге команда аның колы-тоткыны булып калды. Олигархия — ул бер төркем эре монополистик капитал вәкилләренең сәяси һәм икътисади хакимлеге дигән сүз. Әгәр дә илнең киләчәгенә хакимиятнең карашы үзгәрмәсә, реформаларның алга таба үсеше дә шул юнәлештә генә булырга мөмкин. Ә бу хакимият дәверендә үзгәреш булуы бик шикле, берәр могҗиза-фәлән булса гына инде. Россиянең гомер-гомердән могҗизаларга ышанып яшәве юкка гына түгелдер, бәлки?

Халкының үзаңы бик түбән булган, тәмам бөлгенлеккә төшеп, эчкечелеккә бирелгән, рухи-әхлакый сыйфатларын бөтенләй диярлек югалтып бетергән бу "вәхшиләр илендә" мондый вәзгыять әле бик озак дәвам итәрдер шикелле...

Реформаларның төп максаты — киләчәктә гражданнар җәмгыятенең нигезе-төше булырдай хосусый милекче урта сыйныфка юл яру булырга тиеш. Әмма бу бурыч хәл ителмичә кала бирә. Халык социаль тотрыксызлык халәтендә. Вәзгыять сталинчыл бюрократиянең урта сыйныфны юк итеп, һәрнәрсәгә хуҗа булган тоталитар монополистик дәүләт төзегән вакытлардагыдан да яманрак. Сталин һәм аның иярченнәре үз тәгълиматларына ышанганнар һәм шуңа күрә, дәүләт көченә таянып, барлык киртәләрне ватып-җимереп үз максатларына барганнар. Хәзерге хакимиятнең исә нинди дә булса тәгълиматы юк

кына түгел, хәтта берәр юл күрсәтерлек гап-гади концепциясе — карашлары да юк. Дәүләт тә бөтенләй башка —шунлыктан, буталчык-болгавыр чорда төрле юллар белән тиз гене баеп киткән финанс олигархиясен авызлыклар мөмкинлеге булырына өметләнү кыен. "Президент арыды, еш авырый, биреше", — дип сөйләнәләр. Хикмәт анда гына булса икән! Ил алга китсен өчен ришвәтсез яши алырдай намуслы түрәләре булган хөкүмәт кирәк, ә хәзергеләр, ришвәтчеләр булу өстенә, дәүләт милке белән дә ничек теләсәләр шулай идарә итәләр. Халыкны урта сыйныф булдыру мөмкинлегеннән мәхрүм иткән хакимият, үзе дә сизмичә, олигархик капитал барлыкка килүен, киләчәктә хакимият тә шул олигархия кулына күчәчәген чамалагач, аптырап та, гаҗәпләнеп тә калды шикелле. Ә моның соңы халык канәгатьсезлегенең әле тетәп-пыскып кына яткан мәле бер мизгелдә дөрләп-кабынып, көчле ялкынга — яңа революциягә китерү белән тәмамланырга мөмкин.

Шул хәлләрне сизенепме, соңгы вакытта Борис Ельцин авызыннан да хосусый милекче урта сыйныфны булдыру турында сүз чыкты. Хөкүмәтнең бер киңәшмәсендә ул бу хакта Ирина Хакамадага (бу ханым нәкъ менә эшмәкәрлек, кәсәбәчелек һ. б. өчен җавап бирә) туп-туры әйтте: "Бу — сезнең бурыч", —диде. Сүз уңаеннан, кайбер мәгълүматлар китереп узыйк: әлеге урта сыйныф дигәнебез АКШта халыкның 75% тәшкил итеп, һәр кешенең уртача айлык кереме 35-40 мең долларга җитә икән; Японияда бу саннар — 80% һәм уртача айлык керем — 60 мең долларга кадәр. Россиядә исә әлегә халыкның 30%ы (ай-һай, алай ук бармы икән?) урта сыйныф булып исәпләнелә һәм уртача айлык керем 1-3 мең долларга җыела икән. Аерманы чагыштырып карагыз да, шуннан Россиянең хосусый милекче урта сыйныфының киләчәген күзаллагыз...

Алай да бу хакта Б. Ельцинның сүз кузгатуы, шуның өстенә хөкүмәтнең беренче вице-премьеры Б. Немцовның олигархиягә каршы көрәш ачарга җыенуы, ниһаять, Б. Ельцинның кинәт кенә хөкүмәтне куып таратуы (бу хәлләр 1998 елның март аенда булды) — болар бик кызыклы вакыйгалар. Көтик... Ни-нәрсә килеп чыгар?

Россия дәүләт тудырган сәяси шартларның бозык түгәрәгеннән һич кенә дә ычкынып китә алмый. Патша самодержавиесе тарих тарафыннан үлемгә дучар ителгән иде. Ул крестьяннарны ярты гасыр буена диярлек коточкыч зур түләүләр белән җир кисемтәләре — кишәрлекләр сатып алырга мәҗбүр иткән 1861 елгы реформа белән дә, егерменче гасыр башында крестьяннарны тагын да бөлгенлеккә төшергән Столыпин реформасы белән дә, — чөнки боларның һәр икесе җир хуҗасы итеп алпавытларны калдыра килде, — тулы канлы, күпмиллионлы урта сыйныф барлыкка китерә алмады. Оешып кына килүче аз санлы буржуазиянең кул-аягы феодал калдык булган алпавыт җир биләүчеләгә белән богауланган иде, хәзер исә җир дәүләтнеке булып исәпләнә һәм күбесенчә ташландык хәлдә ята бирә: үзебездә алабута үстерәбез, чит илләрдән алтынга икмәк сатып алабыз.

Шул рәвешле, ил-дәүләт үсеш-алгарышның дөнья дәрәҗәсеннән һаман да артка кала бара. Революция объектив котылгысыз, кирәкле гамәл иде, тормышка ашачак гамәл иде. Чөнки унтугызынчы гасырның соңгы утыз елыннан башлап 1917 елга кадәр җәмгыятьтә революцион-демократик партияләр барлыкка килгән, "буаны ерып җибәрердәй" көчләр пәйда булган иде. Болар арасында иң оешканы һәм иң максатчаны большевиклар партиясе булып чыкты. Аның социаль җирлеген люмпенлашкан пролетарийлар — эшчеләр һәм өлешчә һаман да ярлылана барган крестьяннар тәшкил итте, аларга солдатлар килеп кушылды. Әгәр дә большевиклар, феодаллардан тартып алынган

байлыкны үзләренекенә кушкан һәм аның бер өлешен вак буржуага (крестьяннарга һәм шәһәр мещаннарына) биргән көнбатыш буржуалары шикелле, үзләре хосусый милекче булып киткән булса иде, ул чагында башка социаль катламнардан чыккан эшлекле-булдыклы кешеләр белән берлектә алар Россиянең үсеш-алгарышын тәэмин итә алган булырлар иде. Һәм без бүген алга киткән башка илләрдән бер дә калышмас идек. Бер гасыр диярлек ара эчендә илнең төрле социаль катламнары бер-берсенә яраклашкан-килешкән булыр иде. Көнбатышта һәм Азиянең дә бер өлешендә шулай булган ич. Чөнки үсеш-алгарыш табигый рәвештә хосусый милекчелек юнәлешендә генә барыр иде. Әлбәттә, Сталин һәм аның өере таркатып ташламаган булса, НЭП һәм кооператив башлангычларда үсеп киткәндә, Россиядән дә бай һәм гадел төзелгән ил-дәүләт булмас иде. Ләкин, җәмгыятьне үзгәртеп кору бурычын хакимият кулы белән башкарырга тырышып, аны дәүләт өстенә йөкләп, большевиклар чын-асыл "үсеш-алгарыш субъектын" — урта сыйныфны шуның белән алыштырдылар. Ә дәүләт андый сыйфатлардан мәхрүм, ул урта сыйныфның ялган-ясалма алмашы гына була ала, тәрәккыятне "иптәш маузер сүзе" белән көчләп башкара башлый, димәк, нәтиҗәдә — җиңелү. Хәзер дә шул ук хәл. Ил белән һаман да бюрократ түрәләр идарә итә, алар — олигархия хезмәтчеләре. Бюрократия элек тә хосусый милекче урта сыйныфны тудыра алмый иде, хәзер дә шулай. Алар, халыкны һәм дәүләтне талап, алыпсатарлар һәм җинаятьчел финансчылар — "акча капчыкларын" гына ишәйтәләр һәм ахыр чиктә үзләре дә шулар кулында уенчык курчак хәлендә калалар.

Димәк, максатларның максаты — үзгәреш-реформаларны тизләтү, дәүләткә җәмгыять белән идарә итүчедән җәмгыятькә хезмәт итүче вазифасын үтәрлек демократик хокукый вәкаләт бирү. Юкса — һәлакәт. Бу уңайдан "патриот демократлар" кабул итмәстәй бер фикер әйтәм: Ельцин-Гайдар-Чубайс өере халыкны талады, үз кесәләрен шыплап тутырып, дәүләтне дөнья буйлап хәер сорарга этәрде. Оят вә хурлык! Халык аларны мәңге гафу итмәячәк. Әмма тормыш диалектикасы шундый: бер яхшының бер яманы, бер яманның бер яхшысы була. Болар, икътисадның шактый өлешен хосусыйлаштырып һәм шул рәвешле бюрократ түрәләр "тагарагындагы азыкны" шактый нык киметеп, монстр дәүләтне күпмедер дәрәҗәдә кысрыкладылар. Монысын Тарих галиҗәнапләре искә алмый калмастыр, бәлки. Хәзерге икътисад әллә нинди бер гарип-мутант: ул ярымхосусый, ярымдәүләти, ягъни ярымбернинди дә түгел. Бу сыйфатта ул озак яши алмаска тиеш. Гайдарлар-Чубайслар, аның әле урланып-таланып бетмәгән өлешен дә сатып-таркатып, "казна акчасына яшәүчеләргә — бюджеттагыларга түләргә кирәк" дигән сылтау белән аны бөтенләй "үтерерләр". Черномырдинның ай саен "җитештерү үсә башлады" дигән сафсатасы сай акыллылар өчен генә иде. Американнар вә немецлар белән берлектә Халыкара валюта фонды да "Кремльдәге дустына" һаман кесә ачып тормас: "дуслык дуслык белән — акча аерым булыр". Бигрәк тә хәзер, Черномырдин-Чубайс хөкүмәтен куып тараткannan соң. Шул рәвешле, халыкның яшәеш-көнкүренешен хәл итеп, тәэмин итеп торучы дәүләт милке бетерелер. "Гайдарономика"ның тарихи роле шул булыр. Алар эшчәнлегенең "яхшылыгы" да шул булыр. Әмма монысы — киләчәк буыннар өчен, ә безнең өлешкә исә бары тик "яманы" гына тия әлегә...

Шулай итеп, өстә сөйләгәннәрдән чыгып, урысның мәңгелек ике соравына — "Кем гаепле?" һәм "Нәрсә эшләргә?" дигән сорауларына җавап бирергә мөмкин, минемчә. Россиядәге бөтен азатлык хәрәкәте, дәүләтчелекнең асылын үзгәртеп, социаль-икътисади мәсьәләләрне хәл

итәргә тырышуга кайтып кала. Моны иң нәтиҗәле һәм чагыштырмача озак вакытка Октябрь революциясе хәл иткән шикелле. Әмма бу революция, дәүләткә милли байлыкларның милекчесе бурычын йөкләп, аннан гаять зур авторитар-тоталитар дәүләт ясады. Шуннан соң аның җимерелүе-таркалуы да башланды: тыштан караганда чәчәк атып торган бөек ил-дәүләт СССР эчтән черек иде. Шуңа күрә дә ул, кешелек тарихында күрелмәгәнчә, бер көн эчендә таралды да төште. Хәзерге иҗтимагый фикер (идарә итүче даирәләрнең "җырчыларыннан" кала) дәүләтне милли байлыкларга хуҗа булу һәм аны туздырып, әрәм-шәрәм итеп бетерү хокукыннан мәхрүм итү зарурилыгын алга сөрә. Әмма җәмгыятьнең күчеш чорындагы максатларын хәл итәрлек көче юк. Димәк, шундый көчләрне үстерергә кирәк.

Иң төп сорау: "Нәрсәдән башларга?" "Үсеш субъекты" булырлык урта сыйныф әлегә юк һәм якын киләчәктә генә булыры да күренми икән, эшне "буаны ерып җибәрерлек" көчләр туплаудан башлау зарурдыр. Тарихыбызның үткәненнән (унтугызынчы гасыр азагы-егерменче гасыр башлары) сабак алсак, җәмгыятьнең иң түбән баскычына төгәри барган демократик зыялыларыбыз шундый көчне төшкил итә алырлар иде. Мин биредә хакимият башыннан сыйпап иркәләтелгән зыялы элита — сайланып алынган "бәхетлеләр" турында сүз йөртмим. Сатып алырга мөмкин булмаган күпмиллионлы зыялыларны — әдәбиятчылар, журналистлар, галимнәр, укытучылар, табиблар, юристлар, инженерлар һ. б. ишеләрне күз алдында тотам. Аларга, акыл хезмәте кешеләре буларак, үзләренең шәхси һәм социаль мәнфәгатьләре белән инде башкалардан аерылып торган зур бер социаль катлам булып оешып җитүләрен, ниһаять, аңларга вакыттыр. Вакланып-бүгәләнеп, башка сыйныфларның мәнфәгатен яклый-яклый, төрле сәяси партияләрнең хезмәтчесе булып яшәүдән арынырга кирәктер.

Җәмгыятьнең үсеше-тәрәккыяте, дөресрәк әйткәндә, кешелекнең яшәеше турыдан-туры аң-белем үсешенә бәйле, дигән фикер күптән исбатланган. Кайчандыр фараз кылынган ахырзаман әллә кайда еракта түгелдер, аның якын киләчәктә булуы бик мөмкин һәм аны кешеләр үзләре китереп чыгара да алалардыр: беренчедән, дөньяның күпчелек илләрендә, бигрәк тә Россиядә социаль киеренкелек гаҗәп көчәеп килә; икенчедән, экологик һәлакәт булуы да бик ихтимал. Шуңа күрә, зыялыларга, әле хакимияткә, әле "гегемонга", ягъни коммунистларга хезмәт итүдән баш тартып, кичекмәстән үз мәнфәгатьләрен һәм җәмгыять мәнфәгатьләрен кайгыртa башларга вакыт. Академик Н. Моисеевның бер фикере бик кызыклы: Россиядәге җәмгыятьнең киләчәк үсеш мәсьәләләрен тикшереп өйрәнердәй бер иҗтимагый оешма төзү фикере. Бары тик шул очракта гына үз ватаныннан куылып, даими эзәрлекләнеп килгән, буталчык-болгавыр заманнарда иң беренче чиратта корбан ителә торган зыялылар — интеллигенция үз урынын табачак, аның җәмгыятькә кирәге чыганак. Түбәнсетү-кимсетүле караш хакимияттә генә булса, бер хәл иде, зыялылар да үз чиратында хакимияткә шундый ук мөнәсәбәттә бит. Юк, хакимият бу яман эш-гамәлләрен үзе томаналыкка дучар иткән халык массалары ярдәмендә, аларның сүгенү-сызгырынуларына кушылып алып бара. Халык өчен янып-көеп йөргән, "народниклар" дип тарихка кергән зыялылар узган гасыр азагында шулай таркатыла, 1907-1910 елгы реакция чорында да шул ук хәл кабатлана, аннары большевиклар җәмгыятьнең каймагы булган иң затлы иске зыялыларны кыра, совет зыялылары да мескен бер хәлдә иделәр, бүгенге зыялылар исә алардан да кызганыч: мәдәният, фән, мәгариф һ. б. үлеп бара, зыялылар, аптырагач, гаҗизлектән ачлык игълан итәләр, академиклар протест йөзеннән атылып үлә, эшче-крестьяннар дәшми-тынмый карап

тора... дияр идек, үз хәлләре — хәл... Әйе, гавам белән зыялыларның үзаңы вә мәдәни үсеше арасында аерма — җир белән күк арасы. Әмма бу әле мәсьәләнең бер ягы гына һәм, бәлки, бик мөһиме дә түгелдер.

Иң төп мәсьәлә — илдә әйдәп барырдай, иләмән булырдай демократик шәхесләр юклыгында. Сталин өере иң асыл затлы зыялыларны кырып бетергәннән соң, ил менә ничә дистә еллар инде чын илбашларына, чын юлбашчыларга кытлык кичерә. Шуның аркасында, үзгәртеп кору-реформалар демократиясе, антикоммунистик максатлардан чыгып, КПССның болай да бик белекле булмаган җитәкчеләре арасыннан тагын да наданрак, әмма демократия ягына авышырдайракларын сайлап алды. "Ит булмаганда — үпкә тансык", — дигәндәй булды инде бу.

Димәк, зыялыларның иң беренче бурычы — үз сәяси партияләрен булдыру. Шул рәвешле, аерым сыйныфларның киләчәктәге җитәкчеләре түгел, ә барлык Россия халыкларының җитәкчеләре — әйдәп баручылары булырлык шәхесләр сәяси эшчәнлек мәктәбе үтәрләр иде.

Ниһаять, мәсьәләнең өченче ягы — акыллы идея-фикерләрдән тыш, аларны хакимияткә иңдерерлек, ә хакимият аны тормышка ашырырлык сәяси көч булу зарур. Мондый партия, беренчедән, үзенең аңлату-агарту һәм оештыру эшчәнлеге белән ил-халыкның, коммунистлар коткысына бирелеп, яңа революция-контрреволюцияләргә кереп батмавын тәэмин итәр иде. Даими хыянәт итеп торсалар да, коммунистлар төрле сул партияләр белән берләшергә гаять осталар. Ленин әйтмешли, "шайтанның әбисе булса булсын, тик революциягә генә хезмәт итсен". Коммунистик һәм аңа тугандаш булырдай партияләрнең икенче мәртәбә сәяси мәйдан тоту куркынычы бик зур. Хәзерге хөкүмәтнең рәтсез-юньсез эшчәнлегенә каршы без ниндидер акыллырак һәм мәгънәлерәк эш-гамәл белән җавап бирергә тиешбез. Икенчедән, демократик зыялылар партиясе үзе тәрбияләп үстергән демократларның илне халык мәнфәгатьләренә туры килерлек итеп тәрәккый иттерердәйләрен хакимият оешмаларына сайлауларда халык тарафыннан сайлауларын тәэмин итәр иде.

Демократик зыялылар партиясе төзүне максат итеп куйганда большевиклар партиясенең тарихи тәҗрибәсен, ачы сабагын онытмаска кирәк: ватанпәрвәр зыялылар оештырган большевиклар партиясе соңыннан үз халкын үзе юк итү юлына баскан тоталитар көчкә әйләнде. Ни өчен шулай булды соң? Партия сафларына төрле социаль катламнар кереп тулганлыктан, эшче-крестьяннар һәм солдатлар партиясе үзеннән-үзе "солдат партиясе" булып калды, большевизм казарма мантыйгын, аның алымнарын үзләштерде, аның яман гадәтләрен, зарарлы максатларын үзенеке итте. Шул рәвешле, "иптәш маузер сүзе" законны алыштырды.

Димәк, демократик зыялылар партиясе һәрвакыт үзара килешеп эшләргә сәләтле, югары белем-зәвыклы шәхесләрдән генә торырга тиеш. Кагыйдә буларак, бюрократ түрәләргә аның ишекләре ябык булу шарт. Бары тик шулай гына.

Бу партия нинди юнәлештә эш алып барырга тиеш соң? Беренче чиратта, ил-халык байлыгын талауны туктатырга һәм түрәләр, һәртөрле намуссызлар үзләштергән милекне кайтарып алырга бурычлы булыр ул. Шул ук вакытта аның аңлату-агарту эшчәнлеге халык аңыннан милекчелеккә булган тискәре карашны кырып ташлауга, милеккә, аерым алганда, намуслы хезмәт белән баеган милек хуҗаларына хөрмәт тәрбияләүгә юнәлтелгән булырга тиеш. Табигый ки, бу партия җәмгыятьне үзгәртеп кору, халыкның күпчелеген ялланып хезмәт итүчеләрдән милекче урта сыйныфка әверелдерү программасын эшли башлаячак. Чөнки, әйткәнебезчә, бары тик урта сыйныф кына

үсеш-алгарыш, тәрәккыят итәрлек көч була ала.

Минем әле сиксәненче еллар азакларыннан ук тәкъдим итеп килгән карашларым, үз концепциям бар. Аның асылы болай: Россия халкының үзаңындагы коллективчылык хисен хосусый милекчелек хисе белән берләштереп, аларның табигый кушылмасына ирешергә кирәк. Менә бу фикер демократик зыялылар программасының бер варианты була алыр иде.

Фән, мәгариф, гомумән, мәдәниятнең көче гаять зур. Бу өлкәләрдә үсеш, һичшиксез, бик әһәмиятле. Халыкларның имин киләчәге кешеләрне шәхес буларак тәрбияләүгә, шулай тәрәккый иттерүгә бәйле. Әмма аң-белем үзлегеннән барлыкка килеп үсә алмый. Ул милекчелек мөнәсәбәтләренә, шуңа ярашлы дәүләт төзелешенә, иҗтимагый фикер-карашларга тулысынча буйсынган, күпчелек халыкның социаль-икътисади дәрәҗәсен чагылдырган, шул рәвешле җәмгыятьнең социаль тотрыклылыгына ирешкән очракта гына ачык чагылыш таба ала. Җәмгыятьнең тотрыклы үсеше күпчелек ярлыланып, алар хисабына азчылык баюга нигезләнгән милекчелек мөнәсәбәтләрендә була алмый. Җәмгыятьнең тотрыклы үсеше — мәдәниятнең, фән-мәгарифнең, югары фәнни технологиягә нигезләнгән ысул-процессларның туктаусыз тәрәккый итүе дигән сүз ул. Димәк, үзаңы җитлекмәгән, аң-белем дәрәҗәсе түбән булган халык белән һәм артка калган фән, искергән технологияләр белән алга барып та булмый.

Иң беренче бурыч — милекчелек мөнәсәбәтләрен шундый итеп оештырырга кирәк ки, алар шәхесне ирекле-азат итсен, шәхес дәүләткә яки берәр хуҗага матди бәйле булмасын, тормыш төбенә ыргытылмасын. Матди бәйлелектән котылган ирекле-азат гражданнар җәмгыяте үзе үк фән-мәгариф, мәдәният һ. б. хакында тиешенчә кайгырта башлаячак. Бу җәмгыять үзенең бетмәс-төкәнмәс ихтыяҗларыннан артып калган тиеннәрне генә аңа ыргытучы дәүләткә, хөер теләнеп, кул сузып утырмаячак инде. Ул үзе хуҗа булачак.

Совет хакимияте чорында ул хакимияткә каршы көрәшерлек, аны ташламалар ясарга мәҗбүр итәрлек сыйныф барлыкка килә алмады. Шунлыктан яңа хакимияткә дә шул ук партия кешеләре килде, әмма болары "демократик" аңлылар һәм кирәкле сыйныфны булдырырга тырышалар, янәсе. Имеш, алар урта сыйныфны булдыруны тизләтергә омтылалар. Ләкин, монысы, имеш, булмастай эш, чөнки әле тарихи процессларны беркем дә тизләтә алмаган. Кайбер сәясәтче публицистларның фикере өнә шундый. Тарихи процессларны тизләтергә була һәм, бу очракта, Россия кебек артка калган илне алга киткән илләр үрнәгендә "куаларга" кирәк тә. Хәзерге реформаторлар гына үсеш-алгарышта бөтен чор-этапларны үтеп, башта башлангыч капитал — байлык туплап, аннары аны тизләтелгән рәвештә монополистик-олигархик капиталга әйләндерергә омтылалар. Гайдар-Чубайс реформаларының уңышсызлыгы гражданнар җәмгыятенең нигезе-төше булган урта сыйныфны тизләтелгән ысул белән булдыру котылгысыз икәнлекне искәртә. Әмма шунысы бар: гомер бакый ач-ялангач Россия халкы байларны яратмый, ул аларга нәфрәт белән карый. Шуңа күрә без: "Кол булып калсак калабыз, әмма хөерче булсак та — бертигез булабыз!" — дигән шигарь-лозунглар белән яшәргә күнеккәнбез. Димәк, хосусый милекче урта сыйныф Америка, Японияләрдәге кебек үк күпчелекне тәшкил итәргә тиеш булачак. Димәк, кешеләрне мал-мөлкәтле, мул-имин тормышта яшәрлек итү бурычын турыдан-туры, "маңгайга бәреп" майтарып булмаячак. Әйләнеч юллар үтәргә кирәк булыр. Моның кыенлыгы шунда — халыкка кемдер яшәү-тормыш итү шартларын алдан әзерләп куярга тиеш түгел, киресенчә, халык үзе үзенә яраклы социаль, икътисади, сәяси һәм хокукый нигезләрне

билгеләп-сайлап, үзенең эшчәнлеген шуларга таянып җәелдерергә тиеш булачак. Башкача булса, ул янә дәүләт кулына карап, шуңа өметләнеп торачак. Суга кермичә йөзәргә өйрәнеп булмый.

Мин Россиянең үсеш сыйфатларын, алшартларын тамырдан үзгәртердәй социаль юнәлешле реформа тәкъдим итәм. Ул Көнбатышның алга киткән илләре сафына барып кушылырга мөмкинлек бирердәй, аннары социаль мәсьәләләрдә тагын да алга атлардай яңа тарихи юл булачак. Без гадәти булмаган теоретик адым ясарбыз, яңа тәгълимат ачарбыз, шуның нигезендә халык өстән оештырылган революцияләрсез-нисез генә үз тормышын үзе теләгәнчә корыр. Моның чыганагы бер генә — милли байлыкны индивидуальләштереп, гражданнарның хосусый милекче булып җитлегүе. Башка чара юк.

Безнең барлык милли байлыгыбыз исәпкә алыначак. Аннары һәр гражданның башлангыч "бәясе" билгеләнер — җир-суларны, урманнарны, җир асты байлыкларын һ. б. кертеп, барлык милли байлыктагы үз өлеше аныкланыр. Социаль гаделлек җәһәтеннән караганда, һәр гражданга аның "бәясенә" торырлык ваучерны (яки банктагы шәхси исәбен ачып) түләүсез бирү дөресрәк булыр иде. Әмма безнең халыкның бушка килгән малны әрәм-шәрәм итеп бетерү гадәтен истә тотсак, әлеге өлешне арзан гына бәһагә, ә сатып алырга мөмкинлеге булмаганнарга бик аз процентлы кредитка бирү, мөгаен, максатка ярашлырак булыр. Бу кыйммәтле кәгазь яки банктагы шәхси исәп Үзәк Банк тарафыннан "тере" акчалар белән гарантияләнеп, милек хуҗасы аны йә акцияләр сатып алырга, йә берәр эш башлап җибәрергә генә тота алырга тиеш. Акцияләр алса, милек хуҗасы дәүләт предприятиеләрен үстерүгә-яңартуга, яки яңаларын төзүгә үз өлешен кертүче инвестор була һәм алынган табыштан үзенә тиярен алып яши башлый. Инде үзе берәр эшмәкәрлек-кәсәбәчелек эше башлап җибәрергә уйласа, ваучеры (банктагы исәбе) янына үзе туплаган сумнарын да кушып яки банктан кредит алып кына эшли алырга мөмкин булыр. (Бу хакта тулырак мәгълүмат минем "Откуда и куда идешь, Россия?" дигән китабымның 9 нчы бүлегендә бирелә. Мәскәү, 1996.)

Мин тәкъдим иткән бу программа нәрсәләр бирә соң?

**Беренче.** Милектәшләр булу концепциясе азчылыкның баеп, күпчелекнең бөлгенлеккә төшеп рухи-әхлакый таркалуына —шуның нәтиҗәсендә башлангыч капитал туплау чорында котылгысыз революцияләр килеп чыгуга кайтып кала торган каһәрле түгәрәк-әйләнешкә чик куячак. Мәсьәлә шунда ки, милекне һичбер төрле монополияләштерү, ягъни аерым бер тар төркем кулында туплау, шулай итеп халыкның пролетарлашуы-ярлылануы булмаска тиеш. Ә бу бары тик милекнең бер өлешен, йөгәнсез көндәшлек, көрәш-ярыш кәсафәтләреннән аралау йөзеннән, базар әйләнешеннән һәм мирас итеп бирелүдән аерып алып калган очракта гына мөмкин. Бу өлеш гражданны тормыш төбенә төшүдән саклап калырлык кагылгысыз керем чыганагы булыр. Әмма ул кем дә булса бер эш эшләмичә ашап кына ятарлык зур да булмас. Ил хуҗалыгында хезмәт процессына катнашмаганда, гражданның милли байлыктагы өлеше тиешле дәрәҗәдәге тормыш шартларын тәэмин итә алмаячак. Һәркемнең милли байлыктан үзенә тигән өлешен әнә шул кагылгысыз керем чыганагы итәргә кирәктер, бәлки. Ә инде гражданның үзе эшләп тапканын шуңа өстәп үстергән кадәре базар әйләнешенә һәм мирас итеп бирелүгә дә тотыла алыр иде. Бәлки, шул рәвешле, Льюис Г. Морганның фараз кылып әйткән фикерен тормышка ашырырга мөмкин булыр. Ул болай дигән: "Бер көн килер, кешe акылы байлык өстеннән хакимлек итәрлек дәрәҗәгә ирешер, ул дәүләтнең үзе саклап торган милеккә мөнәсәбәтен дә,

милекчеләрнең хокук чикләрен дә билгеләр. Җәмгыять белән аерым шәхесләр арасында гадел һәм үзара килешкән-ярашкан мөнәсәбәтләр урнашыр". Икътисадны моңа кадәр булган һәм хәзер дә яшәп килүче системалардан тамырдан аерылып торган яңа ысул-алымнар белән оештыруны тәкъдим итүебезнең төп хикмәте дә әнә шунда дип уйлыйк.

**Икенче.** Яшенә, җенесенә, эшләмә-эшсезме булуына карамастан, һәр граждан хосусый милекче була ала. Ясалма тигезләүләрсез тигезлек, милли байлыкны бүлүдә социаль гаделлек барлыкка килә. Бүген бу мәсьәлә чиктән тыш катлаулы һәм четерекле әле.

Бездә кешеләрнең иркен-мул тормышы ике чыганактан хасил була ала: 1) шәхси куллану фонды һәм 2) җәмәгать куллану фондыннан. Әгәр беренче очракта аның аерымлыклары, дәрәҗәсе һәркемнең хезмәтеннән чыгып, азмы-күпме шәхеснең үзенә бәйле булса, икенче очракта ул шәхескә дәүләт тарафыннан көчләп диярлек тагыла һәм шунлыктан гадел дә түгел. Әйтик, мәгариф, сәламәтлек саклау, йорт-җирләрне төзекләндерү, юллар салу, экология мәсьәләләре һ. б. тотыла торган чыгымнар күләме белән дә, сыйфаты белән дә төрле төбәкләрдә төрлечә була. Шуңа күрә җәмәгать куллану фонды хисабына гражданнарның ихтыяҗларын канәгатьләндерү дә бик чуар, төрлечә килеп чыга. Халыкның кайбер катламына бөтенләй өлеш калмый диярлек (крестьяннар, мәсәлән, бу фондтан шәһәр халкына караганда чама белән ике мәртәбә кимрәк файдалана). Җәмәгать куллану фонды бушлай булгач, димәк, көндәш-конкуренциясез аның яшәргә сәләте дә юк. Бүген гади халыкның: "Сәламәтлек саклау һәм иң әйбәт уку йортларында белем алу бары тик байлар буе гына җитәрлек булып кала", — дип аһ орулары нигезсез түгел. Чөнки гасырлар буена халык кулы белән тупланган милли байлыкның күп өлеше "яңа урысларга" — яңа байларга күчеп бетте, ә мал-милексез халык берниндн матди ярдәмсез, шымытыр тотып калды. Һәлакәт чигенә килеп җитә язуыбызның, мәдәниятнең барлык тармаклары таркала баруның мөһим сәбәпләреннән берсе җәмәгать куллану фондына өметләнеп яшәүдәдер. Партсовноменклатура үзенең комсыз ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, әйләнеч юллар табып, юкка гына "спецсанаторийлар", "спецхастаханәләр", "спецкибетләр" һәм тагын әлләникадәр башка "спецлар" — үзе өчен махсус мөмкинлекләр оештырмаган инде. Горбачевның "үзгәртеп корулары" башлангач, күп кенә "демократлар" шул өстенлекләргә каршы көрәшүчеләр булып танылдылар, шул дулкында яңа "тәхеткә" үрмәләделәр һәм... өстенлекләрен ("спец"ларын!) тагын да үрчетеп җибәрделәр шикелле. Моннан шундый нәтиҗә ясарга кирәктер: җәмәгать куллану фонды бары тик шәхесләргә бүленмәс тармакларга гына, әйтик, илне саклау өчен армиягә, халыкның тыныч-имин тормышын тәэмин итәр өчен милициягә, экологияне саклауга һ. б. гына тотылырга тиеш. Калган бөтен нәрсә сату-алу аша базар мөнәсәбәтләре белән хәл ителергә тиеш. Әгәр дә һәркем милли байлыктан үзенә тияр өлешне гадел алса, аның шәхси ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлеге дә артачак. Шул ук сәламәтлек саклау һәм белем бирү өлкәсендә моны, мәсәлән, махсус ваучерлар-чеклар белән хәл итеп булыр иде. Медицина ваучерлары һәр гражданның кулына бирелә, кирәге чыккан кадәресе тотыла бара, ә тотылмаган өлеше ел саен турыдан-туры гражданның шәхси пенсия фондына күчерелә. Уку-белем алу ваучерлары да шулай тотылып, артып калганы дәүләткә яңадан кайтарыла.

**Өченче.** Милеккә ия булган кеше шәхес буларак үзен күрсәтергә, үзенә генә хас асыл сыйфатларын ачарга матди мөмкинлекләр ала, сәләтен үстерә. Ул үзен-үзе һәрвакыт тәэмин

итәрлек була. Башкача яшәү мөмкинлеге булмаганлыктан, мәҗбүри рәвештә ялланып эшләргә дучар ителгән эшче куллар (ялчылар) бетерелә. Шулай итеп, җәмгыятьтәге иң яман күренешләр юкка чыгарыла. Дәүләт милке белән идарә итүче түрәләр җитештерү көчләренә һәм җитештерелгән мал-мөлкәткә мөнәсәбәттә калган барлык гражданнар белән тигезләштерелә. Идарәчеләр һәм идарә ителүчеләрнең мөнфәгатьләре арасындагы мәңгелек каршылыкның матди нигезе юкка чыгарыла: һәркем бер үк вакытта хуҗа да, хезмәткәр дә булып кала. Икътисадта бюрократия бөтенләй кирәксезгә әйләнә, ә хуҗалык эшләренә катнашы булмаганнары нык киметелә. Шулай итеп, бюрократ түрәләргә каршы куярлык демократик көчләр туплана, түрәләр исә бары тик сайланып кына куела яки акционерлар тарафыннан яллана, димәк, үз милектәшләре алдында хисап тотарга тиеш була; икенчедән, түрәләрнең дә үзләре идарә иткән икътисад өлкәсендә матди мөнфәгатьләре барлыкка килә, чөнки аларның үз милекләренең дә бер өлеше шунда салынган була. Нәтиҗәдә түрәләрнең үзеннән өстә утыручыларга ярарга тырышуы да бетә, ике арадагы каршылыклар юыла. Барысының да мөнфәгатьләре бер булып кала.

**Дүртенче.** Хосусый милекчелек белән яраклаша алмаган дәүләт хуҗалыгы һәрвакыт монополистик була, аннан аермалы буларак, хосусый милекчелеккә нигезләнгән икътисадның күп төрле формалары барлыкка килә: акционерлык җәмгыятьләре, кооперативлар, ширкәтләр, гаилә милкенә нигезләнгән эш-шөгыльләр, шәхси хуҗалыклар һ. б. Алар үзәкләштерелә дә алмыйлар. Дәүләт милкенең күпчелеген, аерым шәхси милекчеләргә бүлгәләмичә, бөтенлеген саклап халык (акционерлар, ширкәтләр) милкенә әйләндерү хосусый милекчелек мөнәсәбәтләрендәге тискәре күренешләргә чик куяр, үзенә күрә бер ышанычлы кирттә булыр иде.

**Бишенче.** Матди байлыклар җитештерү өлкәсендә эшләмәүче гражданнар (укытучылар, табиблар, галимнәр — кыскасы, зыялылар) үзләренең милли байлыктан алынган башлангыч өлешләрен теге яки бу эшкә (бизнеска) салып, анык бер бәйләнештә тора алырлар.

**Алтынчы.** Хәзер милләтара мөнәсәбәтләрдә һәм хәтта урыс төбәкләрендәге җирле җитәкчеләр белән Үзәк арасындагы мөнәсәбәтләрдә дә үзәктән качучы көчләр шытып чыкты. Бу хәл Үзәктә дә, төбәкләрдә дә икътисади тотрыксызлык булудан гына килеп туган хәл түгел, ул әле төрле төбәкләрнең табигать шартлары аерымлыгына, җитештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсе төрле булуына да бәйле күренеш. Икътисадны мин тәкъдим иткән алшартларда оештыру ил гражданнарының, кайда яшәүләренә карамастан, гомуми милли байлыктан бертигез башлангыч өлеш алуларына нигезләнеп, матди мөмкинлекләрен дә тигезли. Бер ил — бер үк башлангыч мөмкинлекләр. Ләкин хезмәткә мөнәсәбәт, җитештерү ысулларына һ. б. бәйле аерымлыклар да кала. Һәм бу аерымлыклар төбәкләрнең үзара ярышуына, халыкларның бер-береннән көнләшеп эшләвенә этәргеч, дәртләндерүче-кызыктыручы сәбәп була ала. Халыкның иркен-мул тормышта яшәү чыганагы хезмәт, оста хуҗалык итә белү булыр. Табигать шартларына сылтап яки бюрократ түрәләр билгеләгән өстенлекләрне күтәп утырулар бетәр. Кайсы гына төбәктә яшәсә дә, халыкның тормыш-көнкүреш дәрәҗәсе анык үз эшчәнлегенә бәйле булып калыр.

**Җиденче.** Эшләгән кешенең дә, пенсионерның да милек өлеше өзлексез хәрәкәттә булгач, янә бер әһәмиятле социаль мәсьәлә хәл ителә — җәмгыятьнең имин-мул тормыш дәрәҗәсе үсә барган саен пенсионерларның да матди хәле яхшырганнан-яхшыра бара, ул хакимият карарлары белән эшләнми, ә турыдан-туры эшләнә.

**Сигезенче.** Һәркемнең кереме хәрәкәттә — кешенең хезмәтке салган көченә бәрабәр рәвештә генә түгел, ә милли байлыктагы үз өлеше күләменә дә карап даими үзгәреп торганлыктан, аны туктаусыз үстерүгә юнәлтелгән шәхси мәнфәгать барлыкка килә. Бу мәнфәгать башкаларныкына кушылып гомуми мәнфәгать тууга ярдәм итә. Милекче милли байлыктагы үз өлешен һаман да ишәйтергә тырыша, шул рәвешле аны арттыра бара. Шулай итеп, барлык мәнфәгатьләр берләшеп, җәмгыятьнең һәр күзәнәгенә үтеп керерлек бербөтен көчкә әверелә.

**Тугызынчы.** Гражданнарның барлык милли байлыкка ия булган хосусый милекчелеге халыкның, бигрәк тә сәләтле-талантлы зыялыларның чит илләргә күпләп чыгып китүләрен туктатачак. Алай гынамы соң, киткәннәр дә кире әйләнеп кайта башлаячак әле. Ватанпәрвәрлек хисе халыкта яңадан дөрләп кабыначак. "Патриот" сүзенең башлангыч асыл мәгънәсе — "милек буларак Ватан" дигән сүз бит (П. Струве).

**Унынчы.** Милек, мал-мөлкәт — җаваплылык ул. Милекченең психологиясе ялланып эшләүченекеннән нык аерылып тора. Ялланган эшче-хезмәткәр азрак эшләп, күбрәк алу ягын каерса, милекче тырышып эшләп, сакчыл булып үз мөлкәтен арттырырга-ишәйтергә омтыла.

**Унберенче һәм соңгысы.** Әмма әһәмиятсезе түгел: гражданнарның милли байлыктагы башлангыч өлеше милли байлыктан да, милекченең үзеннән дә (хәтта үзе тарафыннан да!) аерып алына алмаганлыктан, күпсанлы хосусый милекче урта сыйныф булдыру җиңеләя. Урта сыйныф исә — "үсеш субъекты". Безгә нәкъ шул кирәк тә!

Кызыл тоталитаризмны көрәненә яки Ходай белсен тагын ни төслесенә алыштыруны булдырмауның бердәнбер юлы — коммунистик чордан соңгы ил-дәүләтне милекчеләр җәмгыятенә әйләндерү. Тәрәккыяткә-алгарышка хәрәкәтнең, табигый демократик хокукый дәүләткә күчүнең башка юллары юк. Башкалары — артка... Барлык бәла-казалары белән үткәнгә кайту гына булачак.

Россия халкы гомер-гомердән кол хезмәтендә. Әмма хәтта совет хакимияте дә аңа, очын-очка ялгап торырлык булса да, хезмәтенә даими түләп килә иде. Ә хәзерге хакимият айлар буе, кайбер очракларда еллар буе хезмәт хакы түләми. Хакимият башындагыларның тагын бер кабат исләренә төшерергә туры килә: безнең агай нык түзем-түземен, аны "озак җигә, тиз юырта" дибез, хәерчелеккә-бөлгенлеккә төшеп, ач-ялангач калганнан соң, түземе төкәнгәч, бу агай, үзенеке булмаган бөтен нәрсәне кырып-яндырып, гаеплесен дә, гаепсезен дә тетеп салырга да күп сорамас. Аны шундый итеп Россия дәүләте тәрбияләгән. Бу агайны мал-мөлкәтсез ярлы-ябагайлыктан йолып алырга, хосусый милекче урта сыйныф итеп үстерергә кирәктер.

Әлбәттә, соңгы елларда халык байлыгының байтагы юк бәягә сатылып, урланып юкка чыкты... Шулай да әле калган кадәре дә иҗтиһат итүгә йөз тоткан күпсанлы урта сыйныфны барлыкка китерергә җитәрлектер. Шулай түгелме, олигарх әфәнделәр һәм токсын сыйфатында аларны каплап-ышыклап торучы Кремль түрәләре?! Уйланыгыз — әле соң түгел. Ходайның бер бирмеш көнендә, — өлгерә алсагыз! — чит илләргә чыгып сызарга туры килмәгәе. Ватанның татлы да, рәхәт тә исләреннән, иркәләүче җилләреннән мәхрүм калырсыз бит. Кылган җинаятьләрегез өчен күпләрегезне Интерпол (халыкара полиция) эзли башласа, "чит ил безгә булышыр" дип утырырсыз аннары. Әле бит анда — сез таясы чит илләрдә, диюем — үзебезнең урыс мафиясе дә бик котырына, дип сөйлиләр. Уйланыгыз — әле соң түгел...

*Мәскәү. 1998 ел*

*Сәнгать*

# ТЕАТРЫБЫЗНЫҢ ӘҺӘМИЯТЕ ХАКЫНДА

Юбилейлар узгач

1996 елда җәмәгатьчелегебез татар театрының 90 еллык бәйрәмен билгеләп үтте. Бу вакыйга ерак булмаган киләчәктә безне тагын да зуррак бәйрәм көтүен искә төшерде: күз ачып йомганчы йөз еллык та килеп җитәчәк икән... Шуңа күрә хәзер, туксан еллык уңаеннан күрелгән кайбер чараларга кыскача йомгак ясап, алда торган бурычларны билгеләү артык булмастыр кебек. Сүз гомумән сәхнә сәнгатебезнең — театр спектакльләре булсын, эстрада концертлары булсын — тоталитар тәртипле совет шартларында гамәлдә булган, дөресрәге тормышка ашырыла килгән үзенчәлекле бер хосусыяты хакында бара. Ул — сәхнәгә чыккан тамашаларның цензор чикләүләреннән чагыштырмача иреклерәк булу мәсьәләсе.

Мәгълүм булганча, 20 нче елларның урталарыннан алып, рухи дөньябызның төрле тармаклары цензура кысуларына —төрлечә чикләү, кисеп ботарлау, тулаем тыюга — дучар ителгән иде. Солтангалиевчелеккә каршы большевистик көрәш, репрессияләр башланудан алып, саклык, "тыйнаклык" рәвешендә барлыкка килгән авторларның "үз цензурасына" (үз-үзен чикләүләргә) "җаваплы" редактор белән главлит әһелләренең кайчылары, кусәкләре дә өстәлгән иде. Елдан-елга, буыннан-буынга цензорларның надан-лана һәм кырыслана баруы аркасында совет халыкларының әдәбиятлары (татарларныкы бигрәк тә — татар әдипләренең зур күпчелеге "солтангалиев-челек"тә гаепләнүен дә искә төшерик), фикер мөстәкыйльлегеннән мәхрүм калып, тәмам төссезләнгән иде. Идеологиядәге "берфикерлелек" үләт кебек сарылудан вакытлы матбугатыбыз да бөтенләй йөзсезләнгән, тешсезләнгән иде. Моның барысы да халыкны үзенең кешелек дәрәҗәсен тоюдан, милли хистән, фикер хөрлегеннән аеруга "хезмәт итте". Нәтиҗәдә — милли аң, тарихи традиция тамырларына кат-кат балта чабылды. Халыкның зур күпчелегендә рухи пессимизм, милли нигилизм хисләре көчәеп, милли мәнфәгатьләргә карата битарафлык мөнәсәбәте хасыйл булды. Бу иң элек туган телнең кулланылыш мәйданы тараюда, иҗтимагый хаҗәте кимүдә чагылды.

Шул рәвешчә, фикер буларак тәмам төссезләнгән, рухсызланган (күпчелек очракта ялган пафослы "иллюстративлыкка" тарыган) әдәбият оешты. Каты итеп сүгенә алса да, фикри мөстәкыйльлек җәһәтеннән бөтенләй тешсезләнгән вакытлы матбугат бер урында таптанып калды. Ниһаять, милли рухы, тарихи һәм гуманистик традицияләре төптән печелгән, бары тәгәл һәм табигый фәннәрдә генә үз йөзен саклап кала алган мәктәп системасы барлыкка килде. Менә шушы шартларда бары сәхнә сәнгате генә азмы-күпме дәрәҗәдә үзенең мөстәкыйльлеген саклап кала алды, дип расларга мөмкин.

Болай дип әйтү белән мин сәхнә әсәрләренең текстларын түгел (пьесалармы, җыр-скетчлар, конферансье чыгышларымы —барыбер), бәлки теләсә нинди әсәрнең башкарылу үзенчәлеген, ягъни артистның осталыгын —

үз-үзен тотышын, сөйләү стилен, хис тудыра алуын, хәтта интонацияләргә дә мәгънә бирә алу сәләтен күз уңында тотам. Чөнки теләсә нинди әсәрне сәхнәдә башкаруның цензура-чикләүләргә буйсынмый торган үз хосусыятлары — үтемле, мәгънәле итеп башкарылу мөмкинлекләре бар һәм булыр. Бары артист осталыгы белән барлыкка килә торган хикмәтле мөмкинлекләр. Язма текстны, матбугат әсәрен басылып чыкканчы, ягъни игълан ителгәнче һәръяклап кискәләргә, өтекләргә, хәтта "йолкып ташларга" да мөмкин. Ә сәхнәгә чыгып, тамашачы каршына килеп баскан артистның мөмкинлекләрен чикләү цензораларның да кулыннан килә торган эш түгел, чөнки сәхнәгә чыгып өлгергән башкаручының осталыгы, омтылышы атылган ук төсле икенче халәттә яши башлый. Яңгырап өлгергән сүзләрне, кыю әйтелгән фикерләрне яңадан кире артист авызына кертеп, томалап куеп булмый ләбаса!..

Сәхнә сәнгатебезнең икенче объектив өстенлеге дә бар иде. Ул — милли мәктәпләр ябылып, татарча китаплар елдан-елга азрак таралган, халкыбызның күпчелеге үз ана телендәге матбугатны иркенләп уку мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән елларда барлыкка килгән бушлыкны тутырырга омтылудан гыйбарәт. Чөнки шул шартларда СССР буйлап сибелгән, үзара мәдәни-рухи бәйләнешләре зәгыйфьләнгән халкыбызда милли бердәмлек хисе саклануга хезмәт иткән бердәнбер дип әйтерлек чарабыз беренче нәүбәттә сәхнә сәнгате — театр һәм эстрада сәнгатебез булды.

Бу хөкемнең коры дәгъва гына булмавын аңлар өчен сәхнә-эстрада, күчмә һәм академик театр хезмәткәрләренең бихисап гастрольләрен искә төшерик. Ерак өлкә-республикалардагы чыгышларыннан тыш, ярты караңгы авылларыбызда алар кабызган "клуб утларын"да истән чыгармыйк; төрле яклап таланган, кыерсытылган авыл халкына артистлар күрсәтә килгән игелекле, тәэсирле хезмәтнең әһәмиятен онытмыйк!..

Артист хезмәте дигәч, шуны да һәрвакыт истә тотарга кирәк: совет җәмгыятендә матди яктан иң кыерсытылган (түбән эш хакына көн кичергән) халыкның беренче зур төркемен колхозчылар тәшкил итсә, икенчесе, һичшиксез, артистлардан һәм гомумән сәхнә хезмәткәрләреннән гыйбарәт иде. Шуны һәрвакытта исәптә тотсак, алар күрсәткән чын фидакарьлекне беркадәресе дөрес бәяләп булыр иде.

Бу әйтелгәннәрдән чыгып, кайберәүләрдә сәхнә сәнгате интеллектуаль эшчәнлегебезнең башка төрләренә, мәсәлән, язма әдәбиятка, матбугатка каршы куела, аларның әһәмиятләре инкяр ителә дигән фикернең тууы ихтимал. Дөреслектә мин аларны бер-берсенә һич тә каршы куярга җыенмыйм. Минем теләк башкачарак: мин бары тик сүз иреге, фикер хөрлеге чикләнгән, эзәрлекләнгән җәмгыятебездә сәхнәдә башкарылган әсәрләрнең тәэсири мөмкинлеге икенчерәк, киңрәк, үтемлерәк иде дип әйтергә телим. Чөнки сүзне, фикерне авызлыклау "осталыгын" югары камиллеккә җиткерә алган совет цензурасы артист осталыгын, аның омтылышларын тулысынча чикли, богаулый алмый иде.

Шул ук вакытта, әлбәттә, сәхнә әсәрләренең дә (пьесаларның, җырларның, эстрадада яңгыраган шигырьләрнең) цензура узуларын, димәк, кискәләнүләрен, тыелуларын да инкяр итеп булмый. Күп кенә артистларның, "җор телле" конферансьеларның эштән куылуларын, "себер китүләрен", режиссерларның махсус үтерелүләрен дә тарих яхшы хәтерли. Ләкин монда да театр сәнгатенең "үз өстенлекләре" бар. Язучылар әсәрләре әле дөньяга чыгып җиткәнче, цензура узган вакытта ук эзәрлекләнә башласа, артистлар нигездә үз эшләрен башкаргач кына төрле җәзага тартылалар иде.

Бу фикерләрне, ягъни сәхнәнең кайвакытларда басмадан өстенрәк (ирекләрәк, кыюрак, үтемлерәк) булуын раслый торган фактларны язучы-шагыйрьләребезнең үз гамәлләреннән дә күрергә мөмкин. Әйтик, аларның төркем-төркем, яисә аерым-аерым булып "гастрольләргә" чыгулары, шәһәр-авылларда "халык белән очрашулары" сәхнә мөмкинлекләреннән файдалану булмыйча ни булсын?!

Ниһаять, театр файдасына татарча китапларның саннары, тиражлары елдан-ел азая, вакытлы матбугат эчтәлеге дә гел саега барган елларда театр һәм сәхнә сәнгатебезнең гөрләп эшләвен, тамаша залларының һәрвакыт тулып торган булуын да "өстәп язып куйыйк". Татарстаннан читтәге шәһәрләрдә гастрольләр барган чакта никадәр халыкның театр ишекләренә ябырылу фактларын да истән чыгармыйк. Гыйбрәт өчен тагын бер чагыштыруны искә төшерәм. Алматы, Ташкент кебек шәһәрләргә Казанда чыккан кайбер китаплардан нибары дистәгә якын нөсхә алдырылып, аларны санаулы гына кеше укыган була иде. (Милли китапның таралуын чикләү буенча китап сәүдәсе өлкәсендә дә махсус сәясәт алып барылуы мәгълүм факт.) Әмма артистларның гастрольләре вакытында спектакльләр белән концертларны йөзләгән-йөзләгән, ягъни меңләгән кеше карап, туган сәнгатькә, туган телгә тартылалар иде.

Ни кызганыч, читтәге кардәшләребезгә мондый бәйрәмнәргә катнашу сирәк, һай, бик сирәк насыйп була иде!..

Кыскасы, сәхнә сәнгатебез, артистларыбыз адресына югарыда әйтелгән мактау сүзләре буш дәгъва түгел, бәлки тарихи нигезле ихлас рәхмәт сүзләре алар. Әйе, безнең төрле яклап милли-рухи эзәрлекләнгән, таланган, бүлгәләнгән халкыбызда бүген милли бердәмлек, рухи һәм тарихи уртаклык хисе азмы-күпме дәрәҗәдә сакланып калган икән, без моның өчен сәхнә сәнгатебез алдында да бурычлыбыз.

Әлбәттә, бу әйтелгәннәрдән чыгып, матур әдәбият, басма сүз һәм "бер уч" хәлендә генә калган милли мәктәпләребез белән җыр-музыка, сынлы сәнгатебезнең дә милләтне саклау юлындагы хезмәтләрен онытырга тиеш түгелбез. Аларның да зур өлешләре бар. Һичшиксез! Мин исә бу урында тулаем әһәмияте әлегә кадәр төгәл өйрәнелеп, бәяләнеп бетмәгән сәхнә сәнгатебезнең, милли театрыбызның хосусый әһәмиятенә, төртеп дигәндәй, басым ясап күрсәтергә теләдем.

Димәк, 1996 елда без асылда бер аерым театрның гына түгел, бәлки бөтен сәхнә сәнгатебезнең, шул олуг күренешнең чын байрактары (флагманы) булган Академик театрыбызның йөз еллык бәйрәменә таба узганбыз икән.

Болай дигәндә, алдагы юбилейга ишарә итү очраклы түгел. Дөресен әйткәндә, без сәхнә сәнгатебезнең, бигрәк тә Галиәсгар Камал исемендәге театрыбызның, гәрчә аны бик яратсак та, тарихи әһәмиятен, иҗтимагый миссиясен чын-чынлап аңлап һәм аңлатып җиткермәдек әле.

Әлбәттә, 90 еллыкны уздырганда да, традицион конкрет чаралардан (тантаналы җыелышлар үткәрүдән һәм буклетлар чыгарудан) тыш, матди эз булып калырлык җитди публикацияләр дә эшләнде. Беренче булып, "Җыен" фонды тарафыннан В. Мортазин белән Т. Ченәкәй язган "Татар театры тарихыннан" исемле гарәп язулы китапның (Мәскәү, 1926) икенче кат нәшер ителүен күрсәтергә кирәктер. Ул китап авторларның, бигрәк тә беренчесенең, тасвирлана торган процессның замандашы, хәтта актив геройларының берсе булуы белән әһәмиятле. Мираска карый торган мондый истәлекләрнең яңа басмалары киләчәктә дә чыгып торыр дип ышанасы килә. Бәлки шул китапның яңа басмасын әзерләүдә актив катнашкан Илтани ханым Илялова да яңадан-яңа инициативалар күрсәтер.

Илтани ханымның исеме телгә алынган икән, форсаттан файдаланып, аның театр сәнгатебез тарихын өйрәнү юлында моңарчы да күрсәткән фидакарь эшчәнлеген махсус билгеләп узу зарур. Аның тырышлыгы белән узган елны Камал театры хакында тагын түбәндәге өч хезмәт дөнья күрде: "Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры" (альбом, 192 бит), "Г. Камал театры артистлары" дигән биографик белешмә (250 бит) һәм "Репертуар Татарского академического театра имени Галиасгара Камала. 1906 — 1996 гг." исемле кыскача библиографик белешмә (46 бит). Өч китапта да текстлар татарча һәм русча вариантлары белән параллель рәвештә бирелгән. Бу очракта юбилей

мөнәсәбәте белән басылган материалларның ике телдә чыгарылуын акланган дип бәяләргә кирәк — чөнки тәкъдим ителгән информациянең киңрәк таралуы бәхәс тудырмый.

Ак-кара төстә генә басылган альбом театрның ерак һәм якын тарихын, бүгенгесен күргәзмәле чаралар белән шактый киң күзалларга ярдәм итә. Артистлар белән режиссерларның, драматурглар белән рәссам, композиторларның эшчәнлекләре фототарихта шактый төгәл, эзлекле чагылган. Язма текстның чагыштырмача аз, әмма фотоматериалларның гаҗәеп бай булуы күзгә ташлана. Кайбер фотолар чын сәнгать әсәре югарылыгында эшләнгән.

Дөрес, альбомның гел ак-кара төстә генә булуы, гәрчә ул махсус шулай уйланган, стиль җәһәтеннән акланган булса да, китапка бертөрлелек, сорылык кыяфәте бирә сыман. Әгәр аңа, ара-тирә дигәндәй, төсле һәм тоташ башка төстәге материаллар кертелгән булса, китапның сәнгатьчә һәм эстетик тәэсире тагын да көчәя төшәр иде.

Мәсьәләгә шушы күзлектән караганда, артистларыбызның кыскача тормыш юлларын, иҗатларын яктыртуга багышланган биографик белешмә китабы шактый пөхтә һәм бәйрәмчәрәк килеп чыккан. Китапны һәр актарган, биографик белешмәләрне яңадан-яңа караган саен мәшһүр театрның ерак һәм якын узганы хакында белмәгәнеңне беләсең, белгәннәреңне яңартасың, тагын яңа мәгълуматлар туплау хисе белән яна башлыйсың.

Дөрес, зәвыкъ белән һәм популяр итеп эшләнгән белешмәнең кайбер кимчелекләре, төгәлсезлекләре дә юк түгел. Мәсәлән, китап исеменең астына "биобиблиографик белешмәлек" дип өстәлгән. Ләкин, беренчедән, китапта кыскача биографияләр генә бар, ә библиография юк. Минемчә, библиографик мәгълуматларның бер өлеше "Репертуар..." дип аталган өченче белешмәлектә бирелгән. Шулай ук ул китап, әгәр ул биобиблиографиялыкка дәгъва итә икән, анда театр һәм спектакльләр, аерым артистлар хакында да төп хезмәтләрнең исемлеге булу сорала. Ниһаять, китап шул хәлдә калган тәкъдирдә дә, тагын бер кечкенә белешмәнең булуы зарур иде. Ул — исемнәрнең алфавит күрсәткече. Бу мәсьәләне эчтәлектә китергән фамилияләрне алфавит тәртибендә урнаштыру юлы белән дә хәл кылып булыр иде сыман. Шулай эшләнгәндә үзеңә кирәкле шәхес хакындагы белешмәне тизрәк табу мөмкинлеге артыр иде.

Конкрет биографияләргә караган төгәлсезлекләрнең, ялгышларның булуы да ихтимал. 500 дән артык кеше турындагы белешмәлектә барысы да бер дәрәҗәдә төгәл булып җитмәс, әлбәттә. Театр җәмәгатьчелегендә ул китапта киткән кайбер фактик төгәлсезлекләрне киләчәктә бетерү өчен мәгълуматлар туплау да табигый күренеш.

Әлбәттә, бу әйтелгәннәрдән чыгып, театрның 90 еллыгына багышлап чыгарылган хезмәтләрнең әһәмиятләрен киметергә һич тә ярамый. Киресенчә, И. Илялованың гаять зур эшләр башкаруын икърар итәргә кирәк. Театрыбызның, күпсанлы артистларыбызның, гомумән театр коллективының эшчәнлеген шулай киң планда мөмкин кадәр тулы яктыртуга омтылу үзе дә зур фидакарьлек. Әгәр 70-80 нче елларга кадәр театр тарихы буенча чыккан хезмәтләрнең шактый "сайланган", ягъни аларда кайбер фактлар, исемнәр бөтенләй аталмаган булуын исәпкә алсак, яңа альбом белән яңа белешмәнең әһәмияте тагын да ачыграк күренә.

Өстәвенә шуны да истә тотарга кирәк. 90 еллыкны билгеләү, югарыда әйткәнемчә, ул тагын да зуррак тарихка — 100 еллыкка әзерлек дигән сүз. Олы сәхнә сәнгатебезнең байрактары булган театрның безнең гомердә билгеләнәчәк шул иң олы бәйрәменә тагын да җитдирәк әзерләнү һәммәбезнең изге бурычы.

**Миркасыйм ГОСМАНОВ,**
ТФА академигы.

# ГӨЛСЕМ БӘХЕТЕНЕҢ СЕРЛӘРЕ



– Коткар, зинһар, – диде көннәрдән беркөнне нәшрият мөхәррире Венера Шәрипова, – календарьны типографиягә төшерер көн житте, ә Гөлсем Исәнгулова турында язма юк. Артисткага тиздән алтмыш тула бит...

– Ярар, – дидем. Яраткан артистка турында машинкада бер бит язып бирү кыен түгел лә. Календарьда басылып чыккан түбәндәге язма шулай туды.

**"Назлыгөл-Энҗебикә**

*Кайсыбыз гына Гөлсем Исәнгулова уйнаган, Мар Байҗиев пьесасы буенча куелган "Хуш, Назлыгөл!" спектаклендәге Назлыгөлне хәтерләми икән. Яки Нурихан Фәттахның "Кол Гали"ендәге Энҗебикәне. Автор язган роль белән башкаручы артистка шулкадәр туры килсә дә килер икән. Үзе чибәр, үзе горур, үзе шәфкатьле, үз кыйбласыннан тайпылмас Гөлсемебез ул безнең.*

*Күпме татар кызлары Башкортстанда башкортча театр уйнап йөргәндә, Гөлсем ханым – татар театрында уйнаучы бердәнбер башкорт кызы. Аллаһы Тәгалә аңа фаҗигале язмыш биргән – ул балалар йортында тәрбияләнгән. Аннан Мәскәүдә укып, артистка булып Казанга килгән. Гөлсем апа гомер буе көрәшеп яши. Яшәү өчен, матурлык, гаделлек өчен көрәшә ул. Шуңа аны Мостай Кәрим, Рәми Гарипов кебек олы шагыйрьләр үзләренә тиң күрә, хөрмәт итә. Сынмас, сыгылмас булганың, кайгы-хәсрәт, борчуларыңны безгә күрсәтмичә, якты, матур образларың белән татар тамашачысын сөендергән өчен рәхмәт сиңа, Назлыгөл-Энҗебикә."*

Элек тә Гөлсем апа турында да, ул уйнаган рольләр турында язасым килә иде. Ничектер җае чыкмады. Инде менә Гөлсем апа турында язмый чарам юк. Язарга кирәк, ләкин аның турында язу җиңел түгел. Чөнки ул – үтә катлаулы, башкаларга охшамаган шәхес.

...Уены-чыны бергә... Советлар Союзының бетәчәген-таркалачагын да Гөлсем Исәнгулова бик күп еллар элек әйткән кеше бит.

1956 ел. Мәскәүнең Щепкин исемендәге театр училищесына керү өчен. Татар дәүләт академия театрында имтиханнар бара. Имтихан гына түгел, чын мәгънәсендә тикшерү, сынау. Сынаучылары: Хәлил ага Әбҗәлилов, Хөсәен ага Уразиков, Шириязданов ага Сарымсаков, Һидият ага Солтанов. Беренче турда ук игътибарны җәлеп иткән бердәнбер чая башкорт кызы, рәхәтләнеп көлдерә имтихан алучыларны. Күрәсең, башкорт телен бозып татарча сөйләргә тырышуы имтихан алучыларга кызык тоелгандыр. Шириязданов Сарымсаков Гөлсемгә: «Весь Советский Союз" сүзенең татарчасын әйтеп күрсәт әле», – ди. Шомлы, серле күз карашыннан бер мәлгә каушап та кала әле кыз бала. Югыйсә, бик җиңел сорау, инде иң авырларын да җиңеп чыккач, каушата да калдыра. Сорауның мәкерле икәнен чамалый кыз. Юри бирәләрдер аңа бу сорауны, батырыр өчен. «Татар артисты булам дип йөргәнче, сөйләшергә өйрәнеп кил», – дисәләр, нишләрсең. Югыйсә, укырга озатып калган башкорт театры артисты Рәфкать Фәйзи:

– Башкорт сүзенә "лар-ләр"не кушасың да татарча була ул, – диган иде. Советский – Совет "лар"ны кушкач, "Советлар Союзы" була, "весь" – анысы "бөтә" була.

Шириязданов ага туп-туры күзгә карап тора, Гөлсем дә туп-туры ярып сала:

– Бөтә Советлар Союзы, — ди.

Шул өч сүзе белән башкорт кызы имтихан алучыларны аяктан ега да инде. Ярый әле, Мәскәүдән килгән вәкил ул сүзләрнең мәгънәсен аңламый. Ул чакта әле берәү дә 30-35 елдан Советлар Союзы чыннан да таркалыр, дип күз алдына китерә алмый.

Шулай итеп, Гөлсемне укырга кабул итәләр. Гөлсем Исәнгулованың башка берәүгә дә охшамаган үз юлы, үз урыны. Аны башкалар белән бутап булмый. Югыйсә, әгәр ул башкалар кебек үз әти-әнисе белән үссә?.. Колхоз хисапчысы, эчкерсез, ярдәмчел Сабир агай белән Дәүләткол авылына Ашказар буендагы Мостафа авылыннан килен булып төшкән Гафифә апаның кадерле, иркә баласы булып үссә?..

Юк шул, андый бәхет Гөлсемгә эләкми. Каһәр суккан сугыш, кызны әти-әнисез генә түгел, туган җирсез, туган авылсыз да калдыра. Әтисен хәтерли ул, бүгенгедәй хәтерли, кара карлыган кебек күзле, мыеклы, озын буйлы, чибәр кеше була ул. Балачак хәтере, бәлки, шулай булырга тиеш булган, дип уйлыйдыр.

Әтисеннән калганда өч яшь була аңа. 1943 елда Сабир агайның соңгы хатын алалар. Шуннан озак та үтми тетрәндергеч хәбәр килә. "Өлкән сержант Исәнгулов Сабир Хафиз улы хәбәрсез югалды", диелгән була. Мондый хатлар бу чорда һәр авылга, һәр шәһәргә килә. Инде менә сыңар канат булган әнинең дә югалуы... Бусы инде бигрәк үзәкне өзә, бәгырьләрне кисә. Җитмәсә, сугыш беткәч бит әле, ике авыл арасында гына...

Сабир агайның авыр хәбәре килгәч, озак та үтми, әниләре тарафыннан да, сеңел-энеләре тарафыннан да зур өметләр багланган Әкълимә апалары кайтып төшә. Җиде класс бетергәннән соң шәфкать туташы булырга Эстәрлетамакта укып йөрүче апалары: "Эстәрлебаш районында салым агенты булырга эш белешеп кайттым, торырга – өй, ашарга – ризык та булачак", – дип сөендерә. Әй, язмыш, язмыш... Әкълимәне чуаш авылы Тәтербашка күчерәләр. Шул авылдан исә Гөлсемнең гомер буена бердәнбер таянычы булып калачак Зөбәер абыйсы ун чакрымдагы Тормайга укырга йөри.

Язмамны шул урынга кадәр укыгач, Гөлсем ханым, моның кемгә кирәге бар, дияр. Укучыма да шулай тоелуы бар. Ләкин монда бик тә үзенчәлекле, талантлы, фикерле артистканың холкы формалаша, монда да ул яшәү өчен көрәшә, көрәшергә өйрәнә. Язмышның бөтен ачылыгын татый.

Әкълимәне дәүләт акчасын әрәм-шәрәм иткән, дип, кулга алалар. Әниләре ут йота, төннәрен йокысы кача. Кызының гаепсезлеген исбатларга тырыша. Яхшы адвокат эзләргә Уфага җыена. Зөбәере җигеп йөрергә өйрәткән зур үгезне акчага әйләндереп, балын, маен табып, ике чуаш ир янына утырып юлга кузгала. Күңеле нидер сизенгәндәй, 7 яшьлек Гөлсемне кысып-кысып кочаклый. Ун көннән әйләнеп кайтырмын, балалар, ди. Айдан артык вакыт үтә, Зөбәер, Гөлсем, Альберт әниләрен көтәләр. Ләкин юкка. Ана бер хәбәрсез юкка чыга. Хәбәре дә булмый, кабере дә калмый. Балалар Мостафа авылына, бабаларына хат язып салалар. Әниләренең абыйсы Сынтимер бабай килә. Зөбәерне әнисен эзләтергә, көтәргә кушып калдыра да Гөлсем белән Альбертны үзләренә алып китә. Кечкенә Альбертны тәрбиягә бирә. Зөбәер белән Гөлсем монда тамак хакына хезмәтчегә әйләнәләр. Унөч айдан, гаепсез табылып Әкълимә дә кайта. Ләкин әнә шул каһәрле айлар аның холкын бик үзгәрткән була. Нахакка рәнҗетелгән унҗиде яшьлек кыз бала кешеләргә, тормышка ышанычын югалта. Гомере буена дөреслек эзләп, аны таба алмыйча, йөрәк авыруыннан дөнья белән бәхилләшә. Энеләре Альбертның да гомере фаҗигале тәмамлана, аны да ун класс бетергәч армиягә алалар. Өч ел Мәскәүдә хезмәт иткәннән соң, аны җинаятьчеләр эзләү бүлегендә эшкә калдыралар. Дүрт ел эшләгәч, ул егерме биш яшендә бандитлар тотканда һәлак була.

Абыйсы Зөбәер бик тырыш була. Ул әле әниләре исән чакта да, чуаш авылында яшәгәндә дә ун чакрымдагы авылга йөреп, туган телендә белем ала. Аны бик яхшы укыганы өчен Уфадагы башкорт балалар йортына күчерәләр. Соңрак ул, бик кыенлык белән булса да, сеңелесе Гөлсемне дә үз янына — балалар йортына алдыруга ирешә. Ул – Гөлсемнең беренче укытучысы. Кагылып-сугылып үскән, әле хәреф танырга да өлгермәгән унбер яшьлек Гөлсемне яше буенча дүртенче сыйныфка утырталар. Абыйсы сәгатьләр буена, кешедән качып, төннәрен, сеңлесенә хәреф өйрәтеп азаплана. Һәр көнне сәгатьләр буе хәреф өйрәнеп утыралар, булмагач, булмый гына. Бүре көтүенә очраган, адашып кырларда калган, катлы-катлы авыр операцияләр кичереп, күз яше күрсәтмәгән Зөбәер сеңлесенә хәреф таныта алмаудан гаҗиз булып, кычкырып елап җибәрә. Йа, Раббы, нинди могҗизалар була. Шуннан соң Гөлсем укырга, язарга өйрәнә. Яшьтәшләрен куып җитә. Яхшы укучылар рәтенә баса. Балалар йортында ул башкалардан бәхетлерәк тә, горуррак та. Чөнки аның абыйсы бар. Ул ятим түгел.

Ул чордагы балалар йортлары да бөтенләй башкача була. Монда сугыш ятим иткән балалар яши, яхшы кеше, чын ата-ана балалары. Директор Әхмәров абый үзе ни тора. Монда теләгәнеңне эшләп, үзеңчә яшәп була.

Беркөнне Гөлсемне телефон янына сакка куялар. Ә ул тота да үзе үлеп гашыйк булган артистка Рәгыйдә Янбулатованы ятим балалар йортына кунакка чакыра. Яңа елга. Бу Рәгыйдә ханымның "Отелло" трагедиясендә уйнап, тамашачыларны "аһ" иттергән еллары була. Ул елларда (кирәк бит!) балалар йортында тәрбияләнүчеләрне концерт, спектакльләргә йөртәләр. Башкорт академия драма театры артисты Гата Арысланов алар өчен драма түгәрәге оештыра. Алар үзләре дә спектакльләр куялар. Октябрь бәйрәменең 35 еллыгына

Баязит Бикбайның "Кунагына күрә кадер" дигән әсәрен уйныйлар. Зөбәер — ягу материаллары ташучы, Гөлсем- комбайнчы ярдәмчесе. Ул елларда башкорт театры артистларга кытлык кичерә. Беренче мәртәбә Гөлсем Исәнгулова Уфа театрында «Кара йөзләр» спектаклендә кумәк күренешкә чыга. Артистка Тәлига Бикташева Галимәне уйный. Их, артистка бул идең дә, әнә шундый рольне, әнә шулай уйна идең. Ул көндәге хыяллар, ул көндәге хисләр, көнләшү-кызыгулар... Ә менә Рәгыйдә апаны якыннан күрү, аның белән,



*Уфа шәһәренең 7 нче балалар йортында уйналган спектакльдән күренеш. (Б. Бикбай. «Кунагына күрә кадере»). Уңнан беренче — Гөлсем Исәнгулова. Уртада аның абыйсы Зөбәер Исәнгулов.*

телефоннан гына булса да, сөйләшү хыял, буй җитмәслек мизгел була. Гөлсемгә дә тәрбиячеләр шикләнеп:

— Булмас, килмәс, — диләр.

— Килә, киләчәк, "киләм", дип әйтте бит, — дип гөрли, очына Гөлсем.

Чыннан да, җиденче сыйныф укучысының чакыруын кабул итә шул Рәгыйдә ханым. Берсүзсез. Балалар йортына кызы Гөлли Мөбарәкова белән килә. Әй, ул көндәге сөенеч, шатлыклар, бәхетле минутлар. Бүгенгедәй күз алдында. Шуннан соң Гөлсем бу мәшһүр артистның өйләренә, нәкъ менә Рәгыйдә Янбулатова, Арыслан Мөбарәков янына йөри башлый. Дүрткә генә бүленәсе ризык бишкә бүленә. Үз итәләр, яраталар. Хәер, еллар узгач, Гөлсем ханым Башкортстанның олуг артистларына бурычлы булып калмый. Аларны зурлап, Казанда кунак итә, кадер-хөрмәт күрсәтә. Ул гомер буена үзенә аз гына яхшылап эшләгән кешеләргә дә мең белән җавап бирергә, бурычлы булып калмаска тырыша. Шулай итеп ул, кунакка чакырып, барысы өчен дә кызыклы очрашулар оештырып, Мостай Кәрим, Нажар Нәҗми кебек зур шагыйрьләр белән таныша, дуслаша, кеше таныргә, шигырь аңларга өйрәнә.

Гөлсем сигезенче классны бетергәндә, ГИТИСка башкорт студиясенә Мәскәүдә укыр өчен, Уфада укучылар җыялар. Бүген тотып китәр иде, яшь җитми. Гөлли Мөбарәкова китә. Гөлсемгә — язмаган. Укытучыларның, тәрбиячеләрнең дә җибәрәселәре килми. Алар Гөлсемдәге оештыру сәләтенә, хәтеренә, булганлыгына карап, зур өмет баглыйлар. Гөлсем инде үзе дә нефть институтына керергә уйлап йөри. Бүген-иртәгә тәвәккәллим, дип йөргәндә, Рәфкать Фәйзи очрый. Ул «Отелло»да атаклы Ягоны уйнаган артист, башкорт театрында уйнаучы татар кешесе икән. Күңеле иләс-миләс йөргән кызга юл күрсәтә:

— Казанда «Щепкин»га укучылар җыялар, синнән чын артист чыга, бармасаң, гомерең буена үкенерсең, — дип татарча сөйләшергә, "лар-ләр"не кушарга өйрәтеп кала...

1956 ел. Гөлсемгә Балалар йортыннан бер кило прәннек, бер бөтен ипи һәм Казанга барырга билет бирәләр. Шулай итеп, Татарстанның егет-кызлары белән бердәнбер башкорт кызы, ятимә Гөлсем Мәскәүгә артистлыкка укырга китеп бара.

Мәскәү хәтле Мәскәүдә укып кайтачак беренче "щепкинчы"ларны бер дә күз уңыннан ычкындырмыйлар. Сайлап җыелган төркем, чыннан да, бик көчле, бердәм була. Алар — күптән инде Камал театрының, татар театрының умыртка сөяге, халык артистлары.

Һәр яз саен ап-ак чәчәккә күмелгән алмагачтай салкын кырауларга, кырыс сынаулар,

өелеп килгән алкышларга, табу-югалтуларга бирешмичә, әле Гагарин галәмгә очкан елны шаулап-гөрләп Казанга кайтып төшкән артистларыбызга да тамашачыны сискәндереп 60 яшь тула башлады.

Туфан, Тажи, Шәрәфи, Дунай, Гөлсем, Батулла, Нәҗибә, Фирдәвес, Әзһәр – "щепкинчы"ларның өзелмәс чылбыры. Титулларын санамыйча, әтиләрен искә төшермәгәнгә, "әфәнде", "ханымнар" дип кушмаганга, гап-гади, үз итеп. Европа халыклары кебек кенә. Дунай, Тажи, Нәҗибә, Батулла, дигәнгә ачуланмаслар дип уйлыйм. Аларның һәрберсе турында бик күп язылды. Гөлсемнең генә алай чынын-уенын бергә кушып язуларга исе китмәде. Югыйсә, бик рәхәтләнеп Мәскәүдә калырга да мөмкинлекләр бар иде.

Гөлсем дипломсыз калудан да курыкты, бигрәк тә бу адым хыянәт булыр дип уйлады. Чит ил кешесенә кияүгә чыгуын да килештермәделәр. Гөлсем тормышын гади, бергә укып йөргән, үз араларыннан булган егет белән башлавын күз алдына да китерми иде. Аның ире ниндидер серле булырга тиеш кебек иде. Андый кеше табылды. Кыш уртасында күз явын алырлык чәчәк бәйләме, яисә хыялланып кына йөргән затлы ислемай бүләк итү аңа берни дә тормый иде. Каршысында тезләнү, баш ию, кулларны үбү дисеңме... Андыйны күргәне бар идемени соң Гөлсемнең? Зур-зур концерт заллары, мәшһүр театрлар... Үзе шул дөнья кешесе. Румыниядән Мәскәүгә кинематография институтына сценарий язучылар факультетына укырга килгән. "Табор күгенә юл ала" фильмын куючы Эмиль Лотянуның якын дусты. Улларына да нәкъ менә аның хөрмәтенә Эмиль дип куштылар. Гөлсем чит илдә яшәүне күз алдына да китермәде. Юлиу урысча да, татарча да белми иде. Казанга килеп тә карады. Графлар гаиләсеннән, ата-анасына кадерле бер генә бала булса да, безнең тормышка яраклаша алмады. Гөлсем, улын күтәреп, Казанга, гомерлеккә кайтып төште. Ул тормышын театрдан башка күз алдына китерә алмый иде инде. Соңыннан Гөлсем улы белән Бухарестка алты-җиде тапкыр кунакка барды. Көтәләр, яраталар, чакыралар иде аларны. Калырга да кыстыйлар иде. Гөлсемнең күңеленә: бала хакына калыргамы әллә, дигән уй килгән чаклар да булды. Әмма бераз вакыт үтүгә, театрсыз яши алмавын аңлады. Дөрес, анда да театр бар. Киносына



*А. Гыйләҗевның «Әңгер-меңгер» әсәре буенча куелган спектакль. Сулдан уңга: Р. Җиһаншина, Ш. Биктимеров, Г. Исәнгулова, Г. Надрюков. 1971 ел.*

да төшәр иде. Әмма инде ул татар театры булмас, татар киносы булмас иде. Борчумәшәкатьсез, рәхәт тормыш, ир белән тору бәхете артка чигенде.

Театрга кайткач, уйнаган беренче рольләрне саный китсәң дә, укучыга әллә ни бирмәс кебек. Шулай да онытылмый торганнары, Гөлсемне Гөлсем иткән, башкалардан аерган рольләр бар: Зәйтүнә, Зөһрә, Гөлзифа, Маһи, Мәдинә, Линочка. Болар әле беренче, кыяр-кыймас уйналган рольләр. Кырык елга якын иҗат гомерендә ул җитмешләп роль башкарды, шуларның яртысыннан артыгы — төп рольләр.

Менә Индонезия язучысы А.Муисның "Фаҗигале юлда" драмасындагы француз кызы Корри образы. Әсәрне режиссер Ш.Сарымсаков сәхнәләштерде. Шуны татар сәхнәсендә, татар тамашачысы өчен, башкорт кызы Гөлсем уйнарга тиеш. Кыска чалбар – шортиктан чыгу Гөлсемгә зур гөнаһ кебек тоелды. Чалбар тектерде, әле анысын да тамашачы гаеп итә торган чак иде. Бу рольне яратып, рәхәтләнеп уйнады ул. Бу әсәрне телевизордан күрсәттеләр. Шуннан соң тамашачы Гөлсемне таный, ярата башлады. Аны, ул уйнаган образларны карау өчен генә театрга йөрүчеләр күбәйде.

Озак та үтми, театрга яңа режиссер – Марсель Сәлимжанов килде. Зур бер вакыйга булды бу. Яңалык, яшьлек, илһам, иҗади дәртле рух килде. Нәкый Исәнбәтнең "Миркәй белән Айсылу"ын куйды. Айсылу – "Кара йөзләр"дәге Галимәнең фаҗигале игезәге кебек. Шул ук язмыш. Рауза, Гөлсем, Дания – Айсылуны уйнарга тиеш артисткалар. Бер гаепсезгә яла ягылган кызның акылдан язуы тетрәндергеч. Өч артистканы да уйнаталар. Нидер җитми. Акылдан язып булмый. Шунда Марсель, тормышта булган хәлләрнең киресен эшләп кара, диде. Бу сүзләргә ниндидер мәгънә салынган иде, Гөлсем берсүзсез аңлады. Эшләргә, диде, ләкин ничек? Гөлсем шуны эзләде, сәгатьләр буена театрда ялгызы калды. Ике метрга якын биеклектән «үләм» дип егылырга өйрәнде. Гөлсем режиссер кушмаганнарны да эшләде. Аның Айсылуы гашыйк иде, башкалардан аерылды. Иң авыр чакта әти-әнисенең югалуы турында уйлады. Елавы үзәкләрне өзгеч булды, чөнки чын иде. Кыядан ук курыкмыйча ташланды. Гөлсем гаҗәп мөлаем, нечкә күңелле, гашыйк, җирдән күтәрелгән образ тудыра алды. Соңгы күренештә — Миркәйне озаткач акылдан язу күренеше җанны тетрәткеч иде. Тамашачы да, сәхнәдәшләр дә аны яраттылар. Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә», «Кыз урлау» әсәрләрен сәхнәләштерделәр. Шәфәк, Җәмилә булды Гөлсем. Чын башкорт хатын-кызларын яратып уйнады. Ул нәкъ менә үзе уйнаган образлар аша уйланучан, фикерле, үзенә дә, башкаларга да таләпчән, тынгысыз чын актриса булып күз алдына килеп баса.

Элек-электән Гөлсем ханым турында сәер, усал, таләпчән, дигән сүзләрне ишеткәнем бар иде. Инде менә икенче мәртәбә өендә чәй эчеп утырам. Чыннан да, сәер икән ул. Кешегә күчтәнәч алып киләсең, мин дә конфет алып килдем. Алмады, бик оялдым. Бик тәмләп чәй эчертте. Зур алманы урталай кисте дә, әрчеп, яртысын миңа бирде. "Алманы ашарга кирәк", – диде. Ул шундый буйсындыручан, тешсез килеш алма ашый башладым. Өендәге чисталык, пөхтәлекне күреп тә исем китте. Сәхнәдә дә шундыйдыр ул. Үзе әнә шундый булгач, башкалардан да шуны таләп итәдер. Аның уйнаган рольләре дә әнә шундый, кырт итеп торалар.

Санарлык та, сөйләрлек тә бик матур рольләре бар Гөлсемнең. Хәтергә А. Гыйләҗевның («Әңгер-меңгер») Розасы, Н. Погодинның («Баһадирлар») Настясы, И. Дворецкийның («Чит кеше») Щеголевасы, Г. Боровикның(«Канлы күләгәләр») Мартасы, Б. Горбатовның («Бер төн») Лариса Даниловнасы, соңрак М. Фәйзинең ("Асылъяр") Вәлиясе, М. Байҗиев героинялары, Г.Исхакый ("Зөләйха") Мәгүбәсе, Ф. Бүләковның ("Әбиләргә ни җитми?") Сәлимәсе, Т. Миңнуллинның ("Хушыгыз") Сажидәсе килә. Урыс, башка милләт классикасындагы персонажларны да, образларны да Гөлсем Исәнгулова җиренә җиткереп башкара, геройларны татар тамашачысына ачып бирә ала торган талантлы артистка. Минем, ахры, ул уйнаган рольләрдән иң яратканым, карап та, тыңлап та, сокланып та туя алмаганым икәүдер: беренчесе – моннан нәкъ 30 ел элек куелган "Хуш, Назлыгөл"дәге Назлыгөл (М. Байҗиев әсәре). Ул – татар театр сәхнәсендәге яңа образ. Бу спектакльдә бары өч кеше катнаша. Егетләр Газиз-Дунай, Искәндәр-Таҗи һәм Назлыгөл-Гөлсем. Марсель Сәлимҗанов бу әсәрне бары тик Гөлсем өчен куйгандыр кебек тоела.

Гөлсем-Назлы сәхнәдә ике сәгатькә якын була. Сүзе генә дә кырык бит чамасы. Ул аны бер тында уйный. Янды, көйде, алданды, сатылды, кыйналды, гашыйк булды. Мондый рольне сөюнең ни икәнен белгән, алдануның, аерылуның ничек булуын аңлаган, бу кичерешләрне үз йөрәге аша үткәргән актер гына уйный ала. Спектакль барышында 5-6 мәртәбә елый ул. Җаны, йөрәге белән елый. Уйнашчы бер хатын күз алдында бик тә матур, шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм бәхетле бер ханымга әйләнә. Моннан соң ул бәхетле булачак.

Моннан соң ул уйлый, фикерли алачак һәм изгелекләр эшләячәк, яхшылык эшләгәннән соң, җанында рәхәтлек тоячак. Бу спектакль турында: "Исәнгулованың бер роле", дип бик тә үзенчәлекле, мактауга саран, таләпчән язучы Шәриф Хәсәенов, Гөлсем-Назлыгөлгә сокlануын аз гына да яшермичә, "Азат хатын" журналына зур мәкалә язды. Сонрак Гөлсем Исәнгулова нинди генә рольгә алынса да, үзенчә хәл итәргә тырыша. Хәтта аның Зәмзәмбануы да (Таҗи Гыйззәт, "Ташкыннар") начар хатын түгел икән бит. Аны шундый хәлгә куйганнар. Ул тавыш чыгаручы түгел, ул хәтта башлап сүз дә әйтми, бары тик җавап кына бирә. Театр дөньясында бик кызыклы ачышлар була. Беркөн килеп Башкорт театрының баш режиссеры Рифкать Исрафилов «Галиябану»ны куйганда Галиябануга гашыйк Исмәгыйльне дә уңай образ итеп күрсәтә алды. Зәмзәмбану да Гөлсем башкаруында уңай образга әйләнде. Нихәл итәсең: Зәмзәмбану тәвәккәлдер, туры әйтәдер, ир табып, бәхетле хатын да буласы киләдер?!

Нурихан Фәттах әсәре буенча куелган «Кол Гали» спектаклендә Энҗебикә ролендә Гөлсем Исәнгулованың таланты тулысынча ачыла кебек. Бүгенге артисткаларга үрнәк итеп куярлык героиня.

Әйе, тормыш уза тора, авырлыклар сакта тора. Мәкерле хатын-кызлар йөрәген талаган чаклары да булды. Ирләргә бирешмәде ул. Шулай да бу артисткага карата рухи җинаять кылынды. Арадан "кара күләгә" үтте.

Гөлсем — кем соң ул, кеме бар соң аның? Әлбәттә, "кара күләгә" җинде. Күпләр әйләнеп узды, исәнләшмәделәр, күрмәгәнгә салыштылар. Аны зурайтсалар, үзләре кечерәеп калудан курыкканнар җиңел сулыш алды. Бетте, бетердек, дип уйладылар. Бетерерсез алай гына Гөлсемне! Хатын-кызның кырык шәме була, утыз тугызы сүнгәндә дә, берсе кала, диләр. Гөлсемнең тормышында ак белән кара гел алышынып торды. Мактаулы исем сорап хатлар язсалар да алар төрле вакытта төрлечә югала тордылар. Уфа гастрольләрендә үз илендә, үз халкына аның зур рольләрен күрсәтмәделәр. Мостай ага Кәрим барыбер элемтәне өзмәде, игътибарыннан калдырмады, читтән генә булса да иҗатын күзәтеп, тормышы белән кызыксынып торды. Татарстан хөкүмәтенә үзе килеп Гөлсемгә яхшы фатир сорады. Казаннан өч йорт күрсәттеләр — сайлап ал, диделәр. Гөлсем театрга якынын сайлады, аның ордерын да сейфта ярты ел яшереп яткырдылар. Нинди генә кыен хәлләргә калганда да Гөлсем үзенең дөреслеген тоеп горурлана, аннан чыгу юлларын таба белде,чөнки аның ышанычлы таянычы булып, атасы-анасы урынына калган абыйсы бүгенге көндә лаеклы ялдагы очучы полковник, Зөбәер торды.

Ул һәрвакыт үзе тирәсендәгеләргә җайлы, җиңел булуын теләде. Шул гадәте сәхнәдә дә еш була. Шуңа күрәдер Равил Шәрәфи: "Гөлсем белән уйнау авыр да, җиңел дә", — ди. Авыр — чөнки бик таләпчән, дөрес кеше. Җиңел — беркайчан да кыен хәлдә калдырмый. Үзенә сорый алмаса да, яшьләргә кирәк булганда обкомына да, министрына да керде. Сүзе үтә иде. Ул елларда яшь артистларны, кулыннан тотып, редакциягә алып килә иде. Ул чакта "Азат хатын" журналында "Гүзәллек дөньясы"нда, "Таныш булыгыз" дигән сәхифәләр бар иде. Алсуны да редакциягә Гөлсем апа җитәкләп алып килгән иде. Ул елны журнал тышында Энҗебикә ролендә Гөлсемне, Гөлфирә ролендә Алсу Гайнуллинаны чыгарган идек. Соңыннан күпме яла, көнләшү, бер-берене пычратырга тырышу хатлары килә торды. Мондыйлардан Гөлсем ханым бер башка, юк, бик күпкә өстен калды.



*Г. Боровик. «Буэнос-Айрестан интервью». Рольләрдә Ф. Халитов һәм Г. Исәнгулова.*

Кайбер сабакташлары ташлады Гөлсемне. Хәер, куркак, көнчел, хатын-кыз белән булышучы дусларга караганда, аларның булмаулары яхшы. Гөлсемнең дусларга таләпләре дә икенче төрлерәк бугай шул, алар аның өчен йә бар, йә юк. Уртача була алмый. Равил Шәрәфиев — дус, ул уртача

дусларның унына тора. Ул хыянәт итмәде, аның хатыны Раушания дә карангы йөз күрсәтмәде. Фирдәвес Әхтәмова ташламады. Дөньяда берәүгә дә дуссыз калырга язмасын иде.

Гөлсемнең бик тә беләсе килде, ничек бу хәлгә төште дә, нәрсә өчен каһәрләнде соң әле ул? Шуны белер өчен генә булса да, яшәргә кирәк иде. Яшәде, башкалардан ким булмады. Өч ел буена бер генә роль бирмәсәләр дә түзде. Артистканы бары тик роль бирмичә генә үтереп була. Ул үлмәде, бар энергиясен укыту эшенә бирде, булган рольләрен җиренә җиткереп уйнады, театр училищесында укытты.

Һәм, ниһаять, Празат Исәнбәт рольләр бирә башлады. Аннары режиссерлар Дамир Сиражиев, Фәрит Бикчәнтәев үз спектакльләренә ала башладылар. Сабакташы Батулла "Кичер мине, әнкәй" дигән бик тә озын гомерле пьеса язды. Празат куйды, Гөлсем белән Шәрәфи баш рольләрне уйнадылар. "Гөлсем өчен язмадым, ләкин бик тә Гөлсем уйнавын теләгән идем", – диде Рабит Батулла.

"Щепкинчы"ларның икенче төркеме кайтып эшли башлаганга да байтак. Бу төркем икенчерәк, араларында Гөлсем җитми кебек. Хәер, ул анда да житешә, аларны чын күнелдән үзләренең дәвамы дип саный. Гөлсем Исәнгулованың оештыру сәләте гомер буе үзе белән. Матур кичәләр, бәйрәмнәр ясарга оста булса да иң тыйнак бәйрәмнәр – аныкы була. 50 яшенә багышлап спектакль уйнадылар да, тәмләп сыйландылар. Алтмыш яшькә дә спектакльдә уйнарга уйлый ул. Аларның икесенә Празат әфәнде Исәнбәт "Банкрот"ны яңартты. Равил Шәрәфи – Сиражи, Гөлсем Исәнгулова – Гөлҗиһан.

Гөлсем ханым гомер буе ир-егетләр белән, аның да талантлылары белән дус булуны өстен санады. Ул — бик күп әдәбият-сәнгать әһелләренә илһам биргән кеше. Аны укытучым Мөхәммәт ага Мәһдиев тә, язучы Рафаэль Мостафин да хөрмәт итә. Ир-егетләр аның турында: әй, егет тә кеше инде, диләр. Гөлсем апа да хатын-кыз. Үтә дә хисле, йомшак. Тыштан гына ул шулай горур йөри. Хатын-кызлыгын бәяләрлек кеше булмаганга гына, эчтәгесен берәүгә дә күрсәтми дә, зарланып та йөрми. Ә йөрәк барыбер бик нечкә, хатын-кызныкы. Хәер, аңлаучылар булды, булмады түгел. Беренче чиратта аның белән аларның үзләренә җиңел, күнелле, рәхәт иде. Без бит үзебезгә рәхәт булганга, иҗатыбыз гөрләп чәчәк атканда башка кеше турында уйлап та тормыйбыз.

Ә менә татар театрына тулы цикл багышлаган, мәхәббәтнең зурлыгын олылаган шагыйрь бу бәйрәмдә нинди шигырь сөйләр икән? Язылганмы ул шигырь, әллә әле язылачакмы? Мәһабәт гәүдәле, таза, ап-ак озын куе чәчләрен җилфердәтеп, юан таягын кулына гына элеп Нури ага Арысланов килеп чыкса?.. Килер шул, ник килмәсен. Аның инде олы яшендә иҗатының яңадан чәчәк атуына, ялкынланып мәхәббәт шигырьләре яза башлавына Гөлсем сәбәпче түгелмени?! Ибраһим абый Нуруллин да башкода булырга бик оста иде. Әмирхан абый гына сәламен кеше аша гына әйттерде. Мостафа Ногманның бик аны тә Рөстәм Яхинга кияүгә бирәсе килде. Башкодалар күп булды ла ул. Гөлсем исә үз гомерендә бары тик бер кешегә генә кияүгә чыгарга риза иде. Кыш уртасында кәрзин белән чәчәкләр ташу бар идемени әле ул?! Ул чакта бит роза чәчәкләрен кыш көне йоклый, дип сөйлиләр иде. Кыш уртасында драматург аңа, юк, юк үз әсәрен уйнаган өчен түгел, кеше язганны уйнаган өчен, бер кәрзин розалар китерде. Алтын тәңкә бүләк итте. Ышанды аңа Гөлсем. Чын дип уйлады, бергә булыйк, дип карады. Юк. Изге теләк күк белән җир арасында асылынып калды, һәр икесе ялгыз булды. Юк, ничек ялгыз булсын, берсе – шәһәрнең бер башында, икенчесе – икенче башында. Ике ялгыз бер пар инде ул. Бу дөньяда парлы ялгызлар күпме?!

Әйе, яшәгән кадәр яшисе юк инде. Театрның зәңгәрсу түбәсенә менеп карасаң, алтмыш яшьлекләр китәсе капкалар шар ачык. "Щепкинчы"лар әле генә уйный башлаганнар иде бит, югыйсә. Инде менә ашыга-ашыга, бер-бер артлы юбилейлар үткәрәләр. "Хушыгыз!"ны уйнап, сәхнә, тамашачы белән хушлашырга азапланалар. Болай ярамыйдыр ул, ашыкмагыз! Татар театры сәхнәсен ничек Шәрәфи, Тажи, Дунай, Әзһәр, Гөлсем, Фирдәвес, Нәҗибә, Туфан, Батуллалардан башка күз алдына китерәсең? Алар үзләре дә тамашчылардан башка яши алмаслардыр. Юк әле, бүген аларның берсе дә сәхнәдән, тамашачылардан китә алмый, хаклары юк, җибәрмибез. Тамашчыга Назлыгөлдәй, Энҗебикәдәй, Минзифадай тетрәндергеч тагын бер образ – героиня Гөлсем бүген бигрәк тә кирәк.

**Фәния ХУҖАХМӘТ.**

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

## Шакир Мөхәммәдев

# ЯПОН СУГЫШЫ ЯКИ ДОБРОВОЛЕЦ БАТЫРГАЛИ АГАЙ

Запасный унтер-офицер Кәлүч (Кәлимулла) агай, Плевна сугышында сул күзе сукыраеп кайткач, үзенең сөекле ватанына (җиренә) хезмәт итмәк нияте белән, "Шушма башы" исемендә һәркем аңларлык ачык Казан телендә көндәлек бер газета чыгара башлады. Казан халкының, хосусан, Печән базары халкының сөеп укый торган политикасыннан (сугыш хәбәреннән) язганга күрә, бу газетаның алучысы да көннән-көн артып, эшләре бик тиз алга китте. Чыга башлаганның икенче елында ук алучысы ун меңнән арткан иде. Бу газетаның редакторы (язучысы) Кәлүч агай үзе туган җирен бик сөюче (патриот) бер адәм булганлыктан, бик йогымлы сүзләр, бик әсәрле статьялар язып, Россиядә булган барлык исламнарны патшага итагатьле вә тугры булып, сугыш-фәлән булган вакытларда руслар берлән бер җан вә бер тән булып дошманга каршы торып, патшаның һәрбер әмеренә бил бәйләп хәзер булмакны тәклиф итә (ягъни боера) торган иде. Күп вакыт башка газеталар да "Шушма башы"ның сүзе рас вә фикере тугры идекене яза башладылар.

"Шушма башы"ның укучылары һәркайсы политикага (сугыш хәбәренә) оста булып, болар эчендә Батыргали исемле тире-яры һәм мануфактурный товар белән сәүдә кылучы бер бай адәм бигрәк тә атаклы иде. Яшьтән үк "Сәет Баттал", "Салсал" вә башка сугыш китапларын укып үскән Батыргали агай, "Шушма башы" газетасын укый-укый, политикага ихлас куеп, тәмам икенче Бисмарк * булган иде. География, тарих кебек газета укыганда һәрвакыт кирәк була торган гыйлемлекләрне укымаган булса да, газетада күп мәртәбә очраганга күрә, шәһәр, су, диңгез, тау, җир һәм мәмләкәт исемнәрен Батыргали агай яхшы ук аңлый һәм белә башлады. Хәтта бервакытны, җилкенеп китеп, Казанда басылган төркичә бер география китабы да алган иде. Әмма җирнең һәмишә үгез мөгезендә, балык мыегында торганына игътикаты бик куәтле булган сәбәпле, кәррәи әрыз, гарыз, тул, шимал, җәнүп дигән сүзләргә зиһене җитмичә, бу география китабыннан да күп файда тапмады. Шул сәбәпле бәгъзы вакыт, гәрчә әйтерлек зур булмаса да, кечерәк хаталары булгалый торган иде. Аның фикеренчә, Австралия илә Австралия арасында һичбер аерма булмаенча, икесе дә бер иде. Күп вакытта, Австрия императоры, диясе җирдә — Австралия императоры француз Юсыф, дигән кебек, англичаннарның пайтәхете (патшасы тора торган шәһәр) — Берлин, итальяннарның пайтәхете — Вашингтон, дию күңеленә беркеткән иде. Аның игътикатынча, Һиндстан кыйтгасы Боз диңгезе буенда, Бомбей шәһәре Амур суы янында, Сахалин атавы Африкада, имеш. Әгәр дә бер адәм килеп: Байкал — Сибириядә мәшһүр зур бер күл, дип сүз чыгарса, Батыргали агай, аның якасына ябышып, сакалын йолкырга хәзердер. Чөнки Байкал, аның уенча, Африкада бик зур, яна торган таудыр.

* Бисмарк — политика һәм сугыш эшләренә бик оста, Германиядә бер министр иде. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

Географияне укымаса да, Батыргали агай французлар җирен, шәһәрләрен бик яхшы беләдер. Франциянең пайтәхете Париж һәм Сена суы буенда икәнен бер французнан артык белмәсә дә ким белмидер. “Моны кайдан белә, моның сәбәбе ни?” — дисәгез, сәбәбе французларны дуст вә якын күреп, мәхәббәт иттеке өчендер. Батыргали агай Россиянен дусты булган французларны да бик ярата һәм якын күрәдер. Хәтта французларның сугыш корабльләре бер елны, кунак булып, Кронштадтка килә дигән хәбәрне ишеткәч, дуслык күрсәтер өчен каршы алырга да бармакчы булып хәзерләнгән иде, әмма хатыны Җомабикә абыстай: “Саташып йөрмә! Өченче ел Мәкәрҗәдән азып-тузып конвой илә яланаяк кайткан шикелле, бу ел да шулай эчеп-исереп, адәм мәсхәрәсе булмакчы буласың икән”, — дип юлыннан туктаткан иде. Кронштадтка барырга мөяссәр булмаса да, Батыргали агай шул елны Мәкәрҗә ярминкәсендә французларга дуслык һәм мәхәббәт күрсәтмәк өчен, ун мең башлап кәҗә тиресен сум егерме биш тиенгә англичаннарга сатмаенча, сум унбиш тиеннән үзебезнең якын күргән дустыбыз французга сатамын диеп, Москвада торучы бер яһүдигә хата ычкындырган иде. Шул Мәкәрҗәдә янә беркөнне Батыргали агайның эшлиясе койрык астына эләккәч (кызып алгач), “Амун” исемендәге атаклы трактирда дуслык күрсәтмәк нияте илә француз кызларын хөрмәт итәмен, сыйлыймын дип, Одессадан килгән җырлаучы чегән кызларын ике йөз егерме тәнкәлек эчергән иде. Боларның эчендә бәгъзы французча сөйләшүчеләр дә булганлыктан, Батыргали агай берничә сүз французча да өйрәнде. Французларга мәхәббәте шулкадәр артты ки, акча хисапларын да франк хисабы илә йөртә башлап, үзенең Гыйсмәтулла кодасына да сәлам бирү урынына французча “бонжур” гына ди торган иде. Шул елны Мәкәрҗәдән берәр дюжина француз аршыны (метр) * алып кайтып, кибеттәге красный малны шул метр берлән үлчәп сатып, хисапларны да франк вә сантим илә йөртә башлады. Әлегә чаклы тукталып торган кибет сәүдәләре, шул француз аршыны берлән үлчәп сата башлагач, хикмәте хода, көннән-көн алга китеп, Батыргали агай кибетенә, алучы күплектән, сыеша алмый башлады. Батыргали агай, француз саны илә эшләрнең алга киткәнен күргәч, французларга тагы да мәхәббәте артыбрак, вывескаларны да французча яздырып куйдырды. Бу ел чамасы Мәкәрҗәдә товарны арзан алгандыр дип, приказчиклары да да һич илтифат итми, хуҗалары кушканча, рус аршыны хакына француз аршыны илә сата бирделәр. Әмма, тутый кошча йөрим, дип, үз йөрүеннән адашкан саескан кебек, Батыргали агай да уналты вершок бәһасы илә егерме ике вершок товарны сату бик файдалы түгел икәнен годовой хисап вакытында гына аңлады!

Батыргали агай үзе асылда Казан губернасында М... карьясеннән булса да, Казанда кибете һәм үз йорты булганга күрә, күптән бирле Казанда тормакта иде. Урта буйлы, зәңгәр күзле, кызыл сакаллы, юан тавышлы, бик зур тукмак борынлы һәм бигрәк тә юан бер корсакка хуҗа булган илле яшьләр чамасында бер кеше иде. Кышның каты суыкларында зур борыныннан күп зәхмәт чиккән кебек, җәйнең эсселәрендә һәм чамадан тыш юан корсагыннан Батыргали агай бик рәхәт күрми зарлана торган иде. Чөнки, утыз градус эсседә мичкә юанлыгы корсакны күтәреп йөртүе бик җиңел булмаган шикелле, утыз-утыз биш градус суыкларда һәм шул мөбарәк борынны өшетмәенчә саклап йөртүе бик мөшкел булып, күбесенчә Батыргали агайның борыны өшеп, тиресе кубарчыкланып кутырлаудан чыкмый торган иде. Дөнья йөзендә гыйлем-һөнәрнең, осталыкның шулкадәр алга китеп, телефон, граммофон вә башка төрле машиналар чыгып кайнап торган бер заманда, кышның каты суыкларында колак белән борынны суыктан саклап, өшетми торган простой гына бер футляр чыгарырга зиһеннәре җитмәгән немецларга, англичаннарга ачуы килеп, күп вакыт Гыйсмәтулла кодасына шул турыда зарланып сөйли торган иде.

---

* Метр — 22 вершокка туры килә торган француз үлчәведер. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе).*

* * *

...елда бурлар белән инглизчаннар сугыша башлады. Сабан туенда чабып өйрәнгән ат ничек яз башы житеп, сабан туйлары була башласа, чабарга жилкенгән кебек, безнең Батыргали агай да бу сугыш хәбәрен "Шушма башы"нда укыгач, барлык сәүдәсен, эшен онытып, төн-көн йокламастан, уенда, сагышында шул сугыш кына булды. Чөнки "Шушма башы" газетасы, ач күзле инглизчаннар Жәнуби Африкада Трансвааль * хөкүмәтенең алмаз һәм алтын чыга торган жирләренә тамгы кылып, һичбер гөнаһлары булмаган бурларга жәбер вә золым белән сугыш ачдыкларыны, мазлум бурларга һәркем кулыннан килгән кадәре теләсә мал белән, теләсә кул куәте белән ярдәм итәргә, булышырга тиешле идекене, бик ачык һәм озын вәгазьләр язып, укучыларга анлатмакта иде. "Шушма башы" укучылары көннән-көн инглизчаннарга дошманлыкларыны арттырып, кыңгыр карый башладылар. Болар эчендә иң беренчесе, әлбәттә, Батыргали агай иде.

Сугыш башлаганнан бер-ике атна чамасы вакыт үткәч, беркөнне Батыргали агай тире-яры илә сату кыла торган Иван Шубин дигән бер дус урысы илә "Золотой якорь" исемендәге өч этажлы биек бер трактирга чәй эчәргә керделәр. Берәр сәгать эчеп, сугыш хәбәрләрен сөйләшеп утыргач, икесенең серләре бик килешеп китеп, Шубин бер рюмка гына коньяк китерергә кушты. Үзенең һәмишә алыш-биреш кыла торган кешесе булгач, Батыргали агай, Шубинның сүзен аяк астына саласы килмәенчә, берәрне генә жибәрергә риза булды. Шубин да, Батыргали агай кебек, инглизчаннарны бик дошман күреп, бурларга мәхәббәт итә торган адәм иде. Әүвәл бурларның саулыгына һәм өстен чыгып инглизчаннарны кыруларына берәр рюмка жибәрделәр. Аннан соң залим инглизчаннарның аяк астына калып, жиңелүләре өчен рюмкаларны бушаттылар. Бурларның рәисе Кругерның да исәнлегенә эчми калдыруны һәм килештермәделәр. Рюмкаларның саны күбәйгән саен, бурларга мәхәббәт, инглизчаннарга дошманлыклары арта барган кебек, Батыргали агайның әфлисун төсендәге зур борыны да коричневый, ягъни чөгендер төсенә керә башлады. Дингездә шторм, давыл буласын капитаннар барометр дигән кораллардан анлап, хаталык илә корабларны ташка бәрдереп һәлак кылудан куркып, диңгез кырыена яки бер тау ышыгына барып якорь салган кебек, Батыргали агайның да холкын, фигылен белүче дус-ишләре, борынының чөгендер төсенә кергәнен күргәч, кычкырыш-сугышның якынлашдыгыны белеп, берәм-берәм бүрекләрене алып,трактирның икенче бүлмәсенә күчә башладылар. Чөнки шундый вакытларда Батыргали агайның күзләрен кан басып, үзенең белгән-күргән дус адәмнәре дә күзенә дошман булып күренгән кебек, ялгыш бер-бер хилаф сүз әйтсә дә , хәзер тавыш чыгарып, алдындагы бутылкалары илә көзге, мебель вә гайре жиһазларны кыра башлыйлар иде.

Бу көндә Батыргали агайның йөрәгендә ватан мәхәббәте, бурларга дуслыгы шулкадәр кузгалган иде ки, инглизчаннарга ачуы килеп, ике рюмка илә бер тарелканы идәнгә бәреп ваткан иде. Эш бу рюмкалар вату белән генә калса, бәлки, ул кадәр зурайммаган булыр иде. Әмма эш бу рюмка ватулар белән генә калмады. Гөнаһ шомлыгына каршы, шул арада гостиницаның эчтәге бер бүлмәсеннән озын буйлы, бик арык тәнле, сары сакаллы, авызына кыйммәтле "Гавана" сигарын кабып, бик кәеф корып "Международный банк"ның директоры мистер Робинсонның үтеп барганын Батыргали агай күрмәсенме? Бу инглизчанны күргәч тә, Батыргали агайның каны куерып, күзләрен кан басып, әүвәлге дошманлыгы тагы да артыбрак, ачуыннан барып бугазына ябышырга житте. Чөнки, бер яктан, нахак жирдә бурларга золым кылып, сугыш ачканнары өчен ачуланган кебек, икенче яктан, берничә көн әүвәл учетка * керткән вексельләрен алмаенча кире кайтарганга, Батыргали агайның бу инглизчанда үче дә бар иде. Башына киләчәк бәлане белсә, бу

---

* Трансвааль — кечерәк кенә, бур дигән халыкларның жиредер. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

* Учет — банкка кертеп, вексель сатуга әйтеләдер. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

адәм, бәлки, Батыргали агай утырган залдан үтмәгән булыр иде; әмма киләчәк казаны кайдан белсен? Батыргали агай, бик тирән уйламастан, утырган урыныннан сикереп тә торды, йөгереп барып бичара зәгыйфь бәдән инглизнең җилкә тамырыннан сул кулы белән кысып тотып, аягын җиргә тигезмәстән, җилтерәтеп, өстерәп алып барып, трактир коридорының урамга чыга торган икенче этаж баскычына житкәч, уң кулы илә җилкәсеннән кадап та җибәрде!.. Бичара адәм биек баскычтан баш түбән мәтәлеп төшкәндә, түбәнге этаждагы трактирның кухнясыннан югарыдагы кунакларга зур миски илә балык солянкасы күтәреп, баскычтан менеп килүче картрак бер половойга бәрелеп, икесе дә бергә шалдыр-шолдыр түбәнге баскычка кадәр мәтәлчек аттылар, половой кулындагы миски йөзгә ватылып, икесе дә балык шулпасына чумдылар. Бу кадәр гөрелдәгән тавышка барлык трактирдагы халык илә урамдагы халык та күбесе җыелды. Полициягә дә хәбәр бирделәр. Безнең Батыргали агайның банк директоры инглизчан Робинсон дип трактирның икенче этаж баскычыннан аркасыннан кагып хөрмәтләп озаткан кешесе сәгать остасы Абрам исемле яһүди икәнлеге околодочный тарафыннан протокол язганда гына мәгълүм булды!.. Батыргали агай үзенең азрак хата эш эшләгәнен соңыннан аңласа да, нә файда, эш эштән кичеп, бичара һичбер гөнаһсы булмаган Абрамның баскычтан баш түбән төшкәндә бәрелеп ике теше сынган һәм югарыгы иреннән бармак башы кадәр ите өзелеп салынып тормакта иде.

Бу вакыйга шәһәр халкына бер-ике атнагача сөйләргә, тикшерергә, бер-берсе илә кычкырышырга эш булды. Бәгъзы халык Батыргали агайның бу эшен мәдех кылып, мактап сөйләмәктә, бәгъзылары коры ахмаклыктан башка һичбер файдасы юклыгын бәян кылмакта иде. "Шушма башы" газетасы бу турыда Батыргали агайны бер атаклы каһарман, ватан пәрвәр кебек мактап озын-озак статьялар язды.

* * *

Россиянең бер өязенә караган халыктан артмаган, ягъни ике йөз мең чамасындагы бурлар, дөньяда иң зур патшалардан саналган инглизчаннарны дер селкетеп, өч ел кадәр сугыштылар. Аурупага, Америкага илчеләр җибәреп, үзләренең эшләре хаклыкта, тугрылыкта, инглизчаннарның нахак җирдә золым кылып җәбер иттекләрен сөйләп, башка патшалардан ярдәм теләсәләр дә, нә файда? Гәрчә, бурларның илчеләрене Аурупада һәм Америкада күп хөрмәт итеп, яхшы каршы алып, кунак итеп, "ура" кычкырсалар да, акча илә, корал һәм солдат биреп, бер тиенлек ярдәм, булышлык кылган адәм булмады. Ахырында бичара, гөнаһсыз бурлар, инглизчаннар аягы астында изелеп, Трансвааль исемендәге хөкүмәтләре дә инглизчан җире булды да калды...

* * *

Көннәр, айлар, еллар кичте. "Шушма башы" һәмишә татарларның эшсезлегеннән, ялкаулыгыннан, фәкыйрьлегеннән, фанатиклыгыннан һәм бу килешле заманасына кирәкле һөнәрләрне укымаенча рус мәктәпләренә, гимназияләренә кереп, гыйлемлек алмыйча, русча белмәенчә йөреп, ахыр бер көнне һөнәрле халыкларның аягы астында таптылып, изелеп юкка чыгачагыннан бәхәс кылып язмакта иде.

Менә бервакытны, җәй көннәрендә, көнчыгыш ягында кич белән күктә кызыллыклар, койрыклы йолдызлар, башка төрле галәмәтләр күренә башлады. Бу кызыллыкны, койрыклы йолдызны күргәч, һәр җирдә кара халык, хатын-кыз, бала-чага, шау-шу итеп, куркыша башладылар. Бәгъзысы хәзрәттән, бәгъзысы күргән тәҗрибә иясе картлардан, карчыклардан бу кызыллыкның сәбәбе ни икәнен сораша башладылар. Дөньяда житмеш-сиксән ел гомер сөреп, сука сукалап, урак урудан, каравыл ызбасына җыенга барып көтүче яллаганда, син белмисең, мин беләмен, дип кычкырышудан башка һөнәре булмаган Бикбау картлар, өшкерүче-төкерүче, бала тапмаган хатыннарга сукыр кычыткан, тиле бәрән орлыгы, әрекмән яфраклары кайнатып

эчереп, дару кыламын, бала таптырамын, диеп, бичара хатыннарны гомерлек авыруга, гомерлек җәфага салучы Бану карчыклар, пәйгамбәрлек кылып, сугыш, ачлык, ваба булачагыннан хәбәр бирә башладылар. Һәр җирдә, һәр авылда кара халык җыелышып: "Бу күктәге кызыллык, койрыклы йолдыз бушка түгел инде, ни булса да, сугыш, ваба галәмәте инде, ахыр заман алдында шундый кызыллыклар-фәләннәр булыр дип, мәрхүм карт хәзрәтләр әйтә торган иде. Ахрысы, шул заманнар җитте инде, уф алла, дөнья куып булмас, барлыюклы калган гомеребезне хода юлында гыйбадәт кылып, тәүбә тәзаригъ кылып уздырырга кирәк. Үзебез ризыклар өчен бер-ике дисәтинә ашлык саксак, житәр, тулы әмәл илә балаларыбыз өчен ашлык хәзерләп, мал җыеп калдырыйк, диеп йөрергә ярамас. Артык җирне һәм печән чаба торган болынлыкны, тугайлыкны күрше авыл урысларына яки чирмешләренә сораган хакларына сатарга кирәк, фәлән..." — дию кинәшә һәм сөйләшә башладылар.

Күңелгә килгән алга килә, диләр, бар да дөрес. Күктә күренгән кызыллыкның, койрыклы йолдызның ни сәбәптән булганы аңлашылды. Күп вакыт үтмәде: Порт-Артур дигән шәһәрдә Россиянең сугыш корабларына төннең караңгысында япон дигән халык, һич сугыштан хәбәр итмичә, килеп мина салып, бер-ике корабны тишкәненнән газеталар хәбәр бирделәр. Ничә йөз елдан бирле дөньяда беренче дәрәҗәдә булып килгән Россия хөкүмәтенә диңгез эчендә атауларда мең еллардан бирле һич исеме-фәләне ишетелми яткан кечерәк кенә бер япон дигән халыкның искәрмәстән килеп сугыш ачуы Россиягә һәм бөтен Россиягә караган халыкларга бик зур хурлык булды. Бөтен Россия шау итеп: "Бу эшне болай калдырырга ярамый, японнарга русларның кем икәнен бик яхшы таныйтырга кирәк, японнарны, Манчжуриядән сөбереп, диңгезгә түгәргә кирәк; ах, мичтә арыш сугучы макакалар (маймыллар), ничек батырчылык кылып, безнең белән сугышмакчы булалар икән, аларга бик яхшы сабак укытырга кирәк, икенче очраганда бик ерактан сәлам бирерлек булсыннар, фәлән" — дип, һәр җирдә халык сөйләшә башлады. Газеталар, кыямәт купкан шикелле, төрле-төрле хәбәрләр, бик күп ялганнар яза башладылар. Бәгъзысы биш йөз мең, бәгъзысы миллион солдат җибәрергә кирәк, дөньяда япон исеме калмасын, японнарны кырып бетерергә кирәк, фәлән, дип яздылар. Россиянең түгел шәһәрләрендә генә, хәтта иң ерак вә иң эчтәге авылларында да ватан мәхәббәте кузгалып, сугыш өчен һәр шәһәрдә, һәр авылда кием-салым, ашлык, акча вә гайре солдатка кирәк нәрсәләрдән җыеп бирә башладылар. Һәр шәһәрдән, һәр авылдан запасной солдатларны җыеп сугышка җибәрә башладылар. Сакалы агара башлаган запаснойлар да, һич тартынмыйча, аурaймыйча, туган җирләре өчен камил мәхәббәтләр белән, сабан туена барган кебек, шатлана-шатлана, актык тамчы каннары калганчы сугышу нияте илә, японнарга каршы сугышка китә башладылар. Бик күп авыллардан, бик күп шәһәрләрдән солдат булмаган адәмнәр дә, туган җир өчен җанын-тәнен фида кылып, ата-анасын, бала-чагасын, сәүдәсен һәм эшен ташлап, үз ихтыярлары белән добровольный булып язылa башладылар. "Шушма башы" газетасы да японнарны англичаннар котыртып сугыш ачканлыклары турысында озын-озын нәсыйхәтләр язып, бөтен Россиядә булган урыс, татар, яһүди, башкорт, поляк вә гайре милләт һәммәсе бертуган кардәш кебек бер җан, бер тән булып, туган җиребезгә һөҗүм кылучы дошманга каршы торып сугышу фарыз икәнен төрле-төрле йогынлы сүзләр илә халыкка аңлата башлады.

"Шушма башы" укучылары японнарга һәм котыртып сугыш башлатучы англичаннарга шулкадәр ачуландылар ки, хәтта күзләренә бер англичан күренсә, терелəй тотып ашарлар иде. Хосусан, Батыргали агайның сугыш башланганнан бирле күзенә йокы кермәс булды. "Егерме сигезенче гыйнварда, японнар сугыш булачагыннан һичбер хәбәр бирмәенчә, караңгы төндә килеп, юл басучы разбойниклар кебек, безнең сугыш корабларына мина салып, ничә җирдән тиштерделәр", — дигән хәбәрне "Шушма башы"нда укыгач та, нишләргә белми, базардан гайрәтләнеп кайтып, иң әүвәл үзенең залындагы көзге алдында тора торган Мәкәрҗәдә алган бик кыйммәтле һәм нәфис

* Ваза — гөл банкасы кебек озынча һәм бизәкле матур савыт буладыр. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

японский вазаларны * идәнгә күтәреп бәрде. Аннан соң шкафта никадәр японский аталган кыйммәтле чәйнек, чынаяк, тарелка һәм шкатулка бар булса, берәм-берәм барын да ватарга тотынды.

Шалтыр-гөлдер иткән тавышка хатыны Җомабикә абыстай йөгереп кереп, күзе илә бу эшне күргәч, хәйран калды. Җомабикә абыстайның кергәнен күргәч, Батыргали агай, кала алган кебек, кукрәгән киереп: "Ха! ха! ха! Менә японнарга, менә макакаларга! Ахрысы алар безне куркак халык дип уйлый торганнардыр. Менә япушкаларга, менә мичтә арыш сугучы макакаларга!" — дию, кызып китеп, шкафта сәламәт калган кыйммәтле Кузнецовский чәйнекләрне вә гайре посудаларны да вата башлады.

Бәлки, эш тагы да зурракка киткән булыр иде, әмма стенадагы кыйммәтле зур көзгеләрнең, түшәмдәге зур лампаларның гомере бетмәгәнгә каршы, шул арада почтальон кереп хатлар тапшырды. Шул хатлар арасында "Шушма башы" газетасы да бар иде.

Батыргали агай, "Шушма башы"нда тагын сугыш турысында ят хәбәрләр юкмы икән дип, куен кесәсеннән күзлеген алып күзенә куйгач, газета укырга кереште. Беренче битендә үк эре хәреф илә басылган ошбу хәбәр күзенә төште: "Японнар белән сугыш башланганны ишеткәч тә, Уфа губернасында, Мәмәткол авылында җитмеш яшендәге Җомагыл исемле Николаевский бер башкорт солдаты, туган җиребезгә мәхәббәте камил бөтен улганлыктан, алты улы белән сигез кызын ташлап, добровольный * булып язылып, Порт-Артурга сугышка китте. Ай яшьләр, и мөселманнар! Җомагыл картка карап гыйбрәт алыгыз! Хәзер мич башында кабырганы җылытып, арканы кыздырып ята торган вакыт түгел, аяк-кулыгыз сәламәт булганнарыгыз, әйдә, марш сугышка!".

Бу хәбәрне укыганда, Батыргали агайның тамырларындагы каннары кайнап, үзен-үзе белмәенчә гайрәтеннән йөрәге "дөп-дөп!" сикермәктә иде. Әгәр дә мөмкин булса, ягъни Порт-Артурга шул сәгатьтә алып барсан, берничә минут кына әүвәл японнарның посудаларын кырган кулындагы таяк илә японнарның адмиралы Тогоның башын сугып ярырга хәзер иде. Шулкадәр ватан (туган җир) мәхәббәте кузгалган иде.

Шул арада хатыны Җомабикә абыстай, идәндәге сугышта һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән посудаларны җыйнап, кухняга чыгып китте. Дүрт чәйнек, ике ваза, алты пар чынаяк һәлак, тугыз тарелка илә өч чәйнек каты җәрәхәтле булган иде.

Хатыны кухняга чыгып киткәнне күргәч, Батыргали агай, залда арыбире йөреп, үз-үзенә шушы рәвештә сөйләнә башлады: "Китәмен, мин дә китәм! Сугышка добровольный булып китәмен. Мин кемнән ким? Җитмеш яшендәге башкорт сугышка үзе теләп китсен дә, Казанский первой гилдий купец Батыргали Шалканов Казанда хәбәрсез рәхәтләнеп ятсын! Шушындый дошманнар туган-үскән җиребезгә ут ачып, кылыч күтәреп, сугыш кылган заманда, сату итәмен, файда кыламын, диеп, Казанда яту хурлык түгелме? Сату-алу шайтанга да китмәс әле, сатудан бигрәк туган-үскән җирне сакларга тырышырга кирәк. Юк, юк, бер минут та монда ятарга ярамый. Тизрәк сугышка, уррррра!!

Тукта әле, алдан бик кычкырырга ярамас, сиздермәстән, шыпырт кына сызарга кирәк. Югыйсә безнең бикә кәҗәләнә башлар. Хәтта түгел кәҗәләнү генә, алла сакласын, бөтенләй юлдан туктатыр. Англичаннар белән бурлар сугышкан вакытта да, бурларга ярдәм итәргә дип тәмам к тугә хәзерләнгәч, юлымнан туктаткан иде. Юк, юк, анарга әйтергә һәм белгертергә ярамас, башкача бер хәйлә табарга кирәк. Әгәр дә хәҗтә сәфәр кыламын дисәм, ничек булыр икән? Ә, юк, юк! Алай ярамый, хәҗгә китәмен дигән сүзгә ышанмас, моннан әүвәл дә шулай, кай елны соң әле, Мотыйгулла кода коршау аткан елныны, хәҗгә барам дип китеп, Москвада шул... корсак Галиәкбәр бай белән эләгеп китеп, адәм рисвае булып кайткан идем. Тукта әле, нинди генә хәйлә табарга кирәк соң? Ә, әгәр дә Мәкәрҗәгә барам

---

* Добровольный — сугышка үзе теләп киткән кеше. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе).*

дисәң, хәзер Мәкәрҗә вакыты түгел, бу тагын туры килми. Тукта, тукта, таптым! Таптым! Әтнәнең Искәндәр хажи киләсе җомга көн мәҗлесенә чакырган иде. "Мәликә кодагыйларда өч-дүрт көн кунак була торырсың" дип, бикәне алдан шунда озатырга кирәк. Кунакка барырга дисәң, аның дөньясы җитәдер. Сәмигулланы да анасы илә бергә җибәрергә кирәк, барыбер монда да әтәч сугыштырудан, күгәрчен очырудан башка эше юк. Сатуалуның да рәтен белмидер, тире-яры алырга кушсам да, бер нәрсә белмидер. Былтыр да Әтнә базарыннан көя ашаган кәҗә тиресе илә укралы сыер тиресе җыеп кайткан иде. Аларны кунакка озаткач кына, мылтык белән кылычны һәм дә хәнҗәрне тагып һәм юл кирәкләрен хәзерләп, губернатордан кәгазь алырга да, добровольный булып, әйдә Порт-Артурга!.."

* * *

Май аеның бишенче көнендә, иртә белән сәгать уннарда Печән базарыннан юан корсаклы, зур борынлы, кызыл чырайлы, бик озын һәм тутыгып беткән кылыч, дүрт көпшәле, борынгы формалы пистолет таккан, бер мылтыкны җилкәсенә куйган, өстенә серый шинель, аягына озын балтырлы күн итек кигән бер адәм ашыга-ашыга губернатор йортына таба үтеп бармакта иде. Печән базарында, кибет алдында торучы кечерәк малайлар, аю күргән кебек, бу гаҗәп кыяфәтле адәмнең артыннан иярә башладылар. Печән базары мәчетенең каршысында, әгъла читек-кәвеш, чиккән кәләпүш, җиз комганнар сатыла торган бер зур кибет алдында, ак альяпкыч бәйләгән бер кибетченең, тотлыга-тотлыга, "Шушма башы" газетасын укыганын бер карыш авызларын ачып тынлап торучы башка кибетчеләр дә, бу юан корсаклы, кылыч, мылтыклар таккан адәмне күргәч, үзара пышын-пышын сөйләшә башладылар.

Арадан берсе: — Бу кем икән? Бу кешене бер күргән кебек буламын, карасана, хәтеремнән чыкты ла, кайда гына күрдем иде соң?

Икенчесе: — Корсагына караганда, мәчет, мәдрәсә яисә башка хода юлында йөрүче адәмгә бик охшап бетмидер, кайда да булса портерныйда яки трактирда сыра эчкән вакытында күргәнсең, корсагы сыра мичкәсенә бик охшаган икән.

Өченче кибетче: — Тукта әле, бу соң безнең Мотыйгулла абзыйның кодасы Батыргали агай түгелме? Шул, шиксез шул! Йә раббым, ходаем, бу кораллар, бу кыяфәт илә кая бара икән? Әллә тагын сугышка барам дип котырына микән? Шиксез, шундый бер җиргә китмәк була торгандыр, бу көннәрдә Сәрби карчык безгә килеп сөйләгән әле: "Батыргалиләргә барган идем; сугыш башланганнан бирле һәмишә ничек кенә өйдә ялгыз калды исә, залында идән буенча: шагум арыш! кругум! пли! дип, солдат уены уйный, имеш", — ди.

Әүвәлге кибетче: — Хәер, кыяфәтенә караганда, солдат булырга да охшыйдыр; тик бераз корсагы зуррак, казенный шинель (чикмән) таррак булыр...

Икенчесе: — Корсагының зурлыгыннан һичбер зарар юк; әгәр дә барабанщик кылсалар, барабан да кирәкми, тик барабан суга торган ике палка гына кирәк, чөнки корсагы турецкий барабаннан да шәбрәк.

Бу сүзгә һәркайсы шаркылдап көлештеләр.

Әүвәлге кибетче: — Корсагының зурлыгының бигрәк тә зур файдасы шул булыр: сугышта бит әнә ышыкланып мылтык атарга тау кебек туфрак өяләр, ди, ә моның корсагы, туфрак өймичә дә, Ослан тавы кебек. Беләсезме, моның корсагына ничә солдат ышыкланырга мөмкин? Аз, дигәндә, ун солдат.

Янә "Ха! ха! ха!" дип көлештеләр. Үзләре күрмәгән, танымаган яхут азрак простой киенгән бер адәм күрсәләр, "Өяз агай, сала абзый", — дип кешедән көлүче бу Печән базары кибетчеләре, үзләренең гадәтенчә, Батыргали агайны да аркылысын-буен, кием-салымын, корсагын, башка нәрсәсен үз аршыннары белән үлчәп, үзләренчә хөкем кылып озаттылар. Белмим ничектер, Батыргали агайның мөбарәк борынына боларның күзе төшмәде, югыйсә борынына да әллә ничә төрле исемнәр кушып, берсе чөгендергә, икенчесе

кишер, өченчесе Һиндстанда үсә торган помидорга охшатып, аркылысын-буен, авырлыгы ничә кадаклыгын, борын тишекләренә сыерчык яки чәүкә кебек кошлар оялый алып-алмаучылыгына кадәр бәхәскә, сүзгә керешерләр иде. Чөнки болар кешене киеменә һәм тышкы күренешенә карап хөкем кылалар. Үзләре кебек шома киенеп, сәгать таккан кеше булса, болар каршында иң акыллы, иң белекле вә иң кадерле кеше саналадыр, боларның карамагында безнең Батыргали агай бер мужик, һичбернәрсә белмәгән бер кеше иде. Әмма, чынлап уйлап караганда, Батыргали агайның исемен алтын путал илә язып, кыйммәтле рамкаларга куярга, хәтта ошбу сугышта вафат булса, аның исеменә Печән базарының иң күп халык кайный торган бер җиренә мәрмәр ташыннан памятник салырга Казан халкы шик вә шөбһәсез бурычлы иде. Түгел Казан халкы гына, хәтта бөтен Россиядә булган татарлар бурычлы иде. Чөнки Россиядә булган унбиш-егерме миллион мөселман эченнән, туган җире вә патша юлында бала-чагасын, йорт-җирен, сәүдәсен ташлап, үз ихтыяры белән сугышка китүче купецтан, байлардан Батыргали агай беренче иде.

Батыргали агай туры ук губернаторның канцеляриясенә барды. Юлда барганда, Батыргали агайга бәгъзы белеш-таныш руслары очрап, баш алсалар да, Батыргали агай, бүркен алмаенча, солдатлар кебек, военный честь кына биреп үтә иде. Губернатор канцеляриясендә халык бик күп булып, кайсы прошение бирергә, кайсы башка йомыш илә килгән иде. Мылтык-кылычлар таккан Батыргали агай килеп кергәч тә, халык һәркайсы, гаҗәпсенеп, шаккатып калдылар. Берсе икенчесе илә пышын-пышын сөйләшә башладылар. Бәгъзысы, мыек астыннан гына көлеп: "Менә Манчжуриягә командир кылып җибәрергә муафыйк кеше, японнар моның корсагын күргәчтән үк качарлар иде". Губернатор канцеляриясендә прошение илә килүчеләр һәмишә артмакта иде. Тәгаен кылынган сәгате җиткәч, губернатор приемныйга чыкты. Иң әүвәл күзе Батыргали агайга төшеп, ни йомыш илә килгәнен сорады.

Батыргали агай, бер-ике мәртәбә тамак кырганнан соң, шушы рәвештә сүзгә башлады:

— Хөрмәтле губернатор хәзрәте! Мәгълүмегездер, безнең Пуртапур (Порт-Артур) дигән калада кардәшләребез, җирдәшләребез актык тамчы каннары калганча, япон дигән дошман илә сугышып, кырылышып яталар, Русиянең һәр шәһәреннән, һәр авылыннан яшьләр һәм җитмеш яшендәге картлары, үзләре теләп, сугышка, дошманга каршы китә башладылар. Шулар шикелле, минем дә ватаныма мәхәббәт тамырларым кузгалып, төн йокысы күземә кермәс булды. Бөтен йорт-җиремне, бала-чагамны, җәмәгатьләремне, сәүдәмне ташлап, туган җиребез өчен җанымны фида кылып, сугышка китәргә хәзерләндем. Шул сәбәпле сезнең хозурыгызга килдем, мине добровольный гаскәр кылып кабул кыла күрегез.

Губернатор, бик озак Батыргали агайга карап торгач вә елмаеп көлгәч:

— Молодец, князь, молодец! Сезнең кебек туган җиренә вә падишаһына мәхәббәтле адәмнәрнең күбрәк булганы яхшы. Сезнең кебек гайрәтле һәм куркусыз кешеләрнең минем карамагымда булган Казан губернасында бар булуына да бик сөенәмен, бик шатланам. Әмма шулай булса да, хәзер сезнең сораган нәрсәгезне урынына китерә алмыймын. Чөнки бу эш турысында министрдан сорарга кирәк. Бу минем кулымдагы эш булса иде, бер сүз әйтмәстән, сине, ротный командир кылып, Манчжуриягә сугышка җибәрер идем.

"Ротный командир кылыр идем", — дигән сүзгә Батыргали агайның бик кәефе килеп, гүя чыннан ук ротный командир чинын алган кебек булып, күкрәген киереп, бер тамак кырып та куйды.

Губернатордан чыккач, Батыргали агай туры үзенең бер белгән урысына барып, бик озын кылып, министрга телеграмма яздырып бирде. Батыргали агай сораган йомышына министрдан шөбһәсез үзе теләгәнчә җавап килүне дүрт күз илә көтмәктә иде, әмма аннан да шатлык хәбәре килмәде. "Петербургта министрлар бер генә булмаган сәбәпле тапшырылмады" дип телеграмма тапшырылмыйча кире кайтты.

— Инде нишләргә кирәк? Сугышка, дошманга каршы туган җиребезне

сакларга барырга рөхсәт бирмиләр! Юк! юк! Болай юлда калдырырга ярамый, рөхсәтсез булса да, Пуртапурга тизрәк китәргә кирәк. Анда баргач, Куропаткин хәзрәте, иншаллаһ, кире кайтармас, кабул итәр, инде монда бер минут та торырга ярамый, тизрәк заманалар тыныч вакытта сызарга кирәк. Инде күптән Пуртапурда булыр идем дә, шул Шубинга карап калдым. Бәлки, ошбу көннәр аның да эше бетәр, аның илә бергә китсәк, яхшырак булыр. Бикәне кайда булса да кунакка озатырга кирәк.

Казанда, Усиядә, иртәдән үк пароход пристаньнарында халык күплектән, ары-бире үтеп йөрерлек түгел иде. Яшь-карт, бала-чага, хатын-кыз белән Усия тулы иде. Бәгъзысы кычкыра-кычкыра сөйләшмәктә, шаркылдап көлмәктә вә бәгъзылары, хосусан, хатын-кызлар, елашмакта иде. Чөнки бүген запасный солдатларны Манчжуриягә сугышка озаталар иде. Солдатларның бәгъзылары ата-анасы илә, бәгъзысы хатыны һәм кардәш-кабиләсе илә бәхилләшмәктә, актык нәсыйхәтләрен әйтешмәктә иделәр.

Казан халкының күбесе карар өчен, тамаша кылыр өчен генә килгән иде. "Кавказ-Меркурий" пароход компаниясенең каршысында гына, ике этажлы "Волга" исемендәге трактирның балконында, ике бик юан кешенең утырганы күренмәктә иде. Боларның өстәлендә ике-өч бутылка "арыслан сөте" илә төрле закускалар да хәзер иде. Болар, бик гайрәтләнеп-гайрәтләнеп, сугыш хәбәрләрен сөйләшәләр иде.

Бу ике адәмнең берсе безнең пәһлеван Батыргали агай, икенчесе Иван Шубин иде. Шубинның судтагы эшләре бер атна әүвәл генә беткән иде. Судка бәйләнүенең сәбәбе ошбу рәвештә улды: урыслар белән японнар сугышка башлаган көннәрдә, юлдашлары илә Шубин беркөнне "Казан" дигән гостиницада ашап утырганда, эчләрендә Морис исемле бер маклер, политикага керешеп китеп, англичаннарны мактый башлады. "Дөньяда англичаннар кадәр бай, диңгездә куәтле, күп кораблы патша юк; алар диңгездә балык кеби йөзәләр, фәлән", — дип спорлаша башлады. Англичаннарны яратмаган Шубинга бу сүзләр бик хурлык булды. Әүвәл, эндәшмәенчә, тынлап кына утырса да, зур миски белән дүрт порция кайнар балык солянкасын половой боларның өстәленә китереп куйганны күргәч, Шубин, ачуына чыдый алмыйча, сикереп торып: "Ах ты, Куроки! Ах, Гладсон *, менә руслар англичанның корабларын шулай диңгездә астын-өскә китерәләр", — дип, өстәлдәге миски илә солянканы күтәреп Морисның башына каплады да куйды. Өч айдан соң Шубинның суды булды. Шубин үзен аралау өчен, Казанда беренче дигән адвокатны күп акча биреп яллап, "патриотизм" бәласеннән коры гына котылмак булса да, суд ике йөз сум штраф илә ике атна арестка хөкем кылды. Арестның срогы тулып чыккан көнне үк добровольный булып сугышка китәргә Шубин ант итте. Батыргали агай кебек, Шубин да, губернатордан рөхсәт сорарга барса да, юньле-башлы җавап ала алмады. Ахырында Батыргали агай илә икәү бергә, язылмыйча һәм кешегә-карага, дус-ишләргә сиздермичә генә, сугышка китмәк булып, вәгъдә куештылар. Чөнки дус-ишләренә сөйләсәләр, берсеннән икенчесе, өченчесе ишетеп, озатырга төшәрләр, аннан соң хәбәр бөтен шәһәргә таралмак кирәк. Батыргали агайның нияте, кеше-карага белдермәстән сугышка китеп, берничә айдан соң искәрмәстән генә күкрәге тулы "Ягорский крестлар"ны * тагып кайтмак иде. Чөнки Батыргали агайның Георгиевскийның кадерле икәнен ишеткәне бар иде.

Бүген китә торган запасныйлар илә Батыргали агай илә Шубин да бергә китәргә дип хәзерләнеп, Усиягә төшкәннәр иде. Пароход китәргә ике-өч сәгать вакыт калган сәбәпле, болар, бераз кәеф кылыр өчен, югарыда әйтелмеш трактирга кергәннәр иде.

Трактирда берәр сәгать утырып, берсенең борыны чөгендер, икенчесенең коричневый төсенә керә башлады. Шул арада болар утырган трактирның

* Куроки — японнарның генералы. Гладсон — англичаннарның вафат улмыш министрыдыр. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

* Георгиевский диячәк жирдә, Батыргали "Ягорский" ди торган иде. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

балконына өч запасный татар солдаты кереп, болардан ерак түгел икенче өстәл янына утырып, чәй сорадылар. Берсенең өстендә серый солдат шинеле, аягында сары күн итек, икенчесенең өстендә искерәк кызыл бишмәт, аягында чабата иде. Өченчесе, бу ике юлдашына караганда, яхшырак киенгән иде.

Бу өч запасный кереп утыргач та, Батыргали агайның кәефе бозылды. Чөнки ул үзе кебек юан корсаклы булмаган кешеләрне кешегә хисап кылмыйдыр иде. Дәрхаль шул турыда Шубинга зарланып сөйли дә башлады. "Ни өчен мондый алама киемле ярлы кешеләрне безнең шикелле, туган җире өчен җанын фида кылып, үз ихтыяры илә сугышка бара торган байлар янына кертәләр икән? Кара инде син боларны, ни дип сугышка җибәрәләр икән? Болар сугышта нишли алалар инде? Менә минем белән сине, үз ихтыярыбыз илә барабыз, дисәк тә, кабул кылмыйлар. Без бер сукканда японнарның биш-унысын кырып салыр идек. Ә бу манкаларның кулыннан ни килер!" Фәкать, Батыргали агай бик гакыллы баш булып, шулай хөкем кылса да, үзе кебек бер ашаганда унбиш кадак елкы ите ашап, ике чирек кымыз эчеп, җомга намазларында "голдыр-голдыррр!" кикергән өчен, әдәплерәк адәмнәрдән: "Тфү, бирәнгә сапкыры! Шулкадәр корсагы ярылганчы тыгынмаса, ярамыймыни соң?" — дигән сүзне ишетүдән, хәерчене капкадан керткән өчен яисә бер шакмак шикәрне артык бетергән өчен, тубыктан түбән салындырган чалбар балагы өчен тамаклары карылганчы приказчикларын сүгүдән, атналап эчеп-исереп, эт булып, шайтанның үзе кылмаган явызлыкларны кылып, "Базар күмәче мәкруһ түгелме? Сиһшәнбә көн чәч алдырырга, тырнак кисәргә ярыймы?" дип мулладан мәсьәлә сорап, ялган суфыйлык, рия тәкъвалык күрсәтүдән башка һичбер һөнәре булмаган юан корсаклы байлардан әлеге кызыл бишмәтле, сары итекле, арык запасный солдатлар патша хәзрәтнең каршысында кадерлерәк икәненә Батыргали агайның зиһене җитмидер иде.

Половойны чакырып, Батыргали агай бу запасный солдатларны хәтта балконнан кудыртмакчы да булган иде. Әмма шул арада пароход икенче свисток бирде. Шубин илә Батыргали агай, половойны чакырып, бурычларын түләгәч, трактирдан чыкмак булдылар гына түгел, чыга башлаганнар иде. Әмма, искәрмәстән, безнең пәһлеван Батыргали агай, сискәнеп китеп, ап-ак булып үлем чыраена керде. Гаҗәп, ни булды! Нәрсәдән курыкты? Әллә, искәрмәстән, авыру булдымы? Юк, юк, авыру булмады, пристаньда пароход конторы алдына җыелган халык арасында күзенә хатыны Җомабикә абыстай күренде. Һәм, чыннан да, Җомабикә абыстай кайнап торган күп халык арасында, бернәрсә югалткан кебек, бик ихлас илә ашыгып-ашыгып, арыбире бернәрсә эзләп йөрмәктә иде. Батыргали агай хатыны Җомабикәнең бүген монда, Усиядә, булачагын һич хәтеренә дә китермәгән иде. Чөнки ул хатыны Җомабикәне дүрт-биш кенә көн моннан әүвәл бер айга утырмага дип Казаннан йөз егерме чакрым читтәге бер якын кардәшләренә озаткан иде. Аннан тиз кайту ихтималы да юк иде. Батыргали агай үзенчә кешекарага әйтмичә, сөйләмичә йөрсә дә, йорт эчендә йөрүче бер приказчигы, хуҗасының мылтык, кылыч вә гайре нәрсәләр хәзерләп йөргәнен сизенеп, Мотыйгулла кодасына барып әйткән иде. Мотыйгулла кодасы һәм бер минут кичектермичә кодагыйсына ошбу рәвешчә хат язды:

*"Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү булып торучы Җомабикә кодагыйга күп сәлам бәгъдендә үзебезне сау вә сәламәт беләсез, бәгъдә мәгълүм булсын: бу хатны алгач та, бер минут торма, кайта күр, чөнки Батыргали кода тагын үткән елгы кебек тилерә башлаган ахры. Японнар илә сугышырга китәмен, дип, мылтыклар тагып, кылычлар асып йөридер, мылтыкны яхшы атарга өйрәнеп китәмен, дип, һичбер гөнаһлары юк тавыкларыңны кырып бетерде, диләр. Бу көннәрдә сугышка запасный солдатларны озаталар, имеш, җуләрләнеп шуларга ияреп китеп бармасын. Картаймыш көнеңдә сиңа да бик кыен булды инде. Әүвәл нинди яхшы сәүдә илә үз эшендә генә йөри торган кеше тәмам харап булды бит. Шул каһәр суккан, утка яндырасы гәҗит укый-укый харап булды шул. Бар да ахыр заман галәмәте, кай җәһәннәмнән чыкты шул гәҗит дигән нәрсәсе, әүвәл заманда андый шайтан сабаклары юк иде. Укыйсы килгән кешегә "Сәет Баттал", "Кырык вәзир", "Алты*

*бармак" китаплары да җитәрлек иде. Менә, ходага шөкер, без дә торабыз ич әле, гәҗит дигән нәрсәләрен кулыма да тотып караганым юк, углым угыл, кызым кыз, һич кешедән ким түгел. Хода үзенең күңеленә инсаф бирсен инде; безнең кулдан һичбер нәрсә килмидер. Һәрничек бу хатны алгач, тизлек илә кайтырга карагыз, китеп-нитеп бармасын. Хуш, сәламәт буласыз. Язучы Мотыйгулла Алтынбаев дип беләсез".*

Бу хатны алгач та, Җомабикә абыстай бик ашыгып Казанга кайтты. Өенә кереп, иренең юклыгын белгәч тә, тиз-тиз Усиягә, пароход пристаненә төште.

Батыргали агай, хатынын күргәч тә, гүя яшен суккан шайтан кебек, куркып, аптырап калды. Җитмәсә тагын, үч иткән кебек, Җомабикә абыстай шул арада болар утырган трактирга таба килә башлады. Инде нишләргә кирәк? Тизрәк трактирдан чыгып сызудан башка чара юк. Батыргали агай да, тиз-тиз мылтык, кылыч, хәнҗәр һәм калканнарын тагып, "шалтыр-шолтыр" трактирдан чыгарга хәзерләнде. Әгәр дә урам ягындагы зур парадныйдан чыксам, ихтимал, бикәгә каршы очрармын, дип куркып, Батыргали агай трактирның кухнясы аркылы, арттагы ишектән, чыкмак булып, кухняга керде. Батыргали агай, бик исерек булмаса да, яхшы ук кызган, күз аллары томалана башлаган иде. Кухняның миче артыннан тар гына бер юлдан үткәндә, гөнаһ шомлыгына каршы, хатаән аягы абынып, помой салган зур бер лаканга барып батты! Шул арада пароходның өченче свисток биргән тавышы ишетелде. Халык һәр тарафтан йөгерешә-йөгерешә, берсе-берсенә бәрелә-сугыла, пароходка керә башлады. Болар арасында, суга баткан тавык кебек, өс-башы помойга чыланган, киеменең бәгъзы җиренә лакандагы бәрәңге, суган кабыклары ияркән безнең доброволец Батыргали агай илә Шубин да "пуф! пуф!" итеп, ашыга-ашыга, пароходка карап йөгермәктә иделәр.

Бер яктан, хатыны Җомабикә күреп тотар куркусыннан, икенче, пароход кузгалып китү ихтималы булганлыктан, Батыргали агай күп халык арасыннан бәрелә-сугыла барганда, пароход конторы алдында чынаяк ташыннан ясалган һәртөрле савытлар, уенчыклар сатучы бер урысның башындагы корзинкасы илә барлык уенчыкларын бәреп төшереп, чирекле шешә илә квас күтәргән бер карт маржаны бәреп егып, пароходка кереп китте. Бичара маржаның, кулындагы чирекле шешәсе йөзгә ватылып, квасыннан мәхрүм калган кебек, урысның таш уенчыклары да берсе бишь булды.

Бер тарафтан: "Тиз! Өченче свисток булды, пароход хәзер китә! Хуш, сау булыгыз! Багажлар кайда? Гыйлажи! Баргач та тизрәк лимон җибәрегез! Гайни кодага сәлам әйт! Хуш, хәерле сәфәр! Хат языгыз!" — дигән юлчылар тавышы, "Князь, скорей! Отчаливой! Задний ход!" — дигән капитан һәм матрослар тавышы, "Казанский телеграф", "Шушма башы", "Кичке телеграмм! Кырык мең японны кырганнар!" — дигән газета һәм телеграмма сатучы малайлар кычкырганы колакларны тондырмакта иде. Ул гына аз булса, квас сатучы карт маржа илә уенчыклар хуҗасы урыс, тагын бер жандармны уртага алып: "Зур корсаклы бер татарны пароходтан алып чыгып, безнең зарарыбызны түләттер", — дип бәйләнмәктә иделәр.

Пароход тагын кыска-кыска гына свисток бирде, халык тагын шаулый башлады: "Хуш, сәламәт бул! Сәлам әйт! Безне дә онытма!" — дигән тавышлар янә ишетелә башлады.

Пароход акрын гына кузгалып китте. Һәр ике тарафтан, ягъни сәфәр китүчеләр пароходтан, озатып калучылар пароход пристаненнан фуражкалар, эшләпәләр, ак яулыклар илә болгый башладылар. Яулык болгаучы озатучылар эчендә йодрык күрсәтеп калучы бер мөселман хатыны күренмәктә иде: "Ах, йөзең кара булгыры, бәдбәхет! Ах, чүпрә корсак! Тагын кай җәһәннәмгә барасың? Тагын, әллә бер елны Мәкәрҗәдән канбой илә кайткан кебек, кеше көлкесе, рисвай булып кайтмакчы буласыңмы? Яхшылыкка йөрмисең инде син, үз башыңа йөри торгансың, бәхетең икән, пароход кузгалып киткәнче килеп җитешә алмадым, бөтен галәм алдында сакалыңнан өстерәп чыккан булыр идем. Алай да бик иркенләп йөри алмассың, артыңнан куып җитеп, бәйләп алып кайтырмын, насыйп булса", — дип кычкырмакта иде.

Бу кычкыручы Батыргали агайның хатыны Җомабикә абыстай иде.

Пароход пристаненнан ерак киткән саен, озатып калучылар да акрын-акрын, берәм-берәм тарала башладылар. Ерак киткән саен, пароход кечерәеп күренә башлады. Ярты сәгатьтән соң пароходның моржасыннан сузылып чыккан кара төтене генә күренә башлады.

Инде бер кәррә бу пароход эчендәге юлчыларның хәленә күз салыйк: пароход кузгалып киткәч, юлчыларнын күбесе пароходның палубасына, ягъни өстенә чыгып, Казан шәһәрен тамаша кыла башладылар. Идел өстеннән караганда, Казанның мәчет манаралары, биек-биек чиркәүләре, тегермән, завод моржалары, пожарный каланчалары, биек йортлары ерактан бик матур, бигрәк һәйбәт булып күренә иде. Пароход ерак киткән саен, Казанның аермачык күренгән биек йортлары, мәчет манаралары, завод моржалары кечерәя-кечерәя, кояш шәүләсе илә, бер күренеп, бер күздән югалып, ахырында бөтенләй күздән югалып, күренмәс булдылар...

Пароходтагы юлчыларның бәгъзысы чәй эчәргә, ашарга, бәгъзылары газета, телеграмма, китап укырга кереште. Кайберсе, эч пошканнан вакытларын кәеф вә хозур илә үткәрмәк өчен, арпа һәм арыш сулары илә тутырылган шешәләр илә "уйнарга" тотындылар. Безнең Батыргали илә Шубин да ошбу соңгы партия халыклар эчендә иде. Болар янә Казанда Усиядә "Волга" трактирында тукталган җиреннән эшне башлап, әүвәл бер-берсенең сәфәрләрен котлап, берәрне, аннан соң сугышта Куропаткин хәзрәтләренең сәламәтлегенә, өстен чыгуына, японнарның главнокомандующие Уяманың волчий ямага төшеп һәлак булуына эчтеләр. Пристаньда да яхшы ук кызганнар иде, хәзер бөтенләй "кеше" булдылар. Батыргали агай, үзенең юл өчен алган елкы казылыклары илә генә канәгатьләнмичә, тагын балык солянкалары, котлетлар, жаркойлар хәзерләргә кушты: корсаклары ярылганчы ашап, эчләре купканче һәртөрле эчкелектән эчтеләр.

Пароход беренче пристаньга туктап утын һәм юлчы алды. Кич сәгать уннар булгач, юлчылар акрын-акрын гына йокларга хәзерләнә башладылар. Батыргали агай, күптән урынында чалкан ятып, баһадирлар йокысы илә "гыр-гыр!" итеп йокламакта иде. Хәтта Батыргали агайның гырылдаганына йоклый алмыйча каршысында яткан бер мадам, төн уртасында мырылдана-мырылдана, ераграк икенче урынга күчте. Төн уртасы үткәч, сәгать первыйларда, Батыргали агай, кисәктән генә йокысыннан уянып, сикереп торгач, корсагын уа башлады. Әллә кичтән ашаган солянкалары эченә йокмады, әллә казылыкны күбрәк ашаган, әмма ничек булса да, корсагы авыртуга чыдый алмыйча йокыдан уянган иде. Тиз-тиз генә пароходның бәдрәфе тарафына юнәлде...

* * *

Иртәгесен пароходтагы юлчылар бары да торган, кайсы юынырга, өстен-башын тазартырга, кайсы чәй эчәргә керешкән иде. Һава аяз, бик саф, һәр тарафтан май аенда сайрый торган сандугачлар "чут, чут!" итеп сайрамакта, пароход та, бакча эченнән барган шикелле, яшел урман эченнән Идел суын ерып, Һәмишә төньякка карап бармакта иде. Бераздан: "Нижнийга житәбез, Мәкәрҗә күренә", — дигән тавышлар ишетелә башлады.

Батыргали агай илә Шубин да торгач баш төзәтергә тотындылар. Кичә градуслары артыбрак киткәнлектән, бу көн башлары тубал кебек булган иде. "Мәкәрҗәгә житәбез", — дигән тавышны ишеткәч, Батыргали агай бик гаҗәпкә калды. Сембергә яки Самарага життек, дигән сүзне ишетсә, бер дә гаҗәпләнмәс иде. Аның фикеренчә, тиздән Самарага җитәргә тиеш иде. Чөнки ул сугышка Самара аркылы китәсе булгач, Самарага китә торган пароходка утырган иде. Самарага бара торган пароход ничек Нижнийга житсен? Юкса, пароход, юлын ялгышып, Самара дип Нижнийга киттеме? Бу бит акыл житми торган гаҗәп эш. Эшнең хакыйкате менә ничек булды: Казанда пристаньда "Кавказ-Меркурий" компаниясенең конторы алдында янәшә өч пароход торадыр иде. Бу пароходның берсе Самарага, икенчесе

Мәкәрҗәгә китәргә тәгаен кылынган, һәм юлчыларга билетлар да сатылган иде. Өченче свисток тавышын ишеткәч тә, Батыргали агай, пароходтан каламын һәм хатыным Җомабикә килеп юлдан туктатыр, дию курыкканыннан, бик ашыгычлык илә, Самарага китә торган пароходка утырам, дип, хаталык илә Нижнийга бара торган пароходка утырып киткән иде. Шубин, һәм аны-моны тикшермәстән, юлдашының артыннан пароходка кергән иде. Без хәзер, Батыргали агайны юлдашы Шубин илә Нижний пристанендә калдырып, Казан пристанена, ягъни Усиягә кайталем.

* * *

Самарага китәчәк пароходка запасный солдатларны утыртырга әмер бирелгәч, һәркайсы озата килгән ата-анасы, бала-чагасы, хатын-кызы илә кочаклашып күрешә, үбешә, елаша, бәхилләшә башладылар. Һәркем актык сәламен, актык сүзен әйтмәктә иде. Ап-ак сакаллы бер карт, сугышка китүче мөселман солдатларына карап, ошбу сүзләрне сөйләде: "Әй балакайларым! Ерак җиргә сугышка китәбез, дип кайгырмагыз; ата-анабыз, бала-чагабыз кала, дип һәм хафаланмагыз, хода үзе жан биргәнгә җүн бирер, һичвакытта үзегезнең татар улы икәнегезне онытмагыз, туган җиребез өчен дошманга каршы торып сугышу һәрберегезгә фарыздыр; бабаларыгыз дүрт йөз елдан бирле Русия дәүләтендә торып һичбер сугышта үзләренә оят, йөзләренә каралык китергәннәре юктыр; инша алла, сез дә шул арыслан балаларысыз, үлемнән курыкмыйча, актык тамчы каннарыгыз калганчы дошман илә сугышачагыгызга халис күңелемнән ышанамын. "Алла өчен кылган гыйбадәт, ил өчен кылган хезмәт һичвакыт югалмас", — дигән картларның сүзен хәтерегездән чыгармагыз. Сез арысланнарны тудырган аналар, тәрбия кылып үстергән аталар җир кырыена, Мохит диңгезе янына, ят падишаһ җиренә сугышка киткәнегезне күреп, никадәр шатлансалар да хаклары бардыр. Хода кушса, берничә айдан соң һәрберегез күкрәге тулы медаль тагып, җир-су, дөнья күреп, дошманны кырып туган җирегезгә кайтырсыз. Хуш, сау булыгыз, балакайларым, хода ак юл бирсен!"

Бу бабайның сөйләгән сүзләре сугышка китүче мөселман солдатларына шулкадәр әсәрле, шулкадәр ягымлы булды кин, күбесенең күзеннән яшьләр агып, биш-алты йөзләп адәм бер авыздан, "Урра! Уррра!" кычкырып:

— Рәхмәт, бабай, яхшы сүзегезгә, рәхмәт, йөз яшә! Үлемнән курыкмыйбыз, барабыз сугышка, туган җиребез өчен утка каршы гына түгел, хәтта тупка каршы барабыз, — диделәр.

Арадан берсе: "Сиражетдин, Әхмәдулла! Әйдә, гармонь илә скрипканы парлап уйнагыз әле, без сугыш бәетен әйтәбез", —диде. Скрипка илә гармоньны парлап уйный башлагач, дүрт-биш запасный шушы бәетне әйтә башладылар:

Без барабыз сугышка, ерак кояш чыгышка,  
Патша өчен үлешкә барабыз без сугышка.  
Байкал күлен кичәрбез, татлы суын эчәрбез,  
Утларны без сачәрбез, без барабыз сугышка.  
Шәһәребез Казан каласы, үзебез татар баласы,  
Арысландыр анасы, без барабыз сугышка.  
Безне үстергән аналар, ак сакаллы аталар  
Озатышып калалар, китәбез без сугышка...

..................................................

Япон чыгарды бу эшне, ул башлады сугышны,  
Туры килми үлешми, марш, егетләр, сугышка!  
Англичан илә япон, икесе булганнар, ди, кум *,  
Без аларга бирербез ум **, марш, егетләр, сугышка!  
Англичаннар хәйләкәр, уйлаганнары мәкер,

* Кум — кода, димәктер. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*  
** Ум — гакыл. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

Күрсәткән юллары кәкре, марш, егетләр, сугышка!
Манчжуриядә каты мороз, японга англичан бирә карыз.
Алай булгач, сугыш фарыз, китәбез без сугышка!
Кигәнебез кыска тун, каршыбызда торадыр япон,
Алар безгә нипочем, керәбез без сугышка!
Япон бурычка акча аладыр, җирләрен заклад саладыр,
Англичанга кол булып каладыр, чыдый алмый ул сугышка!
Аларны англичан котырта, юкса хәлләре бик урта,
Штыктан алар курка, чыдый алмый сугышка.
Җаныңны син аяма, каршыда маршал Уяма,
Казыйк ана волчий яма, марш, егетләр, сугышка!
Японнар бик вак халык, ашлары аларның балык,
Безнең җиңәчәгебез анык, әйдәгез, барыйк сугышка!

## "Манчжурия — Харбин"

Көз көне, сентябрь башларында, аяз һәм җылы һавалы бер көндә, иртә белән сәгать уннарда Харбин вокзалында рус, татар, грузин, әрмән, черкас, төрек, кытай, кореец вә башка милләтләрдән бик күп халык кырмыска кебек, мыж итеп, кайнап тормакта иде; рус хезмәтендә булган кызыл киемле кытай полицейскийлары, кулларындагы бамбук агачы илә, тимер юл буенда, рельс өстендә папирос, шырпы, квас, чикләвек сатып йөрүче кытайларның аркасына, һич тәкәллефсез "Суба!" дип сукмакта иделәр. Күп тә вакыт кичмәде: кытайлар бер авыздан: "Хчулайла, хчулайла" * дип кычкырыштылар. Һәм вакыйган бик күп вагоннар таккан воинский поезд, Мукленнан килеп, Харбин станциясенә туктады. Полицейскийларның куганына, хәтта сукканына да карамыйча, кытай носильщиклары, һәр тарафтан вагоннарга кереп, "Капитан, мая канхуди!" ** дип, күбесе яралы булган офицерларның һәм солдатларның багажларын чыгара башладылар. Бәгъзысы култык таягы илә, бәгъзысы ак полотенце илә уң яки сул кулын муенына аскан ранный солдатлар вагоннардан чыга башладылар. Бигрәк тә агыр хәстәләрне, носилкага салып, күтәреп чыгардылар; носилка илә чыгарган каты авыруларны Яңа Харбиндагы лазаретларга алып киттеләр; җинелрәк авыруларны, санитарный арбаларга утыртып, пристаньга озата башладылар.

Бу җирдә хөрмәтле укучыларыбызга Харбин шәһәрен тәгъриф итмәк лазем булды. Мең сигез йөз туксан алтынчы елга кадәр хәзерге Харбин урынында, ягъни Сунгари суының уң сахилендә (ярында) Харбин исемендә кечерәк бер кытай авылы гына иде. Шул елларда Россия хөкүмәте Сибирия тимер юлын Амур нәһеренең сул ягыннан кичереп, иң Ерак кояш чыгыштагы Владивостокка кадәр озайтмак булса, Шилка һәм Амур суы буенда ниһаятьсез булган таш-тауларын кисеп юл салмак бик читен булып, бик кыйммәт төшәчәк булгач, җир казучы, юл эзләүче инженерлар тимер юлны Манчжуриядән (Кытай җиреннән) үткәреп, Владивостокка чыгаруны мәслихәт һәм арзанрак төшәчәк кылып күрсәттеләр. Шуннан соң Россия хөкүмәте дөньяда иң озын Сибирия тимер юлыны, Манчжурия кыйтгасеннән үткәрмәк өчен, Чин (Кытай) хөкүмәтеннән туксан тугыз елга имтияз (рөхсәт) алып, 1897 елда тимер юлы эшләнә башлады. Хәзерге Харбин җире эшләнәчәк тимер юлының һәм Сунгари дигән пароходлар йөрерлек зур суның өстендә, Манчжурия кыйтгасенең тәмам урта бер җирендә, сәүдә вә гайре җәһәтләрдән дә бик яхшы, бик важный булдыгы өчен, бу җиргә Харбин исемендә зур шәһәр салына башлады.

Харбин шәһәре өчкә бүленәдер: Россиядән, Порт-Артурдан һәм Владивостоктан килгән тимер юллары Сунгари нәһереннән ике чакрым

* Хчулайла — поезд килә, димкәтер. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*
** "Капитан, мая канхуди" — әфәнде, мин хезмәт итәчәкмен, димәктер. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

шәрыктә корылган Яңа Харбинда тукталадыр, соңгы план илә салынган казенный йортлар, Чин шәркый тимер юлының правлениесе, Русско-Китайский банк зданиесе, киң урамнар, гүзәл бакчалар бу Яңа Харбинны тәзәйн итмәктәдер. Яңа Харбиннан дүрт чакрым тагын шәрык тарафына китсәк, Иске Харбин шәһәрен күрәчәкбез.

Владивосток тимер юлы Иске Харбиннан үтеп китәдер. Яңа Харбиннан ике чакрым кояш баешы тарафында, Сунгари суының уң сахилендә пристань исемендә янә бер шәһәр бардыр. Рус, татар, кытай, грузин, яһүди сәүдәгәрләре, зур магазиннар күбесе пристаньдадыр. Пенза губернасы мишәрләреннән: Виргазов, Агишев, Агиев вә гайре исемнәрдә һәм зур-зур магазин сазипләре бардыр. Россиядән килгән поездлар үтәр өчен Сунгари нәһеренә салган гаять озын, биек таш баганалар өстендәге тимер күпере пристаньга аеруча матурлык бирмәктәдер. Җәй көннәрендә, Сунгари суында урысның пароходлары, кытайларның Нух туфанын ясалмыш бик озын мачталы җонкалары (баржалары), ары-бире йөреп, кайнап торадыр. Бөтен Манчжуриядә тимер юлы буенда, Хинган тавында тоннельдә * эшләүче Россия татарларының, Амур буенда алтын эзләп йөрүче прискательләрнең, узелчы мишәрләрнең җыелышып, бер-берсе илә күрешеп, танышып сөйләшә торган җирләре — пристаньда уникенче урамда N 1028 йортта, "Казанский столовой" исемендә чәйханәдер. Россиядән яна килгән чуклы кәләпүшле, мескен бүрекле татарлармы, Амур, Зәя суы буенда алтын прискаларында йөргән унике аршын плистән теккән, киң балаклы чалбар кигән прискательләрме, Сахалин атавыннан каторжный хезмәтне бетереп, рөхсәт алып чыккан мөселманнар кирәкме, һәммәсе шул "Казанский столовой"да буладыр. Казанда ничек Печән базарында... чәйханәсе атаклы, билгеле булса, Харбинда "Казанский столовой" шулай ук атаклыдыр.

Без янә Харбин вокзалына киләлем. Мукденнан килеп туктаган поездлан, берсе акбүз илә уң кулын муенына аскан, икенчесе култык таягы илә таянып, ике мөселман солдаты чыктылар. Һәр икесенең күкрәгендә Георгиевский крестлар ялтырыйлар иде. Болар, акрын гына атлап килеп, вокзал алдында торучы ап-ак сакаллы бер картка сәлам бирделәр. Бабай, боларның сәламен алгач:

— Нихәл, егетләр, сез кайдагы буласыз, сугышта кай җирдә булдыгыз? — дип сорады.

Кулсызы:

— Без Казан губернасы, Чар өязе... авылыннан, Ляоян сугышында булдык; икебез дә, ранный булган сәбәпле, өйгә кайтырга рөхсәт алдык; Харбинда бер-ике көн торып, хәл алмак өчен калмак булабыз; бер-ике көн торырга тынычрак һәм унайлырак фатир булмасмы икән? Сез монда тора торган кеше булсагыз, бәлки, белә торгансыз?

Бабай:

— Булыр, булыр, табарбыз; әйдәгез, менә минем атларым да хәзер, сезне утыртып, пристаньга "Казанский столовой"га алып барырмын. Аның хуҗасы дөнья күргән мәрхәмәтле кеше, сезгә яхшы бер бүлмә бирер, бик рәхәт, тынычлап ятырсыз, ял итәрсез, агай-эне бар да шунда, күрешерсез, сөйләшерсез.

Ак сакаллы бабай, бу ике ранный солдатны пар ат җиккән пролеткасына утыртып, пристаньга алып китте. Ярым сәгатьтән соң "Казанский столовой"да өстәл өстендә зур самавыр чажылдап кайнап утырганы, өстәл янында җиде-сигез кешенең гөрелдәп сөйләшкәне күренмәктә иде. Әлеге ике ранный солдатлар да болар эчендә иде. Боларның сөйләшкәне сугыш хәбәре иде. Уң кулы ранный булган солдат, дүрт-биш чынаяк чәй эчкәч, шушы рәвешчә сүзгә керешге:

— Без күбрәк охотничный командада йөрдек, бер кечне егерме биш солдат, егерме алтынчы ротный офицерыбыз илә, японнарның кайда күпме

---

* Тимер юл үтәр өчен биек тауларны тишеп ясаган юлга тоннель диләр. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

* Георгиевский крест — чамадан тыш эш кылган адәмгә бирелә торган кадерле медальдер. *(Ш. Мөхәммәдев искәрмәсе.)*

гаскәре, күпме туплары, күпме сугыш материаллары, ерак яталармы, шуларны күреп белер өчен разведкага киттек. Төн бик караңгы, күзгә төртсәң, күренерлек түгел иде. Үзебезнең яткан позициядән унбиш чакрым чамасы кояш чыгыш тарафына киткәч, бер тау артында, кечерәк бер су буенда, берничә җирдә, аш пешерү өчен ягылган ут яктысында, ары-бире йөргән япон гаскәре күренде. Без, боларны ут яктысында күргәч, тагын якынрак барып, күпме куәтләре барлыгын карамак булдык. Акрын-акрын гына, кайсыбыз ашлык арасыннан, кайсыбыз су буендагы камыш арасыннан, боларга якынлаша башладык. Японнарның алдагы цепьлары * безне күрмәделәр, йоклап калдылар. Боларның яткан җире илә безнең арабызда кырык-илле сажен кадәр генә җир калды; аермачык булмаса да, сөйләшкәннәре безгә ишетелә башлады; шул җирдә ротный командирыбыз, безгә якынрак килеп, акрын гына:

— Егетләр! Арабызда туган җиребез өчен җанын фида кылучыгыз бармы? Әнә шул гаскәрләрдән читтә тау кебек өелеп торган дары, снаряд ящикларын күрәсезме? Шул җирдә японнарның аз дигәндә ике айлык сугышка җитәрлек снарядлары, дарылары вә гайре сугыш кирәкләре бар, әгәр дә эчегездән бер тәвәккәл егет чыгып та, шул өелеп торган сугыш снарядлары янына бер уч кына саламга яки бераз гына чүп-чарга шырпы яндырып ут ташларга кулыннан килсә, килүебез бушка китми, максудыбызга тәмам ирешәбез. Чөнки шул җиргә бер шырпы кабызып ташлау илә бер минут эчендә дошманыбызның ике айлык куәте, никадәр сугыш коралы һәм никадәр солдаты һәлак булачак, менә шул эшне урынына китергән кешегә биш йөз тәңкә награда үзем бирәм! Желать итүчегез бармы? — диде.

Шул сүзне ишеткәч тә, мин, алга чыгып, “Мин барам! Акча өчен түгел, туган җиребез хакына барамын”, — дидем. Ротный: — “Молодец! Бер-ике сәгать сабыр ит әле, хәзер японнар бар да уяу күренә, төн уртасы үткәч, анлар йоклагач, барырсың”, — диде.

Төн уртасы үткәнче шул җирдә яттык. Бервакытны японнарның яккан утлары да азая башлады; тавышлары да ишетелмәс булды, мылтыгымны юлдашларыма калдырып, янымa хәнҗәремне тагып, иптәшләрем илә бәхилләшеп, акрын-акрын, поса-поса, бәгъзы җирдә дүрт аяклап, бәгъзы җирдә күкрәк белән шуып, дошман яткан җиргә карап киттем, японнарның аш пешерү өчен төрле җиргә яккан утлары бөтенләй сүнеп җитмәгән иде: бәгъзы вакыт ялтырап-ялтырап киткәндә, снарядлар өйгән җирдә часовойларның ары-бире йөреп торганы күренмәктә иде. Ничек итеп якын барып ут салырга кирәк? Үлән арасыннан күкрәк илә шуып барсаң да, якын баргач, часовойларның күрми хәлләре юк. Юлдашларым калган җирдән байтак җир киткәч, бер чокырда туктап, алдыма, артыма, унга, сулга яхшылап карый башладым. Японнарның снарядлар өйгән җирдән унбиш сажен чамасы читтәрәк, бер агач янында часовой — бер япон солдаты сөялеп йоклаганын күрдем. Шул минутта күңелемә бер фикер, бер уй төште. Гаҗәбән, булдырып булырмы, юкмы? Шуннан башка чара юк, шушы өстемә алган эшне булдыра алмыйча, юлдашларым алдына кайтуы үлемнән мең мәртәбә авырдыр, ни йөз илә: “Булдырып булмады!” — дип кайтырга кирәк! Юк, юк! — үләм, әмма шул өстемә алган хезмәт юлында үләм. Тычкан саклаган мәче кебек, бик сакланып кына, бик акрын гына күкрәгем өстеннән шуып, шул йоклаган солдатка таба киттем. Күңелемнән үз-үземә: “Шул япон солдаты әгәр дә биш минутка кадәр уянмаса, безнең эш була”, — дидем.

Һава тыныч, җил-фәлән һич юк иде; еректан, су буендагы камышлыктан, таң алдында кычкыра торган бәгъзы кош тавышлары илә тау арасыннан бер чишмә суының челдерәп акканы гына ишетелмәктә иде. Хәтта сулышымны да бик акрын алып, мин янә алга таба, шул часовойга якынлашмакта идем. Чөнки шул минутта минем әҗәлем йоклаган япон солдатының кулында иде. Әгәр дә ул уянып китсә, минем эшем беткән, башым югалган иде. Йөрәгем һич урынында түгел, дөп-дөп сикермәктә иде. Арабызда бер-ике сажен гына җир калган иде. Янымдагы хәнҗәремне кулыма алып, аяк өстенә торгач: “Йә алла, мәдәт бир!” — дип янә өч-дүрт адым алга атлап, барлык куәтем илә кулымдагы үткен хәнҗәрне йоклаган часовойның күкрәгенә чәнечтем!

Бер генә “Ух!” диде дә шунда ук егылып җан бирде. Мин, дәрхаль аны аягыннан өстерәп, биш-алты сажен җирдә бераз агачлык җиргә алып барып ташладым һәм өстенә кигән мундирын салдырып үз өстемә кидем; үземнең ак фуражканы ташлап, үлгән япон часовоеның сары кырыйлы фуражкасын киеп, мылтыгын иңбашыма күтәреп, гүя япон солдаты булып, әлеге тау шикелле снарядлар өйгән җиргә киттем. Миннән башка да бернич япон солдаты каравыллап, ары-бире йөриләр иде. Кайдан ут салырга унайлырак җирне карап, мин дә ары-бире бер-ике әйләндем. Күп йөрергә вакыт юк иде. Чөнки часовойлардан берсе килеп, бер сүз сораса, хәзер минем урыс солдаты икәнлегем беленәчәк, башым һәлак булачак иде. Снарядлар өйгән җирдә күземә бер аралык күренде, тиз генә шунда кереп кесәмнән спичканы, сумкадагы үзебезнең позициядә вакыт хәзерләп килгән, түгәрәкләп төреп керосинга батырган иске чүпрәкне алып, бер шырпы яндырып, шул чүпрәккә кабыздым. “Гөлт” итеп ут алды. “Йә алла!” диеп, шул утлы чүпрәкне дарылар арасына ташладым да үзем тизрәк йөгердем. Биш-алты сажен киттеме, юкмы, күк күкрәгән кебек тавышлар күтәрелде, бөтен дөньяны ут алды, һәр җирдән кешеләр, атлар вә башка хайваннарның куркынычлы акырган тавышлары, бергә кушылып, ишетелде; бөтен дөньяны төтен, томан алды, һичбер нәрсә күренмәс булды... искәрмәстән минем дә уң кулым беләгемнән ут яккан күк булды. Күз алдым караңгыланып китте, егылдым... Шуннан соң ни булганын белмимен.

Иртәгесен күземне ачсам: позициядәге лазаретта ятканымны, беләктән уң кулым өзелгән икәнен күрдем. Егылган җирдә кулымнан күп кан агып, мин һичнәрсә белмәгәнмен. Рәхмәт әле, менә шушы юлдашым, мина андый-мондый каза ирешсә, дошман кулына төшмәсен, дип, мин ут салган җиргә кадәр минем артымнан ияреп килгән икән. Мин егылгач та, мине күтәреп алып кайткан. Өч көннән соң икенче сугышта аның да аягы өзелде. Мин ут ташлаган җирдә японнарның барлык сугыш коралы, снарядлары, азыклары һавага очып, ун меңләп солдаты да һәлак булган дию, кытайлар килеп сөйләделәр. Менә ун мең чакрым җиргә килеп безнең кылган хезмәтебез шул булды. Шуның өчен безгә менә шушы Георгийларны бирделәр, — диде.

Бу, башыннан кичкән хәлләрне сөйләүче ранный солдатны тыңлаучы кешеләр, һәркайсы бер киң сулыш алып: “Һай, рәхмәт, туган! Сезнең кебек арыслан йөрәкле бала тудырган аналар, тәрбияләп үстергән аталар мәңге җәннәттә калсыннар, татарлык исемен аяк астына салмаган икәнсез, урра!” — дип кычкырыштылар.

* * *

Батыргали агай, Нижнийда Шубин илә берәр атна чуалып, баш төзәтеп йөргәч, бер көнне Москвага китте. Москвада әүвәлдән белеш-таныш байлар, фабрикантлары очрап, “Амун”, “Эрмитаж”, “Золотой якорь” вә гайре рестораннарны һәммәсен зиярәт кылдылар. Батыргали агайның көннән-көн ватан мәхәббәте артып, циркларда, театрларда илә япон сугышын уйнаган вакытларда, һич урынсыз җирдә кул чабып, “ура” кычкырып, скандал чыгара торган булды. Чөнки һич айнымастан, запой эчәргә тотынган иде. Шәһәрдән шәһәргә йөргәндә ялгыш поездга утырып китү сәбәпле, юлдашы Шубиннан да аерылган иде.

Кайда гына барса да, Батыргали агай сугыш коралларын янынан калдырмый, “шалтыр-шолтыр” тагып йөри торган иде. Максуды Һәмишә Порт-Артурга барырга иде. Вокзалларда, вагоннарда моны күргән халык, аю күргән кебек, ияреп йөриләр иде.

Күп йөри торгач, Батыргали агай бервакытны Баку шәһәренә килеп чыккан иде. Бер кичне Батыргали агай зур гына бер трактирда кәеф кылып утырганда, коньяклар, ромнар чамадан артыграк әсәр кылып, күз аллары томалана башлады. Өстәлдәге тезелгән бутылкалар лампа яктысында күзенә япон гаскәре, закускага китергән тозлы кыярлар япон тубыннан чыккан унике дюймлы снарядлар булып күренә башлады: җиз башлы коньяк

бутылкалары Батыргали агайның күзенә гүя япон офицеры булып күренә башлады. Бу офицер (коньяк бутылкасы) япон гаскәренә (башка бутылкаларга) гүя Батыргали агай өстенә һөҗүм кылырга команда биргән кебек күренде, Батыргали агай әллә нинди уйларга, тирән фикерләргә китте.

Гөнаһ шомлыгына каршы, шул көнне бер зур бай купецның туй мәҗлесе булып, ошбу трактирның залында кодаларына аш-су, уен-көлке, музыка бирәчәк, имеш. Менә бервакытны, искәрмәстән, шалт-шолт иткән шампанский бутылкасы ачылган тавышлары, кодаларның һәр җирдә "ура" кычкырган тавышлары, барабан суккан, музыка уйнаган һәм җырлаган тавышлары ишетелә башлады. Бу "ура" тавышлары, пробка шартлаулары, барабан кагулар бөтенләй безнең Батыргали агайны гакылдан шаштырдылар; чөнки ул хәзер үзен бөтенләй сугышта, Порт-Артур янында дип хыялга киткән иде; шампанский бутылкасыннан атылып, шартлап чыккан пробка тавышларын туп тавышы, "ура" кычкырган тавышлар, гүяки японнарны атаковать итеп, плен алган тавыш дип уйлый башлады. Коньяк кызуы белән ватан мәхәббәте, гайрәт тамырлары шулкадәр кызды ки, үзен үзе белмичә, кулына бер бутылка алып, өстәлдәге япон гаскәрен (бутылкаларны) кыра башлады. Өстәлдәге бутылкалар, посудалар, рюмка вә гайре нәрсәләр, шалтыр-шолтыр идәнгә төшә башладылар; бу посудалар ватылу илә генә безнең "пәһлеван" Батыргали агай туктаган булса, эшләр, бәлки, бик зурга китмәгән булыр иде. Чөнки трактирда мондый вакыйгалар, Батыргали агай кебек, юан корсаклы байлар арасында булгалый торган иде. Әмма Батыргали агай, япон гаскәрен (бутылкаларны) тиз генә кырып, һәлак кылганын күргәч, тагын гайрәтләнеп, тагын күзләрен кан баса төшеп, һәртөрле шәһәр сурәтләрен күрсәткән стенадагы кыйммәтле рәсемнәрне, картиналарны да, японнарның шәһәрен бомбардировать итәмен, ваттырамын, дип, венский урындык илә бәреп вата, кыра башлады.

Трактирның хуҗасы, эшләр бик зурга китә башлагач, бу ялганчы доброволецны (Батыргали агайны) тотып бәйләр өчен, хезмәткәрләренә әмер бирде. Өстәлдәге посудаларны, бутылкаларны кырган вакытта, бер пыяла кисәге атылып китеп, Батыргали агайның күз-кашын ярып җибәргән сәбәпле, кашыннан аккан кан бөтен битен һәм кулларын кып-кызыл буяган иде.

Трактир хуҗасы полициягә хәбәр биреп, күпме посуда, күпме мебель һәм картиналар ватылганын протокол яздырган вакытта, Батыргали агай, кул-аягы бәйләнгән булса да: "Японнарның шәһәрен алабыз, япон пулясы күземә тисә дә, курыкмыйммын, әйдәгез, егетләр, минем арттан калмагыз, японнарны кырыгыз", — дип акырмакта һәм тыпырчынмакта иде. Чөнки Батыргали агай, күп мөскират истигъмал кылганлыктан, тәмам хыялый булган, тилергән иде.

## "Сугыштан кайтыш"

Казанның тимер юл вокзалында бик күп халык поезд килгәнне көтмәктә иде. Юан корсаклы шәһәр байлары, кечерәк кенә бүрекле, ак якалы, нечкә сыйраклы байбәтчәләр, аягында чабата, өстендә керән чикмәнле сала мужиклары илә авылдан килгән хатын-кыз да күп иде. Чөнки бу көнне сугыштан ранныйлар кайта дию хәбәр таралган иде. Шуның өчен бәгъзысы угылларыбыз, туганнарыбыз, бәгъзысы ирләребез, бәлки, кайтмасмы дип, авылдан да күп халык каршы килгән иде.

Ярым сәгать үткәч, "Поезд килә!" дигән сүзләр ишетелде, халык һәммәсе вокзалның тышкы ягына, платформага чыкты. Күп вакыт та үтмәде, бик күп вагоннар таккан машина вокзал алдына туктады; яшел, сары, кызыл вагоннар арасында санитарный ак вагоннар да бар иде; халык, бәрелә-сугыла, каршы алырга вагоннарга керә башлады. Әүвәл яшел, сары, кызыл вагондагы юлчы рабочий, сәүдәгәр һәм господа халкы чыктылар; аннан соң ак вагоннардан берәм-берәм акрын гына ранныйларны, бәгъзысын носилкага салып, бәгъзысын

култыклап, чыгара башладылар. Һәр тарафтан кочаклашып шатлыктан елашу, үбешү, көлешү, сөйләшү ишетелмәктә иде; ак санитарный вагоннарның берсеннән, беренең ун кулы юк, икенчесе култык таяктан, күкрәкләрендә георгиевскийлар тагылган ике мөселман солдаты чыктылар; вокзал алдында аулаграк бер җиргә туктап, болар үткән-барган адәмнәрне күздән үткәрсәләр дә, белгән-күргән агай-энеләре очрамады, бу ранный ике солдатны Казан вокзалында белүче, танучы булмаса да, безнең хөрмәтле укучыларыбызга болар мәгълүмдер, чөнки югарыда бер кәррә язылмыш, Харбинда "Казанский столовой"да сугышта башларыннан үткән хәлләрне хикәя кылучы ранный солдатлар ошбу адәмнәр иде...

Ак вагоннардан ранный гаскәрләрне тәмам чыгарып бетерделәр. Ин артта бик эре хәреф илә "Юләрләр вагоны" дип язылган, тәрәзәләре тимер рәшәткәле бер вагоннан ике солдат, озын серый киемнәр кигән бер юан корсаклы, зур борынлы кешене ияртеп, чыктылар: әлеге ике ранный мөселман солдаты яныннан узганда, бу адәм һәр икесене бик карап китте. Солдатларның да кулсызы, монарга бик турылап башыннан-аягына кадәр күздән үткәргәч, юлдашына акрын гына:

— Әхмәдулла! Хәтерлисеңме, без, сугышка киткәндә, Усиядә ике ятажлы трактирда чәй эчәргә кергән идек бит; әнә шул трактирда мылтык, кылычлар таккан бер юан мөселман илә бер урыс эчеп утыралар иде; шул юан татар: "Бу маңкалар сугышта ни эшли алалар инде?" — дию, бездән мыскыл итеп көлеп утырган иде; менә бу серый киемле шул кеше ич, таныйсыңмы?

Култык таяклысы: — "Һәм чыннан шул икән", — диде.

Шул арада чал сакаллы, урта буйлы бер кеше каушый-каушый килеп, әлеге "Юләрләр вагоныннан" чыккан серый киемле адәмгә: — "Әссәламегаләйкем! Батыргали кода, исәнме?" — диеп кулын сузып күрешмәк булса да, юан корсаклы адәм чал сакаллыны төртеп җибәрде. Бу чал сакаллы адәм Батыргали агайның кодасы Мотыйгулла абзый иде; юан корсаклы, серый киемле чыннан ук Батыргали агай иде. "Ватан мәхәббәтеннән" запой эчә-эчә тәмам тилереп, сумасшедший домга (тилеханәгә) тотып ябылгач, Бакудан туган җире Казанга җибәргәннәр иде. Әлеге берсе кулсыз, икенчесе култык таяклы солдатлар һәм ничә ай мөкатдәм сугышка киткәндә Усиядәге трактирда күргән солдатларыбыз иде...

Батыргали агай үзе тилереп кайткан кебек, Казандагы сәүдә эшләре дә тәмам чуалып тукталган иде.

*Сон*

*Оренбург.*
*Май 1 ндә 1905 сәнә.*

## Батыргали агайга ачык җавап

*Тугры әйткән туганга ярамый.*
Картлар сүзе.

Бу көн почтальон китергән хатлар арасында Казаннан да хатлар бар иде. Казаннан килгән бер хат өстендә "14 тиен түләргә" дигән сүзне күргәч тә, бу хат бик якын дусларымнан икән, дип, шатландым; мондый хатлар миңа һәрвакыт мине бик якын күргән дусларымнан килгәли торган иде.

Дәрхаль, конвертны ертып, имзасына күз салдым; гәрчә, "Дустыгыз Батыргали Шалканов" дип кул куйган булса да, кулы безнең Батыргали агайның кулына бик охшамаган иде. Хатны башыннан укый башладым; сәлам соңында ошбу сүзләр язылган иде: "Безне искә төшереп, безнең өчен "Япон сугышы" исемендә китап чыгарган өчен, Сезгә бүгенге почтада бүләкләр җибәрдем. Ходайдан курыкмыйча ничек шундый китаплар яздың? Ул китапка киткән кәгазьнең, исраф булган караның хода каршында ничек җавабын

бирерсең?" — дип, Батыргали агай безне бик әшәке сүзләр илә сүгеп, бик үгетләп язадыр. Илтифат итеп, без язган китапны укыган өчен, Батыргали агайга без үз тарафыбыздан бик рәхмәт укыйбыз. Әмма шулай да булса, дустымыз Батыргали агай "Япон сугышы"н башыннан ахырына кадәре укымаган булса кирәк. Яки укыса да, банкы директоры англичан илә сәгатьче яһүди Абрамны аера алмаган кебек, казенка куәте белән күзләрен томан басканлыктан, Порт-Артурга житә алмыйча зиһене чуалганлыктан, мәгънәсен бик яхшы аңламаган булырга охшыйдыр. Гәрчә мин аны туган жиребез, падишабыз өчен жанын фида кылучы дип, мылтык-кылычлар тагып, гайрәтле, һичнәрсәдән курыкмый торган батыр кылып, Усиядә азан әйтеп, сугышка озатып калсам да, ул мин уйлаганча булып чыкмады. Түгел кылыч, мылтык тотып японнарга каршы бару, хәтта миңа язган хатына да үзе кул куярга курыккан. Кеше яллап хат яздырган. Әй, бичара ялганчы Батыргали агай! Син, никадәр бияләй эченнән кукиш күрсәтсәң дә, һичнәрсә эшли алмассың. Төрекләр әйтмешли: "Бән сиури синкели жирдә чук булындым, уйкусыз да калмадым" ("Черки бар жирдә күп булдым, аның мызылдаганына карап, йокламый да калмадым"). Хатында: "Синең кем икәнеңне бик беләбез", — дигәнсең, бу жирдә һәм бераз хата кылгансың. Чамасы син мине бик белеп бетерә алмагансың. Минем кем идекемне син Казанда Әхмәт байдан сораш, ул мине бик яхшы беләдер һәм таныйдыр:.. Әй фальшевый Батыргали агай! Алай итеп, койма ышыгында торып сугу егетлекмени? Гәрчә син, кәгазьне исраф кылгансың, дисәң дә, янә хат язгансың. Чөнки синең хат илә бер почтада Казаннан Галиәсгар әфәндедән: "Тагын ике йөз Батыргали китабыны" тизрәк жибәрсәгез лә, мондагысы сатылып бетте", —дип язган хаты бар иде. Син яратмасаң да, Казанда чамасы һәммәсе сезнең кеби ахмак түгел, укучылар да күп. Батыргали агайның Һәдияләрен дә почтадан алдым.

Посылкасы эченнән: тарак, канат, күзлек, көя ашаган фуфайкалары чыкты. Аңлашылды ки, безнең Батыргали агайны Бакудан юкка сумашедши вагонга утыртып кайтармаганнар икән; посылканың тышкы ягында: "Галиев мәдрәсәсеннән" дип язылса да, Галиев мәдрәсәсендә мондый ахмаклар булыр ди алмыйм.

Мондый юк нәрсә өчен "Казан мөхбире" кебек милли булган бер газетаның сәхифәсен тутырмак мөнасип түгел исә дә, Батыргали агай кебек адәмнәр бераз инсафка кайтып, алтыннан кыйммәтле вакытларны юк нәрсәләргә заигъ кылмаенча, файдалырак эшләргә сарыф кылмаслармы, дип, шушы хатымны язмага мәжбүр булдым.

**Шакир МӨХӘММӘДЕВ.**
*Оренбург.*

Кайбер сүзләргә аңлатмалар *(текстлардагы тәртиптә):*

Игътикат — ышану.
Кәррәи әрыз — жир шары.
Гарыз — киңлек.
Тул — озынлык.
Шимал — төньяк.
Жәнүп — көньяк.
Карья — авыл.
Мөбарәк — изге; кадерле; бәхетле, хөрмәтле.
Хилаф — каршы; кире, тискәре.
Половой — ашханәдә аш-чәй бирүче, официант.
Тәүбә тәзаригъ кылу — түбәнчелек белән тәүбә итү.
Тулы әмәл — озын планнар һәм хыяллар белән шөгыльләнү.
Коршау аткан — банкротлыкка төшкән.
Әгъла — бик яхшы; бик кадерле.
Портерный — сырахanә.
Муафыйк — яраклы, килешле, урынлы.

Мәкруһ — шәригать кушмаган; начар күрелгән; усаллык.
Кәррә — тапкыр, кабат.
Халис — чын; саф.
Карыз — бурыч.
Тәгъриф итү — анлату.
Тәзәйен — зиннәтләү, бизәкләндерү.
Сахип — хужа, ия.
Мөскират истигъмал кылу — исерткеч эчү.
Мөкатдәм — элек.
Дәрхаль — шунда ук.
Мөнасип түгел — килешеп бетмәсә дә, мәгънәсендә.

ИСКӘРМӘ

**Шакир Мөхәммәтша** улы Мөхәммәдев (1865 — 1923) татар әдәбиятында юмор-сатираны олы юлга алып чыгучыларның берсе булды. Аның хикәяләре, шигырьләре, фельетоннары һәм мәкаләләре, мәсьәләне үзәгеннән эләктереп, гаҗәеп үткән тел белән язылган. Ш. Мөхәммәдев 1906 елда үз мөхәррирлегендә "Карчыга" исемле сатирик журнал нәшер итә башлый. Язучының күп әсәрләре басылган бу журнал — татар вакытлы матбугатында алгы сафта булган журнал — тугыз саны чыкканнан соң, 1907 елда ябыла.

Әдипнең әсәрләренә тормыштагы тискәре күренешләрне бик тә күпертеп күрсәтү хас, шулай ук язучы сурәтләүдә мондый күренешләргә җай чыккан саен астыртын гына "терсәк белән кагылып китү" мөмкинлеген дә "кулыннан ычкындырмый". Хәер, көчле сатирага нәкъ шушы сыйфатлар килешә ләбаса.

Ш. Мөхәммәдев иҗатында "Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе" һәм "Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай" исемле әсәрләр үзәк урынны алып тора. "Батыргали агай" хикәясендә туган илне яраткан булып кылану-саташу, буш куык "патриотизм" ягъни, үтә дә көлке итеп сурәтләнә. Бүгенге ялган патриотларга-демократларга да Батыргали агайның кайбер сыйфатлары тач килә кебек. Димәк, әсәр бүген дә заманчалыгын югалтмаган.

Бу күләмле хикәясе басылгач, Шакир Мөхәммәдевкә янаучылар да була. Әдипнең туганнан туган энесе Тәуфыйкка язган хатында мондый хәлләрне раслаучы түбәндәге юллар бар: "Казаннан Батыргали дигән бер адәмнән миңа хат бар иде. "Батыргали"не язган өчен бик сүгеп хат язган иде. Чамасы Казанда шундый юан корсаклы бай бардыр. Сәламәт булсам инде, Батыргали агайны Петербургка Государственный Думага член кылып җибәрергә ният кылып торамын".

Һәм Шакир Мөхәммәдев "Батыргалинең Думага сайлануы" исемле әсәр язган да булган икән. Бу хакта профессор М. Гайнуллин мәкаләсеннән өзек китерик: "1908 елда аны язып тәмамлагач, рөхсәт алу өчен цензурага җибәрсә дә, тормыш иптәше Суфия ханымның раславына караганда, рөхсәт тә килми, кульязмасы да кире кайтмый."

"Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай" әсәре (язучы аны "рисалә" дип тә атый, ягъни шулай ук хикәя) язылган елында ук Оренбургта Кәримовлар матбагасында басыла. Шулай ук ул югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләре студентлары өчен 1947 елда чыгарылган "Татар әдәбияты. Дәреслек-хрестоматия. XX йөз" исемле китапта (төзүчеләре М. Гайнуллин һәм Җ. Вәзиева), язучының 1958 елда басылган "Сайланма әсәрләр"ендә (төзүчесе М. Гайнуллин) бар.

Әдипнең "Батыргали агайга ачык җавап" исемле мәкаләсе әлеге хикәягә турыдан-туры бәйле. Шуна күрә без аны әсәр ахырына "ялгауны" кирәк санадык. Ул 1906 елда "Казан мөхбире" гәзитендә беренче тапкыр басылган.

"Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай" һәм "Батыргали агайга ачык җавап" текстлары Шакир Мөхәммәдевнең югарыда аталган "Сайланма әсәрләр"еннән алынды.

Әсәрне журналда бастыруга
**Мәгъсум ХУҖИН** әзерләде.

*Фән*



**Равил Фәхретдинов,**
тарих фәннәре докторы

# ТАТАР ТАРИХЫ БИТЛӘРЕННӘН

## Борынгы төрки чор. Һуннар империясе. Төрки һәм Кимәк каһанлыклары

Халкыбызның бөек әдибе, XX гасыр башы милли-азатлык хәрәкәте житәкчеләреннән берсе Гаяз Исхакый: көрәшләрдә чыныккан һәм бәйсезлек өчен көрәшен дәвам иттерүче татар халкы үзенең психологиясе буенча житәрлек дәрәжәдә дәүләтчел ул, дигән иде. Әйе, дөньяның зур төрки халыкларыннан саналган татарның ерак гасырлардан килүче олуг тарихы —дәүләтчелек тарихы бар, ул тарих халыкның бай этник һәм мәдәни үткәне белән аерылгысыз бәйләнгән. Бу тарих ифрат катлаулы чорларга һәм данлыклы вакыйгаларга, урта гасырлар Евразиясенең сәяси дөньясында онытылмаслык эз калдырган берләшмәләргә һәм дәүләтләргә, дөньякүләм мәшһүр цивилизация учакларына, бөек, кодрәтле, шул ук вакытта каршылыклы вә фажигале шәхесләргә бай. Бу тарих халыкның үзе кебек үк олуг һәм фажигале.

Татарның мең еллык тарихы бар дип әйтү гамәлгә кергән. Бу билгеләмә төгәллеккә мохтаж. Халкыбызның дәүләтчелек тарихы гына да мең еллык! Ә татарның бөтен тарихы, аның үз милли дәүләтләре юкка чыкканнан соңгы чорларын да кертеп, мең ярым еллык дәвергә сузыла. Ә бу бит әле язма чыганаклар белән билгеләнгәне генә, аңарчы күпме булганлыгын тәгаенләп әйтү әлегә мөмкин түгел. Мөмкин булганы исә, ягъни тарихи чыганаклар белән расланганы, VI гасырның уртасына — 552 елга барып тоташа. Нәкъ шул елда татар дәүләтчелегенең дә башлангычы булган Төрки каһанлыгы оеша, шул ел белән язма тарих мәйданына "Утыз татар" исемендәге зур кабиләләр берлеге килеп керә.

Әлбәттә, Төрки каһанлыгы оешканчы да борынгы төрки дөнья булган, күп санлы төрки кабиләләр, аларның берлекләре яшәгән. Төркиләрнең иң әүвәле ватанының кайда икәнлеге, аның башлангычының кайсы тарихи дәвергә барып тоташуы хакында фәндә, гомумән, иҗат дөньясында бәхәсләр күп булды, алар әле дә дәвам итә. Бу бәхәсләр еш кына чын гыйлемнән шактый ерак торган төрле имеш-мимешләргә, теләгәненне хакыйкать итеп күрсәтергә тырышуга, хыял дөньясына чумып, фәнни булмаган, гайре табигый фикерләр әйтүгә дә кайтып кала. Әмма тарих, археология һәм антропология гыйлемнәренең бүгенге көнгә тупланган дөньякүләм казанышлары борынгы төркинеке дип чынлап торып атарлык зур этномәдәни дөньяны безнең эрага кадәрге II- I меңъеллыклар аралыгыннан башлап, аның фәнни чыганаклар белән расланучы башлангыч ватанын Үзәк Азия һәм Алтай киңлекләре белән билгеләргә мөмкинлек бирә. Алтайның атаклы Пазырык, Башадар һ. б.



*Каюлы читекнең алгы бизәлеше. Алтай, 2 нче Пазырык корганы, б. э. к. V йөз.*

курганнары, ягъни корганнары, Көньяк Себер, Тува җире, Байкүл (Байкал) артының гаҗәеп бай матди дөньясы, шул исәптән мәгълүм Тагар археологик культурасы — болар һәммәсе борынгы төрки мәдәниятне кешелек җәмгыятенең цивилизация тарихында лаеклы урынга куйдылар. Матди культураның Алтай корганнарында — ә алар безнең эрага кадәр V-III йөзләргә карыйлар — бик яхшы сакланган ядкярләре, бигрәк тә бизәкләү-гамәли сәнгатенең төрләре һәм техник алымнары, шулар арасында төсле күн вә киез ябыштыру һәм каюлау ысуллары, келәм һәм тукымалардагы бизәк төрләре, гасырлар дәвамында тотрыклы булып калган лалә чәчәге рәсеме һ. б. гомумтөрки мәдәниятенең генә түгел, ә татар халык сәнгатенең дә ерак башлангычы булып торалар. Мондый охшашлыкны, хәтта тәңгәллекне икрарлау шөбһәчел затларда шик тудырыр, бүгенге татар дөньясы белән Үзәк Азия һәм Себер киңлекләрендә моннан ике мең ярым ел элек калган археологик истәлекләрнең вакыт һәм территориаль аралыгы аларны әлегә ышандырмас. Әмма әйтеп үтелгән генетик тамырлар, мәдәни якынлык — шиксез, алар берни белән дә кире кагыла алмаслык матди мәдәният истәлекләре белән расланалар.

Безнең эрага кадәр яшәгән әлеге төркиләрнең чын тарихи исемнәре тәгәл билгеле түгел. Хәер, аларны фәндә беркадәр шартлы рәвештә “Алтай скифлары” дип атыйлар атавын, әмма “скиф” атамасы үз чорында Кара диңгез буеннан алып Иртеш-Алтай тирәләренә кадәрге киң далада яшәгән күп санлы күчмә кабиләләргә карата кулланылган. Ә менә тарихта тәгәлрәк исем белән билгеле булган беренче төркиләр итеп һуннар (сөннәр) исәпләнә.

Һуннар — безнең эрага кадәр IX гасырдан “хунну” исеме белән мәгълүм булган төрки телле күчмә кабиләләр. Алар бүгенге Монголиянең үзәк җирләрендә һәм Төньяк Кытайда яшәгәннәр. Вакытлар үтү белән аларда ыруглык-кабилә мөнәсәбәтләре үзгәрә барып, безнең эрага кадәр II гасырда Модэ җитәкчелегендә ярымфеодаль дәүләт оешкан. Тора-бара эчке каршылыклар ныграк кискенләшкән, һәм күчмә дәүләт ике өлешкә бүленгән: көньяк хуннулар үз җирләрендә, Кытайда, торып калганнар, ә төньяктагылары Җидесу ягына, хәзерге кыргыз-казакъ далаларына күчеп киткәннәр. Аларның да беркадәресе далада калган, икенче өлеше исә, иң зур күпчелеге, арырак, Көньяк Уралга таба юлын дәвам иткән.

Менә шушы һуннар IV гасыр ахырларында көнбатышка үзләренең атаклы һөҗүмнәрен башлыйлар. Алар Иделне кичеп, Азак (Азов) диңгезенә, тагын да ары — Кырымга кадәр барып җитәләр. 375 елда һуннар готлардан, ягъни борынгы герман кабиләләреннән, һәм сарматлардан оешкан Германарих дәүләтен җимереп, Үзәк Европага бәреп керәләр, Рим империясе җирләрен яулап алалар. Көнбатыш Евразиянең гаять зур мәйданында, Идел белән Рейн елгалары арасында, яңа империя — Һун империясе барлыкка килә.

V йөзнең 30 елларында империя икегә бүленә: көнбатыштагы яртысы белән Атилла, көнчыгыштагысы белән Блада идарә итә башлый. 445 елда Атилла үзенең көндәшен җиңә һәм бөтен империягә тулы хуҗа булып кала. Талантлы сәясәтче һәм атаклы гаскәр башлыгы Атилла 453 елда үлә. Империя таркала һәм аннан аерым кабилә берлекләре бүленеп чыга, алар озакламый мөстәкыйль дәүләтләр булып яши башлыйлар.

Һуннарның язмышы турында тарих фәнендә мондый фикер хөкем сөрә: алар башка төрки кабиләләр, шулай ук аланнар, готлар, өлешчә славяннар һәм мадьярлар белән кушылып, йотылганнар; Көнчыгыш Европада һуннарга гына кагылышлы археологик истәлекләр аз табылган, моны исә аларның һәрвакыт күченеп йөрүләре һәм башка кабиләләргә кушылып бетүләре белән генә аңлатырга мөмкиндер. Безгә калса, бу мәсьәлә өстәмә өйрәнүләрне, яңа фәнни тикшеренүләрне таләп итә. Ни өчен, мәсәлән, бөтен Европаны диярлек яулап алган һуннар тиз арада йотылып бетәләр дә, алар составына кергән һәм шулай ук күчмә кабиләләр булган хәзәрләр һәм болгарлар озак, берничә гасырлар яшиләр, хәтта дәүләтләр тоталар?



*Татарстанның Аксубай районы, Татар Сөнчәләе авылы янында табылган һун (сөн) казаны. IV йөз.*

Һуннар-сөннәр урдасындагы төрки кабиләләрнең кайсыдыр бер төньяк төркеме борынгы Татарстанның далалы көньяк өлешенә дә килеп чыккан. Бу хакта 1980 еллар башында Сөлчә елгасы буендагы Татар Сөнчәләе авылы янында табылган ике сөн казаны сөйли. Борынгы казаннар, башка төрки халыкларда да булган кебек (безнең эрага кадәрге Тагар археологик культурасы чорында, соңга таба кыпчакларда, тагын да соңгарак Казан татарларында) , кабилә яки ил башының хакимият билгесе, регалие булып саналган. Сөнчәләй авылы янында табылган бронза казаннар халыкларның Бөек күчеше чорында һуннар ташкынында безнең якларга да килеп чыккан беренче төрки кабиләләрнең бик кыйммәтле тарихи истәлеге булып саналалар.

Һуннар Европа һәм Азиядәге күп халыкларның һәм, әлбәттә, беренче чиратта төрки телле халыкларның, шулар арасында татарның да ерак тарихында зур эз калдыралар. Нәкъ менә һуннар хәрәкәте белән башланган халыкларның Бөек күчеше Евразиянең яңа этнографик картасын тудыра. Яңа этник башлангычлар, яңа халыклар һәм, инде әйткәнемчә, яңа дәүләтләр барлыкка килә. Һуннар империясе таркалгач төзелгән яңа берләшмәләр арасында иң зурларыннан Төрки каһанлыгын атарга кирәк.

Төрки каһанлыгына 552 елда Бумын каһан нигез сала (каһан яки каган “бөек хан” дигән сүз). Яңа дәүләт тиз арада шундый зур үсешкә ирешә ки, ул Алтайның, Үзәк һәм Урта Азиянең бик күп кабиләләрен бер хакимлек астына берләштерә. Төрки кабиләләр бөтен Евразия далаларын биләп алалар, каһанлык көнчыгышта Кытай империясе белән чикләнә, көнбатыш биләмәләре Кырымга кадәр барып җитә. Вакытлар үтү белән илнең эчке эшләренә Кытай тыкшына башлый, төрки җәмгыятьнең үзендә дә каршылыклар туа. VII йөз башында каһанлык ике өлешкә — Көнбатыш һәм Көнчыгыш Төрки каһанлыкларына бүленә.

Урта Азия җирләрен биләгән Көнчыгыш каһанлык Бумын каһанның оныгы Дату каһан җитәкчелегендә зур куәткә ирешә, әмма көнчыгыштан Кытай һәм төньяктан яңа кабиләләр кысрыклавы нәтиҗәсендә 740 елда яшәүдән туктый. Көнчыгыш Төрки каһанлыгына, җирләре янәшә үк булганлыктан, Кытай империясеннән саклану өчен тагын да зур көч куярга туры килә. Берничә тапкыр булган бәрелешләрдә, бигрәк тә 730 елларда ике арада барган зур сугышларда, каһанлык үзенең бәйсезлеген саклап кала ала. Бу сугышларда Билге каһан, бигрәк тә аның энесе, урта гасырларның атаклы гаскәр башлыгы, ханзәдә Күлтәгин зур батырлыклар күрсәтәләр. Көнчыгыш Төрки каһанлыгы, 745 елда Уйгыр каһанлыгы белән булган зур сугышта җиңелеп, яшәүдән туктый.



*Кәнчыгыш Төрки каһанлыгының атаклы гаскәр башлыгы, ханзадә Күлтәгиннең истәлек ташы. VIII йөз.*

Төрки каһанлыгында башлангыч феодаль мөнәсәбәтләр урнашкан булган. Хуҗалыкның нигезен терлекчелек тәшкил итсә дә, игенчелек белән дә шөгыльләнә башлаганнар. Металл, шулай ук тире, күн эшкәртү алга киткән. Акча сугу җайга салынган —Сөяб, Тараз,Утрар кебек шәһәрләрдә сугылган акчалар мәгълүм. Язу барлыкка килү, төрки җәмгыятьнең, аеруча, Көнчыгыш Төрки каһанлыгының зур казанышы, цивилизация билгесе санала. Узган гасырда ук Төньяк Монголиянең Урхун елгасы буенда борынгы төрки-рун язулы истәлек ташларының табылуы бөтендөнья тюркология фәнендә искиткеч зур ачыш булды. Билге каһан һәм Күлтәгин, шулай ук төрки каһаннарның гаскәр башлыгы һәм киңәшчесе, зирәк Тонйокук ташларындагы язулар чын мәгънәсендә тарих һәм тел гыйлеме фәнен шаккаттырды. Бу язмалар бөек ханнарның һәм атаклы гаскәр башлыкларының тормышын, сәяси вә хәрби эшчәнлекләрен Төрки каһанлыгының гомум тарихы яктылыгында төгәл һәм ачык итеп тасвирлыйлар, борынгы төркиләрнең телен өйрәнүдә бәя биреп бетергесез зур фәнни байлык булып саналалар.

Ул борынгы телне җентекләп өйрәнү безнең мөхтәрәм тел белгечләребезнең әле чынлап торып тотынмаган, әмма якын киләчәктә башкачарак мөһим, изге бурычы, мин исә миллəттәшләребезнең игътибарына шул таш язмалардан бер-ике генә өзек китереп үтим.

Күлтәгин ташыннан:

*"Иним Күлтигин эр ат булты."*

Чагыштыру өчен шул ук юллар бүгенге яңгырашта:

*"Энем Күлтәгин ир-ат булды."*

Яки менә тагын:

*"Күлтигин алты утуз йашына...*
*Күлтигин йити утуз йашына...*

Бүгенгечә:

*"Күлтәгин утыз алты яшенә (җитеп)...*
*Күлтәгин утыз җиде яшенә (җитеп)..."*

Тонйокук ташыннан:

*"Билге Тонйокук бән өзүм*
*Табгач илинә кылынтым."*

Бүгенге яңгырашта:

*"Зирәк Тонйокук мин үзем*
*Табгач (Кытай) иленчә тәрбияләндем."*

Тагын ике юл:

*"Кызыл каным төкти*
*кара тирим йүгүрти."*

Бүгенгечә:

*"Кызыл канымны түгеп,*
*кара тиремне йөгертеп (агызып)."*

Әдәби телне белгән һәм милли аһәңне тоя белгән һәр укымышлы татарга бу юллар бик якындыр дип уйлыйм. Ә бит 730 еллар башында язылган ул заманнан соң 1370 ел, ягъни 14 гасырга якын вакыт узып киткән...

Шушы рун язулы истәлек ташларында VI йөз уртасы һәм VII йөзнең икенче яртысындагы тарихи вакыйгалар уңае белән "утыз татар", ә 722 — 723 еллардагы сугышларны тасвирлаганда "тугыз татар" кабиләләре искә алына. Боларны утыз һәм тугыз кабиләләрдән торган зур берлекләр, ягъни кабиләләр союзы дип атарга кирәк. Уйгыр ханы Муенчур ташында 745 елгы хәлиткеч сугышта Көнчыгыш Төрки каһанлыгының гаскәрендә 30 мең татар сугышчысы булганлыгы әйтелә (очраклы булса да, бер чагыштыру китерик: 1552 елда Казан Явыз Иван тарафыннан яулап алынганда татар гаскәрендә шулай ук 30 мең сугышчы була).

Каһанлык җиңелгәннән соң борынгы татарларның бер өлеше көнбатышка юнәлә, Иртеш суы белән Урал таулары арасында VIII гасыр уртасында Кимәк каһанлыгы төзи. Татарлар шулай ук X йөз башында Урта Азиядә Караханилар дәүләтен оештыруга да зур өлеш кертәләр. Ә Үзәк Азиядә, Байкүл артында, ягъни үзләренең башлангыч ватаннарында калган татарларның (күпмесе көнбатышка киткән дә, күпмесе үз җирендә калган — әлегә билгеле түгел) бер өлеше Уйгыр каһанлыгына буйсындырыла, башкалары кидан (кара кытай, кара китән) исемле төрки кабиләләр белән яңа берлек төзи.


Татар халкының баштагы дәүләтчелек, этник һәм мәдәни тарихын Төрки каһанлыгы җимерелгәннән соң төзелгән бер борынгы дәүләтсез күз алдына китерү кыен булыр.

Бу дәүләт — Көнбатыш Себердә, Иртеш елгасы белән Урал таулары арасында урнашкан Кимәк каһанлыгы. Аны төзүчеләр булып борынгы татарларның VIII гасыр уртасында Көнчыгыш Төрки каһанлыгы Уйгыр каһанлыгы тарафыннан җиңелгәч, үз җирләреннән кояш баешына таба хан ( каһан) улы Шад җитәкчелегендә киткән бер төркеме санала. Бу хакта XI йөз фарсы тарихчысы әл-Гардизинең "Хәбәрләрнең күрке" дигән китабында сөйләнә һәм ул тарих VIII йөзнең инде безгә таныш булган Урхун язмаларындагы, мәсәлән, Тоньокук ташына уелып язылган тарихи вакыйгалар белән беркадәр аваздаш —язмаларның беренче өч бүлеге, 10 — 18 юллар.

Кимәк каһанлыгының төп халкын борынгы татарларга кардәш төрки халык булган кимәкләр тәшкил иткән, алар VII йөздә үк Көнбатыш Төрки каһанлыгына кергән булганнар. Кимәкләрнең Урал тауларына якын яшәгән зур бер төркеме кыпчаклар дип аталганнар. Бераз алгарак китеп әйтеп куйыйк: каһанлык таркалганнан соң, инде XI йөздә, кыпчаклар көчәеп, көнбатышка юл алалар, Иделне кичеп, Днестрга кадәр булган зур далага хуҗа булалар һәм ул яңа дөнья тарихка "Дәшти Кыпчак", ягъни Кыпчак даласы исеме белән мәңгелеккә кереп кала.

Кимәк каһанлыгы, башка төрки берләшмәләр кебек үк, башлангыч феодаль дәүләт булган. Дәүләтнең башкаласы — Йөмәк шәһәре. Күченеп йөрүче кыпчак кардәшләреннән бераз үзгә буларак, кимәкләр утрак тормышка керә башлаганнар, хайван асрау белән бергә җир эшкәртү, иген игү урын алган: бодай, арпа, хәтта дөге дә үстергәннәр. Кимәк иленең башкаласында, кайбер башка шәһәрләрдә дә базарлар гөрләп торган, тышкы һәм эчке сәүдә шактый таралыш алган булган.

Кимәк гаскәре атлы һәм җәяүле сугышчылардан торган, алар озын кылычлар, сөңгеләр, ук-җәяләр белән коралланган булганнар. Бу хакта археологик табылдыклар ачык сөйли; алар арасында төрле көнкүреш кирәк-яраклары, эш кораллары, бизәнү-ювелир әйберләре, мәсәлән, металл көзгеләр, муенсалар, алкалар, бизәкле төймәләр һ. б. истәлекләр шактый күп. Гомумән, шәһәр тормышының шактый ук таралган булуы археологик казулар белән байтак ачыкланды.




*Кимәкләрдәге рун язулы бронза көзге (арткы ягы). VIII-IX йөзләр.*

Кимәкләр, нигездә, мәҗүси булганнар һәм Иртеш елгасына табынганнар, шулай ук

утны, кояшны, йолдызларны да изге итеп санаганнар. Гарәп географларының мәгълүматларына караганда, кимәкләр һәм кыпчаклар хәтта астрология белән дә шөгыльләнгәннәр, йолдызлар "телен" аңлаганнар. Күп кенә төрки халыклардагы кебек, кимәкләрдә дә каһарман сугышчылар, күренекле гаскәр башлыклары хөрмәтенә таш сыннар кую гадәте булган. Әйтергә кирәк, кимәк сыннары белән кыпчак балбаллары арасында охшашлык зур. Кимәк җәмгыятендә рун язуы да кулланылган, ул анда Төрки каһанлыгыннан килеп кергән.

Кимәкләрнең бер өлеше, нигездә, югары катламы, соңга табарак Мани динен, ягъни заманында Фарсыда, Урта Азиядә һәм Һиндстанда шактый киң таралган динне кабул иткән, аны әкренләп ислам алыштырган. Гомумән, VIII йөз уртасы — X йөзләрдә яшәгән Кимәк каһанлыгы татар халкының сәяси һәм этномәдәни тарихында, шул исәптән Себер татарларының үткәнендә беркадәр башлангыч эз калдырган борынгы бер дәүләт булып санала.

## Дәшти Кыпчак

"Дәшти Кыпчак"ның кыпчак далалары дигәнне аңлатуы хакында югарыда, Кимәк каһанлыгы турында сөйләгәндә әйткән идек. Кемнәр соң ул кыпчаклар, кайчан һәм кайлардан килеп әлеге шул каһанлыкның Урал тауларына таба булган көнбатыш җирләрен, ә инде XI гасырда тагын да арырак күченеп, Идел белән Дунай тамагы арасындагы киң далаларны биләгәннәр? Биләгәннәр һәм үзләренә яңа ватан табып, мәңгегә онытылмаслык булып тарих битләренә кереп калганнар, сөннәрһуннардан соң яңа бер зур көчеш тәшкил итеп, Евразиянең этник картасын яңарткаnнар, үзләреннән соң далаларны тутырып таш балбаллар гына түгел, ә бүгенгәчә яшәп килүче тере тел калдырганнар...

Төрки телле кыпчак кабиләләре тарихи чыганакларда беренче тапкыр безнең эрага кадәр III-II гасырлар белән искә алыналар. Төньяк Алтайда яшәгән ул кабиләләр Кытай елъязмаларында "циньча" дип аталалар. Хөрмәтле укучыларның исләренә төшерик: алдарак Алтайның V - III йөзләргә караган Пазырык һ. б. корганнары, алардагы бик тә бай матди культура, бизәклəү-гамәли сәнгатенең ачык үрнәкләре хакында, ул истәлекләрнең төрки халыкларга кагылышлы булуы турында әйткән идек. Димәк, шул замандагы Алтай кабиләләренең төркилеге язма чыганаклар белән дә раслана.

Шуннан соңгы мең елга якын вакыт эчендә кыпчаклар хакында ниндидер мөһим хәбәрләр күренми диярлек. Хәер, кыпчакларның уйгырлар өстеннән ярты гасыр буена (VII-VIII йөзләр аралыгында) хакимлек итүе хакында уйгыр каһаны Муенчур ташында бер хәбәр чагылып китә китүен. Әмма Төрки каһанлыгы таркалганнан соң, борынгы татарлар тарафыннан VIII йөздә төзелгән Кимәк каһанлыгының көнбатыш кабиләләре буларак, алар яңадән язма тарих мәйданына килеп керәләр, ә инде ул дәүләт тә яшәүдән туктагач, XI йөздә, тагын да көнбатышка таба үзләренең атаклы хәрәкәтен башлыйлар. Бераз гына көньяктарак яшәгән бәҗәнәкләрне һәм угызларның бер өлешен (урыс чыганакларында "торки" дип аталалар) кысрыклап, кыпчаклар Иделне кичәләр һәм тагын да арырак узып, Дон, Днепр һәм Днестр буйларына барып җитәләр, шулай итеп, Идел белән Днестр, хәтта тагын да арырак, Дунай елгасының түбән агымына кадәр сузылган гаҗәеп зур далаларга хуҗа булалар. Ул далалар Шәрекъ дөньясында соңгарак "Дәшти Кыпчак" дип атала башлый (кыскартылып "Дәшт", ягъни Дала дип кенә дә йөртелгән).

Урта гасырларның гарәп-фарсы географиясендә, хәтта соңгырак әдәбиятта да, бу далалар турында бик матур язылa, һава-суларның чисталыгына вә сафлыгына, үләннәрнең муллыгына, мал-туарның күплегенә соклану белдерелә. Шундый язмаларның берсенә генә мөрәҗәгать итик — аларны 1260 елларда фарсы тарихчысы әл-Җузҗани калдырган: "Чыңгыз ханның улы Туши (Җучи. — Р. Ф.), кыпчак җиренең һава һәм суларын күреп, шуңа инанды: бөтен дөньяда моның кебек күңелгә ятышлы бүтән бер җир, моннан да чистарак һава, тәмлерәк су, киңрәк болын һәм көтүлекләрнең булуы мөмкин түгел". Шуңа охшашлы җылы сүзләрне XV йөз башы

гарәп тарихчысы, Алтын Урдада булган Ибне Гарәбшах, XVIII йөз немец сәяхәтчесе-профессор Тунманн, урысның атаклы язучылары Н. Гоголь, А. Толстой һ. б. әсәрләрендә дә очратырга була.

Урыс тарихы чыганакларында әлеге далалар "Степь половецкая" дип аталалар. "Кыпчак"ның урысча атамасы булган "половец" сүзен күпчелек галимнәр "половый, ягъни сары, аксыл-сары дигән мәгънәне белдерә, диләр. Бу фикер тарафдарлары кыпчакларны аксыл чәчле һәм зәңгәр күзле булганнар дип саныйлар һәм аларның килеп чыгышын әле безнең эрага кадәр I меңъеллыкның ахырында Көньяк Себердә яшәгән "динлин" дигән ярымлегендар кабиләләр белән бәйлиләр.



*Кыпчак ханының өске киеме — кафтан. Чыңгыл корганын (Көнбатыш Украина) казыганда табылган. XII йөз.*

Казакъ шагыйре Олжас Сөләйманов үзенең күпләргә мәгълүм "Аз и Я" дигән китабында "половец" сүзен "поле", ягъни "кыр" сүзеннән ясалган, дип язды. Кыпчакларның күчмә булганлыгын, ягъни нәкъ менә кыр, дала кешеләре икәнлеген искә алсак, мондый фикер шактый эзлекле булып яңгырый. Һәм, әлбәттә, урыс елъязмаларын төзүчеләр өчен дә кыпчаклар иң әүвәл дала кешеләре булганнар. Ниһаять, төркиләрнең күпчелеге кебек үк, кыпчак та, нигездә, кара чәчле, кара күзле булган — юкка гына "кара" сүзе төрки халыкларга еш кына символик тагылма булып йөрми, мәсәлән, кара кытай (кара китән), карачалы (карачай), кара болгар, кара нугай, кара татар һ. б. Кыпчаклар арасында ак йөзлеләрнен дә булуын мин инкяр итмим, әмма сүз халыкның күпчелеге турында бара.

Дәшти Кыпчак тарихы, бигрәк тә аның Алтын Урда чорына кадәрге сәяси үткәне Урыс дәүләте, аның тышкы сәясәте белән тыгыз бәйләнгән һәм ул тарих урыс елъязмаларында шактый тулы чагылыш тапкан. Башта менә шул сәяси тарих белән кыскача танышып үтик.

XI йөзнең икенче яртысы кыпчак кабиләләренең яңа жир, яңа ватан табу, шунда берләшү чоры ул. Бәҗәнәкләр белән угызларның шактыен һәм Азов-Дон буйларында күченеп йөргән калдык болгарларны да үзләренә буйсындырып һәм йотып, кыпчаклар шактый үсешкә ирешәләр, ике зур төркемгә бүленәләр: Днепр белән Днестр аралыгында һәм тагын да арырак жирләрне билә гән көнбатыш берләшмәгә һәм Днепрдан алып Иделгә кадәрге көнчыгыштагысына.

Шул ук вакытта, урыслар белән мөнәсәбәтләр шактый киеренкеләнә, һәр ике яктан һөҗүмнәр еш. 1061 елдан алып 1097 гә хәтле чорда унга якын бәрелеш билгеле, шуларның күбесендә өстенлек кыпчаклар ягында була. Гасыр азагына таба кыпчак җәмгыятендә ханнар һәм бәкләр үсеп чыга. Бүнәк атлы хан (урыс елъязмаларында — Боняк) — кыпчак дөньясында гына түгел, гомумән, тарихта иң озак идарә иткән кеше, ул 1090 —1167 елларда, ягъни 77 ел хан булып, 95 яшьләрдә үлә, "бөек хан" исемен ала. Бүнәк көнбатыштагы берләшмә белән идарә итсә, көнчыгышның хакиме Тогур хан (Туторкан) була. Шунысы мөһим, бу ике хан арасында бердәмлек, хәтта шәхси дуслык урнаша. Тогур ханны урыслар әсир итеп үтергәч, Бүнәк алардан үч ала, Киев янында тегеләрне тар-мар итә, бу сугышларда кыпчаклар яхшы хәрби чынығу үтәләр, ә Бүнәкнең гаскәри осталыгы, даны кыпчак һәм урыс жирләренә генә түгел, еракларга да тарала.

Әмма XII гасыр башыннан хәл үзгәрә, кем әйтмешли, рольләр алышына. 1103 елда Владимир Мономах житәкчелегендә урыс кенәзләренең съезды үткәрелеп,

кыпчакларга каршы киләчәк сугышның, бүгенгечә әйтсәк, кин программасы кабул ителә. Шуннан соң Кыпчак җиренә ел саен дип әйтерлек, барлыгы 12 поход оештырыла, аларның күпчелеге урысның өстенлеге белән тәмамлана. Монда, әлбәттә, дәһшәтле кенәз һәм оста полководец Мономахның роле зур була. Гомумән, бу рәхимсез кенәз кыпчак дөньясы өчен зур зыяннар эшли: сугышта җиңелгәннәрне вәхшиләрчә үтерәләр, аларның гаиләләрен әсир итеп, кенәз һәм боярларга, хәтта сугышчыларга бүлеп бирәләр. Шул чорда кыпчакларның урыслашуы шактый көчәя.

Владимир Мономах 1125 елда үлә, ләкин аның кыпчакка каршы сәясәтен уллары, бигрәк тә олы улы, Киевнең бөек кенәзе Мстислав дәвам иттерәләр. Ул берничә тапкыр далага уңышлы походлар оештыра, күп әсир һәм ганимәт туплап кайта. Мономах башлаган эшне — урыс елъязмаларын үзгәртүне —Мстислав тагын да уңышлырак дәвам итә, ул язмалар "славян бөеклеге" рухы белән сугарыла. Каттый идеологик кысаларга кертелгән елъязмалар 1073 елда Никон төзегән беренчел чыганактан бик нык аерылалар, аларда тарихи гаделлек күзгә бәрелеп кими. Бөтен сәясәт, идеология урыс коралының көчен, урыс баһадирларының җиңелмәслеген мактауга, аларның дошманнарының, иң әүвәл "поганый" кыпчакларның кыргыйлыгын, явызлыгын сурәтләүгә, аларга каршы дошманлык тудыруга юнәлдерелә.

Урысның былиналарында гына түгел, хәтта елъязмаларында да елан кыяфәтендәге ("Змеево", "Змеевич") кыпчак сурәтләндерелә. Ә инде урыс халык әкиятләрендәге өч, җиде, унике башлы аждаһа-еланнарны әйткән дә юк — болары да кыпчак образы. Змей-Горынычлар, Кощей-Бессмертныйларның "явызлыгына" каршы көрәш рухында шул чор кешеләре генә түгел, уннарча буыннар тәрбияләнә. Шунысын да әйтеп үтик: Кощей Бессмертный ул, кыпчакларның җыен, җәйләү, авыл (аил) мәгънәсен аңлаткан "күч ("көч") сүзеннән алынган, аларның башлыкларын урыслар "Кощей" дип атаганнар (явыз мәгънәдә булмаса да, "Кошевой" варианты да бар, монысы көймәле арбаны яки тирмәне аңлаткан "кош", "куыш" сүзеннән ясалган).

Мстислав 1132 елда үлә һәм урыс-кыпчак мөнәсәбәтләре дә йомшый, ул мөнәсәбәтләрнең яңа дәвере башлана. Җитмәсә, урысның үзендә чуалыш, хакимият өчен көрәш көчәеп китә. Бу көрәштә кенәзләр һәм бөек кенәзләр күчмәләр (кыпчаклар, бәҗәнәкләр, берендейлар, карабүрекләләр) көченнән файдалансалар да, Кыпчак иле үзе яңа көч җыя, аякка баса. Элеккеге кечерәк берләшмәләр үсеп, урдалар тәшкил итәләр, аларның яшәеш, күчеш мәйданнары киңәя, җәйләүләр, халык саны арта. Көнбатышта, бигрәк тә Кырымда, гомумән, Кара диңгез буйларында элеккеге, антик дөньядан калган шәһәрләргә күчү, утраклану, игенчелек белән дә шөгыльләнү башлана. Феодализм тамыр җәя, феодаль иерархия, ягъни нәселдән килгән хакимият баскычлары урнаша: хан; аның улы, тәхет варисы — солтан; эре феодал, ягъни тархан — бәк; аннан түбәнрәк, әмма шулай ук затлы, аксөяк нәселеннән — би.

Шулай итеп, XII гасырның икенче яртысында Дәшти Кыпчакның яңарышы, кыпчак тарихының яңа чоры башлана. Кодрәтле бүтән ханнар үсеп чыга, араларында Кунчак (Кончак) аерылып тора. Чыгышы белән ул инде безгә мәгълүм Бүнәк хан нәселеннән, аның оныгы Әтрәкнең улы. Ул бөтен кыпчак җирен берләштерүгә ирешә, Дәшти Кыпчакның гомум ханына әверелә. 1174 елда урыс белән ике арада башланган уңга якын сугышта өстенлек Кунчак ягында була. 1183 елда Киевнең бөек кенәзе Святослав һәм Новгород-Северский кенәзе Игорь кыпчакларның көнбатыш берлеген җимереп, аның ханы Күбәкне (Кобяк) үтерткән булалар. Уңыш белән рухланган Игорь "Кыпчак даласының читенә сөңге кадау", ягъни бөтен Дәштне ут һәм кылыч белән аркылыга-буйга үтү максатында 1185 елда яңа сугыш ача. Кунчак оста хәрәкәт ясап, Игорьне алдый, аның бөтен гаскәрен тар-мар китерә, кенәзнең үзен әсир итә, Переяславль һәм Путивль шәһәрләрен ала. Бу сугышлар урысның күпләргә мәгълүм "Игорь полкы турында җыр" исемле поэмасында чагылыш таба, ә анда сурәтләнгән вакыйгалар атаклы композитор А. Бородинның "Князь Игорь" исемле операсына нигез була. Шундагы "Половец кызлары җыры"н тыңлап, "Половецлар биюе"н карап күпләр ләззәтләнгәндер. Гомумән, әлеге операда кыпчак дөньясы шактый дөрес тасвирланган.

Искиткеч зур кыпчак дөньясы бер хан — Кунчак кулы астында берләштерелсә дә, Дәшти Кыпчак чын мәгънәсендә дәүләт булып оешып бетә алмаган, дип әйтәләр

күпчелек тарихчылар; кыпчак җәмгыятендә феодаль дәүләт өчен кирәкле бөтен билгеләр дә булмаган, диләр алар. Бу мәсьәләдә соңгы ноктаны куймас идем мин. Һәрхәлдә, олуг кыпчак җиренең бербөтен этник дөнья һәм феодаль берләшмә, зур этномәдәни мохит булганлыгы шөбһәсез.

Мөстәкыйль Дәшти Кыпчакның соңгы дәвере монгол яуларына каршы көрәштә уза. 1222 — 1223 еллардагы беренче һөҗүм нәтиҗәсендә кыпчаклар җиңеләләр (бу вакытта Кунчак юк инде —ул XIII гасыр башында үлә һәм хан булып аның улы, христиан диненә күчкән Юрий кала). Көнбатыш биләмәләрне икенче бер хан — Котан үз кул астына ала, әмма ул, Бату яуларыннан качып, 1237 елда 40 меңлек урдасы белән Венгриягә китә, аны анда, урыслар һәм монголлар (?) белән элемтәдә гаепләп, җәзалап үтерәләр. Аның гаскәре венгр короленә каршы баш күтәрә, Болгариягә күченеп китә һәм ул кыпчаклар шунда төпләнеп калалар. Кыпчак җиренә монгол явы 1228 — 1229 елларда кабатлана, халыкның шактый өлеше тагын Венгриягә, шулай ук урыс һәм Литва җирләренә китә. Ниһаять, 1237-1238 еллардагы зур яу нәтиҗәсендә Дәшти Кыпчак бөтенләе белән басып алына һәм 1243 елда төзелгән зур бер дәүләтнең — Алтын Урданың төп җирләренә әверелә.

Кыпчаклардан калган фәнни байлыкларның өчесенә генә —безнең карашка, бик тә мөһимнәренә, — кыскача тукталып үтик. Шуларның берсе — 1303 елда Кырым шәһәрләренең берсендә төзелеп, бүгенге көндә Италиянең Венеция шәһәрендә, Изге Марк китапханәсендә саклану чы мәшһүр "Коман мәҗмугасы" ("Кодекс Куманикус") — кыпчак-латин-фарсы сүзлеге. Ни өчен "коман", чөнки кыпчакларны Көнбатыш Европада команнар дип атаганнар (коман дип кыпчакларның көнбатыш төркеме йөртелгән дигән фикер дә таралып бара соңгы елларда). Үзенең сүзлек составы, андагы әйтем-табышмакларның, кыска хикәяләрнең җөмлә төзелеше, грамматик калыплары ягыннан әлеге мәҗмуга бүгенге татар теленә бик якын, аның теле, нигездә, — безнең татар теле.

Икенчесе — кыпчаклардан калган һәм үзенең кümү йолалары, анда сакланган әйберләрнең байлыгы белән аерылып торучы каберлекләр. Ул заманда әле кыпчакларда ислам дине таралмаган һәм алар мәҗүси булганнар, шуңа күрә, теге дөньяда да тормышны дәвам итү максатында үлгән кешенең каберенә үтереп атын, коралларын, ашарына салып, савыт-саба куя торган булганнар. Болар — бик тә әһәмиятле археологик, антропологик һәм тарихи-этнографик материаллар, алар тарихыбызны торгызуга ифрат зур өлеш кертәләр.

Өченчесе — атаклы кыпчак балбаллары, ягъни шул чордагы сугышларда, атабаба җиренең иминлеге өчен башка төрле көрәшләрдә шәһид булганнар истәлегенә куелган таш сыннар. Алтын Урда дәүләте төзелеп, анда ислам дине кабул ителгәч, сыннарны ясау гадәте бетә, әмма ул балбалларга тимиләр, алар урыннарында калалар. Тик ул җирләр инде урыслар тарафыннан басып алынгач, сыннарның шактые юкка чыга, ватыла, җимерелә. Сакланып калганнары да халыкның күплеге хакында, кыпчак дөньясындагы матди культураның гаҗәеп байлыгы, шул дөнья рухиятының бөеклеге дә, серлеге дә турында сөйлиләр.

Мөхтәрәм укучылар танышкан әлеге язма Равил Фәхретдиновның "Татар тарихына кереш" исемле яңа китабының кулъязмасыннан алып басылды. "Мәгариф" нәшриятында быел дөнья күрәчәк ул китап борынгы дәверләрдән алып, XX гасыр башындагы милли көрәш чоры белән тәмамланган олуг тарихыбызны — татарның дәүләтчелек һәм азатлык көрәше тарихын эченә ала. Күләме ягыннан зур булмаган, җиңел тел белән язылган һәм күп санлы рәсемнәр белән бизәлгән яңа китап укучыларда зур кызыксыну уятыр дип өметләнәбез. "Татар тарихы" исемле китапка заявкаларыгызны түбәндәге адрес белән җибәрә аласыз:

**420503, г. Казан, Бауман урамы, 19, "Мәгариф" нәшрияты.**
**Телефоннар: 32-49-97, 32-11-90**

*Хәтер*

# ТУКАЙЛАР ЗАМАНДАШЫ

## КҮРЕНЕКЛЕ ӘДИП ЗАРИФ БӘШИРИНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Халкыбызның ифрат бай әдәби мирасында егерменче гасыр башы шагыйрьләренең иҗаты зур урын биләп тора. Тукай, Рәмиев, Гафури, Дәрдмәндләрнең шигърият җимешләре эстетик кыймммәтләрен югалтмаган хәлдә бүген дә күңелләребездә яши. Тормышчан эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнешләре белән әлеге классик әдипләребез әсәрләренә тиңләшерлек шигъри җәүһәрләрен язып калдырган күренекле шагыйрьләребез дә бар безнең. Нәҗип Думави, Зыя Ярмәки, Миргазиз Укмасый, Сәгыйть Сүнчәләй, Габдрахман Сөнгати, Габдулла Харис — әнә шундый каләм ияләреннән. Бүген исә сүзебез хаклы рәвештә алар арасында йөртелә торган икенче бер әдибебез турында барыр. Ул — Зариф Бәшири.

Егерменче гасыр башы татар әдәбиятыннан хәбәрдар затлар, әдәбият тарихчылары күзаллавында барыннан да бигрәк шагыйрь, шулай ук прозаик, очеркист, балалар язучысы, журналист-публицист сыйфатында гәүдәләнә ул...

Татарлар күпләп яшәгән урыннар арасында Казан арты, Пенза, Тамбов, Нижгар, Башкортстан, Урал яклары гына түгел, Тау ягы да гасыр башында әдәбиятыбыз, сәнгатебезгә, мәдәниятебезгә мәшһүр шәхесләр биргән төбәк буларак тәкъдир ителергә тиешле. Форсаты чыккач, тау ягында туган олы шәхесләрнең исемнәрен дә атап китмәкче булам. Менә аларның кайберләре: язучы, журналист Касыйм һәм Ибраһим Биккуловлар, күренекле әдәбиятчы Җамал Вәлиди, язучы Садри Җәлал, Тукай остазы Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин һәм аның балалары, шагыйрә һәм педагог Маһруй Мозаффария, матбагачы Шәрәфләр, шагыйрь Г. Харис, журналист Кәлимулла Сәгъди (1911 елда Америкага барып яшәгән), әдип Әхмәтҗан Биктимеров...

Зариф Бәшири (Бәширов) дә — әнә шул якның уңдырышлы туфрагында туып үскән затлардан. Ул 1888 елның 5 маенда хәзерге Татарстан республикасының Кайбыч районына керә торган Чүти авылы мулласы Шәрәфетдин хәзрәтнең ишле һәм катлаулы тормышлы гаиләсендә дөньяга килгән. Республикабызның иң көнбатыш чигендә диярлек урнашкан бу мөселман татарлары авылы белән янәшәдә керәшен татарлары, чуваш авыллары да гомер кичерәләр (аның иҗатында чуваш темасы мәгълүм дәрәҗәдә чагылуга да китерде бу). Атаклы Шәкүр "карак" исә — З. Бәширинең авылдашы, аңар хәтта туган тиешле кеше: әтисенең атасы Таҗи белән Шәкүрнең анасы —бертуганнар.

Егерменче гасыр башларында кулларына каләм алган барлык татар язучылары кебек, З. Бәшири дә 1905 елгы иҗтимагый хәрәкәтләрнең йогынтысыннан читтә торып калмаган. Ул яңа гына чыга башлаган милли газеталарны, бигрәк тә "Казан мөхбире"н, зарыгып көтеп ала, һәр санын йотлыгып укый. Электән үк туган авылы тормышыннан җырлар, бәетләр чыгарырга гадәтләнгән шәкерт, газеталарда М. Гафури, Н. Думави, М. Укмасый, яшь Тукайларның шигырьләре күрендеме, берсен дә кат-кат укымыйча күздән уздырмый, алар үрнәгендә тиздән үзе дә кулына каләм ала. Аның иң беренче иҗат тәҗрибәсе "Яшә, хөррият, яшә!.." дип башланып китүеннән үк ("Казан мөхбире", 1906 ел, 4 гыйнвар) — унҗиде яшьләрендәге авыл мәдрәсәсе шәкертенең нинди уй-хисләр белән рухланып яшәвен ачык тоясың. "Йолдыз" газетасында басылган "Кем икән без татарны уятучы?" исемле икенче тезмәсендә дә заман сулышы ачык сизелә.

Буа, Акъегет (хәзер Яшел Үзән районындагы авыл) мәдрәсәләрендә укып дөнья хәлләренә шактый күзе ачылган Бәшири, бер кыш үз авылында балаларга сабак биргәннән соң: "Мәҗит Гафуриныкы төсле китап бастырып чыгару өчен, әлбәттә, Казанга "Мәдрәсәи Мөхәммәдия"гә укырга барырга кирәк. Чөнки Мәҗит Гафури да шунда

укый ич", — дип уйлап, Казанга килеп урнаша һәм мәшһүр "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укый башлый. 1908 елда ул, Ғалиәсгар Камал, Борһан Шәрәфләр димләве белән Оренбургка килеп, Кәримов-Хөсәеновлар матбагасында корректор (үз сүзе белән әйткәндә, баш редактор), "Чүкеч" журналы редакциясендә сәркәтип (мөхәррир) булып эшли, журналист тәҗрибәсе туплый. Бервакыт бу шәһәргә "ике елдан бирле Россиядә, татар, башкорт һәм чувашлар тикшереп, өйрәнеп йөри" торган венгр галиме Ю. Мессарош килеп чыга һәм аның белән мөсахәбәләр нәтиҗәсендә Бәшири уенда берәр мишәр авылында мөгаллимлек итү теләге уяна. Ул 1909 елдан Пенза губернасының Яңа Аллагол, Тамбов губернасындагы Вәрәки авылында укытучылык итә. 1913 елдан әлеге төр эшчәнлеген ерак Җидесу өлкәсенең Капал шәһәрендә дәвам иттерә. Әдип 1917 ел вакыйгаларыннан соң шактый гомер Казакъстанда һәм Урта Азиядә яши, Алма-Ата, Җаркент, Ташкент шәһәрләрендә мәгариф оешмаларында, газета һәм журнал редакцияләрендә эшли, берара рабфакта үзбәк һәм уйгыр телләрен, әдәбиятларын укыта.



*Сулдан уңга Н. Думави, З. Бәшири, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, М. Гафури*

Ярты гасырдан ашкан иҗат гомерендә бу әдипнең кырыклап китабы басылып чыкканлыгы мәгълүм. Төрле елларда, төрле жанрларда, хәтта төрле телләрдә (татар, башкорт, үзбәк) язылган алар. Әдәбият галимнәре гасыр башы әдәбияты тарихында З. Бәширинең барыннан да бигрәк шигъри әсәрләре һәм "Чуваш кызы Әнисә" исемле повесте белән урын алуын язып киләләр. Аның аерата күп язган, кыска гына вакыт эчендә 7 шигырь китабы бастырган чоры — 1907-1913 еллар. Тарихтан безгә яхшы билгеле: татар әдәбиятында гасыр башы инкыйлаби күтәрелеше тәэсирендә иҗтимагый, сәяси яңгыраш көчәя, күп әсәрләр заман сулышы белән, милләтебезнең хөр киләчәге өчен көрәш мотивлары белән сугарыла. Татар тормышындагы торгынлык күренешләреннән, анда тәрәккыятнең акрын баруыннан ризасызлык З. Бәширинең "Фикер", "Бәянелхак", "Казан мөхбире", "Вакыт", "Йолдыз" газеталарында, "Шура" журналында еш басылып торган шигырьләрендә, "Милләт кайгысы" (1907; 1913), "Язгы кояш" (1908), "Ядкяр" (1909), "Җуаткыч, я уяткыч" (1909), "Яз тамчылары" (1909), "Хиссият ишекләре" (1913) исемле шигырь китапларында да чагылмый калмаган. "Бер асрауның зары", "Акча", "Туй", "Теләнче" шигырьләре мисалында яшь шагыйрьнең гади халык язмышына теләктәшлеклеген күрми мөмкин түгел.

Тәрбияче кешесе юк бер тол карчык,
Капчык тотып, өйдән өйгә йөри алҗып.

Кайбер шаян бала-чага ул үткәндә
Уен санап ыргыталар таш һәм балчык.
Шул көенчә йөреп, һаман капка кага,
Бер сынык икмәк тә аның күңелен таба;
Капкачыдан авыр, каты сүз ишетсә,
Күзләреннән мөлдерәп яшьләр тама, —

дип башлый ул "Кызганыгыз бу карчыкны!" шигырен һәм:

Әй, бай хуҗа! Кайда синең мәрхәмәтең?!
Әллә таштан, тимерданме синең затың?
Алай дисәм, таш, тимер дә иңерәр моңа,
Таш, тимер дияргә әрәм синең атың.
Син бит үзең рәхәт эченә чумган инде,
Мәшәкать, җәфадан күзең йомган инде;
Эретә алмый моңлы күзләр, зарлы сүзләр,
Кальбең нигә шул кадәре туңган инде? —

дип, бүгенге замандагы хәл-әхвәлләргә авазадаш яңгыраган сүзләр белән тәмамлый.

З. Бәшири иҗаты турында сүз чыкканда, аның "Вөҗдан", "Нидән бу хөрмәт?", "Мәче, яхуд тычканнар", "Туган", "Сакла гыйффәтеңне, гүзәл кыз!" кебек әсәрләрен дә телгә алырга тиеш булабыз. Мәгърифәтчелек карашларын алга сөргән шагыйрь күңелен шул чор җәмгыятендәге әхлакый бозыклык күренешләре, ямьсез хәлләр рәнҗетә, ул ихласлылыкка нигезләнгән матур, саф, кешелекле, дустанә мөнәсәбәтләрне яклап чыга, зарланып яшәмәскә чакыра.

Басса безне кайгы, хәсрәт — ялварамыз Аллага;
Башка төшсә уй-фикерләр — киңәшәбез анага.
Эстимез дога-теләкләр үксез, ятим, моңлыдан;
Ул оча нәзер-ниятләр аксак суфи, муллага.
Акча берлән тулса кесә, йә күңелләр булса хуш —
Истә юк дуст-иш, туганнар, юк ата, ана, Алла да, —

ди ул бер шигырендә.

З. Бәширинең әдәби мирасында мәхәббәт хисләре чагылдырган шигырьләр дә аз түгел:

Йөрәктәге каты мәхәббәтнең
Ләззәтенә булып әвәрә,
Акбүз атка менеп, җырлый-җырлый
Сахраларны кичкән мин идем.
Гайрәтемә ярдәм, күңлемә дәрт
Хәзинәсен ачып, туздырып,
Чын мәхәббәт, сөю чишмәсенең
Шәрабларын эчкән син идең!

Шагыйрьнең баштарак чор иҗатында ашыгып язылган, образ-сурәтләре табылып, формалашып җитмәгән, кайчак исә шактый тупасрак яңгыраган тезмәләр дә күренмәде түгел. Андыйлар Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Тукайларның матбугаттагы чыгышларында төртеп күрсәтелә тордылар. 1906 елларда "Фикер" газетасына Бәширинең дүрт шигырен урнаштырган Тукай бераздан аны үзенең сатира объектына да әверелдерде. "Чүкеч" журналында эшләнгән вакытында Бәшири Тукай шәхесенә, иҗатына карата шактый тупас, дорфа чыгышлар ясый, классик шагыйрьебезне мөтәрҗим шагыйрь (тәрҗемә белән генә шөгыльләнүче шагыйрь) итеп күрсәтеп шигырь бастыра. Мондый нәрсәләрне Тукай җавапсыз калдырмаган, билгеле. Бәшириебез "Кшири", "мыраулаучы" (мәче), "кыска аяклы маймылларның бер нәүгысы" (төре) сыйфатында аның шигырьләренә, фельетоннарына кереп китә. Шулай да, ничек кенә ачулы булмасын, Тукай "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре" исемле китабына аның "Балалар теләге" шигырен "мәгънәви яклары яхшы булганга" урнаштыруны тиеш тапкан...

Әйткәнебезчә, З. Бәшири үзен төрле-төрле жанрларда сынап карый. Ул юмор-сатира өлкәсендә эшли, шигъри әкият һәм хикәяләр язып бастыра. Проза әсәрләре дә

иҗатының шактый зур өлешен тәшкил итә. Әдәби эшләнешләре җәһәтеннән төрле дәрәҗәдәге бу очерк, хикәя һәм повестьларының һәрберсенә аерым-аерым тукталып бәя бирү юлы белән китмәстән, бары икесен генә искә төшерәбез: бу — кече яшьтәге мәктәп балалары өчен язылган "Шаян Фәһим" хикәясе һәм "Чуваш кызы Әнисә" повесте. Сәгыйть Рәмиев киңәше белән иҗат ителгән автобиографик характердагы повестьта татар яшүсмере ("мин") белән күрше чуваш авылының ятимә кызы Әнисә арасындагы самими дуслык күренешләре матур, тормышчан детальләр белән тасвирланган. Еллар үтеп, чын мәхәббәткә әверелгән бу дуслыкны заманасының кырыс чынбарлыгы, иске гореф-гадәтләр җимереп ташлый. Әнисә агу эчеп фани дөньядан китеп бара.

Әсәрнең үзәгенә нәкъ менә чуваш кызы образы алыну очраклы хәл түгел. Автор туып үскән Чүти авылына күршедә генә, әйткәнебезчә, чуваш авыллары. Бу тирәдәге татарлар һәм чувашлар борын-борыннан" тел,ләгать, гадәт вә ахлак алмашып" яшәгәннәр. З. Бәшири дә боларны күреп, күңеленә алып үсә. Шуңа күрәдер дә әсәрдә чувашларның гореф-гадәтләре, традицияләре дә, ике халыкның үзара мөгамәләсе дә гаять җылы буяулар белән сурәтләнә. З. Бәшири 1909 елда "Шура" журналы битләрендә этнографик характердагы очерклары белән дә чыгыш ясады. Бераздан алар китап булып басылды.

20 елларда, Ташкент шәһәрендә яшәгән чакларында, әдип Үзбәкстан матбугатында актив язышкан. Үзбәк язучыларыннан Чулпан, Илбәк, Ш. Сөләйман әсәрләре, М. Гафури, Г. Ибраһимов иҗаты турында мәкаләләр, аерым спектакльләргә рецензияләр белән генә канәгатьләнмәстән, ул төп вакыйгалары шушы тирәләрдә бара торган хикәяләр дә иҗат итә. Үзбәк әдәбияты тарихын тикшерүчеләр аның "Ток", "Ефәк күлмәк" исемле хикәяләрендә заман темасының шактый уңышлы чагылуын билгеләп үттеләр (Х. Короглы аны яшь үзбәк язучысы итеп саный). Шуның белән бергә ул шигырьләр язуын да дәвам иттерә һәм аларның күбесе, әүвәлгеләре белән кушылып, 1927 елда Казанда "Зариф Бәшири шигырьләре" дигән җыентыгында укучыга җиткерелә.

Бу чорда ул, татар укучысын башка милли әдәбиятларның иң яхшы үрнәкләре белән таныштыру кебек изге максаттан чыгып, "Уйгыр әдәбияты" (1931), "Чуваш әдәбияты" (1928), "Үзбәк әдәбияты" (1928) дигән җыентыклар төзеп бастыра. Аларда барлык текстлар З. Бәширинең үзе тарафыннан тәрҗемә итеп бирелгән. Кереш мәкаләләрдә татар әдибенең бу милли әдәбиятларны яхшы белүе, ихтирам итүе ачык күренә. Бер үк вакытта шул заманның идеологик күрсәтмәләре басымы астында әдәби күренешләргә сыйнфый позициядә торып якын килүен дә әйтеп узарга кирәк.

Утызынчы елларга кергәч, репрессияләр көчәя барган шартларда, З. Бәширигә дә (1933 елда Уфага килеп урнашкан була ул) яшәү һәм иҗат эше өчен мөмкинлекләр кими. Башкортстан АССРның партия органнары тәкъдиме буенча сәнәкчеләр хәрәкәте турында материаллар җыйнап, "Каракош явы" исемле повесть язып тәмамлаган З. Бәширине 1938 елның 29 апрелендә кинәт кулга алалар һәм биш елга ирегеннән мәхрүм итеп, хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрәләр. Срогын тутырып кайткачтын да аның тормыш шартлары рәтләнеп китә алмый: утырып чыккан кеше буларак аңа кырын карыйлар, торак мәсьәләсе озак хәл ителми, әсәрләрен бастырмыйлар.

Гомеренең соңгы елларында З. Бәшири үз башыннан кичергәннәре, күренекле замандашлары турында истәлекләр язу белән дә шөгыльләнде. Аларда М. Гафури, Г. Камал, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Н. Думави, Ш. Камал, Хәбиб Исхакыйларның тормышларына, холык-фигыльләренә, иҗатларына нисбәтле күп кенә кызыклы, аеруча әдәбият галимнәре өчен мөһим мәгълүматлар, фактлар китерелә. Бигрәк тә Чүтидәге балачак, Буа һәм Акъегет мәдрәсәләрендә узган шәкертлек чоры тәфсилләп сурәтләнгән. Дөрес, алар "Замандашларым белән очрашулар" исеме белән 1968 елда китап булып чыккач (махсус редакторы Гали Халит), Бәширинең субъективлыгы чамадан чыгыбрак киткәнлеге дә күрсәтелде. Мәсәлән, Афзал Шамов язучыларның ел йомгакларына багышланган җыелышында шул рухта чыгыш та ясаган иде...

З. Бәшири 1962 елның 21 октябрендә Уфа шәһәрендә җитмеш биш яшенә җитеп вафат булды.

Бу күренекле татар әдибенең тууына 110 ел тулуга багышлап язылган кыскача гына бер күзәтүебезне йомгаклап шуны әйтәсе килә: шагыйрь, прозаик, тәрҗемәче, публицист-журналист, балалар язучысы, педагог З. Бәшири 1905 еллардагы иҗтимагый кузгалышлар чорында кулына каләм ала һәм ярты гасырдан артыкка сузылган иҗат

гомерендә өч йөзләп шигырь, дистәләгән поэма һәм шигъри хикәя, проза әсәре, очерк, күпсанлы мәкаләләр язып бастыра. Егерменче гасыр татар әдәбияты тарихын хакыйкатькә хилафлык китермичә, уңга-сулга тайпылмыйча кузалларга, халкыбызга күрсәтергә омтылабыз икән, аларны да игътибарлы караш белән өйрәнергә кирәк. Аның шәхси архивы да кызыклы. Зур өлеше исә хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә саклана. Бу фондта басылган һәм басылмаган әсәрләренең автографлары (шигырьләре өч томга бүлеп җыйналган: "Уйларым", "Гөлләрем", "Көннәрем"), шул исәптән ике романының текстлары да бар. 1930 елда язылган "Тау култыкларында" исемлесендә егерменче елларда үзбәк кышлагында барган вакыйгалар тасвирлана. Икенчесе "Аумакайлыкта, яки көннәр өстендә" дип атала. XX гасыр башы татар авылы тормышыннан алынган бу әсәрен З. Бәшири 1945-1946 елларда яза, ләкин тәмамламый. Язучы архивындагы "Авылларда давыллар" исемле зур күләмле кульязма әсәре эчтәлеге һәм формасы белән шигъри романга охшаш.

Кызганычка каршы, Зариф Бәшири калдырган зур әдәби мирасның бик аз өлеше генә бүгенге язуыбызда укучыга тәкъдим ителгән. Исеме әдәбиятыбызга кайтарылганнан соң ук чыгарылган "Сайланма әсәрләр"ен (М. Гайнуллин редакциясендә, аның ук кереш мәкаләсе белән) кулга алуыбызга да кырык ел үтеп киткән ләбаса...

Зөфәр РӘМИЕВ

# Зариф Бәшири

## Ардаклым

Әй минем зифам,
Дәртле музыкам;
Нигә моңайдың,
Ни булды сиңа?
Кемне сагындың,
Кемне сайлыйсың?
Калфагың чугын
Нигә чәйнисең?
    Көдрә чәчем, кара кашым,
    Утырчы монда, килче, кыйгачым!
Матур ардаклым,
Алтын балдаклым,
Нигә күңелсез,
Ни булды сиңа?
Оныт хатамны,
Кичер гайбемне,
Каушу көненең
Укыйк гаедене.
    Карлыгачым, сандугачым,
    Утыр, сөйләшик, дәртле көйләшик!
Бетер үпкәңне,
Ул соң күпкәме?
Җитәр гашыйкның
Яшен түккәне.
Мәхәббәт гөлен

Тергез тагын да,
Бергә булаек
Гыйшык багында.
Юанычым, куанычым, килче яныма,
Килчә, ардаклым!

*1908 ел, 30 апрель, Оренбург*

## Сакла гыйффәтеңне, әй гүзәл кыз!

Кашларынлай кара, битләрең ал,
Тән генәең нинди ак синең;
Кайда гына барсаң — тел өстендә,
Яман сүздән исмең пакъ синең!
Буйларынлай зифа, сәякләрең
Балавыздан койган шәм кеби,
Чәч тәңкәләр тагып артка салган —
Толымың да ике як синең;
Яман сүздән исмең пакъ синең.
Тәэсир итә җанга үткен сүзең,
Җазибәле кара күзләрең,
Табигатең йомшак, гыйффәтең пакъ,
Яман уйдан күңлең саф синең!
Үлек икән — җанны тергезәсең,
Коткарасың төрле җафадан,
Күреп бераз күңел юатырга,
Төшләреңдә нинди зат синең!
Яман уйдан күңлең саф синең!
күзләремнең нуры, җисмем җаны,
Милләтемнең көткән теләге,
Җир йөзенә нурлар чәчкәнеңә
Милләтең дә гаять шат синең.
Кадрең бит нечкә кыл өстендә,
Каты дулкын бәреп какмасын;
Яман күздән, җаным, каты сүздән
Көчле тәңрең үзе сакласын.
Башкаларга үрнәк булыр өчен
Өзмә гел син милләт өмиден,
Яшьлек белән җуйма гыйффәтеңне —
Кыйммәтеңне саклар чак синең,
Гыйффәтеңне саклар чак синең.

*1908 ел, 13 май, Оренбург.*

## Сагыш

Әгәр булса эчең тулы сагышлар,
Һаман артка китәр кыйлган эшләр;
Дәхи булса кулың озын, кесәң сай,
Җиһанның кинлегендә ни табыш бар?

*1909 ел, 8 июль, Оренбург*

Текстларны З. РӘМИЕВ әзерләде.

---

Ардаклым — Тау ягында "тәрбиялем" урынында әйтелгән бер мөгътәбәр сүздер. З. Бәшири.

*Академик Рәфикъ Нәфиговка 70 яшь*

# БОРМАЛЫ ЮЛЛАР



Катлаулы борылышларга бай булган XX гасыр инде тәмамланып килә. Татар халкына бу гасыр зур гына алга китеш тә, байтак фаҗигалар да китерде. Гасыр башында барлыкка килгән куәтле иҗтимагый хәрәкәт Идел буе халыклары арасында беренчеләрдән булып безне автономиягә ирештерде. Ә икенче яктан алсак, ачлык, ялангачлык, империя режимы эзәрлекләүләре аркасында милләтебез үзенең иң асыл затларын бик күп югалтты.

Ләкин татар милләте авыр югалтуларны чагыштырмача тиз арада торгыза алу сәләтен дә күрсәтте. Сугыштан соңгы елларда үсеп чыккан яңа буын моны ачык дәлилләде. 20-30 елларда һәм аннан соңрак дөньяга килгән яшьләр иҗат эшендә дә, көрәш юлында да милли байракны югары тота алуларын расладылар.

Шундый зыялыларның берсе — күренекле тарихчы, фән докторы, профессор, Татарстанның һәм Рәсәйнең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясе академигы Рәфикъ Исмәгыйль улы Нәфигов.

Зур табигый таланты, гаять югары дәрәҗәдәге эш сәләте, армый-талмый эзләнүләре аны тарих өлкәсендә генә түгел, ә гуманитар фәннәрнең күп кенә өлкәләрендә дә яхшы хәбәрдар булган галим итеп танытты.

Рәфикъ Нәфиговның тагын бер күркәм сыйфаты — татар милләтенә, аның бай мирасына нык бирелгәнлеге. Алар белән горурлануы. Нәкъ менә шул сыйфатлары аны Уральск шәһәреннән татарның тарихи үзәге Казанга китергән. Урыс телендә урта мәктәпне, аннары педагогия институтын иң югары билгеләргә генә тәмамлый ул. Инде татар авылларына да урыслашу йогынтылары кергән вакытта булачак галим уку йортлары программасыннан тыш зур теләк белән татар телен өйрәнә, гарәп язуын үзләштерә, 1917 елга кадәр чыгарылган матбугатыбызны тикшерә башлый.

Тарих тармагына килү сәбәпләре турында сүз чыккач Рәфикъ ага урта мәктәптәге укытучыларын исенә төшерә. Алар арасыннан берсе — зур эрудицияле, оста методист — дәресләрне бәхәсләр белән алып бара, катлаулы тарихи мәсьәләләрне чишүдә укучыларда мөстәкыйльлек, эзләнүгә омтылыш сыйфатлары тәрбияли.

Әйе, шигем юк, талантлы укытучының йогынтысы аз булмагандыр. Ләкин милләте буенча яһүдә булган ханым татар егетендә үз милләтенә мәхәббәт һәм хөрмәт уятырга тырышкандыр дип уйлый алмыйм. Аңа гаеп ташларга да теләгем юк. Татарлар үзләре онытып барган тарихны башка милләт кешесе, әлбәттә, бик томанлы итеп кенә күз алдына китерә алгандыр. Бирeдә гаилә тәрбиясе зур роль уйнагандыр. Рәфикъ ага аеруча әнисе турында бик җылы хатирәләр сөйли. Ә бәлки монда эш тагын да тирәнрәктәдер. Буыннан-буынга кешенең аңына, психикасына сеңеп килгән бәйләнеш, элемтә җепләре тәэсир иткәндер аңа.

Нәкъ менә шушы күренми торган җепләр Алма-Ата профессоры Покровскийның үзенә аспирантурага чакыруына карамастан, яшь егетне әле китаплар аша гына таныш булган Казанга тартып китергәндер. Әйе, яшьлек хыяллары, аларны тормышка ашыру теләге бөек Габдулла Тукай эзләре буйлап Казанга алып

килә. Ләкин хыяллар, омтылышлардан тыш реаль дөнья бар әле. Баштарак эшләр җиңел бармый. Хыяллар челпәрәмә килердәй чаклар да була.

Казанга килү белән ул турыдан-туры мәшһүр университетка юнәлә. Тарих-филология факультетының СССР тарихы кафедрасындагы аспирантурага керү өчен гариза бирә. Ләкин анда Урал егетен беркем дә көтеп тормый. Соңрак башка "сер" дә ачыла. "Хуҗа"ларның үзләре укытып чыгарган, аларга яхшы таныш кандидатура бар икән. Җитмәсә кафедра җитәкчеләре арасында бер генә татар да күренми. Имтиханда тирән эчтәлекле җавап бирүенә карамастан, "чит кеше"гә югары бәя бирергә ашыкмыйлар. Ләкин алар аның турында, барыбер, уйланганнар, киңәшкәннәр күрәсең. Имтихан комиссиясендә катнашкан ВКП(б) тарихы кафедрасы мөдиренә Рәфикъның җаваплары бик ошаган. Һәм ул аны үз кафедрасына эшкә чакыра. Кафедра мөдире, тарих фәннәре кандидаты Сурен Аздуни (Мартиросян) аның фәнни җитәкчесе булып китә. Бераздан кандидатлык диссертациясенең темасы турында сүз кузгала.

Булачак галим бер дә икеләнеп тормыйча: "Габдулла Тукайның иҗтимагый эшчәнлеген һәм сәяси карашларын өйрәнергә телим", — дип җавап бирә.

Татар халкы тарихын бөтенләй кузаллый алмаган партия тарихы кафедрасы мөдире, милләте буенча әрмән Аздуни: "Кем соң ул Тукай?" — дигән сорау бирә.

Нәфигов фәнни җитәкчесенең татар халкы тарихында ни дәрәҗәдә "компетентлыгын" бик тиз аңлый һәм укытучысына гади генә итеп аңлатырга омтылып: "Әрмән әдәбияты классигы Туманян кебек бөек шагыйрь" — дип җавап бирә.

Укучыларыбызга аңлаешлырак булсын өчен без берничә искәрмә ясарга тиешбез. Большевиклар хакимияткә килгән 1917 елның октябреннән алып 1944 елга кадәр республиканың беренче җитәкчесе итеп бер генә татарны да тәкъдим итмәделәр. Еш кына яһүд, латыш, урыс кешеләрен билгеләделәр. Идеология өлкәсендә дә алар хакимлек итте. ВКП(б) тарихы кафедрасы мөдире дә шундыйларның берсе иде. Дөрес, шәхес буларак аның турында шактый җылы сүзләр әйтүчеләр дә бар. Рәфикъ аганың да ниндидер начар сүзләр белән искә алуын хәтерләмим. Ләкин аңа үз көченә генә ышанырга туры килә. Һәм Рәфикъ Нәфигов эшен уңышлы башкарып чыга.

50 елларның икенче яртысында һәм 60 елларда иҗтимагый фәннәр өлкәсендә, бигрәк тә тарихи мәсьәләләр буенча, гаять дәрәҗәдә кискен бәхәсләр купты. Бу елларда Рәфикъ ага бик интенсив рәвештә эшли, башта кандидатлык, аннары докторлык диссертациясен яклый. Аны кафедра мөдире итеп куялар. Моңа кадәр дә шактый бәхәсләр барган кафедра яшь галим килгәч Казанның иң кайнар фән учреждениесенә әверелгәндер. Бәхәсләрнең кайберләре Мәскәүнең үзәк журналларында чагылыш тапты, югары оешмаларда тикшерелде. Хәзер киң җәмәгатьчелеккә таныш булган галим Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов турында бара сүз. Аның докторлык диссертациясен тәмамлавы Рәфикъ аганың кафедрага җитәкче булып килү вакытына туры килде. Доцент Борһанов, КПССның XX съезд карарлары нигезендә идеология өлкәсендә шактый яңарыш элементларыннан файдаланып, 1917-1918 еллардагы болгавыр вакытларга яңа карашны алга сөрергә омтылды. Әмма кафедрадагыларның күпчелеге моңа кискен каршы чыкты. Ләкин Р. И. Нәфигов Борһанов эзләнүләрен яклады, һәр бәхәстә, аерым искәрмәләр белән, аңа булышырга омтылды.

Көрәшнең чираттагы этабы докторлык диссертациясен яклау вакытында барды. Кайнар чыгышларга Мәскәүдән килгән оппонент-философ Константинов та катнашты. Р. И. Нәфигов үзенең гадәттәгечә, полемика формасында корылган чыгышында диссертациянең оригиналь фәнни хезмәт икәнен тагын бер кат күрсәтте.

Нәтиҗәдә докторлык диссертациясен яклау өчен төзелгән махсус гыйльми совет бертавыштан Ә. Х. Борһановка фәннәр докторы дигән гыйльми исем бирү тәкъдимен яклады. Бу күпләргә зур бер җиңү булып күренде. Бер яктан ул, әлбәттә, шулай булды. Ләкин XX съезд юнәлешеннән икенче якка борыла башлаган сәясәт мондый чыгышларны инде кичерми иде. Тиздән КПСС Үзәк Комитетының теоретик журналы "Коммунист"та бер төркем галимнәр (аларның берсе Л. И.

Брежневның ярдәмчесе) диссертацияне кискен тәнкыйть белән чыкты. Нәтиҗәдә, Югары Аттестация комиссиясе безнең гыйльми Совет карарын расламады.

Һәм менә шуннан соң урындагы фирка җитәкчеләре диссертацияне яклап чыгучыларга ут ачты. Авырлыкның зур өлеше Рәфикъ ага җилкәсенә төште...

Дөрес, бу бәрелеш беренчесе түгел иде инде. Безнең заман кешеләре фирка өлкә комитеты секретаре язган китапка нинди дә тәнкыйть сүзе белән чыгуны хәтерләмиләрдер. Бигрәк тә республиканың бөтен идеология эшен үз кулында тоткан җитәкчегә карата тәнкыйтьне.

Мондый мәкаләне үз вакытында Рәфикъ Исмәгыйль улы — әле яңа гына кандидатлык диссертациясе яклаган яшь галим — язып чыкты. Шунысын да күрсәтеп үтәргә кирәк: ул мәкалә Татарстан Язучылары Союзы журналы "Совет әдәбияты" битләрендә басылды. Бу журналда аның кызыклы мәкаләләре, яңа табышлары еш дөнья күрде. Рәфикъ әфәнде шактый еллар журналның редколлегия әгъзасы да булып торды.

Төрле фәнни конференцияләрдә журналның кыю, яңа карашларны алга сөргән материалларын яклап чыгарга да туры килде Нәфиговка. Оста полемист Рәфикъ әфәнде күпчелектә һәрвакыт теләктәшлек, хуплау тапты. Көчле кул чабулар аз булмады.

Р. Нәфигов хезмәтләре гаять зур фактик материалга нигезләнгән була. 50 елларның яңа җилләре нәтиҗәсендә архив ишекләре галимнәр өчен киңрәк ачыла башлагач, Рәфикъ әфәнде беренчеләрдән булып, яхшы мәгънәдәге "комсызлык" белән архивларда "бер кыңгыраудан икенче кыңгырауга" кадәр утырды. Мәскәү, Петербург, Саратов, Самара, Казан архивларын актарып чыкты. Дистәләгән-йөзләгән газеталар, китапларны өйрәнеп, тиешле язмалар ясады. Ул очрашкан-сөйләшкән иҗтимагый-хәрәкәт ветераннарын санап бетергесез. Аларның күбесе тарихи агымнарны тирәнрәк аңлау, гаделлекне халыкка җиткерүдә ярдәм итте.

Татар дөньясына килгәндә, сәясәттә актив катнашкан, әдәбиятта һәм мәдәнияттә җиң сызганып эшләгән бик күп шәхесләребез совет чорында чыккан тарихи китапларыбызда күрсәтелә алмады. Ә Рәфикъ әфәнде үз хезмәтләрендә татар зыялыларының күпчелеге патша режимына каршы булуын, яңарышка омтылуын күрсәтте. Ул, фәндә беренче булып, татарлар арасында алдынгы карашлы зыялыларны берләштергән революцион-демократик агым булуын язып чыкты.

Сугыштан соңгы елларда Идел-Урал төбәгендә яшәгән һәм игътибарга лаек йөзләгән-меңләгән шәхесләрне өйрәнде ул һәм аларның исемен матбугатка чыгарды. Шәхесләргә күпләгән биографик очерклар, китаплар багышлап, аларның үткән юлларын, халкыбыз мирасына керткән өлешләрен тәфсилләп тикшерде. Шунысы да игътибарга лаек. Башка күп кенә галимнәрдән аермалы буларак, шәхеснең турыдан-туры үзенә кагылган вакыйгаларны, хезмәтләрен күрсәтүдән тыш, аның хезмәттәшләрен, дусларын, гомумән, теге яки бу формада аның белән элемтәдә торган шәхесләрне тасвирлауга да зур урын бирде Нәфигов. Галимҗан Сәйфетдинов, Касыйм Туйбактин исемнәрен аклау өчен бигрәк күп көч һәм вакыт бирергә туры килде.

Автономияле республика төзелгәннән соңгы чор татар халкының тарихын тикшергәндә аның тик Татарстанда яшәгән өлеше белән генә чикләнү гадәткә кереп китте. Ә Рәсәйнең төрле почмакларына чәчелгән татар халкының зур өлешен бөтенләй игътибарга алмый башладылар. Алар турында язу очракларына "милләтчелек" тамгасын ябыштырдылар. Чит илләрдә яшәүчеләрне инде әйтеп торасы да юк. Алар турында сүз әйтү бөтенләй тыелды.

Үзенең хезмәтләрендә Рәфикъ әфәнде мондый чикләнгән карашка да кискен рәвештә каршы чыкты. Күп санлы фактлар белән аерым шәхесләрнең татар милли мирасына керткән өлешләрен ачыклады.

Рәфикъ Нәфиговның иҗат үзенчәлекләре турында сөйләгәндә тагын бер мәсьәләгә тукталмый булмый. Ул да булса — аның язу стиле. Бөтен нәтиҗәләрне классиклар сүзләре белән җөпләп, әнә шуны фәннең соңгы сүзе дип күрсәтүче галимнәрдән аермалы буларак, галим Нәфигов үзенең фәнни эзләнүләрендә мәсьәләне һәрьяклап анализлап, күп дәлилләр китереп җитди нәтиҗәләр ясый.

Кайбер вакыт киләчәк эзләнүләр өчен сораулар да куя. Аның хезмәтләрендә без күп санлы фаразлар да күрәбез. Мондый алым кайбер галимнәргә ошап бетми. Алар моны "миф" дип күрсәтмәкче булалар. Чыннан да, фаразларның кайберсе эзләнүләр нәтиҗәсендә миф булып чыгарга мөмкин. Ләкин фаразларны куймыйча, аларның мифмы-түгелме икәнен белеп булмый бит. Мондый алым тарихта һәрвакыт яшәп килде. Моннан соң да аларсыз эшләп булмас.

Рәфикъ әфәнде үз хезмәтләрендә публицистикага тартым алымнар да куллана. Чөнки мондый ысулда язылган хезмәтләр киң халык катламына яхшырак барып җитә.

Рәфикъ әфәнденең Мулланур Вахитовка багышланган китабы эзләнүләр юлында иң зур адым булды. Күп санлы яңа документлар белән галим аның тормыш юлын һәм эшчәнлеген тасвирлады, аңа бәя бирде. Китап игътибарсыз калмады. Киң җәмәгатьчелек аны зур кызыксыну белән каршы алды. КПССның өлкә комитеты да зур "игътибар" күрсәтте. Галимне һәм ул вакытларда Казанда яшәүче белгечләрне чакырып фән бүлегендә китап хакында зур "фикер алышу" уздырды.

50 — 60 елларда халкыбызның рухи мирасын өйрәнүдә яңа чор башланды. Бу юлда яңа тармаклар, юнәлешләр барлыкка килде. Шулар арасында иң мөһиме — татар халкының иҗтимагый фикер үсешен өйрәнү иде. Бу юлда академик Р. И. Нәфигов башлап йөрүчеләрдән булды.

Ә Мәскәүнең карашы билгеле инде. Анда безнең бер якташыбыз докторлык диссертациясе яклаган вакытта "татар иҗтимагый фикере" дигән атама куллана. Бу Мәскәү галимнәре өчен бик сәер тоела. Араларыннан берсе — Гыйльми Совет әгъзасы — болай дип чыгыш ясый: "татарларда нинди иҗтимагый фикер булуы мөмкин соң?" Ләкин аңа мондый җавап бирелә: "Әгәр грузиннарда, әрмәннәрдә андый фикер бар икән, ни өчен соң ул татарларда булмаска тиеш?"

Рәфикъ Нәфиговның нәкъ менә шушы темага язылган күләмле китабы чыгу Татарстан җәмәгатьчелегендә генә түгел, ә башка республикаларда зур кызыксыну уятты. Бай чыганакларга нигезләнгән, XX гасыр башының иң катлаулы елларын тасвирлаган бу хезмәт фәнгә зур өлеш кертте. Шушы өлкәне тагын да өйрәнү юлында зур этәргеч булды.

Галимнең шушы темага якланган диссертациясенә кайтып берничә истәлек китерик. 1964 елда 36 яшьлек галим яклаган диссертация белгечләрдә зур кызыксыну уятты. Аңа бик күп фән әһелләре килгән иде. Зур зал шыгрым тулы. Гыйльми Советта да бер генә каршы чыгыш та булмады. Ә менә яклау материаллары һәм диссертация үзе Мәскәүдәге Югары Аттестация Комиссиясенә җибәрелгәч, "каршы як" эшкә тотына. Шактый еллар буена җирле фирка оешмаларында җитәкче эшләрдә утырган бер доцент диссертация турындагы фикерен Мәскәүгә, КПСС Үзәк Комитетына юнәлтә. Аның фикере буенча диссертациянең эчтәлегендә "Солтангалиевчелек идеяләре" ята икән.

Әгәр дә бу хәл 30-40 елларда булса диссертацияне яклаучының язмышын күз алдына китерү авыр түгел. Ләкин 60 еллар уртасында югарыда карашлар шактый үзгәргән иде инде. Шуңа күрә мәсьәләгә шактый җитди карап, аны өстәмә рәвештә тикшерү өчен Фәннәр академиясенең Казан филиалына җибәрәләр. Мидхәт Кәримович Мөхәррәмов җитәкчелегендә эшләгән тарих бүлеге әлеге яланы кире кага, диссертациянең хәзерге фән югарылыгында торуын раслый.

Әйе, мондый хәвефле "деталь"ләрне галимнең сикәлтәле тормыш юлында шактый гына табарга булыр иде. Алар арасында драмага, ә кайчакта трагедиягә якынлашканнары да булган, бүген комедия булып күренердәйләре дә очраган.

Чираттагы хезмәте менә-менә китап булып чыгып җитә дип торганда, автор "китап өстендә эшләү туктатылган" дигән хәбәрне ала. Бу 1964 елның җәй урталарында, ял вакытында була. Мондый очракта тәҗрибәле кешеләр эшнең нидә икәнен тиз төшенәләр. Берничә китап авторы булган Рәфикъ әфәнде дә, яшь булуына карамастан моны аңлый.

Ул турыдан-туры КПСС өлкә комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире, тарих фәннәре кандидаты, Н. А. Андриановка юнәлә. Чыннан да, фирка идеологы китап кулъязмасын укып чыккан һәм анда бер "җитди җитешсезлек"

тапкан. "Ничек инде Сез, — дип эндәшә ул китап авторына, —шундый зур күләмле фәнни хезмәттә бер генә мәртәбә дә Н. С. Хрущев әсәрләрен искә алмыйсыз!"

Рәфикъ әфәнде каршылык күрсәтүнең мәгънәсез булуын аңлап, "әткә сөяк" бирә. Ул вакытта бөтен дәүләт башында торучы Н. С. Хрущев әсәрләреннән бер "тезмә" алып китап кулъязмасында урнаштыра.

Эш алга китә һәм шул ук елның ахырында дөньяга чыга. Әмма хезмәт китап магазиннарына барып җиткәнче Мәскәүдән Н. С. Хрущевның эштән алынуы хәбәр ителә, матбугатта ул җибәргән хаталарга багышланган мәкаләләр күренә. Инде моннан соң авторны икенче яктан тәнкыйтьләү башлана. Беренчеләрдән булып китапны карап чыккан университет ректоры М. Т. Нужин әйтә: "Сезнең китап өчен Хрущев сүзләре нигә кирәк булды соң?" Аның "тарихын" тыңлаганнан соң университетның акыллы җитәкчесе ихтыярсыз көлеп җибәрә.

Рәфикъ әфәнденең иң якын күргән өлкәсе — Габдулла Тукай темасы. "Ни өчен соң Тукай темасы сезгә шул кадәр якын?" дигән сорауга галим: "Уральск шәһәренең һәр җирендә Тукай үзенең эзләрен калдырган. Бу шәһәр Тукай рухы белән сулый", — дип җавап бирә. Һәм аннан соң шагыйрьне хәтерләгән туганнары, якыннары, алардан калган истәлекләр турында бәйнә-бәйнә сөйли башлый.

Шушы көннәрдә галимнең Тукайга багышланган яңа китабы (беренчесе 1986 елда чыккан иде) басылып чыгачак. Анда моңа кадәр матбугатта басылмаган яңа материаллар, фикерләр укырбыз. Аларның кайберләре Рәфикъ әфәнденең соңгы елларда эзләнү нәтиҗәләре.

Галимнең иҗади эшчәнлеге киң җәмәгатьчелекне, күренекле шәхесләрнең игътибарын үзенә тартты. Ул аралашкан, иҗади хезмәттәшлек иткән күренекле әһелләр турында күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Тукай романының авторы Әхмәт Фәйзи үзенең китабы дөнья күргәч тә аның бер экземплярын әле ул вакытта аспирантурада укыган яшь галимгә болай дип язып бүләк итә:

*"Рәфикъ, син Тукайны туган абыең кебек яратасың. Менә бу сиңа шуның өчен.*

*18.XII.52. Әхмәт Фәйзи.*

Тагын бер танылган язучы Атилла Расих үзенең "Каһарманнар юлы" исеме белән чыккан романына тарих юлында эзләнүче, талантлы галим прототибы итеп Рәфикъ әфәндене алган.

Аның иҗатын республиканың элекке җитәкчеләре Фикрәт Табиев, Салих Батыев, күренекле галим һәм дәүләт эшлеклесе Мансур Габдрахмановлар игътибар белән күзәтәләр, кирәк вакытта ярдәмгә киләләр.

Тынгысыз галим Р. Нәфигов барысы ике дистәгә якын китап, 300 ләп мәкалә чыгарган. Алар бүгенге көндә иҗат эшенә кергән галимнәр өчен яңа үрләр яулауда ныклы терәк булып тора.

10 лап фән докторы, 50 гә якын фән кандидаты үстерде галим. Бай тәҗрибәсе, оригиналь фикерләре белән урталашты, аларны фән юлына чыгаруда булышты. 50 елга якын университетта эшләү дәверендә меңләгән студентлар аның тирән эчтәлекле лекцияләрен тыңлаган, күренекле галим җитәкчелегендә курс һәм диплом эшләрен башкарып фәнгә беренче адымнар ясаганнар.

Сүзнең ахырында тагын берничә фикер әйтик. Юбиляр олы талант иясе булу белән бергә, зур хисле, темпераментлы шәхес тә. Тарихи хезмәтләр аның сәләтен тулысы белән үзенә алып бетерә алмаган. Аның таланты шигырьләр аша да дөньяга чыгарга омтыла.

Әле һаман да эштә, хезмәттә яшәгән һәм авыр йөк тарткан ат кебек гел алга омтылган галим бүген һәркайсыбыз өчен үрнәк булып тора, соклану хисләре уята. Аңа сәламәтлек, мактаулы хезмәтендә яңа уңышлар теләп калабыз.

**Риф ХӘЙРЕТДИНОВ**

Тарих фәннәре докторы,
Казан дәүләт университетының
"Татарстан тарихы" кафедрасы мөдире

*Фән*

# ПРОФЕССОР БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?



***Күренекле тел галиме,***
***Казан дәүләт университеты профессоры***
***ФЛЕРА САДРЕТДИН кызы САФИУЛЛИНА***
***белән әңгәмә***

*— Бу әңгәмәбезне остазлар турында сөйләшүдән башлыйк әле, Флера ханым! Сезнең остазларыгыз кемнәр булды икән?*

— Иң беренче остазлар мәктәптә булды инде ул. Шулай ук университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган еллардагы остазларыма да олы рәхмәт! Керү имтиханын Хатип ага Госман һәм Мирфатих ага Зәкиев алган иде миннән... Шул югары таләпләр биш ел буе дәвам итте. Мин укыган группа көчле иде. Егетләр белән кызлар сан ягыннан бер чама булды. Бу группадан күп кенә фән докторлары, профессорлар, доцентлар, шагыйрьләр, журналистлар, хөкүмәт эшлеклеләре чыкты: ирле-хатынлы Нурмөхәммәт һәм Фәһимә Хисамовлар, Казбек Гыйззәтов, Шәйхелислам Садретдинов, Әхмәт Рәшитов, Рәшит Зәкиев, Әгъзәм Фәйзрахманов, Мөнир Абдуллин, Лена һәм Зидә Гайнановалар һәм башкалар...

Остазларыбыз затлы иде безнең. Латыйф ага Җәләй безгә татар диалектологиясе, тел тарихы, тарихи грамматика укытты. Килеп керер иде, өстәл янына утырыр иде. Папиросын, шырпысын өстәлгә куяр иде, бераз гына кыеграк муены белән янтаебрак утырып, тәмәке төтенен суыра-суыра, татар теленең төрле төбәкләргә сибелгән сөйләшләре турында, тел үсешендәге тарихи күренешләр турында әкрен генә, иренмичә, кызык итеп сөйләр иде. Әйтер иде: "Төртеп куй, улым (йә кызым), кирәк булыр!". Хәтеремдә, бервакыт Җәләй ага миңа әйткән иде: "Кызым, син лекцияләрне әйбәт язып барасың, дәфтәреңне миңа бир әле, мин бер китап язарга уйлыйм". Мин ул дәфтәремне Җәләй агага бирдем. Соңыннан аңладым: аның башында шулкадәр кызыклы фикерләр булган. Аларны ул безгә лекция вакытында уйлап, формалаштырып сөйләгән икән. Сөйләгәндә иҗат итә иде шул ул...

Татар әдәбиятын без Якуб ага Агишевтан, Хатип ага Госманнан, Ибраһим ага Нуруллиннан тыңладык. Беренчесенең алласы Тукай булса, икенчесенең алласы Һади Такташ иде. Якуб ага артист иде. Мишәрчә ягымлы сөйләме белән, тел остасы булып хәтердә калды ул.

Хатип ага Госман — фронтовик, теорияне күп укый, лекцияне дә шул югарылыкта сөйли, без аннан бик куркабыз. Бүлмәсе яныннан аяк очларыбызга гына басып үтәбез. Ул бик таләпчән, аңа имтихан бирүе дә авыр. Аннан бер курс эше язганым хәтеремдә: "Азат Себер" газетасында поэзия". Шушы газетаның һәр санын (ә ул гарәп язуы белән язылган!) укып чыгарга туры килгән иде миңа...

Ибраһим ага Нуруллин исә безгә Тукай иҗатын укуы белән, мәгърифәтчелек белән хәтердә уелып калды. Махсус семинары да, гамәли дәресләре дә хәтердә. Имтиханнарда ул төпченеп сорый, үзе күп белә, китаплары, мәкаләләре еш чыга. Ул — күренекле тәнкыйтьче, аның белән исәпләшәләр, шүрлиләр дә... Баксаң, сугыштан аяксыз кайткан Ибраһим абыебыз бик яшь булган икән әле ул чагында.

Ә бишенче курста безнен өчен бөтенләй яна булган бер шәхес турында ишеттек: Галимҗан Ибраһимов иҗаты кире кайтты. Безгә бу зур шәхес, әдип турында ул заманда аспирантура тәмамлаган Мансур ага Хәсәнов махсус курс укыды... Ә менә халык авыз иҗатын аның белгече, шунын буенча китап авторы Хәмит ага Ярми укыган иде. Йотлыгып тынлый идек без бу сөйкемле, һаман елмаебрак, җайлап кына, тыныч кына сөйли торган Хәмит аганы. Аннан имтихан бирә алмаган кеше булмагандыр. Бу фәнне яратмыйча, укымыйча йөргән кеше булмый иде, күпчелек студентлар "бишле" генә ала иде...

Менә кемнәр безгә белем бирде! Бу олуг остазлар безгә үрнәк иде, без аларны яратып, көтеп ала идек. Дәрес калдыру юк дәрәҗәсендә булгандыр...

Хәзерге татар әдәби телен Диләрә апа Тумашева, Мирфатих ага Зәкиев укытты. Телнең анатомиясен анларга ярдәм итте алар. Хатын-кыз буларак, Диләрә апа хискә байлык белән аерылып торса, Мирфатих аганың корыч логикасы, аз сүзле, конкрет булуы безне өркетә дә иде.

Мин Хатип агадан, Диләрә ападан курс эшләре язган булсам да, фәнни язмышым Мирфатих ага белән бәйле булган икән. Мирфатих Зәкиевич мине 5 курста ук әле яна гына оешып беткән татар теле кафедрасына эшкә чакырды. Мин инде кияүгә чыккан идем, кызыбыз Фәридә туган иде. Бишенче курсның икенче семестрында ук мин татар теле кафедрасында эшли башладым. Кызыл диплом алып, бер ел ассистент булып эшләгәч, аспирантурага кереп, Мирфатих Зәкиевич җитәкчелегендә "Татар әдәби телендә сүз тәртибе" дигән темага диссертация яздым һәм 1966 елда якладым. Шул елны татар теле кафедрасыннан җитәкчемне Казан дәүләт педагогия институтына проректор итеп күчерделәр... Ләкин — 1966 елдан алып, шушы көнгә кадәр —Мирфатих Зәкиевич минем олы кинәшчем, рухи терәгем, авыр чакта бөгелеп төшмәскә көч бирә торган остазым булып калды. Ул мине тюркология дигән зур дөньяга алып керде, үзе белән зур конференцияләргә барырга мөмкинлек бирде, кеше арасына кертте, туктаусыз эшләргә, фәнни эштән тәм табарга өйрәтте. Аның ышанычы миңа көч бирде, дөньянын төрле пычраклыкларына, сәхнә арты уеннарына каршы торырга, һәр гаделсезлеккә эш белән, бары эш белән генә җавап бирергә өйрәтте.

Кайдадыр укыганым бар: кеше үссен өчен максат кирәк һәм киртә кирәк! Мине кыйнап үстерделәр... (Бу — үзе бер кыйсса, гыйбрәтле кыйсса. Ходай кушса, язарбыз әле. Хәзер — урыны түгел).

Мәктәп һәм университет остазлары салган оеткы куәтле булган: күңелдә алар — якты бер хатирә, авыр чакларда — юаныч, якты бер маяк кебек...

*— Ә шулай да профессор булу җиңелме?*

— Кемгәдер — җиңел... Ә минем өчен бик авыр булды. Гәрчә моннан 20-25 ел элек деканатка, кафедрага мине якыннан белмәгән, фәнни хезмәтләремне аша гына белгән кешеләрдән "профессор Сафиуллинага" дигән хатлар күпләп килә торган иде.

Мин кандидатлык диссертациясен 28 яшьтә якладым. Кандидатлык дипломы алганнан соң да мине 6 ел буе ассистент итеп йөрттеләр. Ләкин мин фәннең һәм укытуның түбән белеп эшләдем. Шул мәгънәдә үземне бәхетле саныйм.

Төрле шәһәрләрдә фәнни конференцияләрдә катнашу, зур галимнәр белән аралашу, докладлар уку, китаплар чыгару, "Советская тюркология" журналы кебек дәрәҗәле журналда күп санлы мәкаләләрем чыгу мине һәрвакыт канатландырып торды, фән дөньясының яхшы якларын күрергә мөмкинлек бирде.

Әле баштарак зур дөньяга чыгу мөмкинлеге юк иде. Хәтерлим: Сәмәркандтагы фәнни конференциягә чакыру килгәч, мине җибәрмәделәр: янәсе, акча юк. Ә бит бу — минем өчен беренче зур фәнни конференция иде. Алга таба да шулай "акча юклыклар" күп булды. Ләкин башкалар өчен акча табылганда, миңа гына, нигәдер, акча табылмый иде. Үз акчама барган чаклар да булды.

Өч тапкыр Мәскәү университетының Азия һәм Африка илләре институтына стажировкага бардым. 5 елдан 5 елга була торган өч айлык стажировка миңа күп нәрсә бирде: зур галимнәр белән аралашу, танышу бәхетенә ирештем. Н. А. Баскаков, Э. Р. Тенишев, Н. З. Гаджиева, Б. А. Серебрянников, Э. А. Грунина һ. б. белән аралашу

үзе бер фәнни мәктәп иде. Еллар үткән саен, мин аларның зыялылыгына, бөек гадилегенә, фәнни акылына сокланып туя алмыйм...

Татар теле минем язмышым булган икән. Минем беркайчан да: "Ник бу өлкәгә кердем икән?" — дигән үкенечем булмады.

*— Сез — әдәбиятны бик ярата торган шәхес...*

— Әйе, матур әдәбият әсәрләренең теле турында күп кенә мәкаләләрем дә бар. Элеккерәк елларда традиция буларак үткәрелә торган "Әдәби ел йомгаклары"нда хәтта доклад та сөйләргә туры килгәне бар. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ә. Еники, М. Мәһдиев, М. Галиев, Р. Фәйзуллин әсәрләренең тел үзенчәлекләренә караган шактый мәкаләләр язган идем. Шуларны җыеп, текстның оешу мәсьәләләренә багышланган "Текст төзелеше" дигән китабымны да бастырдым. Ләкин китап чыгарганчы, студентларга яңа махсус курс укып, махсус семинарлар үткәргән идем. Бу махсус курсны мин яратып укыдым, чөнки ул әдәбият белән органик рәвештә бәйләнгән. Матур әдәбиятта хикәяләү, автор һәм персонаж сөйләме, аларның бәйләнеше, XX гасыр прозасында уртак сөйләмнең хикәяләүдә һәм психологик анализда гаҗәеп бер көчкә әйләнүе, теге яки бу әдипнең алып килгән яңалыклары, сүзләрнең матур әдәбиятта сурәт буларак кулланышлары, матур әдәбиятта диалог һәм хикәяләү, әдипнең милли колоритны бирү үзенчәлекләре һ. б. турында күп кенә мәкаләләр язылды.

Хәзер бер аспирантым бөек Тукайның компьютер сүзлеген төзү өлкәсендә эшли. Бу сүзлек тә Тукайга яңачарак караш ташларга мөмкинлек бирер, дигән өметтә яшибез. Бәлки, Тукайныкы дип уйланылган шигырьләрнең язмышын да ачыклап булыр.

Матур әдәбиятны иҗат җимеше буларак аңлый башлавым язучыларның иҗат лабораториясенә керү белән дә бәйледер. Хәтеремдә: 80 нче елларда әдәби әсәрләрнең башламнары турында язучыларга 12-13 сораудан торган анкеталар таратып, йә язмача, йә телдән җаваплар сорап алган идем. Минем өчен бу гаять зур мәктәп булды. Шул турыда мәкалә дә язып бастырдым, махсус курсларда да шул материалларны яратып файдаланам.

Шигырьгә керү җинел булмаса да, Г. Тукай, М. Җәлил, Р. Фәйзуллиннарның шигъри синтаксисына караган күзәтүләр ясаганым һәм мәкаләләр язганым булды. Матурлык, нәфислек, аһәңле, бай, сурәтле, җегәрле татар телен яратам. Шуңа күрә күңел Г. Тукайга, Ф. Әмирханга, С. Рәмиевкә, Дәрдмәндкә, Г. Ибраһимовка, Г. Исхакыйга, Х. Туфанга, Ә. Еникигә, Р. Төхфәтуллинга, Х. Сарьянга, М. Мәһдиевкә, А. Гыйләҗевкә, Р. Фәйзуллинга, Зөлфәткә, Р. Сүлтигә, М. Галиевкә тартыла.

Әдәбиятны укып, күзәтеп барам. Яңа китапны алмыйча үтә алмыйм. Аны искәрмәләр ясый-ясый укырга яратам. Диплом эшләренең темаларын тәкъдим иткәндә, теге яки бу язучының стиленә, лексик, синтаксик үзенчәлекләренә караганнарын да яратып бирәм. Бу — студентка да файдалы: ул әдәби әсәрне бер бөтен итеп карарга өйрәнә.

*— Бүгенге әдәбиятта сезне нәрсәләр сөендерә? Нәрсәләр борчый?*

— Сөендергәне шул: әдәби тел төрләнә бара, сүз белән иркенрәк эш итү арта бара, телебездәге төрле катлам сүзләр эшкә җигелә. Кайчак әдәби тел, чын мәгънәсендә әдәби булып, гаять югары күтәрелә, үзенең асыл мәгънәсендә яши башлый. Горурланып, тамакка төер, күзгә яшь тыгылып укыган әсәрләр дә бар. М. Галиевнең "Догалы еллар"ы минем өчен зур ачыш булды. Марсель — шәкертебез, яраткан шәкертебез — бу юлы да сынатмады. Сынатмады гына түгел, телебезнең иң югары мөнбәренә менеп утырды. Олырак буын кимсенмәсен: сүз кадерен, җегәрен, көчен, гүзәллеген бу елларда Марсель күрсәтте. "Казан утлары"ның 1998 елгы 1-2 саннарында чыккан әсәре белән шул фикерләрне тагын бер кат беркетеп, үстереп куйды.

Быел Радик Фәизовның яңа әсәрен укыгач, аны тәмам өлгереп житкән, телебезне нечкә тоемлый торган, кырыс эслүбле, тәҗрибәле язучы дип кабул иттем.

Нәбирә Гыйматдинованы баштарак артык натурализмы өчен бераз кабул итә

алмыйча йөрсәм дә, бу елларда аның әсәрләрендәге ярымтоннарны, катламнарны, яшерен милли колоритны аңладым кебек. Кызым Фәридәнең Нәбирә әсәрләрен русчага тәрҗемә иткәндә аңа соклануы миңа да күчте.

Рөстәм Сүлтиненең иҗаты үсә баруга сөенәм. Дәрдмәндкә тартымлыгы, сүз мәгънәсенең тирәнлеге ошый, бераз серлелеге, гүзәл аһәңе ошый...

Әлбәттә, үз шәкертләреннең әсәрләрен һәрберсен яратып укыйсың инде...

Нәрсә борчый дисез? Борчыган нәрсәләр: бер-берсеннән аерылмаган төссез тел, шаблон чагыштырулар, сүзне үз урынына куя белмәү һәм шуның аркасында мәгънәви ялгышлар, кирәгеннән артык гарәпчә һәм фарсыча сүзләр, сүзнең мәгънәсен белмичә куллану, русчадан сүзгә сүз фразеологик калькалар, җөмлә кытыршылыгы... һәм хаталар. Сүз хатасы, тыныш билгеләрендәге хаталар, стилистик хаталар, орфографик хаталар...

***— Чит илләрдән килгән кешеләргә дә татар теле укытасыз дип ишетә киләбез. Шул турыда бер-ике сүз әйтсәгез иде.***

— Әйе шул. Махсус кафедра ачылган елдан ук (1992 ел) безгә чит илләрдән килеп татар теле өйрәнәләр. Шушы вакыт эчендә бездә 50 дән артык кеше булып китте. Аларның бездә булу вакытлары төрлечә: кайберләре 2 атнага килә. Бу экзотика өчен генәдер кебек. Кайберләре 2-3 айга килә. Ә кайберләре 1 елга, аннан да артыкка. Аларның күбесе каяндыр стипендия алып килә. Кайбер вакытта 8-9 кеше тупланып килә. Алар ни өчен татар теле өйрәнергә телиләр? Мин болай уйлыйм: Татарстан чит илләрне кызыксындыра. Татарларның кемнәр икәнен белергә телиләр. Ә бит "татар" дигән сүз Европада Урта гасырларда куркыныч сүз буларак кабул ителгән. Мин Германиядәге бер эпизодны хәтерлим: кибеткә кереп, башкорт профессоры Ф. Хисаметдинова белән әйберләр алганда, безнең белән бергә йөргән Түлин ханым сатучыга әйтә: "Болар — кунаклар. Татарстаннан, Башкортстаннан. Аларга менә бу әйбер кирәк", — ди. Сатучы ханымның күзләре дүрт булып: "Mongolen!" — дип гаҗәпләнде.

Германиядә мин күргән "Tataren" дип аталган чи ит тә, шул ук исемдәге яшел үләнле тозлы эремчек тә безнең исемнән алынган. Финляндиядә булганда, карабодайны финнарның "татар бодае" дип атауларын ишеткән идем. Чегәннәрне дә "татарлар" дип атыйлар икән алар... Күрәсез, "татар" — Европада яшәп килә торган сүз. Әле бит аның Рудольф Нуриев кебек "оча торган татар"лары да күренгәләп тора...

Татарстан, татар дөньясы Европаны һәм дөньяны кызыксындыра. Татарстанның 80-90 ил белән экономик мөнәсәбәтләре бар, дип язалар. Бу — беренче сәбәп. Икенче сәбәп — Татарстанда сәяси мохит тыныч, милли низаглар, Аллага шөкер, юк. Шул да тартадыр. Өченче сәбәп тә бар: без мәгърифәтле дә бит әле. Тарихтан килә торган бу сыйфат та Татарстан халкының бер үзенчәлеген тәшкил итә. Безнең халыкның кунакчыллыгын да кушсаң... Татарстанның экономик потенциалы да тарта торгандыр. Дин ягыннан дискриминация булмау да тартадыр. Әйтәләр бит: сектантлар безнең җирдә әйбәт яшиләр...

Ничек кенә булса да, татар телен өйрәнергә теләүчеләр байтак. Безгә килгәннәр арасында фәнни эзләнүләр өчен татар телен өйрәнүчеләр дә бар. Әйтик, бер Тайвань егете, бер немец егете, бер Америка егете, академик Миркасыйм Госманов стажерлары булып, берничә ай татар теле өйрәнделәр. Татарча китаплар, газеталар, фәнни чыганакларны укыр өчен татар теле кирәк булып чыккан аларга.

Хәзер бу кафедрада 6 кеше татар теле өйрәнә. Ирле-хатынлылары да бар. Нигездә, Америкадан, икесе —Гонконгтан (хәзерге Кытай).

Алар үз акчаларын университетка түләгәч, тырышып укыйлар, безгә карата да таләпчән, минутларын да юкка сарыф итмиләр. Менә шуңа күрә нәтиҗә бар: алар татарча аңлый, сөйләшә. Без дә канәгать. Димәк, безнең телгә өйрәтү методикабыз дөрес, без дөрес юлда икән. Димәк, башка кешеләр дә телебезне өйрәнә алырлар иде. Теләк булса... Ихтыяҗ булса... Кирәк булса...

Кафедрабыз гөрләп тора. 20 метрлы бүлмәдә — 20 кеше. Икешәр, өчәр урында дәресләр бара, дистәләгән студентлар консультация көтә, 3 компьютер туктаусыз эшли. Укытучыларыбыз да эшли белә, студентлар да өйрәнә...

*— Сез башка миллəт вəкиллəренə татар теле өйрəтүнең фəнни-методик проблемалары белəн шөгыльлəнəсез. Безнең республикадагы башка миллəт вəкиллəренең татарча белүлəрендə үсеш бармы соң?*

— Артык зур уңышларга ирештек дип əйтмəс идем. Лəкин бер казаныш бəхəссез: татар телен өйрəнү нигə кирəк икəн дип əйтүче юк хəзер. Татар теленə өйрəнү балалар бакчаларыннан, башлангыч сыйныфлардан башлана. 50-60 яшьлеклəрнең татар телен массакүлəм өйрəнүенə мин ышанмыйм. Телəгəн кеше өйрəнə ала, чөнки мөмкинлеклəр инде юк түгел: сүзлеклəр күп чыга, сөйлəүлеклəр, үзөйрəткечлəр, ярдəмлеклəр, дəрес цикллары, дəреслеклəр...

Бу эштə əкренлəп кенə алга таба хəрəкəтне мəктəплəр башлар дип уйлыйм. Лəкин Финляндиядəге хəл бездə тиз булыр дип санамыйм: анда 93% финнар, 7% шведлар яши. Лəкин ике тел дə рəсми дəүлəт теле санала. Трамвай билетына хəтле ике телдə языла. Һəр фин шведча укый белə, һəр швед, табигый ки, фин телен белə.

Бездə 51% татарлар, 49% башка халыклар булса да, реаль икетеллелек тиз генə урнаша алмас əле. Сəбəплəре дə шактый һəм катлаулы. Беренчедəн, татарларның бик күбесе үзлəре татарча белми. Бу — зур тормоз. Рус кешесе уйлый: татарлар үзлəре татарча сөйлəшə белми, ник мин сөйлəшергə тиеш? Икенчедəн, катнаш никахлар татар теле үсешенə ярдəм итми. Өченчедəн, татарларның үзлəренең (кайчак руслардан да яхшырак!) рус телен белүлəре бу телдə һəрвакыт актив сөйлəшүгə этəреп тора. Дүртенчедəн, рус мəктəплəрендə татар теле укытучыларының тиешле югарылыктагы фəнни-методик дəрəҗəлəре булмау телне өйрəнүдə көтелгəн нəтиҗəне бирми. Бишенчедəн, татарчага өйрəтү дəреслеклəренең уртак бер фəнни-методик концепциясе булмау да үзен сиздерə. Алтынчыдан, татар теленең мохиты киң түгел; ул административ-дəүлəт аппараты теле булудан ерак тора, бу телдə беренче булып законнар, указлар, боерыклар чыгарылмый, килешүлəр төзелми; рəсми тел буларак та ул кулланылмый диярлек. Фəнни стильдə ул əле яңа гына кулланыла башлады...

*— Соңгы елларда үзегез нəрсə белəн мəшгуль?*

— Əйткəнебезчə, 1992 елдан бирле мин университетның яңа ачылган "Татар теленə өйрəтү кафедрасы"нда эшлəп килəм. Казандагы, республикадагы рус мəктəплəрендə татар теле укыту өчен — 1 нче сыйныфтан алып 8 нче сыйныфка кадəр — дəреслеклəр əзерлəп чыгарылды. Алга таба тагын да чыгачак. Махсус программа да эшлəнеп басылып чыкты. Лəкин нəтиҗəсе əллəни күренми. Сəбəплəре шактый: əле күплəр татар телен гамəлгə куюны бер кампания дип кенə уйлыйлар, "үтеп китəр əле" дигəн караш яшəп килə. Икенчедəн, заманча методика да эшлəнеп җитə алмый. Татар теленə өйрəнү методикасында таркаулык хөкем сөрə. Тəкъдимнəр күп, төрле юнəлешлəр, карашлар бар. Бер фəнни-методик үзəк юк. Уртага салып, һəр мəктəп өчен бер зур юнəлешне сайлап, шуңа барлык көчне салып эшлисе бар... Өченчедəн, дəреслеклəр. Аларны кайчак рус аудиториясенə бер сəгать тə кереп карамаган кешелəр яза. Үзең укытып карамыйча, шуны күрмичə, дəреслек язу авыр, əлбəттə. Дүртенчедəн, кадрлар. Хəзерге рус мəктəплəрендə хəл бераз яхшыра бара, билгеле. Əле бит күптəн түгел генə инженер да, лаборант та, биолог та — татарча белсə — татар теле укытты. Татар телен белү генə рус мəктəбендə укыту өчен җитəрлек түгел шул. Заманча методика кирəк! Рус, инглиз, немец һ. б. теллəрне яхшы укытып, əйбəт нəтиҗə күрсəткəн методика кирəк. Мəсьəлəнең материаль-техник ягы да əһəмиятле. Минем кызым коммерция институтында "бизнес-инглиш" укыта. Мин аның инглиз теле дəресенə ничек əзерлəнгəнен белəм. Аларның махсус дəреслеге, сүзлеге, видеокассетасы, аудиокассетасы бар. Ул дəрескə төн буе шулар белəн əзерлəнə. Ə татар телен русларга укыту өчен төрле методик концепциялəргə нигезлəнгəн 10-12 генə рəсемле, юка тышлы кечкенə генə дəреслеклəрдəн башка нəрсə бар соң? Язылганы да чыкмый ята ич!..

Югары белемне милли телдə алу, милли мəгариф системасы киңəю хəлне үзгəртер дип ышанам. Төзелеш академиясендə белгечлек буенча саф татарча белем алу мөмкинлеге бар икəн, КамПИда автомобильлəр төзү кафедрасында татарча дипломнар яклана икəн, педагогия университетында биология, физика-математика буенча татарча белем алырга мөмкин икəн —хəл үзгəрə барыр дип уйлыйм.

Безнең кафедра Казан университетының дистәдән артык факультетында татар теленә өйрәтү белән шөгыльләнә. Күпчелек факультетларда ул 2 ел өйрәнелә. Сәгате дә күп түгел: атнага 2 сәгать. Аерым факультет студентларының тел өйрәнүгә мөнәсәбәтләре яхшырак: юрфак, халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге студентлары теләбрәк өйрәнәләр. Беләләр: дәүләт структураларында эшләргә кирәк булса, алардан татар теле белү таләп ителәчәк. Телне белү ихтыяҗы әнә шулай гына формалаша ала!

Без эшләгән һәр эш укыту практикасына бәйле. Бу елларда миңа татар мәктәбенең 7нче һәм 11нче сыйныф укучылары өчен, С. М. Ибраһимов белән берлектә, дәреслек язарга, коллегаларым белән 7нче — 9нчы сыйныф рус балалары, профтехучилищелар өчен татар теле дәреслекләре булдырырга, "Антонимнар сүзлеге", "Омонимнар сүзлеге" төзеп бастырырга, дистәләрчә мәкаләләр чыгарырга, дистәләрчә конференцияләрдә докладлар белән чыгыш ясарга, Германиянең Азат университетында 2 тапкыр татар теле дәресләре үткәреп кайтырга, Хельсинкидагы милләттәшләребезгә татар теленнән лекцияләр укырга, халыкара конференцияләрдә катнашырга туры килде. Ш. С. Ханбикова белән берлектә, зур гына "Синонимнар сүзлеге" төзедек, яшь коллегаларым белән руслар өчен күләмле генә "Татар теле дәреслеге" төзеп бастырдык. Шулай ук татар тел белеменнән терминнар сүзлеге юклыгын истә тотып, үземә шундый сүзлек төзергә кирәк булды. Тиздән ул да басылып чыгачак. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләренә багышланган бер китап тәмамлап килөм. Күрәсез, эш муеннан...

Зурысын-кечесен саный китсәң, 40 лап китабым чыккандыр дип уйлыйм. Бер өлешен үземнең коллегаларым, мәсләктәшләрем яисә шәкертләрем белән чыгардым. М. З. Зәкиев, С. М. Ибраһимов, К. Р. Галиуллин белән бергә шактый китаплар эшләдек...

*— Алда торган нинди эшләрегез бар?*

— Эшләр күп. 4-5 аспирантым бар, аларның фәнни проблемалары белән җитәкчелек итү күп вакыт сорый. Мәктәп, югары мәктәп өчен дәреслекләр өстендә эшләргә туры килә. Яшь коллегаларым-шәкертләрем белән берничә яңа тип сүзлекләр әзерләп ятабыз. Зур бер проблема мине һәрвакыт кызыксындырып тора: татар теленең синтаксик-стилистик үсеше. Татар теленең 80-90нчы елларындагы лексикасында үзгәрешләр кызыксындыра, шуңа материал туплыйм. Рус һәм татар телләренең чагыштырма грамматикасын шәп итеп язасы килә. Татар теленең диалекталь синтаксисы һәрвакыт искә төшеп тора. Татар диалектларында рус сүзләре проблемасы да кызыксындыра... Ләкин, кызганыч, гомер бер генә, барысын да эшләп булмаячак. Үсеп килүче яшь буынга да калсын...

*— Әңгәмәгез өчен рәхмәт Сезгә, Флера ханым!..*

*Әңгәмәдәш* — ***Шаһинур ӘХМӘТСАФА***

**Редакциядән:** ***без Флера ханым Сафиуллинаны олуг юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз, аңа нык saулык-сәламәтлек, рухи күтәренкелек, иҗат шатлыклары телибез!***

*Нур Гыйззәтуллинга 70 яшь*

# ГОМЕРЛЕК ДУСЛЫК



*"Хөрмәтле Нур туган!..*

*Беренче рецензияләрегезне тотып, "Совет әдәбияты" редакциясенә беркадәр уңайсызланып, дулкынланып килеп керүегез әле дә күз алдымда... Кап-кара чәчле, алсу яңаклы, талантлы япь-яшь егет... Ә бүген инде Сез — күренекле галим, әдәбиятчы. Юлыгызда — гыйльми тикшеренүләр, әдәби бәхәсләр, йокысыз төннәр белән узган юлыгызда — дистәләрчә рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре, зур-зур гыйльми хезмәтләр, китаплар, нурлы маяктай ялтырап, тезелешеп торалар. Я Алла, Сезгә гомер юлыгызны һаман шулай дәвам иттерергә, аны яңадан-яңа әдәби маяклар белән бизәп барырга насыйп булсын иде!.."*

*(Афзал Шамов хатыннан өзек)*

Күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Нур Габделхәй улы Гыйззәтуллин үзенең шәхси архивында күп кенә язучыларыбызга кагылышлы истәлекләрне, аларның хатларын, фотосурәтләрен күз карасыдай кадерләп саклый. Шундый бай рухи хәзинәгә ия булган Нур абый бәһа биргесез әлеге гуаһнамәләрне (документларны) еш кына кулларына алып, укып-уйланып, хатирәләр язып утыра. Үзенә олы әдәбият дөньясына кереп китәргә хәер-фатыйха биргән остазларын да хәтерендә еш яңарта ул. Шулар арасыннан күңеленә аеруча якын әдипләрнең берсе — Афзал ага Шамов...

1949 елда булды аларның беренче очрашуы. Актаныш районының Яңа Байсар авылында туып, башта Яңа Богады, Актаныш мәктәпләрендә белем алган, аннары Минзәлә педагогия училищесын (1943 — 1945) һәм Казан дәүләт педагогия институтын (1945 — 1949) кызыл диплом белән тәмамлаган егет, ягъни Н. Гыйззәтуллин, җитди сынауларда җиңеп чыгып, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага кабул ителә (Бу вакытта аңа 21 яшь була). Шул елны яшь аспирант үзенең каләмен әдәби тәнкыйть өлкәсендә сынап карарга тели. Һәм ул танылган прозаик Гариф Галиев-нең "Авыл хикәяләре" дигән җыентыгына рецензия язып, аны үзе бик тә яратып укый торган "Совет әдәбияты" (хәзерге "Казан утлары") журналы редакциясенә китерә. Бәхетенә, журнал-ның мөхәррире Афзал ага Шамов яшь авторның үзен дә, язмасын да җылы кабул итә. Тиздән — 1949 елның декабрендә — Н. Гыйззәтуллинның "Иске дуслар белән очрашу" дигән беренче әдәби-фәнни мәкаләсе журнал битләрендә басылып та чыга... 1950 елда аның "Совет әдәбияты" журналында бер-бер артлы өч язмасы дөнья күрә... Башка елларда да шулай...

Саный китсәң, ярты гасырга сузылган фәнни-иҗади эшчәнлеге дәверендә Н. Гыйззәтуллин әдәбиятыбыз өчен күп кенә файдалы эшләр башкарган. 1952 елда аспирантураны уңышлы тәмамлап, 1953 елның гыйнварында "Кави Нәҗми прозасы" дигән темага диссертация яклаган һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия булган яшь галим Тел, әдәбият һәм тарих институтында җиң сызганып эшкә тотына. Ул әдәбият секторы лаборантыннан өлкән фәнни хезмәткәргә кадәр күтәрелә...

Шул уңайдан, Н. Гыйззәтуллинның танылган әдип, СССР Дәүләт премиясе лауреаты К. Нәҗминең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүдәге эшчәнлеген аерым билгеләп үтәргә кирәк. 1956 елда галим "Кави Нәҗми. Тәнкыйди-биографик очерк" исемле китабын бастырып чыгара. Әлеге китапның тулыландырылган басмасы 1957 елда рус телендә дә дөнья күрә. Шул ук елны Н. Гыйззәтуллин Мәскәүдә үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаша һәм, аннан кайтуга, СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә.

1958 — 1960 елларда исә Н. Гыйззәтуллин, мәрхүм К. Нәҗминең хатыны — язучы-тәрҗемәче Сәрвәр Әдһәмова белән берлектә, әдипнең дүрт томлык әсәрләр җыелмасын басмага

хәзерләү буенча зур эш башкара. "Татар совет әдәбияты тарихы" (Казан, 1960), "История татарской советской литературы" (Мәскәү, 1965) кебек күмәк хезмәтләрдә дә К. Нәҗми иҗатына, Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллардагы татар прозасына багышланган өлешләр шулай ук Н. Гыйззәтуллин тарафыннан языла. 1976 елда ул, кереш сүз һәм искәрмәләр белән, К. Нәҗминең "Әдәбият дөньясында" дигән исемдәге әдәби-публицистик мәкаләләр җыентыгын укучылар игътибарына тәгъдим итә. 1981 — 1984 елларда К. Нәҗми "Әсәрләр"енең дүрт томлыгын янадан нәшер итүдә дә Н. Гыйззәтуллин үзеннән лаеклы өлеш кертә.

Болардан тыш, галим СССР Фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты тарафыннан чыгарылган алты томлык "История советской многонациональной литературы" дигән күләмле хезмәтнең икенче һәм дүртенче томнарында (Мәскәү, 1971, 1972) утызынчы еллар һәм сугыштан соңгы татар әдәбияты һәм татар совет прозасы турындагы очерклары белән катнаша.

Н. Гыйззәтуллин Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан әзерләнгән күп томлы "Татар әдәбияты тарихы" өчен егерменче-утызынчы еллар, Бөек Ватан сугышы чорындагы, сугыштан соңгы еллардагы әдәби хәрәкәт һәм проза жанры, әдәби багланышлар һәм тәрҗемәләр, публицистика, егерменче һәм сугыштан соңгы еллардагы тәнкыйть, әдәбият белеме турындагы бүлекләрне, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Гали, Г. Толымбай, К. Нәҗми кебек олы шәхесләрнең иҗат портретларын язды. Бер үк вакытта Н. Гыйззәтуллин "Татар әдәбияты тарихы"ның басылып чыккан I-V томнарының (1984 —1989) Баш редколлегия әгъзасы, V томның гыйльми җитәкчесе һәм җаваплы редакторы булды.

Редактор дигәннән, әдәбиятыбыз тарихына багышланган күпме китап һәм җыентыкларны редакцияләргә һәм бастырып чыгарырга туры килгән аңа! Менә шуларның кайберләре: "Татар теле һәм әдәбияты" (1968), "Герой, стиль, осталык. Татар совет әдәбиятының кайбер мәсьәләләре (1972), "Әдәбият баскычлары. Татар совет әдәбияты елъязмасы (1917 — 1973)" — (1976), "Взаимодействие культур народов Поволжья и Приуралья" (1977), "Писатель, революционер, ученый. Материалы научной конференции, посвященной 90- летию со дня рождения Галимджана Ибрагимова" (1980), "Урта гасыр әдәбияты тарихыннан" (1981) һ. б.

Н. Гыйззәтуллин — татар телендә беренче тапкыр "Әдәбият белеме сүзлеге"н (1958) бастырып чыгаручы да. Аның шулай ук А. Шамов, Ә. Еники, И. Гази, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллин кебек проза осталарына багышланган "Әдәбият һәм тормыш" дигән китабы да (Казан, 1983) күңелдә зур кызыксыну уята...

Әйе, гаҗәеп тынгысыз, эшсөяр шәхес ул Нур Габделхәй улы Гыйззәтуллин! Аның асыл бу сыйфатын күренекле галим-язучы Ибраһим ага Нуруллин да югары бәяли:

"... Менә бүген каләмдәшемнең (Н. Гыйззәтуллинның — Ш. М.) "ташка басылган" хезмәтләрен күздән кичерәм дә, җиңел сулап куям: бәрәкәтле гомер кичергән икән бит ул... Шунысы да күзгә ташлана: яшьрәк чагында ул һәммәбезгә караганда да өлгеррәк булган икән. Әдәбияттагы һәр яңалыкка карата дип әйтерлек үзенең тавышын ишеттерә килгән." (Кара: "Казан утлары", № 6, 1988 ел)

Бу — хәзер дә шулай. Нур абый Гыйззәтуллин һәрвакыт тормыш дингезенең, әдәби мохитнең уртасында кайнап яши. Журналыбызның якын дусы — гомерлек дусы буларак та без аны тирән хөрмәт итәбез. "Казан утлары"ның 75 еллык юбилее һәм 900 нче саны чыгуы уңаеннан да Нур абый "Ватаным Татарстан" (30 май, 1997 ел) һәм "Шәһри Казан" (30 гыйнвар, 1998 ел) газеталарында — һәрвакыттагыча, иң беренче булып! —саллы-саллы язмаларын бастырды. Хәзер исә галим-эзтабар журналыбызның 1922 елдан башлап 1972 елгача тулы тегелмәләрен-томлыкларын булдыру буенча безгә зур булышлык күрсәтә. Шул уңайдан "Совет әдәбияты" ( "Казан утлары" )ның үзендә кадерләп саклана торган 1949 — 1972 елгы саннарын да редакциябезгә беренче булып китереп тапшырды ул...

... Нур абый Гыйззәтуллинда әнисенең — Татарстанның атказанган укытучысы Хәнифә Каһир кызының һәм әтисенең —күренекле педагог Габделхәй Гайнулла улының кайбер язмалары саклана. Шуннан бер өзек китереп үтәсебез килә: "...Бүген —1928 нче елның 12 нче июне. Көндезге сәгать 12 дә улыбыз туды (Авырлыгы — 7 кадак). Көн кояшлы, нурлы иде. Беренче балабызга, гомер буе нур чәчеп, сау-сәламәт яшәргә язсын дип, Нур исеме куштык..."

Инде ул көннән соң төп-төгәл 70 ел вакыт узган. Бүген Нур абый, тугрылыклы-уңган хәләл җефете — югары категорияле физиотерапевт Мәсгудә ханым (фронтовик язучы Әнәс Галиевнең бертуган сеңлесе!), балалары, оныклары, якыннары, дуслары белән берлектә, үзенең гомер бәйрәмен билгеләп үтә. Без юбилярга ныклы саулык-сәламәтлек, нурлы тормыш, күңел бәйрәмнәре һәм җитез каләменең беркайчан да тутык гавын телибез!

**Шаһинур МОСТАФИН**

*Фәннур Сафинның тууына 50 ел*

# АВЫРТУ БУЛЫП КАЛДЫ

*Ул татар шигъриятенең ышанычы иде. Һәрхәлдә, аңа шундый өметләр багланды. Өлкән агайлар аны, беренче җитди адымнарыннан ук күреп алдылар да, шигъри бишеккә салдылар. Ул "беренче адымнарны" миңа үз күзләрем белән күреп-күзәтеп яшәргә насыйп булды — чөнки без сабакташлар идек. Бу хакта Марсель Гали әдәбият-сәнгать әһелләренең бай образлар галереясына тиң гаҗәеп моңлы вә якты рухлы "Догалы еллар" әсәрендә дусларча бер җылылык белән искәртеп тә үтте ("Казан утлары", 1998, 2 сан).*

*Хәтердә,хәтердә... 1969 ел. Казан университетының Кызыл Позиция урамындагы тулай торагы, дүртенче кат, баскычтан күтәрелү белән сул канаттагы беренче бүлмә. Бүлмәдә һәр студентның аерым дәүләте — сиртмәле тимер караваты. Без — Фәннур, Марсель һәм мин — сабакташлар гына түгел, бүлмәдәшләр дә. "Фәннурның кайтып керүе гел бер ритмда була, киемен салып шкафка элә дә, капкасын шапылдатып яба, бөтен авырлыгын салып караватына утыра". Ниләр хакында уйланып утырды икән ул андый минутларында? Әлбәттә, олы юлга чыккан һәр яшь кеше кебек алгысынып һәм борчылып серле дә, билгесез дә, өметләндергеч тә киләчәк яшәеш турында уйланып утыргандыр!.. Һәм караватында "көне буе ятып ул дәфтәр битенә, энә төртерлек тә урын калдырмыйча, сызган-бозган, өсте-өстенә язган сүзләр белән тутыра..."*

*Фәннур университетка килеп кергәндә үк инде "исемле" шагыйрь иде: аның беренче шигырьләре "Ялкын" журналында һәм "Яшь ленинчы" газетасында басылып, уңай бәя алырга өлгергән; 1966 елда урта мәктәпне тәмамлап, Түбән Кама нефть-химия комбинатында эшләү дәверендә әдәби түгәрәкләргә йөреп (ләкин какча сөякле бу дустымны мин беркайчан да эшче-слесарь кыяфәтендә күз алдыма китерә алмадым), тулай тораклар һавасын сулап шактый шомарган егет иде. Шунлыктандырмы — хәер,кешеләр белән ул бик тиз аралашып китә иде — беренче курстан ук Фәннур каршында редакция ишекләре уңай якка, җәелеп ачылды; җитмәсә, Туфаннан дәресләр ала башлады.*

*Менә бүген дә ул җил-җил генә кайтып кереп гөрселдәп караватына ауды да, стенага таба борылып ятып "йокыга" китте. Аннары, уянып, кыштыр-кыштыр килеп, качып кына дәфтәрен актаргалады, — сүзсез генә язды, сызды, бозды. Шушы им-томга тиң серле процедура тәмамлангач кына ул торып утырасы итте.*

*— Хәсән ага Туфан янында булып кайттым әле. — Егетебезнең күзләре ут яна иде. — Ак бабай дәфтәремне карап чыккан, кайбер шигырьләремне ошатып та калган, ахрысы, яшел кара белән тамгалар да салып киткәләгән... Карагыз әле, Туфан ага гел яшел кара белән яза икән бит... Гаҗәп...*

*Әйе, Фәннур шат, бәхетле иде бу минутларда, "яшел тамгалар" игътибарына чалынган шигъри юллар аны ләззәтле канатларында күкнең җиденче катына алып менеп киткәннәр иде.*

Тәгәрмәчләр шпал санап бара,
Баганалар каршы йөгерә.
Һәр багана җирне сөйри, гүя
Кабельләрен салып иненә.

*Вәт могҗиза! — "кабельләрен иңенә салып җирне алга сөйрәүче ул баганалар" һич тә гади бер чыжым баганасы гына түгел ләбаса, ул — шигърият йөген җилкәсенә салган ашкын күңелле яшь бер шагыйрь ич. Мәктәпелларыннан ук Туфан белән җенләнеп, серле иҗатына мөкиббән китеп йөргәнгәме (абзыең да төшеп калганнар түгел, янәсе, Мөслимдә әдәби атналык узган көннәрдә — ә мин ул чакта, "Авыл утлары" исемле район газетасында эшли идем — өлкән шагыйрьдән фатиха алган "шәкерт" тә бит әле), яшел төсләге бәяләмәләрен күргәч йөрәгем кысылып куйгандай булды: димәк, Фәннур дигән яшь дустымның кешеләрдән яшереп шигырьләр язып ятуы бер дә тикмәгә түгел икән. Шушы көннән*

*башлап мин аны шагыйрь буларак кабул иттем, бераздан бу фикерем тагын да ачыграк тәгаенләнә төште. Биектау районының Ямаширмә авылы клубында булды бу хәл. Курс җитәкчебез Лена ханым Таҗиева үзенең "бөек"ләрен авылдашлары белән очрашуга алып кайткач. Әйе, Фәннур "шигырьне ташбака шикелле хәйран интегеп яралдырса да, бер тында язган шикелле йөгерек хис белән сәхнәдән укый белә иде". Яшь шагыйрьгә танылу өчен бу инде аз түгел. Менә Фәннурыбыз халык алдында ярды да салды, әйтерсең лә гомере буе шул эш белән генә шөгыльләнгән:*

Синең якка карап бер кычкырдым:
— Миңа булмас синнән башка яз!
Биек тауга килеп бәрелде дә,
Егылып төште җиргә кайтаваз.

*Билгеле, аның чыгышы алкышларга күмелде.*

*Менә шулай шигырь аша башланган дуслык, шөкер, шагыйрьнең соңгы сулышына кадәр дәвам итте.*

*... Тормыш дигәнең су кебек ага торды, Фәннурның да шигырьләре вакытлы матбугатта басыла торды, шул рәвешле ул "яшь шагыйрьләр" обоймасында үз урынын алды. Студентлык елларында иҗат иткән шигырьләре бер-бер артлы "Беренче карлыгачлар" (1970), "Юл башы" (1972) исемле күмәк җыентыкларда дөнья күрде.*

*"Юл башы" Фәннур өчен генә түгел, шәхсән минем үзем өчен дә юл башы булды — озакламый "Казан утлары" кебек мәртәбәле басмада бу җыентыкка карата беренче әдәби язмам басылып чыкты. Ул чакта дустымның иҗатына мондыйрак бәя биргәнмен икән.*

"Сүз хәнҗәрен ал каныннан,
Тик ятмасын, —

*дигән юллар аның иҗат программасы. Ул шигырьдә кыю хәрәкәт итә. Сыгылмалы формалар табарга омтыла, вакыт-вакыт матур чагыштырулары, образлы сурәтләре ялтырап китә. Шигырь тупламасына халык иҗатыннан килгән мотивлар килеп керә. Кайчагында шигырьнең буеннан-буена бер фикерне үстереп килә дә, соңгы строфада: "ә чынында мәсьәлә менә болайрак тора бит ул" дигән кебек баштагы фикерне кире кагып, көтелмәгән нәтиҗә ясап куярга ярата. Сүз дә юк, болар эзләну җимешләре.*




*Шагыйрьләр Фәннур Сафин һәм Әхмәт Рәшитов. 1986 ел.*

*Әдәбият кырында тагын бер буын төртеп килә".*

*Ниһаять, икенче курсны да тәмамладык. Соңгы имтиханны тапшырып чыккач, ул мине башкалардан читкәрәк алып китеп: "Әйдә әле, дустым, Идел буенда ял итеп кайтыйк, — дип кыстый башлады. — Идел буйлап югары күтәрелгәч, пионер лагерьлары башлана. Шунда укытучылар институты кызлары практика үтәләр. Хәтерлисеңме, институтта әдәби очрашу вакытында танышып калган идек, шул кызлар кунакка чакырдылар... "Омик"та бер сәгатьлек юл.*

*Минем һаман да икеләнеп торуымны күргәч, җилкәмә сугып куйды.*

*— Борчылма, бүген генә уч тутырып гонорар алды абзаң. Онытылмаслык бер сәфәр булды ул. Без — ике яшь пар — Идел ярында төне буе учак ягып, таңны каршыладык. Идел өстенә җәелгән зәңгәрсу, җилбәзәк томан аша аргы ярларны —Киләчәкне! — абайларга тырышып уйга чумып утырдык. Ул кичәнең онытылмаслык матур истәлеге булып түбәндәге шигъри юллар гына калды:*

Икебезгә ике учак яктык,
Берсе сүнсә, берсе калыр дип;
Юл югалткан якын туганнарның
Күңеленә өмет салыр дип.
... Учакларны җилләр сүндерер дә,
Ә күңелдә алар янар күк.
Күңел уты сүнсә, еллар аша
Ике учак бармак янар күк!

*Аһ, синсез моңсу, моңсу, Фәннур туганым... Гомер дигәнең, әнә шул яшьлектә янган учак төтене кебек, күккә аша да бетә икән ул; яшәү дә, учактагы утын кебек, яна-яна да көлгә кала икән.*

*Ләкин Фәннур Сафинның татар әдәбиятында якты исеме, олы иҗаты калды. "Кеше юлга чыкса" (1976), "Сез кемнәр?" (1980), "Тынлык" (1982), "Күкчәчәк" (1985), "Чәчәк гомере" (1988), "Яңгыр малае" (1993) кебек шигырь җыентыкларында шагыйрьнең кешеләргә булган җылы хисләре дә, җан җылысы да, уй-хыяллары да саклана, сакланыр ходай насыйп итсә.*

*Фәннур Сафин нечкә тоемлы, лирик шагыйрь иде. Аның шигырьләре яшьлек романтикасына хас ашкынулы хисләр, туган җир, табигать, замандашлар, тормыш турындагы уйланулар белән сугарылган. Аның лирикасына халыкчан гамь, моң канат куйган. Бәлки шуңадыр Фәннурның шигырьләренә нигезләнеп бик күп композиторлар җыр иҗат иттеләр. "Ялгыз көймә" (Р. Гатауллин музыкасы), "Җырымда юатырмын" (Б. Мулюков) кебек җырлары бүген дә яратып җырлана. Әмма шагыйрьнең күп санлы җырлары арасыннан "Хушлашырга ашыкма" дигәнен халык аеруча якын кабул итте. Композитор Риф Гатауллин белән иҗади дуслыкта туган бу җыр мәшһүр җырчы Илһам Шакиров башкаруында күкләргә китеп иңри, күкрәк читлегенә, күңел киңлекләренә сыеша алмыйча гамәли киңлекләргә тарала. Ул — реквием булып яңгырый.*

Сайрар кошлар синсез нишләр?
Ничек агар бу сулар?
Урман ничек шаулар,
Ишелмәсме таулар? —
Икебез дә моңсулар!..

*Ни кызганыч, Фәннур газета-журналлар каршындагы тыз-быз машиналар чабучы урамны гына түгел, тормыш урамнарын да бик авырлыклар белән кичте шул.*

*Фәннур Сафин татар шигъриятенең ышанычы иде. Талантлы улы иде. Авыртуы булып калды.*

**Наис ГАМБӘР**

# Фәннур Сафин

## Татарстан

Татарстан, синең хөрмәтеңә
Ярышырга әзер юргалар.
Табыныңда дәртле көйләр дә бар,
Ә теләсәң — моңлы җыр агар.

Уйларымны минем сизәсең син,
Татарстан — алтын Ватаным —
Давылларны узып очып бара
Еракларадан муллык бәйрәмеңә
Чакырып язган ярсу хатларым.

Мин аларда яздым сине данлап,
Хыялларны иркен һәм зур дип.
Халкым теләкләрен язсам да тик,
Куйдым гади генә — "Фәннур" дип...

***

Убылып төшкән шикелле
Иңнәренә кайгылар,
Китәсемне белеп мәллә
Гөлләрем саргайдылар?

Киттем, киттем...
Калды Казан,
Ерак калды Казаным.
Оясын югалткан коштай,
Казанымны сагнамын.

Ниндирәк уй, ниндирәк гамь
Казан тирәләрендә? —
Шул уй белән тибәдер кан
Минем чигәләремдә.

... Кайттым, кайттым!..
Туган җирдә
Безгә көрешергә язган.
Каргалган кошың түгел мин,
Югалтма мине, Казан!

## Юлда

Идел-елга ул кич ачуланды,
Дулкыннары килде өстемә.
... Ярда, төнге учак җылысында,
Акчарлаклар керде төшемә...
Күзләремне ачсам: җил басылган,

Давыл тынган, алсу таң аткан.
Юлга дәшкән кебек, акчарлаклар
Тавыш бирә миңа ерактан.
Ә дулкыннар, инде пышылдашып,
Ялый комда яткан ишкәкне.
Учагыма талгын җил җан өрә, —
Иңбашыма салам бишмәтне...
Утка коры чыбык өстим дә мин,
Җан җылысы алам, хәл җыям.
Барыр юллар шундый озын әле,
Җитәсе җир — ерак океан!

## Гитара чиртүче кызга

Гитараңда синең җиде кыл,
Җиде генә моң сыйганмы аңа?
Гитараңда синең җиде кыл,
Җиде ярам гүя әрнеп яна.
Гитараңда синең җиде кыл,
Җанга татлы-хыялый хисләр ява.
Гитараңда синең җиде кыл,
Монда көлү, сыкрау — барсы дәва.
Гитараңда синең җиде кыл,
Һай, ник бүген алар чиксез салкын?!
Кулларыңда гүя җиде кол,
Җырлый тик бер җырны. Сүнә ялкын.
Керфекләргә генә дә түгел,
Күңелемә салкын бәсләр куна. —
"Сөясеңме?" — дип мин сорыйм да,
Шул җыр белән гүя дөньям тула:
"Юк!
Юк!..
Ю-у-ук...
Юк!.. Далаларга чыга, урманнарга, —
Кая гына илтми сукмагым!..
Ничә тапкыр салам эскертләрен
Туган йортым итеп йокладым.
Миңа бәет кебек моңлы урман,
Миңа җырдай иркен кырларым...
Кояш монда таңнан торып үпкән
Әбиемнең айдай урагын...
"Әйдә биик?!" дип үз телләрендә
Ромашкалар кулга сузыла.
Аһ, гүзәлләр нинди охшаганнар
Ак калфаклы болгар кызына!..
Таң сызамы җанга ал нурларын,
Йә барамы кояшын баеп,
Матур! илнең газиз табигате.
... Юк, башкача уйлау да гаеп!..

## Сагынам

Мин дәүләтсез падишадай булам
Читтә ялгыз калган чагымда.
Кояшларга карап елмаям мин,.
Сары айга карап сагынам...
Тентүләрдә туздырылган йорттай
Тәртипсез уй түгел башымда, —
Ераклардан җәһәт кенә килеп,
Син торасың кебек каршымда!
Мин каладан авылыма таба
Сузылып киткән юлга күз атам.
Тәрәзәмне ачып, уйларымны
Туган якларыма озатам...
Ак күгәрчен булып оча хыял
Иң бәхетле узган чагыма.
... Кояшларга карап елмаям мин,
Сары Айга карап сагынам.

## Уян!

Йоклыйсыңдыр инде күптән,
Шундый якын арабыз.
Ефәк чәчләрең ятадыр
Күкрәгеңдә таралып.
Нурга чумган йөзләреңә
Ай сокланып карыйдыр.
Тәрәзәң чиртеп йолдызлар
Дәшәләр күк: "Ярыйдыр?.."
Әкияттә дә әйтелмәгән
Нинди матур кич соң бу?!
Татлы йокыңнан, билләһи,
Уятам сине, сылу!
Шәмәхә энгергә баткан
Киң кырны күрер өчен
Уятамын,
Юкса, берни
Күрми каласың ич син!
Күзләрең су өстендәге
Көймәне күрми кала.
Ә көймәдә икәү бара...
Уятам сине, бала!
Уятам башта үзеңне,
Аннары хисләреңне...
Бүтән йоклап үткәрмәссең
Йолдызлы кичләреңне!

## Бергә

Монсу гына таңнар атсын әйдә,
Бер юансын әле хисләрең.
Көннәр аяз булыр диеп кенә
Алсуланып килсен кичләрең.

Агылсыннар күңел ташкыннары,
Куанычы жанның — ачык йөз.
Аяз күккә карап, ничек инде
Гамьсез генә галәм буйлап йөз.
Якты галәм буйлап без йөзәбез,
Чалкан ятып яшел аланга.
Син гомер сөр, имеш, елмаймый да,
Яши торып шундый заманда.
Куллар кулга үрелеп кенә тора,
Нәкъ йөрәктә дуслык ялкыны.
Җирдә көннәр, төннәр уза шулай
Синең, минем йөрәк аркылы.
Хуҗалары ич без шушы җирнең,
Һәм дөрлибез шуңа күрә без.
Ал таңнарны шулай чакырабыз
Һәм кичләргә бергә керәбез.

## Кеше юлга чыкса...

Кеше юлга чыкса,
икмәк теләп
Калдыра, ди, ишек өстендә.
Аннан инде ничек кайтмый калсын,
Аны монда ризыгы көтсен дә!..
Барыр юлым уңа күрсен, дисә,
Ниятләре булса изгедән,
Юлчы үзе белән
бер уч туфрак
Алып китәр туган нигездән.
Юлчыларны илдән халык шулай
Йолаларны бозмый озата.
Шуңадырмы, ирләр кайталмаса,
Илләр гизеп,
Моңлы җыр кайта!



Китап күзәтү

# КЫРГЫЙЛЫККА КАРШЫ

Нәбирә Гыйматдинованың Татарстан китап нәшриятында "Кыргый" исеме белән басылган повестьлар җыентыгы мине дә битараф калдырмады. Кайсы ягы якын соң безгә Н. Гыйматдинова иҗатының? Беренче чиратта, әлбәттә, әсәр сюжетларының кеше күңелен дулкынланырга мәҗбүр итүче гайре табигый вакыйгаларга нигезләнгән булуында. Мона кадәр без андый хәлләр турында йә фантастик әсәрләрдән укып, йә халык арасында телдән-телгә сөйләнеп йөргән хикәяләрдән ишетеп кенә белә идек. Һәм, ниһаять, вакыт житте: Нәбирә Гыйматдинова аларны безгә житди әдәби әсәрләр рәвешендә тәкъдим итте. Икенчедән, авторның тел-өслүбе көйле, сүзләр, җөмләләр бер-берсенә ятыш, кыскасы — түгәрәк, бөтен. Әсәрләрдә һәр "шәхеснең" сөйләме аның холкына, яшәгән мохитына, эчке халәтенә яраклаштырылган. Психологлар фикеренчә дә бит: кешенең эш-фигылен, үз-үзен тотышын һәм шул җөмләдән, сөйләмен анализлау аша кешенең эчке дөньясын ачып була. Гыйматдинова геройларының да эчке дөньяларына сөйләмнәре аша юл табарга мөмкин. Өченчедән, язучы эмоциональ моментларны артык күпертмичә, күпшыламыйча, гади, әмма үтемле, тәэсирле итеп бирә белә. Китапка барысы дүрт повесть тупланган: "Күке төкреге", "Кыргый", "Китәм, димә", "Болан". Соңгысында Н. Гыйматдинова, минем карашка, иҗатындагы төп проблеманы — табигать һәм кеше арасындагы гармониянең югалуы һәм шуның нәтиҗәсендә килеп туган кешелек дөньясының һәлакәте проблемасын аеруча ачык чагылдыра. "Сихерче"дәге Сәвилә белән "Болан"дагы Акчәч икесе бер "камырдан" булып, икесе дә табигатьне саклау, кешеләрне бәладән йолуны тормышларының төп бурычы иткәннәр. Шушы ук Сәвилә, Акчәч образлары янына "Күке төкреге"ндәге Галияне дә китереп куярга кирәк. Ләкин Галиянең бурычы алдагыларыныкыннан бераз тарайтыла төшкән — повестьта ул күбрәк үз бәхетсезлеге өчен үч алучы образ кебегрәк итеп эшләнгән. Шулай булуга карамастан, Сәвилә дә, Акчәч тә, Галия дә, әйтеп кителгәнчә, бер "лагерь" кешеләре. Өч повестьны берләштерүче тагын бер охшаш деталь — ул да булса, өч әсәрдә дә героиняларны "башка мөхит" белән бәйләүче булып карчыклар образлары килеп баса. "Сихерче"дә —Убыр, "Болан"да — Сузгын, "Күке төкреге"ндә — Карачутыр. Өчесе өч характердагы карчыклар болар, әмма боларны да берләштерүче уртак бер деталь бар: нинди булуларына карамастан, сузгын да, убыр да, карачутыр да мәңгегә кешеләр арасыннан сөрелгән, читләтелгән. "Сихерче"дәге әби, мәсәләң, гомере буе кешеләргә изгелек кенә кылган, әмма авылдашлары аңа "убыр" дигән ямьсез исем ябыштырып, үлгәч, йортына ут салу белән җавап бирәләр. "Болан"дагы Сузгын үзе үк кешеләрдән читләшүне хуп күрә, ә авылдашлары аның мәетен зиратка кертмәс өчен җан талашалар. "Күке төкреген"дәге Карачутыр турында инде әйтәсе дә юк. Илкөнгә төрле-төрле кара эшләр, эреле-ваклы зәхмәт кылып күрүче карчык бу, шуңа да кешеләр аның йортын әйләнеп узуны артык күрәләр. "Күке төкреге"ндә "Сихерче"дәге кебек үк "күршелек" проблемасы бик калку итеп күрсәтелә. Тормышта яман белән яхшы янәшә генә, күпмедер дәрәҗәдә бер-берсенә ярашып гомер сөрә. "Сихерче"дә Тәминәларны бөтен барлыгы белән шашып яратучы, аның өчен бар булганын бирергә әзер торучы Сәвилә һәм янәшәдәге йортта шул ук иргә хыянәт итеп, әзһәр чәчеп яшәүче Мәликә күршелеге... "Күке төкреге"ндәге Акъәни һәм оныкы белән Карачутыр, Газзә, Шәрәф янәшәлеге... Бу янәшәлек сәнгать әсәрләрендә мөмкин булганча, Гыйматдинова повестьларында

берникадәр тарайтылып бирелгән. Эче чиста унай геройларның башка якларына детальле игътибар ителми. Ә бит тормышта бер кеше эчендә яхшы сыйфатлар начарлары белән янәшә яши. Кимчелек дип саналырлык сыйфатлары булмаган кешеләр тормышта бик сирәк очрый. Шуның белән бергә, тискәре сыйфат әле ул һәрвакытта да яманлык, кара эчлелек дигәнне аңлатмый. Н. Гыйматдинова "шәхес"не сурәтләүдә нигездә менә төп шул критерийга — күңел чисталыгы, "шәхес"тә явызлык булмауга, кешеләргә карата начарлык кылмауга басым ясый. Әлеге повестьларында, Н. Гыйматдинованың, алда язылган әсәрләрендәге кебек үк, хатын-кыз образлары ир-ат образларына караганда күпкә нечкә, күпкә сизгер, батыр, күпкә тәвәккәл, чыдам. Мәхәббәт — алар өчен җирдәге бөтен нәрсәдән өстен. Әлбәттә, фрагмент рәвешендә тискәре хатын-кыз образлары да чагылып китә бу иҗатта (Мәсьәлән, "Кыргый"дагы Әсмабикә образы). Шуның белән беррәттән, нигездә хыянәтчел, көчсез ир-ат образлары "лагере"нда сирәк булса да сокланырдай ир-ат "шәхес"ләр очрый. "Кыргый"дагы Җәббәр, "Китәм, димә"дәге Шәнкәле образлары шундыйлардан. Ә калганнары җаннары яхшы булуга карамастан, ничектер, яманлык томанына чорналып яшиләр сыман. Алар өстендә ниндидер каргыш эленеп тора сыман. Шулай булмаганда, тормышлары көйләнә, менә инде бәхеткә тиенә дип торганда гына, бу ирләр кинәт кенә ялгыш адымнар ясап ташлыйлар. Мәсьәлән, "Күке төкреге"ндәге Гыйлемдар, инде кайчандыр эшләнгән ялгышларын төзәтеп, сабыр гына яраткан Галиясе белән кавышасы урынга, ана үч итеп күрешү көннәрен ерагайта, икенче яшь хатынга өйләнә. "Китәм, димә" повестендәге Сәйләш тәмугъка охшашлы тормышыннан йолып алырдай кешесенә — сөйгәне Камиллага хыянәт юлына баса. "Болан"дагы Рыскол, бәхетле булуга бер адым калганда, үзен үлем тырнагыннан йолып алган мәхәббәте белән аны күкләргә күтәргән Акчәчкә хыянәт итеп, антын боза, һәлакәткә юлыга. Китапка кергән "Китәм, димә" әсәре — психологик, фәлсәфи повесть. Кеше үз тормышы, яшәвенең мәгънәсе, үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйласын өчен менә дигән этәргеч бирүче әсәр бу. Илдәге инкыйлаб нәтиҗәсендә өч кешенең язмышы аерычаеры килеп, бәхетсезлеккә дучар була. Салам түбәле өйдә яшәүче чабаталы философ Шәнкәле, затлы сарайда көн күрүче нәзберек графиня Шарлотта, ятимлек ачысын тулысы белән татып, ни ярлылык чокырына тәгәрәмичә, ни байлыкка ирешмичә, ләкин тулысы белән нәсел-нәсәбеннән баш тартырга мәҗбүр булып дөньядан киткән Камилланың әнисе... Ахыр чиктә бәхетсезлек Камиллага да килеп кагыла. Графиняның бөтен милкенә тулы хуҗа булып Парижда яши башлагач, ул тормышындагы ин бәхетле мизгелләрне гипноз ярдәмендә хәтереннән юдыруны хуп күрә. Карынында яралган бала гына аны үткән шул көннәре белән бәйли. Шәнкәле-Шәнгәрәй нәселе өстендә ниндидер каргыш эленеп тора кебек. Бу нәселнең бердәнбер дәвамчысы булырга тиешле бала — Камилланың дөньяга киләчәк баласы инде туганчы ук этисе, нинди нәселдән килүе турында хатирәләрдән дә мәхрүм ителәчәк. Ни аяныч! Димәк, нәселе белән бергә ул халкын да онытачак. Ә бит Камилла-Камилләнең трагедиясенә әлеге дә баягы шул антын тота белмәүче ир гаепле. Ир кеше яшәешнең нигезе булырга тиешле: Ходай тарафыннан шуңа күрә дә ана аек, аналитик акыл биргән, күбрәк физик көч, чыдамлык, түземлек бирелгән. Хатын-кыз ул күбрәк хис белән яшәргә тиешле зат. Әмма көннән-көн ирләр ничектер чигенәчүгә, вакланып, кечерәя, мескенләнә, тормышның бөтен йөген хатыннар өстенә аудара баралар. Тарихтан билгеле: ирләрнең акылларын җуеп, ниндидер шәхси амбицияләр өчен ызгышып-талашуы аркасында зур-зур дәүләтләр һәлак булган. Набирә Гыйматдинова өчен бу проблеманы күтәрү, әйтеп кителгәнчә, беренче түгел. Язучының иҗатында ул мәсьәлә төп урынны тота дип әйтсәк тә ялгышмабыздыр. Китапка кертелгән дүрт әсәр арасында ин уңышлысы, безнең карашка, "Кыргый" повесте. Язучы моны үзе дә аңлый булса кирәк, китапның нәкъ шушы повесть исеме белән аталуы шундыйрак уйларга этәрә. Җәмиләнең трагедиясе, китапка кергән башка әсәрләрендәге героинялар фаҗигасына караганда, йөрәкне күбрәк дулкынландыра. Бу — Җәмиләнең күпмедер дәрәҗәдә безгә якынрак торуыннан булса кирәк. Чөнки, нәрсә әйтсәк тә, Галия дә, Акчәч тә, Камилла да, Тургенев әсәрләрен тикшерүчеләр терминологиясен кулланып әйтсәк,

"галәттән тыш шәхесләр". Безнен арада андыйлар менгә бер генә очрыйлар. Ә менә Жәмилә — гап-гади хатын, андыйларны тормышта эзләп артык жәфаланасы юк. Халыкнын тискәре дә, унай да тәжрибәсен, ышану-инануларын ул ныклап сендергән. Иренен ерткыч булуына карамастан, нечкә, йомшак кунелле Жәмилә ана бөтен жылысын бирә, анын хыянәтен, сугу-орууларын да кичерә. Әмма бу ханымнын эче каршылык белән тулган: бертуктаусыз бәхеткә омтылу, бәхетле булырга хыяллану, шул хакта уйлау белән беррәттән туктаусыз бәхетсезлеккә тартучы эш-гамәлләр кылу... Башта, жаны карышуга карамастан да, карт кыз булып калам дип, яманаты чыккан Идрискә кияүгә бару; аннары бөтен жылысын, бөтен сөюен шул ерткыч, хыянәтчел иргә әрәм итү, аны үзгәртергә тырышу, ике куллап, чатырдатып бәхетсезлегенә ябышу; ахырдан Жәббарнын үзен бәхетле итәчәк мәхәббәтеннән көрәшсез генә ваз кичү... Үзенен ерткыч ире Әсмәбикәгә йортка кергәч, "кайт, аяк астында туфрак булырмын", дип ялварган хатын, башлары әйләнер дәрәжәдә яраткан Жәббарыннан качып, ачылмыйча йөдәтә. Моны ничек анлатып була? Минемчә, бу — хроник рәвештә бәхетсезлеккә омтылыш. Жанытәне белән күрәлмаган качкын Идрискә ишек ачуны да ни белән анлатырга? Куркумы? Юк, Жәмилә батыр хатын. Теләсә, көтелмәгән кунактан котылу жаен таба алган булыр иде ул. Әмма, әлеге дә баягы, шул бәхетсезлегенә "тугры" булу аны Идрис турысында Жәббарга ачылудан тыеп кала. Жәббар Сафин — Жәмилә авылына билгеләнгән участок милиционеры, тәртип сакчысы. Назга, яратуга, сусаган Жәмилә анын мәхәббәтеннән бер дә булмаганча ачылып, яктырып китә. Ләкин Жәббар образы икенче планлагы образ, детальле эшләнмәгән. Әмма анын нинди шәхес икәнлеге әсәрдәге вакыйгалар барышында ачык укыла: бу — көчле, акыллы, тугърылыклы, саф кунелле, яхшы йөрәкле чын ир. Идрис тарафыннан "корыган таяк", "Сасы көзән", "сукыр тычкан" дигән хурлыклы сүзләр генә ишетеп, кыйналып-сугылып яшәгән Жәмиләне үзен хатын-кыз итеп тоярга өйрәтүче нәкъ менә Жәббар. Ана охшашлы геройны Н. Гыйматдинова әсәрләрендә инде бер очраткан идек. Мина калса, Жәббар белән "Ханым-солтаным" повестендагы Таһир бертуганнар кебек охшаганнар. Нәкъ менә шундый тор ир-ат авторнын идеалы булырга охшый. Карачкы-Идрис тә Жәббар кебек ук икенче пландагы образ. Бу геройларнын эчке дөньясында барган уй-кузгалышлардан без хәбәрсез. Ләкин эш — гамәлләрен анализлап, без Идриснен нинди рәк кеше булуы турындагы картинаны ачык күз алдына бастыра алабыз. Жәббарга капма-каршы образ буларак, ул хыянәтчел, вәхши, хәйләкәр, астыртын, көнчел. Чагыштырыр өчен ике геройнын сөйләменнән өзекләр китерик. Жәббар: " — Саумы, Жәмлу-Жәмилә?! (Машинадан алып кыр чәчәкләре сузды) Үзенә охшаганнарын гына жыйдым. Болында чәчәк, чәчәк, күз камаша. Ләкин ин матуры минем каршымда икән бит. Бөтен гөлләрнен матурлыгын үзенә жыйган". Идрис: "Ну, Жәмлә, сасы көзән, сукыр тычкан, арт сабагынны бер укытам мин синен. Икенчеләй урам ярмассын, милисә остермәссен. Идән астына алтөшеп, иләк авызына бәрәнге тутырып, тавышөненне чыгартмыйча гына изәчәкмен". Шушы ике образ яктылыгында Жәмиләнен трагедиясе тулысы белән, бөтен тирәнлеге белән ачыла. Төрмәдән качкан ир бу хатыннын психологиясен шулкадәр яхшы үзләштергән ки, "минем белән бергә инде син дә буялдын, тоттырсан, төрмә ишеген бергә атлап керербез", — дип, Жәмиләнен башына сендергәч, ул бернидән шикләнмичә, жәелеп көн күрә башлый. Никахлы хатыннын "тиешсез" эш кылмасына ул тулысынча ышана. Әгәр Жәмиләнен юлында Жәббар очрамаган булса, эш нәкъ Идрис уйлаганча килеп чыгар иле, мөгаен. Н. Гыйматдинованын күп әсәрләрендә без ятимлек мәсьәләсе белән йөзгә-йөз очрашабыз. Мәсьәлән, "Сихерче"дә Сәвиләне апасы тәрбияли, "Күке төкреге"ндә Галияне дәү әнисе үстерә, "Болан"дагы Акчәчнен Сузгын карчыктан башка беркеме юк. "Кыргый"дагы Жәмилә исә — дөм ятим. Аннары "Күке төкреге"ндәге үги әни һәм кырыс эти кул астына кайтуга караганда ерткыч Шәриф белән көн күрүне артыграк күрүче Нажия... Ятим сабыйнын күнеле сынык була һәм тормышта алар ятимлек татымаган балаларга караганда, ешрак фажигага очрыйлар. Ятимлектә үскәннәр тормышта төрле юллар сайлый: кайберләре явызлыкка тартыла, кайберләре кешеләрдән читләшеп, аларга ышанмыйча көн күрә. Ләкин болар арасыннан Сәвилә, Акчәч, Галия, Нажия кебек чиста, саф йөрәкле,

кешеләргә ышанычын, мәхәббәтен жуймаган, горур шәхесләр дә чыккалый. Авырлыклар килгәндә ышыкланыр өчен нык жилкә булмау бу геройлар холкында үжәтлек тә тәрбияләгән. Шәрәфтән туктаусыз жәбер күреп, туктаусыз кыйналып, тапталып-изелеп яшәгән яп-яшь, яп-ябык Нажия ире көндәш ияртеп кайткач нишли әле? Менә әсәрдән өзек: "Көндә-эш?! — дип чинап жибәргән Нажия һәм, агач башыннан сикергән мәче кебек, теге хатынның бөдрәләткән чәченә барып ябышкан. Хатын селтәп аткан саен килеп ябыша икән яшь килен, ябыша да чиный-чиный тегенең йөзен тырный икән". Бохараны — авыл, парикны шарик дип сөйләүче шушы ук Нажия берзаман үжәтләнеп шәһәрдә табиплыкка укый һәм максатына ирешә дә. Үжәтлек дигәндә Жәмиләне дә искә төшерү урынлы булыр. Ни тырышып, ни үжәтләнеп авылда бер диярдәй йорт житкерә бит ул! Әсәрдә "йорт салу"га юкка гына аерым басым ясалмый. Ныклып уйлап караганда, хатын-кыз күп очракта оясын-йортын ныгытуга бөтен көчен бирүчән була. Ышыкланыр жилкәсе булмаганнар өчен бу бигрәк тә хас. Шуңа күрә Жәмиләнең үз йортын булдырырга омтылышы бик яхшы аңлашыла. "Йорт салу" повестьта тагын символик төшенчәгә дә ия. Идрис белән гомер иткән йорт иске, кыйшайган, черек бүрәнәле — ул Жәмиләнең никахлы ире белән уздырган гомеренә охшаган. Янасы исә, Жәббар Сафин Жәмиләгә бүләк иткән мәхәббәт кебек матур, зур, таза, нык. "Күр, бүрәнәләре нинди нык, калын. Өч кеше гомеренә житәрлек... Калын булмый ни, ирләр белән тин урман кисеште ич! Шәпә Халидәсе ире белән куллдаш иде. Тәрәзәләренә кара син! Күрше авыл остасы Солтан тәрәзә йөзлекләрен челтәрләп ясый дигәч, аны эзләп барды. Челтәр тәрәзәле матур йортта яшәргә хыяллана иде бит Жәмилә". Монысы Жәмиләнең яна торгызган йортының тасвирламасы булды. Жәббар китергән бәхет түбәндәгечә сурәтләнә: "Урман аланында уздырган төннән соң Жәмилә үзен чын хатын-кыз итеп тойды. Жаның төреп торган кабык салып ташланды. Бу мәхәббәт шундый кадерле ки, ана йөрәк каны белән генә түләргә кирәк иде. Ул жиргә басмады — очты, ашамады-эчмәде — һава белән генә тукланып торды, гүя канатлы фәрештә иде. Күңел үсмәгәнгә күрә шкафта киелмичә яткан күлмәкләр дөньяга чыкты, гел жыеп, каптырып куйган чәч дулкынланып иңнәргә сибелде, иннек-кершән күзгә янына барып кунаклады, кыскасы, ул яши башлады". Һәм менә, көннәрдән бер көнне, Идрис дигән ерткыч шушы мәхәббәт утында янган ике кешене аера. Күңеле сынык Жәмиләгә инде матур йортның да кирәге калмый. Мен бәлаләр белән житкерелгән йортка ул үз куллары белән ут сала. Чоланда гырлыйгырлый Идрис йоклы симертә. Үзен нинди ачы үлем көткәнен ул башына да китерми. "Сарайдан бензин алып чыгып су белән коендыргандай шаулатып бүрәнәләргә сипкәндә генә күздән яшь атылды. Өч чиләк бензинның тамчысын да калдырмыйча елый-елый сибеп бетергәч, кочак-кочак күтәреп өйнең дүрт ягына да салам ташыды. Ерткычны оясында дөмектерәләр, оясында... Аны качырырга ярамый... Ул — куркыныч, бик куркыныч ерткыч... Әгәр ычкындырсаң, адәмнәр аннан күпме жик күрәчәк..." Тәвәккәл адым ясар өчен шулай ук мәхәббәтен жую кирәк булдымы икәнни соң Жәмиләгә? Әллә бу Идрис күрсәткән кайгы-золымнарның сабыр савытын ташыткан соңгы тамчысы булдымы? Ни генә булмасын, бу хәл Жәмиләнең үткәненә нокта куючы күренеш иде. Әгәр дә күнелләп генә повестьның дәвамын уйласак: Жәмилә шәһәргә китеп, эшкә урнаша, торак мәсьәләсен хәл итә, хәтта яхшы гына гаилә дә төзи. Ул инде "хроник рәвештә бәхетсезлеккә омтылучы" түгел, ул — тигез, тыныч тормыш көтүче... Әйе, Нәбирә Гыйматдинованың яна китабы — аның яна уңышы. Талантлы һәм жегәрле бу авторга ижади уңышлар һәрчак юлдаш булсын, китап сөючеләрне янадан-яна әсәрләр белән сөендерсен дигән теләктә калабыз!

**Руфия ХӘМИДУЛЛИНА**
"Казан" милли — мәдәни үзәге

# Borъnqъ tatar çъrlarъ

## Iske qara urman

*Tatar xalъq çъrъ*

Qara da qъnaj urman, qaranqъ tөn,
Jaxşъ atlar kirək ytərgə;
Qarurmannъ съqqan caqta
Kisep aldъm par usaq,
Aj, ajъrъlmas dus bulsaq.

Zamanalar awъr, jъllar jabъq,
Dus—iş kirək gөmer itərgə;
Qarurmannъ съqqan caqta
Kisep aldъm par qajъn,
Aj, ajъrъlmajъq, dusqajъm.

Qara da qъna jъlan, aj, tuz başlъ,
Jөrider lə qamъş bujъnca;
Qarurmanqa kergən caqta
Kisep aldъm par usaq,
Aj, ajъrъlmas dus bulsaq.

Jalqъz başъm, juq juldaşъm,
Jөrimen lə jazmъş bujъnca;
Qarurmanqa kergən caqta
Kisep aldъm par qajъn,
Aj, ajъrъlmajъq dusqajъm.

Qara da qъna urman, qaranqъ tөn,
Nindi jullar belən lə ytərbez;
Qarurmannъ съqqan caqta
Kisep aldъm par usaq,
Aj, ajъrъlmas dus bulsak.

Dus—iş belən bergə eş itkəndə,
Teləklərgə tizrək lə çitərbez;
Qarurmannъ съqqan caqta
Kisep aldъm par qajъn,
Aj, ajъrъlmajъq dusqajъm.

## Olь julnьn̡ tuzanь

*Tatar xalьq çьrь*

Olь julnьn̡ tuzanьn
Yzem kyrdem tuzƣanьn.
Belmi qaldьm, sizmi qaldьm
Jəş ƣəmeremnen̡ uzƣanьn.

Olь julnьn̡ tuzanьnda
Qaldь minem ezlərem;
Qajda ikən jəşlegem, dip,
Şul jullardan ezlədem.

Olь julnьn̡ tuzanьnda
Juƣalttьm ezləremne.
Ix, qajtarьp alьr idem
Uzƣan ƣəmerləremne.

Olь juldan atlar kilə,
Bezgə qala tuzanь.
Alda ƣəmer bardьr barьn,
Saƣьndьra uzƣanь.

## Gəlçamal

*Tatar xalьq çьrь*

Şəmdəllərdə genə utlar jana, Gəlçamal,
Çitkən qьzlar kinder çep erlilər.
  Ençe də mərçən qьzlarnьn̡ qul bawь,
  Awьr çan səjgənnərnen̡ bulmawь.
Nindi genə jegetkə barьrbьz, dip, Gəlçamal,
Qolaqtan qolaqqa alar səjlilər.
  Ençe də mərçən qьzlarnьn̡ qul bawь,
  Awьr çan səjgənnərnen̡ bulmawь.

*Укучы сүзе*

* * *

Исәнмесез, милләттәш мөхәррирләр!

"Казан утлары" журналының 1996 елгы тугызынчы санынnan һәм быелгы тәүге саннарыннан Марсель Галиевнең "Догалы еллар" әсәрен укыгач туган тәэсирләремне белдерәсем, аны бастырып чыгарган өчен Сезгә рәхмәт әйтәсем килде.

Кайчандыр кемнеңдер табышы булган тапкыр чагыштыруларны, тел бизәге саналырдай гыйбарәләрне урынлы-урынсыз кат-кат кулланып чүбеккә әйләндереп бетергән, хиссез, төссез тел белән язылган, ни кеше күңеленең кылын да селкетмәслек, ни акылына-аңына мыскал да азык бирмәслек кирпеч калынлыгы роман-повестьлар да чыгып килгән бер заманда үз әсәрләренең геройлары авызыннан әйттергән бер-ике сүзе, бер кыланышы белән тере характерларны күз алдына китереп бастыра алган Мөхәммәт Мәһдиев безне таң калдырган иде. Үзе үскән-яшәгән чордагы татар авылы мохитын, авыл кешеләренең эчке-тышкы дөньясын шулның хәтле осталык белән сурәтләп биргән язучының үзе исән чагында кадерен белә алдык микән без?.. Юктыр...

Менә — Марсель Галиев. Үзенне тудырган, үстергән, Кешемен дип күзгә туры карап әйтерлек дәрәҗәгә житкереп тәрбияләгән Туган жиренә, авылыңа, милләтеңә мәхәббәтеңне, рәхмәтеңне аның "Догалы еллар" дигән әсәрендәгечә итеп кенә белдерергә хакыбыз бардыр. Татар дигән милләтнең кем икәнен бөтен дөньяга таныттырга шундый осталыкка ирешкән сәнгатькярләребез генә булдыра алырдыр.

Марсель үзе әйтмешли, шигырьгә анализ ясап азаплану ахмаклык булыр. Әмма аның телебезнең барлык көч-куәтен, нәзакәтлелеген жиеп язу осталыгына сокланмыйча мөмкин түгел.

Дөньядагы барлык телләр арасында иң матур тел дип француз теле санала бугай — тик, француз телен белмәгәч, анысына бәя бирә алмыйм. Ә менә Марсель Галиев татар теленең иң гүзәл, иң нәфис, иң сәнгати тел икәненә үз ана теленең кадерен белмәгән туң йөрәкле теләсә кайсы мәхлукны да ышандыра алыр. Рәхмәт аңа, Ходай сәламәтлегеннән аермасын, иҗат дәрте сүрелмәсен!..

**Фәния ГАЙНАНОВА,**
*Казан шәһәре*

* * *

Кадерле милләттәшләрем, хөрмәтле дусларым!
Сезгә дигән хатымны җыр сүзләре белән башлыйм әле:

Исмәле, жил, исмәле, жил! —
Кисмә гөлнең чәчәген...
Алга килми, белеп булмый
Башның ни күрәчәген...

Миңа инде 71 нче яшь. Үз гомеремдә күпне күрергә, күпне кичерергә туры килде. Әмма "Совет әдәбияты" (хәзергечә әйтсәк, "Казан утлары") журналыннан аерылмадым. Инде менә 40 елдан артык Уралда — Свердловск

өлкәсенең Лобва дигән поселогында яшим. Яраткан журналыбызны үзем генә укып калмыйм — аның һәр санын күршеләремә, дусларыма-танышларыма да укытам. Әле менә Корбан бәйрәме көннәрендә Тәгъзимә исемле бер әбигә садака илтергә баргач, "Казан утлары"ның ике санын аңа да укырга биреп калдырган идем. Бик ошаткан анда язылганнарны. Бигрәк тә Марсель Галиевнның "Догалы еллар"ын, Марс Шабаевның көчле рухлы язучы Фәнис Яруллин турында язмасын. Фәнис энебезнең шигырьләрен, безнең кебек, елый-елый укыган ул. Әнә шуңа күрә дә Тәгъзимә әбиегез дә, безнең һәммәбез дә Сезгә — журнал редакциясендә эшләүчеләргә, авторларга иң изге теләкләребезне юллыйбыз. Һәр чыккан журнал битләрендә ничә хәреф булса, Сезгә шул хәрефләр санынча саваплы гамәлләр кылуыгызны, сау-сәламәт, иманлы — имин, бәхетле тормышта яшәвегезне телибез. "Казан утлары" һәрвакыт шулай балкып, күңелләрне үзенә тартып торсын. Амин!

Кайнар сәламнәр белән:

Хәят ХӘЛИУЛЛИНА,
*Свердловск өлкәсе.*

* * *

Хөрмәтле редакция!

Башкортстанның атаклы шагыйре Сәйфи Кудашның, хәтерем ялгышмаса, мондый шигъри юллары бар:

Тәнкыйтьчеләр безне Пушкин кебек
Яза алмау өчен тиргиләр...
Ләкин үзләренең Белинский
Булмауларын гына белмиләр.

Мин бу өзекне биредә тикмәгә генә китермәдем. "Казан утлары"ның даими укучысы буларак (инде 42 ел дәвамында!), журналда чыккан һәр язманы (роман-повестьларны, хикәяләрне, шигырь-поэмаларны һ. б.) җентекләп укып барам. Беренче карашка, бәлкем, сәер дә тоелыр: әдәби тәнкыйть мәкаләләре күңелемә аеруча хуш килә. Әле менә үткән елның 11 нче санында танылган шагыйрә Лена Шагыйрьҗанның "Шагыйрь буласың килсә — бул!" дигән күләмле язмасын укыгач, шактый уйланып утырдым. Әле моңа кадәр Шигърият турындагы уйлануларын шундый ачык-туры итеп, йөрәгендә кайнаганны һәркемнең күңел түренә җиткерерлек дәрәҗәдә әйтә алган хатын-кызны хәтерләмим мин. Рәхмәт Сезгә, Лена туганым! Язмагыздан бөек Тукай рухы бөркелеп тора. Ул да бит, чын шагыйрь булу өстенә, туры сүзле, үткен-зирәк фикерле әдәби тәнкыйтьче дә булган!

Бүгенге татар әдәбиятына туры Тукайлар Гаяз Исхакыйлар, Муса Җәлилләр, бунтарь Һади Такташлар, Хәсән Туфаннар җитми. Менә шул бушлыкка җан өрү өчен Лена Шагыйрьҗан кебек әдәбиятне тирәнтен аңлаучы шәхесләрнең калкып-кабынып чыгуы бик тә кирәк!

Әмир МӨЛЕКОВ,
*Башкортстан, Кырмыскалы районы,*
*Иске Шәрәй авылы.*

*Елмаеп-көлеп кенә*

# Маннур Саттаров

## Чыдам Вилдан

Шундый уен уйный идек малай чакта:
Калыр, дибез, дәшми түзеп кем азакка?
Төртәбез дә, чеметәбез дә, — дәшми Вилдан,
Ул ахырга кала иде барыбыздан.

Әллә инде шул сыйфаты ярдәм итте,
Дәрәҗәсе шактый гына үсеп китте.
Вилдан хәзер зур җитәкче — район башы,
Өстәлендә — дистәләрнең гаризасы.

Айлар үтә, көн артыннан көнне санап,
Хатыбызның берсенә дә бирми җавап.
Гозерлибез, ялынабыз , — дәшми Вилдан,
Дәшми Вилдан, ул бит чыдам барыбыздан.

## Агыйделгә йөзек салдым

Агыйделгә йөзек салдым,
Чумарсың — табалмассың.
Түләүсез дару язсалар,
Түләми алалмассың.

Семипалат каласы,
Малга яхшы даласы.
Бер сумлык посылка салу
Хәзер үгез бәһасы.

Кызарып чыккан кояшның
Белмим кайда байганын.
Балконым карый көньякка,
Шунда үтә елларым.

Ал булмый булмас инде,
Гөл булмый булмас инде.
Илсаварлар ныгып калса,
Безгә ит кунмас инде.

Тал егыла, тал егыла,
Әллә тамырсыз микән?
Депутат итеп сайласак,
Безне танырсыз микән?

Юлда тузан таралды,
Ак күлмәгем каралды.
"Яңа руслар" белән бергә
"Яңа татар" яралды.

Абау дия, башын ия,
Башы авыртмаса да.
"Халкым!" — дия, кәпәч кия,
Халкын кайгыртмаса да.

Коттеджының бакчасы,
Тимер икән капкасы.
Тимер булмый, нәрсә булсын,
Бар да бюджет акчасы!

Уйсу җиргә су җыела,
Шунда казлар коена.
Чубайска "лекциядән"
Миллиард сумнар җыела.

Җилбер-җилбер итәрме,
Җилләр алып китәрме?
Патша бурычын түләгәч,
Чират безгә җитәрме?

Ишек алдым ак балчык,
Ак балчыктан атлап чык.
Кыскартыласың килмәсә,
Башлыгыңны мактап чык.

Су буйларын тал алган,
Тамырлары таралган.
Ут-су хакын күтәрмәгез,
Без җитәрлек таланган!

## Ал да була, гөл дә була

Ал да була, гөл да була
Күгәрчен муеннары.
Үләт чагындагы туйдыр
"Телешоу" уеннары.

Сандугачым дип сөйсәм дә,
Талга кунмассың инде.
Бишенче җәй, акча бирми,
Ялга кумассың инде!

Сандугачлар ояда,
Оялары пыяла.
Йолдыз-актер — рекламада,
Күреп йөзем ояла.

Ал да була белмәдем,
Гөл дә була белмәдем.
Янды үлемтек сумнарым,
Алдан үлә белмәдем.

Ал итәем, гөл итәем,
Суларга агып китәем.
Мин агарлык ару су юк,
Инде ни хәл итәем?

Агыйделгә басма салдым,
Су кергән уртасына.
Калдырма берүк, Ходаем,
Хәйрия шулпасына!

Без машинада барабыз,
Төшеп сулар алабыз.
Очын-очка ялгый алсак,
Иркен сулап алабыз.

Өй түбәсе кыектан,
Йөгереп чыктым оектан.
Телевизор антеннасын
Урлаганнар кыектан!

Каракошлы паспортта
"Татар" да юк, "башкорт" та.
Маңгайга номер суксыннар,
Кирәк булмас паспорт та!

Ишек алдым йомычка,
Җыеп алдым бер учка.
Ил байлыгын түгеп-чәчеп,
Кереп баттык бурычка.

— Хөкүмәтне куарга! — дип,
Депутатлар чаң суга.
Кикрикләре шиңеп кала,
Тамак кырса Баш хуҗа.

Ак та кисә, күк тә кисә
Тегүче кайчылары.
Хуҗага каршы ни кылсын
Капитал пайчылары?

## Журналыбызның 7 санында дөнья күрәчәк кайбер әсәрләр:

**Тәлгат Галиуллин.** Гомер тәлгәшләре. Автобиографик эссе.
**Айдар Хәлим.** Мөртәт. Хикәя.
**Суфиян Поварисов.** Күкнең җиденче катында. Романның ахыры.
**Марс Шабаев, Зөлфәт, Рәшит Гатауллин, Нәҗибә Сафина** шигырьләре.
**Рафаэль Мостафин.** Фаҗигале язмыш. Язучы Мин Шабайның тормыш сәхифәләре.
**Барлас Камалов.** Аңлатмалы сүзлеккә кермәгән сүзләр.

# "КАЗАН УТЛАРЫ" — ИҢ ЯХШЫ БҮЛӘК.

Билгеле булганча, шушы елның 1 апреленнән 1998 елның икенче яртысы өчен газета-журналларга язылу башланды. Татарстанда чыга торган вакытлы матбугатка язылу Татарстанда 20 июньгәчә дәвам итәчәк.

Халкыбызның бай тарихлы төп журналы — "Казан утлары" — Сезне яңадан үз яктысына чакыра. Күпьеллык ихлас дуслыгыбыз элеккечә матур дәвам итсен — киләчәктә дә бергә булыйк, кадерле укучыларыбыз!

Журналыбызга язылу бәясе, башка кайбер басмалар белән чагыштырганда, шактый арзан — ярты елга нибарысы 18 сум. Элемтә бүлекләрендә әбүнә тартмалары булган укучыларыбыз өчен безнең басманы алдыру хакы тагын да арзанрак — 16 сум 20 тиен. Журналга шулай ук редакциягә килеп язылырга да мөмкин. Бу очракта аны үзең килеп аласы була һәм почта чыгымнары да тотылмый.

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

**АБОНЕМЕНТ** на газету / журнал | 73210 | (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания) | Количество комплектов: |

на 19 98 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

Куда | (почтовый индекс) | (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер | на газету / журнал | 73210 | (индекс издания)

„Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ___ руб ___ коп | Количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб ___ коп | |

на 19 98 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

Куда | (почтовый индекс) | (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

Алдагы елларның уңай тәҗрибәсен һәм күпсанлы укучыларыбызның теләкләрен искә алып, журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан, 1998 елның икенче яртысы өчен хәзерләнгән әбүнә кәгазен (абонемент үрнәген) тәкъдим итәбез. "Казан утлары"на алдырырга теләүче һәр кеше, шушы квитанцияне кисеп алып, аңа үзенең тулы адресын, исем-фамилиясен, язылырга теләгән айларын күрсәтеп, аны үзе яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга тиеш. ЖУРНАЛНЫҢ ИНДЕКСЫ — 73210.

Мөмкинлектән файдаланып, урыннардагы хакимият башлыкларының, предприятие-оешма җитәкчеләренең, авыл хуҗалыгы, урман хуҗалыгы, һәм мәдәният, мәгариф һ. б. өлкәләрдә эшләүчеләрнең исләренә төшерәбез: "Казан утлары" журналы — алдынгыларны хөрмәтләү өчен иң яхшы бүләк ул!

## ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!

На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.

При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).

---

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

*Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

## ТӨРКИЯ ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — ТАТАРСТАНДА

4 — 7 май көннәрендә Татарстан Республикасында рәсми визит белән Төркия Республикасының Дәүләт министры, профессор Әхәт Әндиҗан булды.

Олы кунакны ТР Президенты М. Шәймиев кабул итте. Дустанә-җылы әңгәмә барышында ике республика арасында үзара файдалы хезмәттәшлекне тагын да үстерү юллары тикшерелде.

Аннары Төркия Дәүләт министры Ә. Әндиҗан Татарстан Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшин белән очрашты.

Сөйләшүләр барышында яклар, Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм Төркия Республикасы хөкүмәте 1995 елның 22 маенда кул куйган Сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турындагы Шартнамәгә нигезләнеп, алга таба да бу юнәлештәге эшләрне тагын да яхшырту турында үзара килештеләр.

## БАШКАРМА КОМИТЕТ УТЫРЫШЫ

5 майда Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының чираттагы утырышы булды. Башкарма комитет рәисе, академик И. Таһиров алып барган әлеге утырышта латин графикасына күчү проблемалары, шулай ук татарлар тупланып яши торган төбәкләрдә радиотапшыруларны киңәйтә бару мәсьәләләре тикшерелде.

## "МӘГАРИФ" КОЛАЧЫН ҖӘЯ

Казанның нәкъ урта бер җирендә — Г. Тукай һәйкәленә каршы йортта "Мәгариф" милли нәшриятының махсус китап кибете ачылды. Биредә әлегәчә фәнни-техник әдәбият сатыла иде.

Яңа мәгърифәт һәм сәүдә үзәген тәгъдир итүдә ТР Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Харисов, Казан шәһәре мэры К. Исхаков, "Мәгариф" нәшрияты директоры М. Вәлиев, танылган әдәбият-сәнгать эшлеклеләре катнашты.

## ЛАТИНЧАГА ӨЙРӘНӘСЕҢ КИЛСӘ...

Мәркәзебездәге "Мәгариф" нәшрияты "Латин хәрефләре белән язу һәм уку" дигән китапчык бастырып чыгарды. Тиражы — 30 мең данә. Рәсемнәргә бай әлеге басма латинча укый-яза белергә өйрәтүче төүге әсбаплардан санала. Монда, шулай ук, Татарстан Фәннәр академиясе галимнәре тарафыннан эшләнгән латин алфавитының проекты да бирелгән.

## ЯКТАШЛЫК ҖӘМГЫЯТЬЛӘРЕНДӘ

Башкалабызның Зур концерт залында, зурлап, "Балык бистәсе районы көне" үткәрелде. Бирегә хакимият башлыгы, Татарстан халык депутаты Хатыйп Газизов җитәкчелегендә районның хезмәт алдынгылары күпләп килгән иде. Зур концерт залы сәхнәсендә, танылган артистлар белән бергә, районның үзешчән сәнгать көчләре дә чыгыш ясады.

Иң мөһиме — бу көнне Казанда "Балык Бистәсе" якташлык җәмгыяте оешты. Аның президенты итеп шагыйрь, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин сайланды.

## ТУКАЙ ТУГАН КӨННӘРДӘ

Халкыбызның бөек шагыйре Г. Тукайның тууына 112 ел тулу уңаеннан, Татарстанның төрле төбәкләрендә Шигърият бәйрәмнәре гөрләп узды. 26 апрельдә аның иң зурысы, мәртәбәлесе Казанда, Тукай һәйкәле янында үткәрелде.

Шигъри митингны Татарстан язучылары оешмасы җитәкчесе Р. Мөхәммәдиев ачып җибәрде. Җөмһүриятебез Илбашының "1998 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында"гы Указы игълан ителгәннән соң, быелгы лауреатлардан шагыйрь Р. Миңнуллин, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академиясе театры режиссер-куючысы Ф. Бикчәнтәев, артистлардан Н. Ихсанова, Н. Дунаев, Ә. Шакиров сүз алды.

Шигъри бәйгедә, Татарстанның халык шагыйрьләре Ш. Галиев, И. Юзеев белән бергә, Р. Гаташ, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Х. Әюпов, Л. Шагыйрҗан, Р. Вәлиев, И. Гыйләҗев, Р. Газизов, Р. Зәйдулла, Н. Акмал, Л. Лерон һ. б. чыгыш ясады. Соңгы елларда исемнәре матбугат битләрендә еш күренә башлаган Ф. Тарханова, Р. Җамал (Корбанов), Х. Бадыйков, Гөлнур, Л. Шарова (Янсуар) кебек яшьрәк буын иҗатчыларның, мәйдан түренә чыгып, шигырь укуларын да халык яратып кабул итте.

Әлеге тантанага Төркиянең күренекле шагыйре Диләвәр Җәбәҗи, Уфадан Башкортстанның халык шагыйре Равил Бикбаев, Мәскәүдән рус шагыйре Николай Корнилов та килгән иде — аларның чыгышлары да зур кызыксыну белән тыңланды.

Танылган җырчыларыбыздан Ф. Сәләхов, Г. Казанцева һәм Р. Гыйләҗев җитәкчелегендәге "Сорнай" ансамбле чыгышлары да тамашачыларның күңелләренә хуш килде. Бәйрәм Г. Тукайның "Туган тел" җырын күмәкләшеп башкару белән тәгәлләнде.

* * *

Шигырь бәйрәменең дәвамы шул ук көнне кичен башкалабызның элеккеге Г. Тукай исемендәге кинотеатры бинасында дәвам итте.

* * *

27 апрельдә бәйрәм Г. Тукайның туган төбәгендә — Арча һәм Әтнә районнарында, шагыйрь белән бәйләнешле урыннарда гөрләде. Әлеге тантаналарда башка төбәкләрдән килгән кунаклар да катнашты.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

3 апрельдә Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында күренекле әдип, редактор һәм тәрҗемәче Рәис Даутовның 70 еллык юбилеена башланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Юбилярны Татарстан язучылары оешмасы җитәкчесе Р. Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиев, Татарстан Фәннәр академиясе академиклары М. Госманов, Ә. Кәримуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Х. Әшрафҗанов, Татар энциклопедиясе институты директоры Г. Сабирҗанов, әдәбият галиме Н. Нәккаш, шагыйрә Ф. Тарханова һ. б. ихластан котладылар, аңа иҗади уңышлар, саулык-сәламәтлек теләделәр.

Кичәдә Татарстанның халык артисты М. Галиев һәм аның шәкертләре, атказанган артистка Р. Зиннәтуллина, композитор И. Дәүләтшин һ. б. да катнашып, юбилярга карата булган самими хисләрен илаһи моңнары аша җиткерделәр.

Р. Даутовны, якташлары исеменнән, Мамадыш районы хакимияте башлыгы урынбасары Ш. Хәсәнов котлады һәм истәлекле бүләк тапшырды.

* * *

22 апрель көнне шул ук клубта "Казан утлары" журналының бүлек мөхәррире — танылган шагыйрь һәм тәнкыйтьче Наис Гамбәрнең дә 50 яшьлек юбилеена багышланган иҗат кичәсе үткәрелде.

Юбилярны әдипләрдән Р. Мөхәммәдиев, Г. Ахунов, Р. Даутов, Р. Батулла, шагыйрьләрдән Р. Гаташ, Зөлфәт, Х. Әюпов, Р. Зәйдулла, Казандагы һәм Чаллыдагы "Мөслим" якташлык җәмгыяте вәкилләре — табиб А. Галләмов, инженер А. Минһаҗев, мөгаллимә Т. Гайфуллина, шагыйрә Ш. Җиһангирова, Чаллыда нәшер ителүче "Фән һәм мәктәп" журналының баш мөхәррире, язучы Ф. Сафин һ. б. чын күңелдән котладылар. Мөслимнең үзеннән исә бу тантанага район хакимияте башлыгы урынбасары Р. Габдрахманов, күренекле прозаик һәм драматург Ф. Садриев, район музее хезмәткәре, рәссам Р. Хантимеров юбилярга изге теләкләрен, котлауларын ирештерделәр.

Кичә барышында Н. Гамбәрнең лирик-фәлсәфи шигырьләре Татарстанның халык артистлары И. Баһманов, И. Әхмәтҗанов, Д. Нурлы башкаруында яңгырады.

Каләмдәшебезнең иҗат кичәсен "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин алып барды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә.** «Борынгыга мәдхия» — рәссам Зөфәр Низаметдин эше.

# ТАТАРСТАНДА ЯҢА "ТАТАРСТАН"




**Республикабыз зур үзгәрешләр кичерә, дөнья цивилизациясендә үзенең лаеклы урынын яулый. Сәяси, икътисади, мәдәни элементләребез дә көннән-көн киңәя, тирәнәя бара. Шул үзгәрешләр нисбәтендә бүгенге көндә җөмһүриятебезнең йөзен чагылдыручы затлы, зыялы, дөнья стандартларына тәңгәл килә торган басмалар күбрәк булырга тиеш. "Татарстан" исемен йөрткән журнал, әлбәттә, әле әйтелгән таләпләргә җавап бирүне күздә тота. Бу журналның быелгы 4 саны, безнеңчә, нәкъ менә шул югарылыкка ирешүне максат итеп чыгарылган. Кайчандыр "Татарстан коммунисты", соңрак "Татарстан" исеме белән чыккан бу журнал бүген бөтенләй бүтән сыйфатта, бүтән статуста. Ул — республикабызда барган үзгәрешләргә тирән, күпкырлы публицистик-аналитик бәя биреп, җәмгыятебездә хәл ителмәгән мәсьәләләрне калку чагылдырып баручы журналга әйләнәчәк.**

**"Татарстан" журналының максаты һәм эчтәлеге үзгәрү, табигый, редколлегия һәм редакция коллективы яңару белән дә бәйле. Журналның бүгенге баш мөхәррире яшь, әмма тәҗрибәле журналист (ул 1990 елдан 1998 елга кадәр "Мәгърифәт" газетасын җитәкләде) — Рифат Фәттахов. Кыскасы, Татарстанда яңа "Татарстан" туды. Президент М. Шәймиев әйткәнчә, ул республикабызның "визит карточкасы, кадерле символы булырга тиеш". Уңышлар сиңа, яңа "Татарстан"!**

Индекс 73210



Язучы Фәрит Яхин

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)